ISSN 0206—418



# КАЗАН УТЛАРЫ

4.1988



# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1988

4

(786)

## *Бу санда*

22 АПРЕЛЬ — В. И. ЛЕНИН ТУГАН КӨН

И. НИЗАМОВ. Ленин белән киңәшик! 3

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

ЗӨЛФӘТ. Шундый чагы әле җанымның. *Шигырьләр* 9

И. САЛАХОВ. Тайгак кичү. *Роман-хроника* 16

РОБ. ӘХМӘТҖАНОВ. Сибгат ага Хәкимгә элегия. *Шигырьләр* 75

БАТУЛЛА. Юл буенда зәңгәр чәчәк. *Повесть* 79

М. ХӨСӘЕН. Туган ягым — гомер таҗым. *Шигырьләр* 129

Н. МАДЬЯРОВ. Еллар уяткан уйлар. *Шигырьләр* 132

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ЛАТЫЙПОВ. Татарстан читекләре 135

Х. ВӘЛИӘХМӘТОВ. Алтын утрау бизгәге 147

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Г. ХАФИЗОВ. Яңарыш адымнары. *(Яңа Чишмә районы)* 153

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

Г. МОРАТОВ. Атомкала эскизлары 156

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Ачышлар һәм бурычлар 159

Р. НУРЕТДИНОВ. Буалар ерылган вакыт 166

СӘНГАТЬ

Тарих — изге. *И. Иляловаyның «Театр имени Г. Камала» дигән китабы турында фикер алышу.* (Р. Ишморат, А. Әхмәдуллин, Г. Арсланов, Х. Гобәйдуллин, Һ. Мәхмүтов) 169

К. МИҢЛЕБАЕВ. Сүз тылсымы *(А. Арслановка 60 яшь)* 186

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

РӘФЫЙК НӘФИКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-65,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

**Ш. САДРЕТДИНОВ. Сәгыйть Рәмиев Уфада** *(А. Тимергалина рәсеме)* 176

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

**С. ХӘКИМ. Редакциягә хатлардан** 178

БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

**Ф. ГАРИПОВА. Шәм Суар** 182

БИБЛИОГРАФИЯ

**Ә. ГАБИДИ. Мәхәббәт яктысы** 184

ҖЫР СӨЮЧЕЛӘРГӘ

**Ф. Әхмәтов музыкасы, Ф. Яруллин сүзләре. Кем елый соң?** 188

**Культура тормышы көндәлеге** 190

**Тышлыктагы сурәтләр** 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

22 апреля — день рождения В. И. Ленина: статья И. НИЗАМОВА «Учиться у Ленина».

Роман-хроника И. САЛАХОВА «Тернистый путь», повесть Р. БАТУЛЛИНА «Вдоль дороги синий цветок», стихи ЗУЛЬФАТА, РОБЕРТА АХМЕТЗЯНОВА, М. ХУСАИНА.

«Публицистика»: очерки Ф. ЛАТЫПОВА «Татарские ичиги», Х. ВАЛИАХМЕТОВА — «Лихорадка золотого острова».

В рубрике «Татарстан — родной мой край» выступление первого секретаря Ново-Шешминского райкома партии Г. ХАФИЗОВА.

«Литературный пост — АЭС»: Г. МУРАТОВ — «Эскизы атомграда».

Литературная критика. Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статьи Т. ГАЛИУЛЛИНА и Р. НУРЕТДИНОВА.

«Искусство»: Р. ИШМУРАТ, А. АХМАДУЛЛИН, Г. АРСЛАНОВ, Х. ГУБАЙДУЛЛИН и Х. МАХМУТОВ — о книге И. Иляловой «Театр имени Камала».

«Памятники татарской культуры в Уфе» — дом, в котором жил Сагит Рамиев.

«К истории литературы»: отрывки из писем С. ХАКИМА в редакцию журнала «Казан утлары».

«Города древней Булгарии»: Шам Суар — статья Ф. ГАРИПОВОЙ.

В рубрике «Библиография» рецензия А. ГАБИДИ на книгу стихов Ф. Зиятдиновой.

В журнале отмечается 60-летие А. Арсланова.

Любителям музыки предлагается новая песня Ф. АХМЕТОВА и Ф. ЯРУЛЛИНА «Кто же плачет».

Дневник культурной жизни.

На наших обложках — золотое шитье (обложка для книг); республиканская научная библиотека имени В. И. Ленина в г. Казани.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина*, *Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 27.01.1988 ел. Басарга кул куелды 16.03.1988 ел. ПФ 05108. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70\times108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 67049. Заказ А-40. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

**Илдар Низамов**

# ЛЕНИН БЕЛӘН КИҢӘШИК!..

Күптән түгел мин бер публицистик чыгышымда ачынып: «Без Ленинны укымыйбыз», дип язган идем. Кульязманың шул төшенә килеп җиткәч, редактор, тукталып: «Бу сүзне үзгәртергә кирәк булыр, без бит Ленинны бөтенләй укымыйбыз түгел»,— диде. Дәлилләр китерә башлады: «Ленин хезмәтләрен укып-өйрәнү, мәктәптән алып, политик мәгариф системасына кадәр барлык программаларда каралган. Ленин — дөньяда иң күп басыла торган автор. Аның хезмәтләреннән цитаталар китерелмәгән берәр карарны, җитәкчеләрнең чыгышларын, җитди теоретик китапларны күргәнең бармы?»

Сизәм: бу тәгъбирне ул туп-туры мәгънәсендә аңлаганга сабыша, хәлбуки, мәгънә без Ленинның хезмәтләреннән хәбәрдар түгел дигәнне аңлатмый, ә бәлки, безнең һәркайсыбыз да әле ихтыяҗ килеп чыккан саен, маякка, компаска инангап кебек, Ленин идея-карашларына таяныр өчен, иман, юнәлеш эзләп, аның китапларына мөрәҗәгать итәргә күнекмәгән дигәнне аңлата иде. Килешик: юлбашчыбыз идеяләрен күпчелегебез дәреслекләрдән, бүтән китаплардан, ягъни икенчел чыганаклардан укып белә. Рәссам ясаган сурәтнең үзен күрү белән аның китапта чыккан күчермәсен карау арасында, кояш җылысын турыдан-туры тою белән тәрәзә аша сиземләү арасындагы кебек, шәт, аерма бардыр?!

Ярар, редактор «тәзәтеп» әйткәнчә дә булсын ди: «җитәрлек укымыйбыз без Ленинны»! Мондый нәтиҗәне мин, төрледән-төрле кешеләр белән аралашып тупланган журналистлык тәҗрибәмә, шулай ук дәрәҗәле галимнәрнең, фәнни оешмаларның кайбер социологик тикшеренүләренә таянып әйтәм.

Тормышта ышанычлы таяныч-компастан башка яшәп булмый, маяксыз юлдан атлауның ахыры яхшыга барып чыкмый. Мондый таяныч, бүгенгедәй, бөтен ил кискен борылыш кичергән вакытта аеруча кирәк. Шушындый чакта үзгәреш һәркемгә кагыла, бүген кагылмаган икән, иртәгә барыбер кагылачак. Үзгәрешләре дә нинди бит: инде берничә буын аңында берегеп-күнегеп беткән фикер-төшенчәләрне тикшереп, аларга бөтенләй бүтәнчә карау, тарихи вакыйгаларны, шәхесләрне башкача бәяләү таләп ителә, моңарчы күнеккәннәрдән нык үзгә өр-яңа төшенчәләрне аңларга, үзләштерергә кирәк — нәрсә ул *революцион үзгәртеп кору, тизләнеш, демократия, хәбәрдарлык, кеше факторы, яңача хуҗалык итү, социаль гаделлек* һ. б.?

Замана бүген боларны тәмам ачыкларга, аларга үз мөнәсәбәтеңне белдерергә мәҗбүр итә, шунсыз син бүген җәмгыятьтә, коллективыңда үз урыныңны тәгаен билгели алмыйсың, бүтәннәр дә сиңа бәяне шул мөнәсәбәтеңә карап бирәләр. Мондый мәлдә нык нигезле таяну ноктаң булса, үзеңне икенчерәк хис итәсең, юнәлешеңне ышанычлырак билгелисең, карашың өметле, адымнарың нык була. Нигезебез — марксизм-ленинизм, кыйблабыз — Ленин төзегән партиябезнең Программасы. Бу фәнни теориягә шикләнеп, икеләнеп караучылар да булды, хәтта шушы тәгълимат тулысы белән кабул ителгән илдә дә аннан кайбер тайпылулар булгалады, әмма болар барысы да төп нигезебезнең чын-чыннан тормышчан, берниндн ике-

ләнүләр дә, хәтта какшатырга маташулар да аны чатната алмавын гына расладылар.

Тагын без шуңа да инандык: тәгълимат, аны һәркем җанына — байрак, кулына — корал, хәрәкәтенә, эшенә этәргечтәй кабул итмәсә, ягъни көндәлек тормышында таянычы итеп тоеп тормаса, ул эссе далада миңгерәүләнеп беткән юлчыга бик ерак-еракта дәрья кебек, ирешә алмаслык хыял булып кына калыр иде. Карл Маркс, массаларны үзенә йолып алса гына теория зур көчкә әверелә, дип бик дөрес әйткән.

Ә тәгълиматны үзләштерү, җаныңа үткәрү өчен аның асыл үзәген — төшен, ягъни Ленин хезмәтләрен, үз күзең белән укып төшенү — мәҗбүри шарт. Әмма эзләгән хакыйкатеңне ачыкларлык, кыйблаңны тәгаен күрсәтерлек асыл төшне табу бер дә җиңел түгел. Дөресен әйткәндә, мондый эзләнү газапларын без соңгы елларда онытa да башладык, кеше төртеп күрсәткән юлдан барырга, кеше җырын җырларга күнектек. Еллар буе, Ленинны укымыйча, зур сүз сөйләүче партком секретарьлары, пропагандистлар барлыгын белмибезмени?! Доклад, чыгышларында Лениннан берике цитата китерә алсалар, халыкны политик тәрбияләүдә зур эш эшләдек дип саныйлар.

Ленин хезмәтләрен — зачет, имтихан тапшырыр өчен язмаңа яки докладыңа ялтыравык-цитата табып кую өчен генә әштер-өштер актару — намуссызлык, бу — кыйммәтле хәзинәне кадерсезләү, Ленинны бәхәсле уйларыңа җавап эзләп, җаныңа азык табу өчен укырга кирәк. В. И. Ленин үзе, мәсәлән, Карл Марксны нәкъ шулай укыган да, шул җаваплы да, бәхетле дә минутларын ул, «Маркс белән киңәшләшеп алу», дип атаган. Ешмы без Ленин белән киңәшәбез, ешмы без аның киңәшеннән акыл, көч алабыз, шик-шөбһәләребезне бетерәбез?!

Күптән түгел архивта күренекле революционер, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының беренче хөкүмәтенең беренче председателе Сәхибгәрәй Сәетгалиевнең 1921 елның 20 январенда Казан елгачылары конференциясендә сөйләгән нотыгына юлыктым.

Үзем укыйм, үзем моңарчы тәгаен генә аңлашылмаган бер төшенчәне ачыклый баруымны сизеп сөенәм.

...Идел буендагы ачлык Владимир Ильичны ифрат борчый. Хәлне яхшырту өчен ул барлык чараларны күрә. Шул чараларның берсе — ул елгачыларга мөрәҗәгать итә: «Идел буена килгән ачлык, өстәвенә, илдә ягулык һәм материаллар да җитмәү, сездән, елгачылардан, Совет республикасы бу юлы да җиңеп чыксын өчен, ...азык-төлек, хәрби кирәк-ярак, ягулык һәм башка йөкләрне су юлы белән ташуны үтәүне катгый таләп итә».

Сәетгалиевнең дә йөрәге бу көннәрдә Ленинныкы белән бер ешлыкта тибә. Ул да елгачыларга өмет белән карый, аларга еш мөрәҗәгать итә. 20 январьда ул аларның конференциясенә килә. Нотыгының башында ул гади, үтемле сүзләр белән Совет властеның эшче һәм крестьянга ни өчен кадерле икәнен, ни өчен алар аны Гражданнар сугышында якларга тиеш икәнен төшендерә, хәзер менә Совет властена янә куркыныч янавын, ачлыкның бөтен илгә ябырылган һәлакәт икәнен яшерми. «Белегез, ди ул, әгәр дә быел җәй безнең баржалар хәрәкәткә килмәсә, азык-төлек фонды булдырыр өчен салган тырышлыкларыбыз юкка чыгачак... Бу яз һәм бу җәй Совет власте яши башлаганнан бирле иң-иң авыры булачак...»

Аның тавышы өметле, әйдәүчән яңгырый: «Су хуҗалыгын торгызу өчен алга бик конкрет план билгеләргә, мәгълүм бер бурыч куеп эш итәргә кирәк...

Безнең дошманнар һәр кимчелегебездән, һәр йомшак ягыбыздан файдаланырга тырыша... Әмма алар ялгыша. Эшче һәм крестьяннар, хәлне инде тәмам аңлап, болай диләр: «Совет власте — ул безнең власть». Алар инде Совет властеның идеяләрен үзләренеке дип кабул иттеләр... Әмма бөтен бәла шунда ки, Ленин сүзләре белән әйтсәк, барыбызның да күңелендә әле «Сухаревка» утыра. Теге базар-толкучка «Сухаревка» түгел, аны бернигә сәгатьтән таратып бетереп була, ә безгә йөз еллар буе сеңдерелгән, шуның көченә буйсынып, һәркем үзенә генә ташыган һәм үзенә генә яхшы булсын, башка берни кирәкми, дип уйларга күнеккән «Сухаревка» утыра. Без нәкъ менә шуны тамырдан йолкып атарга тиеш, без үзебезне үзгәртеп тәрбияләргә тиешбез...»

Игътибар итә алдыгызмы: Сәетгалиев Ленин фикерен ничек оста үтемле, табигый файдаланган! Ленинның уе — аның уе, Ленинның борчылуы —

аның да борчылуы булганга күрә, ул Ленин хезмәтләрен укыганда, аны тыңлаганда юлбашчының фикерләрен күңеленә сеңдереп калдырган да, хәзер менә шуларның көченә, тәэсиренә нык ышанып, аларны корал итеп эшкә куша.

В. И. Ленинның әлеге фикере аның 1920 елның 19 апрелендә тукыма промышленносте работникларының III Бөтенроссия съездында әйтелгән. Ул анда болай ди: «Капитал белән көрәш әле бетмәгән. Капитализм хәзергә кадәр Совет власте башлап җибәргән эшләрне капчыкчылык юлы белән, «Сухаревка» һәм башка шундыйлар белән тоткарлап килә. Бу көчкә үзләренең тар, производство мәнфәгатьләре белән түгел, бәлки бөтен дәүләт мәнфәгатьләрен истә тотып яңача корылган эшчеләр оешмаларының көче генә каршы тора ала».

Ленинның көрәштәшләре аның әше өчен җаны-тәне белән ихласи янганга күрә дә аның хезмәтләрен бирелеп укыганнар, чыгышларын йотылып тыңлаганнар һәм аның фикерләрен халыкка җиткерү, үткәзү өчен үзләре дә бөтен осталыкларын биргәннәр. Безгә менә кемнәрдән өйрәнергә кирәк иде!

Цитата белән мавыгу — начар чир. Кайчак хәтта Ленин язмаларыннан алынган өзекләрнең төп фикергә зыян китерү очрагына туры киләсең. Безнең җирлектән бер мисал китерим:

Шул егерме беренче елларга кайтыйк. В. И. Ленинның ачлыктан җәфаланган халыкларга ярдәм оештыру өчен зур көч куйганлыгы барыбызга да мәгълүм. Бу юлы да ул чын интернационалист, илебездә халыклар дуслыгына нигез салучы икәнен теоретик хезмәтләре белән генә түгел, ә практик эшчәнлеге белән дә күрсәтте. Шушы мәсьәләгә кагылышлы язма һәм чыгышлары пролетар интернационализмга нигез ташлары булыпятты. Менә шушы мәгълүм хакыйкатьне күренекле генә бер авторыбыз В. И. Ленинның Арал диңгезе балыкчыларына Идел буена ярдәм итүләрен үтенеп язган хаты мисалында да расларга омтылган иде. Ул — хаттагы: «Бөтен эшчеләр сыйныфы, бер кешедәй булып, Идел буеның тирән ярасын төзәтергә күтәрелсен...» дигән өзекне В. И. Ленинның чын интернационалист икәненә дәлил итеп китерә.

Ә күңел килешеп бетми — интернационализм шундый берьяклы була микәнни?! Ленин бабайның үзе белән киңәшеп алыйк әле. Бактың исә аның фикере бик урынсыз өзелгән икән, ул: «...ә уңдырышлы Идел буе, үз ягыннан, киләсе елларда икмәк белән безнең яхшылыгыбызны кире кайтарыр. Бары шундый юл белән генә без Совет властен һәм яулап алган азатлыкны бөтен дөнья капиталистларының явыз һөҗүменнән саклап калырбыз», дип дәвам иткән.

Моңа охшаш китеклек, буталчыкларга тарымас өчен, В. И. Ленин хезмәтләре безнең илдә генә дә СССР халыкларының 122 телендә 16 мең тапкыр 620 миллион тираж белән басылган.

Аларны татар теленә бастырып чыгаруның зур тарихы бар. Бу бик әһәмиятле изге эш Хөсәен Ямашев, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов кебек исемнәргә дә бәйле. В. И. Ленинның хезмәтләре беренче мәртәбә татарча 1905—1907 елларда ук «Урал» газетасы, прокламацияләр аша, аннары «Аваз», «Эшче» газеталары аша мәгълүм була. Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң инде аерым брошюра һәм җыентыклары басыла.

Мәскәүдә В. И. Ленинның Үзәк музеенда шул беренче китапларны күреп дулкынлануым, юлбашчыбызның хезмәтләрен дөнья халыклары арасында беренчеләрдән булып үз ана телендә укый алган халкым өчен сөенеп, горурланып торуым әле дә хәтердә. Алар гарәп, латин хәрефләре белән басылган. Һәм ул чакта ук инде юлбашчы әсәрләре татар телендә дә, илдә беренчеләрдән булып, җитди бер системага салынып, күпләп чыгарыла башлаган.

Менә алдымда 1925 елда Казанда чыккан китап. Титул битендә мондый сүзләр: «В. И. Ленин әсәрләре. Беренче серия — беренче китап. *Милләт мәсьәләләре.* РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты янындагы аерым комиссия карамагында чыга». Китап белгече Ә. Г. Кәримуллин бу серияне, илебездәге төрки халыклар арасында В. И. Ленинның иң беренче күптомлы сайланма әсәрләре сериясе булды, дип бәяләде.

Мәгълүм булганча, комиссиянең җитәкчесе Галимҗан Ибраһимов иде. Шушы китапка «В. И. Ленин әсәрләрен татарча чыгару турында» дигән

кереш сүзендә ул комиссиянең планнары белән уртаклаша, тәрҗемәчеләр алдында торган бурычларны ачыклый. Татарстан АССР Китап палатасы мәгълүматларына караганда, 1925—1929 елларда В. И. Ленинның Казанда һәм Мәскәүдә татарча 48 китабы дөнья күргән.

Һәм иң әһәмиятлесе — ул китаплар кулдан-кулга йөртелеп укылганнар! Аларның гомуми тиражы 240 меңнән артып китә. Халыкның ул чактагы аң-белем дәрәҗәсе югары булмаса да, Ленин идеяләренә омтылуы көчле булган, аны укып кына зиһен ачыласын, дөрес юл табыласын, хакыйкать ачыкланасын чамалаганнар. Капиталист, алпавытлар коллыгыннан котылып, Гражданнар сугышында җиңеп чыккач һәм инде хәзер нишләргә, социализм, коммунизмны ничек-ничек төзи башларга? дип, җитди уйга бирелгәндә халык Ленинга мөрәҗәгать итмичә кемгә мөрәҗәгать итсен инде?!. Гел шулай — ил язмышы, халык язмышы авыр хәлдә, уйланырлык хәлдә калса, хаталарны төзәтергә кирәк булса, Ленинга әйләнеп кайтканбыз, аның белән киңәшләшкәнбез.

1932 елда В. И. Ленин әсәрләренең алты томлыгын бастырып чыгарырга карар ителә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты карары белән төзелгән махсус редакция коллегиясе эшкә керешә. Беренче том басылып та чыга. Ләкин бу зур эш азагынача җиткерелмәгән.

Бөек Ватан сугышында фашист илбасарларын тар-мар иткәннән соң, экономика, политика, идеология өлкәсендә булсын, халыкара мәсьәләләрдә булсын, ил каршында мең дә бер сорау килеп тугач та киң халык массаларының янә Ленинга мөрәҗәгать итүләре табигый иде. КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм институты җитәкчелегендә В. И. Ленинның 45 томлык дүртенче басма әсәрләренең СССР халыклары теленә, шул җөмләдән татар теленә дә, тәрҗемәләнәчәге турында хәбәр хуплап кабул ителде.

Бу зур тарихи эш Татарстанда 1954—1972 елларда башкарылды. Хәзерге көндә без Ленинны ана телендә нигездә шушы басмадан укыйбыз. Әмма Ленин хезмәтләренә тартылу тагын да көчәйгән бу көннәрдә аның мирасын ана телендә бастыру дәрәҗәсе, тәрҗемәсенең сыйфаты турында бергәләп фикер йөртү урынлы һәм вакытлы булыр дип саныйм.

Бүген Ленинны өзек-өтек уку ярамый, бу тиңдәшсез хезмәтләрнең иң тулы җыелмасыннан файдаланырга кирәк. Шундый илле биш томлык русча җыелма инде күп кенә телләргә тәрҗемә ителде. Татарча да чыгарырга вакыт җитте. Бер әсәрне — русча, икенчесен татарча укып, иҗтимагый аңның бөтенлегенә, камиллегенә ирешү кыен.

Ләкин биредә сүз 45 томлыкка кермәгән әсәрләрне тәрҗемәләп, өстәп бастырып чыгару турында түгел, әсәрләрнең Тулы бишенче басмасын өр-яңадан тәрҗемә итеп бастырып чыгару турында бара. Бу — тормыш таләбе, өлгереп җиткән ихтыяҗ һәм, шул ук вакытта, үтә җаваплы, күп көч һәм чыгым сораучы авыр эш булса да, без башкарырлык реаль бурыч.

Элеккеге тәрҗемәләр, тулаем алганда, бүгенге укучыны, нигездә, канәгатьләндерсә дә, аларның сыйфаты, һичшиксез, яхшыртуны, камилләштерүне сорый. Публицист буларак, В. И. Ленин темасы белән еш кына эш иткәнгә, миңа үз әсәрләремдә дә, башка авторларныкын редакцияләгәндә дә Ленин әсәрләреннән алынган өзекләрне укучыларга шактый еш тәкъдим итәргә туры килгәләде. Мондый чакта өзекләрне (цитата) Әсәрләрнең 4 нче басмасының татарчасыннан китерергә дигән катгый кагыйдә бар. Дөресен әйтим, мин аны еш кына «бозып», кирәкле цитатаны үземчә редакцияләргә, яисә өр-яңадан тәрҗемә итәргә мәҗбүр булам. Кайбер башка журналистларның да шулай эшләгәнен очраткалыйм.

Бер генә мисал. В. И. Ленинның «Россиядә капитализмның үсеше» дигән хезмәтендәге бер искәрмәдә мондый юллар бар: «Об Уфимской губ. см. Ремезова: «Очерки из жизни дикой Башкирии» — живое описание того, как «колонизаторы» сводили корабельные леса и превращали «очищенные» от «диких» башкир поля в «пшеничные фабрики». Это — такой кусочек колониальной политики, который выдержит сравнение с каким угодно подвигами немцев в какой-нибудь Африке».

Әсәрләрнең 4 нче басмасыннан тәрҗемәне укыйк: «Уфа губернасы турында Ремезовның «Кыргый Башкирия тормышыннан очерклар» дигән китабын карагыз — анда «колонизаторланың» ничек итеп корабль агачлары җыйганнары һәм «кыргый» башкортлардан «арындырылган» кырларны

«бодай фабрикаларына» әйләндерүләре бик җанлы сурәтләнгән. Бу — колониаль политиканың шундый өлеше ки, ул нинди дә булса бер Африкада немецларның теләсә нинди егетлегенә тыңлашә ала».

Бу тәрҗемәне мин болайрак үзгәртергә мәҗбүр булдым: «Уфа губернасы турында Ремезовның «Кыргый Башкортстан тормышыннан очерклар» дигән китабын карагыз — анда «колонизаторларның» ничек итеп корабльлек урманнарны кырганнары һәм «кыргый» башкортлардан «арындырылган» басуларны «бодай кырларына» әйләндерүләре бик җанлы сурәтләнгән. Бу — колониаль сәясәтнең шундый бер кисәге ки, аны немецларның, әйтик, Африкадагы теләсә нинди ерткычлыгы белән чагыштырырга мөмкин».

Кызганычка каршы, дүртенче басма тәрҗемәсендә моңа охшаш, русчасы белән чагыштыргач кына аңларлык урыннар байтак, хата тәрҗемәләнгән җөмләләр дә очрый. Сүз уңаенда әйтик, русча дүртенче басмада киткән хаталар бишенче басмада төзәтелде, ә татарчасы һаман шул көе кала бирә. Аннары, моннан унбиш ел элек чыккан җыелма, тиражы чамалы булганга, күпчелек китапханәләргә, партия оешмаларына эләкмәгән дә иде.

В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итеп бастырып чыгаруның яңа баскычына атлау алдыннан бу өлкәдә тупланган бай тәҗрибәне бөртекләп күздән кичерергә кирәк булачак. Бездә В. И. Ленин хезмәтләрен тәрҗемә итеп чыгаруның бай тәҗрибәсе бар. Мәсәлән, 1925 елгы китаплар сериясен эшләгәндә осталык сабакларының янә бер буыны барлыкка килде. Ул Галимҗан Ибраһимов, Исхак Рәхмәтуллин, Шәриф Байчура, Латыйф Гомәров, Әмирхан Икенче һәм башка күренекле тәрҗемәче һәм мөхәррирләрнең эшчәнлеге белән бәйле. Алар югары сыйфатлы тәрҗемәләр, тәрҗемәгә, иҗат эше, дип, җаваплы караш үрнәкләре калдырганнар. Галимҗан Ибраһимов әлеге сериягә язган кереш сүзендә В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итүнең, иҗади һөнәр буларак методик һәм профессиональ үзенчәлекләрен билгеләгән, бу эштәге кыенлыкларның нидән гыйбарәт икәнен, алардан котылу юлларын ачып биргән. Бу киңәш-күрсәтмәләр берничә буын тәрҗемәчеләр өчен җитди сабак булды. Һәм бүген дә тәрҗемә эшенең фәнни нигезе саналырга хаклы.

Аяныч каршы, бездә тәрҗемә өлкәсендә дөреслектән тайпылган чаклар да булды. Утызынчы елларда — иҗадилык хупланмаган, инструкцияләргә, догмаларга ябышып яткан елларда — бу шаукым хәрефкә хәреф тәрҗемә итүгә, ягъни механик ысулга ябышып яту чиренә китерде. Бу чир 45 томлыкны тәрҗемә иткәндә дә үзен нык сиздерде.

Чагыштыру һәм уйлану өчен В. И. Ленинның «Безнең программада милли мәсьәлә» дигән мәкаләсен егерменче һәм кырыгынчы елларда тәрҗемә итүдән мисаллар китереп узыйк. Оригиналда: «В проекте партийной программы мы выставили требование республики с демократической конституцией, обеспечивающей, между прочим, «признание права на самоопределение за всеми нациями, входящими в состав государства». Такое программное требование многим казалось недостаточно ясным...» Бу өзек 1925 елгы китапта болай тәрҗемә ителгән: «Без партия программасы проектында демократия нигезендәге конституцияле җөмһүрият төзелүне алга сөрдек. Бу конституция «дәүләт эчендә булган милләтләрнең мохтариатькә хаклылыкларын тануны» тәэмин итәргә тиеш. Программага мондый бер сорауны кертү күп кешегә тиешле дәрәҗәдә ачык булып күренмәде»...

4 нче басма тәрҗемәсе: «Партия программасы проектында без, бер уңайдан, «дәүләт составына керә торган барлык милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын тануны» тәэмин итүче демократик конституцияле республика төзү таләбен куйдык. Программаның мондый таләбе күп кешегә бик үк ачык түгел булып күренде...»

Заманында ярарлык текстның да хәзер инде безне канәгатьләндермәве — табигый хәл. Ул заманнан бирле туган телебез рус теле һәм башка тугандаш телләр ярдәмендә нык үсте, баеды, камилләште.

Әсәрләрнең 45 томлыгы тәрҗемәләнеп чыкканнан соң да инде телебезгә күп кенә үзгәрешләр керде, ике телнең дә хәзинәләреннән файдалану активлашты, тәрҗемә осталыгыбыз артты. Аннары, В. И. Ленинның уй-фикерләрен аңлау, төшенү дәрәҗәбез дә елдан-ел үсә бара, автор буларак Ленинның рус теле мөмкинлекләреннән ничек файдалануын, стиль нечкәлекләрен тирәнрәк үзләштерәбез. В. И. Ленинның «Сүзлеген» әзерләү, аның фразеологизмын тәрҗемә итүне җитди өйрәнү кебек фәнни эшләр дә тәрҗемәчеләргә яңа, өстәмә ачкыч-ярдәмлекләр булып тора.

Бүген барыбыз да элекке елларда юл куелган сүзгә-сүз тәрҗемәдән арыну юлларын эзлибез. Соңгы елларда СССР, РСФСР, ТАССР Конституцияләрен, КПСС Программасының яңа редакциясен тәрҗемә итүдә күмәк иҗат алымнары активлашты, формаль тәрҗемәнең янә кайбер тамырлары чабылды.

Г. Ибраһимов: тәрҗемә эшендәге кыенлыкларның берсе — термин камил булмавында, дигән һәм татар теленә термин ясау принципларын билгеләгән, «...башка телләр хәзинәсеннән файдаланганда татарның эшче, крестьяннары аңларлык булсын, гарәпчәлеге белән бөтенләй ят күренмәсен; шуның белән бергә телнең, әдәбиятның элекке тарихи традициясеннән бөтенләй чыгып, яңа керәшен теленә дә әйләнмәсен, электән килгән урта кул киң укучылар массасыннан үзенең артык яңалыгы белән безне аерып җибәрмәсен», дигән. Бу принциплар соңыннан термин ясау кагыйдәләре булып рәсмиләште, шуларга тугры булып эшләү нәтиҗәсендә, бездә уңышлы терминнар ясалды, камилләште, читтән дә алынды.

Әлбәттә, В. И. Ленин әсәрләрен камил тәрҗемә итү бүген дә җиңел түгел. Владимир Ильич рус теле хәзинәсенең иң тирәндә яткан, иң үтемле, үзенчәлекле чараларын файдалана, сирәк очрый торган, тәэсирле афоризм, идиома, фразеологизмнарны оста файдалана. Нәкъ ул кулланган мәгънәдә, нәкъ ул кулланган урында тәңгәл килерлек итеп тәрҗемәләп кара! Моңа берничә буын осталар тәҗрибәсе кирәк. Ә без соңгы егерме-утыз елда ул тәҗрибәне өйрәнү, таратуга, гомумән, тәрҗемәчеләрне укыту, яшь алмаш әзерләүгә бөтенләй диярлек игътибар бирми башладык.

Шулай булгач, В. И. Ленинның 55 томлык Тулы җыелмасын тәрҗемә итеп бастырып чыгарырга көч җитәрме? Бүген нәкъ шундый ихтыяҗ бар — чөнки Ленин идеяләре безгә революцион үзгәрешләрдә көч, белем, илһам бирер өчен кирәк. 6 миллионнан күбрәк татарның 85,9 проценты үзенең ана теле дип татар телен белдерә икән, бу бит шул кадәр кешедә Ленин әсәрләрен туган телләрендә уку теләге һәм хокукы бар дигән сүз.

«Күңел торып-торып Ленинга тартыла»... дигән иде шагыйрь. Хак сүзләр. Ленинсыз яшәү мөмкин түгел. Иң катлаулы, четерекле сорауга дөрес җавап табу өчен без аңа мөрәҗәгать итәбез. Бүген исә сораулар күп, бик тә күп. Әйтик, каян җыйдык без шулкадәр җитешсезлекләрне? Җыела икән! Ике сүзнең берендә без үз кимчелекләребезгә, капитализм калдыгы, борынгы заман тагылдыгы, дип тукыдык, үзебезнеке түгел, янәсе, һич югы, дошманнар йогынтысы гына ул, дип юандык. Совет власте шартларында инде икенче буын кешеләребез яшәп ята — ә кимчелекләребез әле һаман каяндыр ияреп килгән яисә читтән тагылган... Ә Ленин бабай социализмның таңында ук — 1918 елның башында ук — кимчелекләребезнең ике сәбәбен ап-ачык әйткән: искелек калдыклары һәм үзебездә туып торучылар.

Тамырлары бик тирәнгә киткән кимчелекләр бар. Әйтик, сүз белән эш арасындагы аерма бетми дә бетми. Карарлар бар, йөкләмәләр бар, аларны ясауга, язуга көч шулкадәр күп сарыф ителә ки, үтәлешләрен тикшерергә җитми кала. Үтәлеше тикшерелми икән, димәк, сүз, карар, вәгъдә кәгазьдә генә кала. Бу шайтан тәгәрмәченнән котылып була микән соң!? Ленинның бер хезмәтендә, мәсәлән, җитәкченең урынбасары карарларның үтәлешен тикшерү белән шөгыльләнергә тиеш дигән күрсәтмәсе бар бит! Без нигә онытканбыз аны?..

Заман үзгәрешләре безне демократия, хәбәрдарлык, социаль гаделлек кебек күптән мәгълүм төшенчәләр турында кабат уйларга, аларның асылын аңларга мәҗбүр итә. Килешик: без әле еш кына алар белән эш итә дә белмибез икән бит! Үзебезгә турыдан-туры кагылса, бездә йөз сорау туа, югалып калабыз. Ә бюрократизм, волокита кебек социализмның иң явыз, кан дошманнары алдында без югалып калмыйбызмы? Алар бит көн саен өр-яңа битлек кияләр, иң үткен корал белән коралланалар, югалмассың, бар! Ленин ни дигән соң, аларның тамырларын кайсы яктан килеп йолкырга киңәш биргән?..

Укыйк Ленинны, күңегик аның белән киңәшләшергә!

# ПОЭЗИЯ

## Зөлфәт

## ШУНДЫЙ ЧАГЫ ӘЛЕ ҖАНЫМНЫҢ

Ниләр диеп мин аңлатыйм икән
Шушы сәер, иләс чагымны?—
Хәреф төртсәң, шигырь үсеп чыгар —
Шундый чагы әле җанымның...

Вето салдым барлык мескенлеккә!
Җитте! Оят ап-ак болыттан!
Яшәү дигән тантанага бит без
Вакытлыча гына юлыккан...

Без китәрбез һәм башкалар килер
Тантананы дәвам итәргә —
Бирсен шулчак көч һәм куәт, түзем:
«Без китәбез, сез каласыз!» сүзен
Мескен түгел, кискен әйтергә!

Язмасын ла тавыш беткән килеш
Яшәү дигән җырга кушылу
Һәм... теләнеп, артка карый-карый,
Елак эттәй китү шыңшынып.

Язсын безгә,
Соңгы көчне җыеп,
Ак болытка очып менәргә,
Кинәт, йомып горур канатларны,
Ташланырга ташка — түбәнгә!
Ярый әле Бөек Мәңгелектә
Җисем булып гомер сөргәндә
Насыйп булган
Җирдә кеше булып
Балкып алу гүзәл бер мәлдә!

Ярый әле насыйп булган безгә
Биштәр асып юллар үтәргә,
Җир сөрергә, тимер чүкергә

---

ЗӨЛФӘТ *(1947) — шагыйрь, «Язмышлар ярында», «Утлы боздар» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

һәм
Тугайлыкта көтү көтәргә.

Гади куаныч юк яшәештә,
Гади газаплар да юк монда —
Бердәй гүзәл болын түшәге дә,
Җан сораган төпсез упкын да.

Ярый әле насыйп булган безгә
Кош сайраган шомырт янында:
«Мин дә...» — дигән сүзне ишетүләр
«Сөям сине!» — дигән чагында...

Ярый әле насыйп булган безгә
Суга төшү,
Яну ялкында...
Биләүдәге үз парәңне назлап
Уйланулар бәхет хакында!

Ярый әле насыйп булган
Елау
Башны салып еллар иңенә;
Насыйп булган көлү — бәхет тоеп —
Йолдыз яралганда күңелдә...

Яшәү бәйрәменә, юл узышлый,
Язган икән безгә сугылу —
Калсын юллар туймас моңнар булып,
Калсын алсу таңнар сызылып...

Тели күңел:
Бездән башка гына
Гөлләр яфрак ярган заманда
Ерактагы моңлы бер көй булып
Ишетелсәк иде һаман да...

...Шулай диеп
Мин аңлата алам
Шушы сәер, иләс чагымны:
Шигырь чәчеп, давыл урырмын күк —
Шундый чагы әле җанымның!

## Ярый әле...

Ай болытка туңып ябышкан чак.
Аяусыз кыш безнең якларда.
Егылды кош канатлы боз булып,
Очып барган төштән —
Ак карга...

Зәмһәрирле кышта бичара кош
Ярый әле сиңа юлыкты —
Бияләең салып, бичараны
Учларыңа алып җылыттың.

Сулышларың белән терелттең син,
Уянды кош... какты канатын!
...һәм сискәнеп,
Тетрәп куйды йөрәк —
Нәкъ шул мәлдә сине яраттым.

Азмы кичтек гомер зәмһәририен! —
Без дә төштек туңып биектән —
Йөрәгемне учларыңа алып
Тик син булдың мине терелткән.

Авыр чакларымда
Юаттың син
Һәм кышларда туңган кош сыман
Сулышыңнан канат какты йөрәк
Синең нәни, җылы учында.

Һәм без ачтык табигатьнең серен —
Безнең җаннар җирдә бер икән!
Бу — ярату гына түгел бугай...
Сөям, димәк, мин кош терелтәм!

Сагынганда, шул кош белән бергә
Төшләремә килеп керәсең:
«Яшә!.. Яшә..» — диеп, үрсәләнеп,
Нәни кошка сулыш өрәсең.

Карашларың,
Сулышларың белән
Бар дөньямны минем җылыттың —
Бу ярсулы дөнья уртасында
Ярый әле сиңа юлыктым...

## Кайнар кәлтә эзе

Бөек итеп яратырга, ахры,
Соңардым мин, артык кичектем!..
...Кузы Көрпеш белән Баян Сылу
Каберенә бүген тез чүктем.

Эссе капкан мазар ташларына,
Кайнар дала чатнап җил йота.
Борынгы бер хикмәт язуы күк
Кәлтә эзе — утлы комлыкта.

Һәм Турсунтай әйтте:
«Дөньяда бу
Мәхәббәткә һәйкәл — бердәнбер!»
...Һәр таш монда миңа таныш сыман —
Төшләремә, бәлкем, кергәндер.

Ташны-ташка куеп өйгән мазар
Ике гашыйк җанны ышыклап,
Җирнең күккә омтылышы булып
Күтәрелгән чиксез бушлыкка.

«Мәхәббәткә урын — күктә бары!» —
Дигән сүзе мәллә ташларның? —
Яндың, йөрәк, гашыйк булдың дөрләп —
Тик нигәдер күккә ашмадың!..

Булды ла бит юкса тик бер генә
Тибрәп алган керфек хакына
Әзер чаклар — ике уйламастан
Ташланырга төпсез упкынга!

Булды ла бит:
«Юк, син түгел...» — дигән
Котылгысыз җавап соңында
Җан-атымны куып яндырганым
Һәлакәткә илткән юлымда...

Без кичергән сөю газапларын
Тәңре үзе генә күргәндер!
Бөек түгелмени һәрбер сөю? —
Һәркемдә бит йөрәк — бердәнбер!

Яратырга кирәктер шул җирдә
Җаның чүлдәй кибеп корганчы —
Һәлакәтсез булмыйдыр шул сөю,
Булмыйдыр шул Бөек Корбансыз...

...Кузы Көрпеш белән Баян Сылу
Бөек мәхәббәткә кичекмәс —
Ләкин алар
Беркайчан да килеп
Безнең мәхәббәткә тез чүкмәс.

— Сөеп була һәлакәтсез дә! — дип
Бәхәсләштем шушы минутта.
...Хәтерләтте дастан хәрефләрен
Дала кәлтәләре комлыкта.

Мин түзмәдем! — дала авылына
Мотоцикл безнең кузгалды —
Бу авылда гомер иткән диләр
Баян Сылуның кыз туганы.

Шәрә комлык. Кайнар кәлтә эзе.
Әйтерсең лә миңа ук тиде.
Яралылар
Су сораган сыман
Су сорадым — эчем ут иде...

## Тау яшене

(БАЛЛАДА)

Энем, энем...
Кәрҗин үрергә син
Өйрәнергә миннән телисең —
Беләсеңме үзең,
Аңлыйсыңмы,
Тоясыңмы таулар телен син?

...Яраланып әфган тауларында,
Адаштым мин дошман тылында.
Аткаема дәшәм:
— Коткара күр!
Калдырма тик алар кулында!

Җанын коткарырдай бер йолдызы
Бардыр ласа җирдә кешенең?
...Мең йолдызлы ярсу әфган күге
Чайкалды да... төште ишелеп.

...Нәни кулның назлы җылысыннан
Ачылдылар авыр керфекләр.
Кояшлы көн икән... Тере болыт
Йөзә икән биек киңлектә...

Тарлавыкта адашкан бер йортта
Буталдылар көннәр төн белән,
Аның пәрәнҗәсез карашлары
Юк, бирмәде мине үлемгә!

...Мин аякка баскач, алып барды
Ком сарыган үзән түренә
Һәм күрсәтте ике калкулыкка:
— Әткәм белән әнкәм...
Алардан да
Калды бары кайнар җир генә...

Икесен дә бергә, бер өрлеккә
Асып китте дошман... Мин күрдем.
«Бик тә килешә,— диеп көлде алар,—
Икесенә шушы бер өрлек...»

Хәтта ясин чыктылар бит алар!
Япа-ялгыз калдым... Мин куркам —
И шурави[1] егет! Үзең белән
Алып кит син мине бу йорттан!..

Жаның чиста синең, мин ышанам,
Мин ышанам сиңа нигәдер...
Керфекләрең ачылгач ук күрдем:
Күзләреңдә синең — йөрәгең.

Син — үлемнең үзен җиңгән кеше,
Ә үлемне таныйм мин, беләм! —
Ничә убылыплар, ничә тапкыр
Миндән төпсез упкын төбеннән...

Бертуктамый дога кылдым:
«Берүк
Кагылма,— дип,— үлем, син аңа —
Мин сөюдән яралганмын икән,
Димәк,
Бәхет тиеш җирдә
Миңа да!»

Менә шулай таптым җаныңны мин.
Югалтырмын сыман... Мин куркам!
И шурави егет, үзең белән
Алып кит син мине бу йорттан!..

...Кич утырып кәрҗин үрде сылу —
Талчыбыклар алды кулына.
Талчыбыклар сайлый берәм-берәм
Һәм ырымлый үзе тын гына:

— Бусын үрсәм — сагынуга булыр,
Бусын үрсәм — ярың табылыр,
Бусын үрсәм — сүнә белми торган
Ике йолдыз күктә кабыныр.

Бусын үрсәм — гел бәхеткә булыр,
Куеныңда ярың куначак,
Ә аннары алма кебек улың,
Чәчәк кебек кызың туачак.

Бусын үрсәм әгәр — елларыңны,
Юлларыңны имин кичәрсең,
Бусын үрсәм — гомер буйларыңа
Мине сагынып син яшәрсең!..

...Бәхет ырымы бул, әфган талы!
Сакла, язмыш, мине, ярымны! —
Әфган күге шыгрым йолдыз чакта
Кулларыбыз-кулга сарылды.

Фатихаң бир безгә, и пар йолдыз!
Төшә күрмә күктән атылып!
Фатихаң бир, шомлы тарлавыкта
Ком сарыган моңлы калкулык!

Мин югалтмам аны! Мин ант итәм
Гарасатлы еллар алдында!

Инде без дә югалтышсак әгәр —
Дөрес түгел, димәк, бу дөнья!

...Мәхәббәткә чыгар юл эзләп, мин,
Ат иярләп, ялга иелдем:
Бәхетлене үлем алмый җирдә!
Ояты ла бардыр үлемнең!

Чыгар юлны таптым...
Кайтыр юлда
Атым никтер авыр атлады —
Күпме карасам да, аяз күктән
Пар йолдызны безнең тапмадым.

Авызлыктан — ат ирене ертык!
Атым — үрә! — тарттым тезгенне! —
Әйтерсең лә җирне җылы иткән
Бердәнбер кыл зыңлап өзелде.

...Ишек ачык. Әйе, алар эзе.
Тирән иде эзләр, күп иде —
Ак бәхетне кара күмер итеп
Тау яшене суккан күк иде.

Исән иде әле. Сыкранды ул:
— Нишләп болай булдык без генә?
Син онытма мине. Хуш бул.
Ник елыйсың?
Ашыга күр. Сине эзлиләр...

Нишләп язмыш безнең бәхетләрне
Артык санап, артык күпсенде?
Таллар үрәм таңнар кабынганда
Сулышларым барып җитсен дип...

Бусын үрсәм — төпсез кара сагыш.
Бусын үрсәм — чиксез кара сагыш,
Бусын үрсәм — сагыш тагын да...
Бәхетемә шаһит малкаем да —
Аткаем да юк бит янымда...

Әфган кәрҗиннәрен үрергә син
Өйрәт, дисең миңа,
И энем —
Иксез-чиксез сагыш давылына
Сусадыммы әллә күңелең?

Язмышыңны үр син гүзәл итеп,
Тик бер мәлгә дә син онытма —
Күшегүдән тетрәп, ике йолдыз
Җылы көтә ерак суыкта...

[1] Шурави — совет кешесе.

## Әфшан кышлагында бер төн

Монда узды мең төннәрдән бер төн...
Нинди зур бу дөнья! Күк гөмбәзе иркен...

Иксез-чиксез, серле космик чоңгылларда
Әбүгалисина йолдызлары яна!

Күз карашы монда чиксезлеккә китә...
Адәм балаларын Бөек Ачыш көтә!

Аһ син, Акыл, кая ашкынасың шулай? —
Ачышларны ябар көннәр килә бугай.

Һаман уйда кеше... Төн карасы куе...
Курка Бөек Җиһан: ни хакында уе?

Сакламакчы Җиһан җирне, суны, күкне —
Тыелгысыз Акыл аны эзәрлекли.

Шомлы сунар бара... Кача Җиһан Сере —
Ләкин акыл үткен, чая Акыл — тере! —

Якыная, килә... Сер — мушкада һаман,
Кагылмыйча тагын нинди серләр калган?

...Нишлисең син, Кеше, и бер көнлек
миһман? —
Хәрабәләр генә торып кала мифтан!

Серен саклар өчен Җиһан эзли ярдәм —
Тик сунарчы Акыл — шәфкать белмәс
мәргән! —

Артык тирән төшкән, артык ерак үткән —
Каһкаһәләп көлә Акыл чиксезлектән.

Көрсенәчәк Бушлык: «Акыл барып
җитте —
Серне һәлак итте — шуңа дөнья бетте!»

Аһ син, Акыл, кая ашкынасың шулай? —
Ачышларны ябар көннәр килә бугай...

Бөек улың бүген әйтер иде, Әфшан:
«Кеше акылы,— дип,— акылыннан
шашкан!..»

...Борчу белән узды кышлактагы бу төн...
Күк гөмбәзе, юкса, нинди биек, иркен! —

Чиксез-төпсез, серле космик чоңгылларда
Әбүгалисина йолдызлары яна!..

## Йөрсен җылың

*«...Көнбатыш Себер урманнарында эшләдем...»*

Фаил Шәфигуллин

Син сөйлисе сүзләр йөри, туган,
Син көйлисе көйләр бүген дә
Адашкан җил, кырыс хыял булып,
Кары зәңгәр тайга төбендә.

Тапшырасы идем сәламеңне
Синең барлык таныш-белешкә:
Ешлыктагы тырыш тукраннарга,
Калын көрткә чумган инешкә,

Кадерлеңә — каен яктысына,
Киек сукмагына — барсына...
Ләкин — бик тә сак күңелле алар,
Алдавымны аңларлар сыман.

Әйтерләр күк:
— Юк, сәламен түгел,
Бәхиллеген алып килгәнсең...
...Булмый, дускай, җанлы табигатьне
Алдап булмый инде, күрәсең.

Тоям — яннарыннан сүзсез генә
Үтмәгәнсеңдер син һичкайчан —
Һич югында
Моңнарыңны синең
Тапшырыйммы әллә ичмасам?

Йөри бирсен синең күңел җылың
Өстен калып җансыз бушлыктан,
Ирекле җил, азат хыял булып
Актарылып ерак офыкта...

## Тамыр көлләре

Бу төбәктә тайга шаулаганын
Кемнәр, ничек искә алырлар? —
Ул шаулардан инде җилләр искән —
Тау-тау булып яна тамырлар.

Яна тамырларда алтын дастан,
Дастаннарда — кавем тарихы,
Тарихларда яна Җир өмете,
Өметләрдә нәрсә? —
Барысы!

Тамырларда яна батырлыклар,
Батырлыкта — синең намусың,
Намусыңда яна горурлыгың,
Горурлыкта — олы язмышың.

Тамырларда мәхәббәтләр яна,
Мәхәббәттә яна җыр моңы,
Җыр моңында яна кеше дигән
Гали затның бөтен зурлыгы.

Яна тамыр! Тамыркайлар яна! —
Күккә карап нәгърә орырлык —
Көлләр булып кала тамырлардан
Мең буынга җитәр
Бер хурлык.

Үзәк өзгеч бер хатирә булыр
Тайгаларның тере янгыры...
...Язмышларга ургый-ургый дулый
Вәхшәт туе — Тамыр Яндыру.

Тарихларны Вакыт җилләрендә
Карарлар да беркөн җилгәреп —
Офыкларны каплар кара көлләр —
Хурлык көле — Тамыр көлләре...

# ПРОЗА

## Ибраһим Салахов

# ТАЙГАК КИЧҮ

РОМАН-ХРОНИКА

### Юл башы

1

Институтның тулай торагыннан чыкканда, таң атып, кояш инде күтәрелә дә башлаган иде. Гадәттә мондый көзге иртәләрдә Казан өстенә Иделне каплаган куе томан сарыла, көн җылынып беткәнче шәһәр шуннан арына алмый — ак чыбылдык астында кала иде.

Бүген ул томан да юк — күк йөзе күм-күк. Көнчыгыштан көлтә-көлтә алтын нурлар сибелә. Көн җылы, матур булыр, ахрысы. Иртәнге салкын һәм дымсулык, мөгаен, кичәге яңгырның сулышы гынадыр. Гаҗәп! Югыйсә инде «әбиләр чуагы» узганга да айдан артык. Бүген октябрьнең егерме бише бит инде. Бәйрәмгә дә ерак калмады — ике атнадан да ким. Быелгы бәйрәм аеруча тантаналы, күңелле булыр — Бөек Октябрьгә егерме яшь тулачак.

Безнең институт колоннасын бәйрәм демонстрациясенә алып чыгуны ректор быел да миңа тапшырды. Ни генә әйтмә — командир кисәге бит мин. Институтка килеп кергәндә шинель петлицаларымда чия кызыл өчпочмаклар яна иде... Әле дә өстән хәрби мундир төшми. Ләкин студентларның әзерлеге ташкүлчим, нибары ике тапкыр җыелдык — саф дигәннең исе дә юк, сыер көтүе кебек, беребез алда, икенчебез артта. Бигрәк тә кызлар шырык-шырык көлеп теңкәгә тия. Кычкыра-кычкыра тамагым карлыгып бетте. Ай-һай, бу хәтле дә йөгәнсез булыр икән хатын-кыз дигән халык!

Дөресен әйткәндә, әле кайсы факультет артыннан кайсы барасы да ачыкланмаган. Беренче җыелуда тарих факультеты алда иде. Икенчесендә, маршировка вакытында, ректор минем планны бозды да ташлады. «Алдан биофак барсын. Анда кызлар күп, чәчәкләр белән чыгарлар»,— дип, бер көтү йөгәнсез кызны колоннаның алдына бастырды. Ачуымнан шартларга җитештем, чак-чак кына ректорны сүгеп ташламадым — тешләремне кысып калдым.

---

ИБРАҺИМ САЛАХОВ *(1911) — прозаик, шагыйрь, «Күкчәтау далаларында», «Иманнар тамыр җәйгәндә» романнары, «Мәхәббәт картаямы» повесте, байтак хикәя, шигырь, пьеса җыентыклары авторы. Әсәрләре илебез халыклары телләренә дә тәрҗемә ителгән. Күкчәтау өлкәсенең Кызыл Яр авылында яши.*

Ә менә кичә төнлә үзен, ректорны әйтәм, кулга алганнар, халык дошманы булган, ди. Кем белә, булса булгандыр, революциягә хәтле чит илдә укып кайткан зыялы бит. Болай үзе бик Совет яклы булып сөйли иде. Кем әйтмешли, кеше карбыз түгел, эчен ярып карап булмый. Безнекеләр юкка, бер дә тикмәгә кулга алмаслар...

— Борыл, уңга!

Кырыс әмер уйларымны бүлдерде. Мин ялгыз гына түгел, өчәү барабыз икән лабаса.

Толстой тыкрыгыннан борылып — безнең тулай торак шушында — Карл Маркс урамына чыктык. Монда буп-буш, машиналар да күренми. Әле трамвайлар да шолдыр-гөлдер йөри башламаган. Кала өчен сәер бер тынлык. Асфальт түшәлгән киң урамның ике ягы буйлап тезелгән өчәр, дүртәр катлы ташпулатларның тәрәзәләрендә — пәрдәләр. Йоклыйлар. Иртәнге тәмле төшләрен күрә-күрә йоклыйлар булыр бу йортлардагы казанлылар.

— Шарт-шорт!

— Шарт-шорт!

Әңгер-меңгердә йокымсырап торган урам сискәнеп-сискәнеп безнең өч пар дагалы итекләрнең шакылдавын кабатлый.

— Шарт-шорт!

— Шарт-шорт!

Уң ягымдагы оперуәкил (ул үзен шулай таныштырды) буйга миннән аз гына калку, гәүдәгә дә тулырак. Күкрәге киерелеп алга чыккан. Башы югары күтәрелгән — парадта Мавзолей яныннан узамыни. Тырышып кына кырынган булуына да карамастан, сакал-мыеклары күгәреп тора. Борыны — бөкре. Кашлары кап-кара — бергә кушылып, эчкә баткан ачулы күзләрен каплап торалар. Зәһәр, усал күренә, сөйләшми. Янындагы яшьрәк егеткә боерыкны кашлары белән генә бирә; аларны бер төшерә, бер күтәрә — янәсе, алып кал, алып кит, минем кәгазьләрне (хәзер ул яшүсмер-солдат сул ягымнан атлый). Тегесе шуны төшенеп, боерыкны үтәп кенә тора — ишарәләр белән фәрман бирүгә өйрәнеп беткән күрәсең. Бәлки, мондый җаваплы хезмәткәрләр шулай ым белән генә сөйләшергә тиешләрдер. Минем кызым кияү күргәнмени, кодагый, дигәндәй, алар белән кем аралашкан. Тәбәнәк яшүсмер солдат безнең озын-озын итеп атлауга иярә алмый аптырап бетте, гел ялгыша, җәһәт кенә ике-өч адым алга чыгып та карый, тик теге усал кашлар бөгелеп күзгә төшкәч, тагын янәшәбезгә баса. Житмәсә, шинеле дә озын, атлаган саен, ашыккан саен чабуларына урала...

—Тукта!

Атылып килгән автомашина астына чак кына барып кермәде яшь күршем. Машина безне, җиле белән кагып, шофер тормозга баскан күрәсең, чинап сискәндерде.

— Киттек!

Тагын асфальт дөпелди башлады:

— Шарт-шорт.

— Шарт-шорт.

Әй, әйтергә онытканмын бит әле, сул яктагы солдат минем бер кочак китапларны, кульязмаларны күтәреп бара. Җәймәгә төреп бәйләнгән хәзинәдә Күкчәтауда вакытта ук язылып, калын-калын дәфтәрләргә күчерелгән шигырьләр, поэмалар, хикәяләр дә бар. «Тау гыйшкы» дигән хикәянең тышлыгына Нури Арсланов кыя-ташлар ясаган иде. Алар арасыннан ике ачулы күз карый. Күзләр арасында хәнҗәр. Хәнҗәрдән кан тамчылый... Менә хәзер шул «контр кәгазьләрне» солдат күтәреп бара. Әле бер, әле икенче кулына күчерә — кәгазь авыр була бит ул. Үзем булышыйм, дигән идем, опер кашларын җыерды:

— Яр-рамый!

Бигрәк әйбәт, югыйсә, мин дә бу солдат сыман, ул «контр» төенне күтәреп кила-кила шабыр тиргә төшәр идем бит.

Әй әкәмәт тә булды инде тентүләре! Нәкъ бер яшерен-хәтәр әйбер эзләгән сыман кыландылар. Юкса, аркылыга-буйга өчәр метрдан артмаган студент бүлмәсендә ни табасың — карават, өстәл, тумбочка, китаплар да кулъязмалар гына инде. Соңгылары тумбочкада, карават астында, тәрәзә төбендә. Күбесе инде кояшта ята-ята саргаеп беткән. Монда Ленинның утыз томлыгы, Маркс, Энгельс әсәрләре, дәреслекләр һәм кулланмалар — Горацийдан башлап М. Горькийга хәтле. «Тиле таш җыяр, син китап җыясың», ди торган иде өйдә вакытта әни мәрхүмә. Монда, Казанда, чыннан да, гонорар алган саен бер кочак китап күтәреп кайта торган булдым. Хәзер инде менә шуларның астын өскә китерәләр. Опер дигәне һәр китапның бит араларын тикшереп-карап утыра. Көләсем килә: ни эзли? Әллә инде, патша төрмәсендә утырган революционерларныкы төсле, китап юллары арасына сөт белән язылган «контр» сүзләр-өндәмәләр бар дип уйлыймы? Кыяфәте! Шундый житди, бөтен игътибары әлеге саргаеп беткән китап битләрендә — кашлар җыерылып, асылынып төшкән. Актара да актара. Әйдә, бер рәхәтләнсен, ни табар икән!..

Бер вакыт чират гарәп хәрефләре белән язылган караламаларыма килеп җитте.

— Бу ни бу? — Ачуыннанмы, әллә бик җитди бер гаеп таптым дип куануыннанмы, опер сикереп торды: — Бу нинди кыргаяк эзләре?

— Бу бит безнең элекке алфавит.

— Конспирация! — Опер солдатка текәлде: — Кара, бу конспиратив кәгазьләрнең барысын да, бер битен дә калдырмыйча, җыеп бәйлә!

Солдат, чын-чынлап каушап, ашыгып, кулъязмаларымны җыярга тотынды. Шигырьләр, хикәяләр, әле язылып яткан «Мәхәббәт һәм өмет» [1] романымның караламаларын.

— Ә менә монда... Нинди хәнҗәр? Нигә кан? Ә?

Мин чыдый алмадым, көлеп җибәрдем.

— Бу бит «Тау гыйшкы» дигән хикәямнең тышлыгы.

— Ыржайма! — Опер калын дәфтәргә язылган хикәяне кулымнан тартып алды. — Димәк, террорга өндисез! Яле.

Моннан соң опер үзе дә карават астына кереп китте. Бөтен чүпчарны тартып чыгарып актарырга кереште. Мин тәрәзә төбенә менеп утырдым — әйдә, рәхәтләнеп бер тузанга буялыгыз.

Институтның тулай торагында нигездә биш-алты кешегә исәпләнгән бүлмәләр. Ә менә ике кешелеге берничә генә иде.

Деканат, яхшы укыйлар, иҗат эше белән шөгыльләнәләр дип, аларның берсен, түбән каттагысын, Хатип Госманов [2] белән миңа биргән иде. Хатип белән бик тиз дуслаштык: сер уртак, бер сынык икмәкне бүлеп ашыйбыз. Үткән көнне ул бер атнага Васильевога киткәч, бүлмәдә ялгызым гына калган идем.

Әүвәле иртәгәге лекцияләргә әзерләндем — укыдым, конспектлар яздым. Аннан «Мәхәббәт һәм өмет»кә тотындым.

Язучы иҗатында гаҗәп кызык хәлләр була икән. Менә романның кереш өлеше һәм ахыры язылып беткән. Ә уртасы — юк, тотынылмаган да.

Сәбәп? Сәбәп менә нәрсәдә: романның баш герое политрук Гыйльфанов, чик буе бәрелешләренең берсендә яраланып, японнар кулына әсирлеккә төшә. Билгеле инде, аны төрмәгә ябалар, сорау алулар башлана. Чик буе корылмаларының планын, Кызыл Армиянең техник көчләре турында сөйләүне таләп итәләр. Бу сорауларга җавап бирмәгәч, аны газапларга тотыналар.

Менә шушы бүлекләрдә вакыйганы нәкъ япон төрмәләрендәге кебек итеп, бар вәхшәтлеге белән тасвирларга кирәк бит. Ә ничек?

[1] Аның беренче бүлекләре «Кызылармеец» газетасында басылган да иде инде.
[2] Соңрак филология фәннәре докторы, профессор булды.

Мин бит үз гомеремдә төрмә, камера, карцер, сорау алу, надзиратель, тикшерүче дигәннәрне күргән кеше түгел. Язучы бары үзе күргәнне-белгәнне генә язарга тиеш. Укучыларның күңелен җәлеп итәргә тели икән, һичбер уйдырмага урын бирмәскә тиеш. Дөресен генә әйткәндә, мин инде әчемнән, Печән базарына барып, берәр вак-төяк әйбер урлап тотылырга да төрмәгә эләгергә дип, план корып йөри идем.

Ә монда, көтмәгәндә, ходай үзе төрмә капкаларын ачты.

Күзләрем чепелди башлады — арыдым. Сәгатькә карасам, төнге ике икән инде. Чишенә башладым. Ишекне чиртәләр. Мөгаен, Хатип кайткан — ял йорты ошамагандыр, әллә авырып киттеме? Ашыгып ишекне ачсам, менә бу чакырылмаган кунаклар. Башта аптырап киттем.

— Менә ордер,— дип, бер кәгазь суздылар, төшенмәдем, шулай да алдым.

Менә хәзер минем барлык кулъязмаларны, гарәп хәрефе белән басылган китапларымны зур ике төргәк итеп төреп, үзем белән бергә алып киләләр. Кая алып баруларын әйтмиләр — барыбер беләм. Тик менә төрмәгә кертмичә кайтарып җибәрмәсәләр генә ярар иде (бар план җимерелә бит), роман бетмичә ярты юлда калачак.

Әй, мәзәк тә булды бит әле чыкканда. Бүлмәне астын өстенә китереп, туздырып бетергәч, опер үзе дә арыды, ахрысы:

— Җитәр. Киттек,— диде һәм солдатка төргәкләрне күрсәтеп ымлады: — Ал боларны.

Мин шинелемне киеп, тумбочкадан бер пачка папирос эләктердем дә ишеккә атладым. Ул ачылгач, ни күзем белән күрим — Зәйтүнә. Чәчләре тузгыган, үзе эчке күлмәктән генә.

— Ибраһим!

Ул, акырып елап, муенныма сарылмакчы иде, опер арабызга кереп басты:

— Яр-рамый!

Башта үзен сугып егасым килеп, ачуым ташыган иде, аннан суындым. Чын-чынлап кулга алынгандай булсын инде дип, башымны иеп чыгып киттем. Зәйтүнә бер адым артка чигенде дә караватыма тәрәлеп егылды. Үзе һаман үксеп-үксеп елый.

— Тукта!

Баскычка абынып егыла яздым. Алдыбызда бихисап зур ишек. Аның ике ягында мылтыклы ике сакчы, сын төсле катып торалар.

— Уз!

Мин бусаганы атлап эчкә үттем.

Ишекләр шыгырдап ябылдылар.

## II

Бер йомшак кына пышылдап, яшерен сер сөйләп, бер ярсып ярларга сугылып чәчри бу дулкыннар, сихри, илаһи дулкыннар... Менә алар тагын якынлашалар һәм, назлы кочаклап, рәхәтлек диңгезендә тирбәтәләр. Нинди гаҗәп могҗиза бу «Амур дулкыннары».

Гадәттә тикшерүче Бикчәнтәев, өенә җыенганда, тимер рәшәткәләр белән ныгытылган тәрәзәдәге форточканы шап итеп ябып бикләп куя иде, бу юлы ашыгудан ачык калдырган. Менә шушы кечкенә форточкадан аның кабинетына кечке салкын һава белән бергә илаһи бер моң агыла. Черек күл бакчасында тынлы оркестр «Амур дулкыннары»н уйный. Танца мәйданчыгы хәзер яшьләр белән шыгрым тулыдыр. Ярatam шул ерак Амур буйларын җанландыручы, хыял дулкыннарында тирбәтүче вальсны. Зәйтүнә бүген килде микән? Юктыр ла, кем белән килсен, мин киткәндә ничек үксеп елап калды ич ул.

Ә өченче көн... Чыннан да, аны без гаҗәп күңелле уздырдык. Гомергә истә калыр ул көн.

Институт комсомол комитеты мине Казанка елгасы буендагы урамнарның берсенә яңа Сталин конституциясен, аның совет халкына биргән хокукларын танытырга, әңгәмәләр оештырырга билгеләгән. Башта факультет секретаре бу хәбәрне әйтүгә, пыр тузып ачуландым. Стена газетасын мин чыгар. Демонстрациягә колоннаны мин алып бар. Инде йорттан-йортка йөрергә! Юк, булмый! Мин институтның кендеге түгел. Миннән башкалар да бар. Аларны да җигәргә вакыт.

— Җүләр, син анда ялгыз бармыйсың,— секретарь хәйләле елмаеп, күз кысты,— биофакның мадоннасы Зәйтүнә белән...

Эредем дә төштем — балавызмыни.

Инде көзнең соңгы көннәре булуга да карамастан, кояш быел җәйге кебек көләч — кыздырып тора. Якты, матур. Һава саф, үтәдәнүтә күренә. Казанка буендагы бакчаларда алма агачлары ут булып яна. Ботаклар алмаларын күтәрә алмый сыгылган. Әчкелтем тәмле алма исе, хуш ис...

Менә шул алма бакчалары буеннан, тар тыкрыклардан Зәйтүнә белән култыклашып, алма ашап барабыз. Юл уңаенда базарга кереп алган антоновкалар. Тәмле дә, ачы да — тешләр камаша. Зәйтүнә бертуктаусыз сөйли, көлә. Бигрәк чая, авызына шайтан төкергән, хәерсезнең. Әл гаязи биллаһи, әйттем исә кайттым. Ә менә йортларга кереп, халыкны җыйганда, Зәйтүнә, авызына су алгандай, өнсез кала. Монда инде бар авырлык миңа төшә — Конституциянең барлык статьяларын аңлатып чыгарга кирәк!

Ә бүген? Бүген безнең участокка кем барыр икән? Зәйтүнә үзе генә теләмәс. Ни генә әйтмә, каланың чите. Анда әле көндез икәүләп йөргәндә дә куркыныч — атлаган саен исерекләр. Ә кичен! Юк, Зәйтүнә бармас.

Оркестр бераз тынып торган иде, хәзер тагын уйный башлады. Моң! Гаҗәп гүзәл моң. Тукта, бу бит Салих ага Сәйдәшевнең «Шәрык балеты»! Кеше күңелен тирән дулкынландыра торган гали һәм гүзәл моң бит ул. Әйтерсең лә Ямән чүлләреннән, көмеш кыңгырауларын чыңлатып, кәрван килә — комнарга бата-бата дөяләр атлый.

Күңел дулкынлана, тулып ташый. Ә музыка, моң көчәйгәннән-көчәя барып, үзенең тылсымлы канатлары белән мине күтәрә. Мин очам...

— Күтәр башыңны, контр кисәге!

Ачулы җикерену. Кемгә? Чү, мин калгып барам түгелме? Мин кайда? Нindидер бер кул, җилкәмнән кысып, умырып алып артка тартты. Гимнастеркам чытырдап китте, мөгаен, ертылды. Аннан теге кул кинәт алга таба этеп куйды. Башым шак итеп таш диварга бәрелде. Күзләремнән утлар чәчелде. Чайкалып барып стенага ябыштым, әмма тотына алмадым. Тез буыннарым чатнап, бар гәүдәм белән идәнгә авып төштем.

— Ах, хәшәрәт, инде алдаша да башладыңмы? — Авыр дагалы солдат итеге аркамны изә, әллә инде умырткаларым чатный, сыным катты, тыным кысылды.

— Мә сиңа! Мә сиңа, халык дошманы! — Тагын типкәләү...

— Тор, үләксә! Менә следователь килгәч тагын өстәмә паек алырсың, бас аягыңа!

Инде икенче тәүлек мине шулай стенага каратып, үрә катырып тоталар. Борылырга да, утырырга да бирмиләр. Җиде-сигез сәгать тикшерүче теңкәгә тия, аннары чиратлашып сакчылар җәзалый. Мин һаман басып торырга тиеш. Балтырларым итек кунычларына сыя алмый, шартларга җитешеп шешкән. Кургаш булып катканнар. Вакыт-вакыт чатнап, пычак белән чәнчегәндәй, авыртып, бөтен тәнне калтыраталар.

Сакчы солдатлар тагын күтәреп бастырдылар.

Мин диварга сөялеп көчкә торам. Алдымда известь белән акшарланган стена. Нindидер таплар. Кан таплары. Очкыннар.

Стена кинәт чайкалды, әле бер, әле икенче якка авышты. Тагын очкыннар чәчрәде һәм стена әйләнә башлады. Баш чатный. Косасы килә. Томан. Тагын стена калкып чыкты да зырылдап әйләнә башлады.

Шул диваргаябышып, мин дә әйләнәм. Һәм каядыр упкынга авам.

Ниндидер моң. Оркестр уйный. Утлы ком өемнәре арасыннан кызыл кәрваннар килә...

III

— Сез быел май аенда Ялтада булдыгызмы?

— Булдым.

— Нишләдегез?

— Дәваландым. Сеченов исемендәге санаторийда.

— Нинди авырудан?

— Неврастениядән.

— Сезгә әле егерме алты яшь кенә бугай, шул арада неврастениями? Димәк, күп эшлисез. Институтта укыйсыз. Шигырьләр язасыз. Молодец. Сез талантлы егет. Иртәрәк авыргансыз. Үзегезне сакларга, самый главный, минемчә, нервларны туздырмаска иде. Бит сезнең алда зур перспектива. Сез галим, өстәвенә атаклы язучы булачаксыз. Татардан мондый талантлы яшьләр күтәрелүгә мин бик сөенәм.— Бикчәнтәев өстәл өстендәге «Пушка» тартмасыннан бер папирос алып кабызды, тәмләп суырды. Ул үзе буйга миннән тәбәнәгрәк күренә. Әмма гәүдәгә тулы. Йөзе тәгәрәк, мөлаем. Күе кара кашлар, тузгып, бөдрәләнеп торган кара чәч. Мөгаен, әле яңа гына парикмахерда булган, бик пөхтә итеп кырынган, хушбуй исе аңкый. Аның өстендә гәүдәсенә сыланып торган, хаки төсендәге бик килешле өр-яңа китель.

Ул хәзер аеруча җыйнак, пөхтә, хәтта нәзакәтле елмаеп кына сөйли һәм «сез» дип кенә эндәшә. Ә кичә әнә килеп керүгә нинди кабахәт сүзләр белән сүгенде, җикеренде, хәтта сугарга омтылды — кулын тотып калдым.

— Рәхим итегез,— Бикчәнтәев өстәл аша үрелеп миңа папирос сузды,— тартыгыз.

Мин, «юк, тартмыйм», дип башымны чайкадым.

— Менә бик шәп. Сез сәламәтлегегезне саклыйсыз. Умно. Ә безгә менә тартырга туры килә. Гомерне кыскартырга. Берни эшләп булмый, язмышыбыз шундый әшәке.— Бикчәнтәев тагын озак итеп суырды. Һәм кинәт нәрсәнедер хәтерләгәндәй, тәмәке тартуын өзеп, бик җитди кыяфәт белән миңа карады.— Гафу итәсез, мөгаен, сезнең ашыйсыгыз киләдер? Мин үзем тук булгач, онытып та киткәнмен.

Дәшмәдем. Инде икенче тәүлек авызга бер валчык ризык төшмәгән. Эчем борып-борып ала.

Өстәл астында кнопка бар, ахрысы. Бикчәнтәев бармагы белән басып торды. Озакламый кырыйдагы ишек ачылды, аннан ак алъяпкыч бәйләгән сары чәчле бер кыз күренде.

— Галя, бу бүлмәгә кичке аш алып килегез.

Галя «ярый» дип акрын гына ишекне япты.

— Яхшы, ашны әзерли торсыннар, без өзелгән әңгәмәне ялгыйк әле.— Папиросы сүнгән икән, Бикчәнтәев бик пөхтәлек, тәкәллеф белән шырпы кабызып папиросын төтәтте, гадәтенчә, ашыкмыйча суырды.— Тәк, тәк... Сез Ялтада дәваланып кайттым, дисез. Бик әйбәт булган. Ярый. Ә менә Ялтада кемнәр белән очраштыгыз?

— Ялтада халык җитәрлек.

— Анысын мин үзем дә беләм. Мин язучылар турында фикер йөртәм.

— Ә-ә-ә. Галимҗан ага Ибраһимовның хәлен белергә бардым.

— Менә бу — мин көткән җавап. Путевканы кайдан алдыгыз?

— Кайдан булсын, Язучылар союзыннан. Кави ага бирде.

Бикчәнтәев тагын елмайды. Әле генә Галя ябып чыккан ишеккә дикъкать белән карап торды. «Кичке ашны нигә тоткарлыйлар инде?» мәгънәсендә. Мин дә ихтыярсыз шул ишектән күзләремне ала алмыйм. Өзелеп ашыйсым килә. Кайчан гына китерерләр икән? Кара, бу тикшерүче начар кеше түгел икән, әнә ничек ипле сөйләшә. Ашарга бирергә җыена. Мөгаен, гаебем юклыгын төшенеп, инде кайтарып җибәрергә ниятлидер. Аз-маз тукмадылар-тукмавын — ярар, җимерелгән төш юк. Итек куычларын Бикчәнтәев үзе телеп җибәрде, утырырга урындык бирде. Аякның шешләре бераз кайта да башлады, сызлау кимеде.

— Тәк, тәк,— Бикчәнтәев урыныннан торып, өстәл артыннан кабинет уртасына чыкты, ишекле-түрле атлый башлады. Яңа хром итекләр шыгыр-шыгыр килә. Борынга тәмәке, хушбуй исе кагыла. Ә мин аш исен эзлим, кайчан гына ул ишек ачылып, ашарга китерүче күренер икән? Ни алып килерләр? Икмәк белән су булса да, бик әйбәт булыр иде.

— Менә сез, Ялтага барыр өчен путевканы Кави Нәҗми бирде, дидегез, әйеме?

— Әйе.

— Яхшы. Аннан инде сез шул путевка белән Ялтага барып, Галимҗан Ибраһимов белән очраштыгыз, әйеме?

— Әйе.

— Яхшы. Хәзер сез менә мондый логик нәтиҗә ясагыз. Сезгә путевка бирүче Кави Нәҗми халык дошманы. Хәзер ул төрмәдә утыра. Ә сез барып күргән Галимҗан Ибраһимов та халык дошманы, хәзер Плэтән төрмәсендә ята.

— Булмас! — Мин җан тавышым белән кычкырып җибәреп, аягүрә басарга омтылган идем, тора алмадым — аякларым кузгалмады. Ул арада ишек ачылып, Галя дигәннәре поднос күтәреп керде — тәмле аш исе борынны ярып китте. Авызымнан сулар килде.

— Менә монда язучы егет алдына куегыз,— диде Бикчәнтәев йомшак кына елмаеп.— Җитмәсә, мин тагын кнопкага басармын.

Галя өстәлгә зур таш тәлинкә белән итле токмач шулпасы, кечкенә тәлинкә белән түбәсеннән тулы дөге боткасы, симез иттән гуляш һәм бер стакан ахак булып янып торган кайнар чәй куйды да тиз генә чыгып китте.

— Тәк,— Бикчәнтәев кире дән өстәл артына, урындыгына килеп утырды.— Тәк, нинди нәтиҗә: бер халык дошманы сезгә путевка бирә, икенче халык дошманы сезне каршы ала, нигә?

— Юк, мин ышанмыйм. Алар икесе дә большевиклар. Галимҗан ага әле 1905 елдан ук революцион хәрәкәттә катнашып, Киев төрмәсендә утырган, Колчак тылында йөргән разведчик ул.

— Ха-ха-ха! Ха-ха-ха! — Бикчәнтәев буылып-буылып, эчен тотып көлә башлады. Кысла сыман кызарды. Күзләреннән яшьләр атылып чыкты. Һаман туктала алмый.— Ха-ха-ха! Ха-ха-ха!

«Әллә инде акылдан шаша»,— дип куркып киттем. Әмма мин гаҗәпләнеп өлгерә алмадым, следователь сикереп торды, йөзе агарып-күгәреп китте. Кашлары салынды, күзләр акайдылар. Әйтерсең лә, күз алдында күз буып битлек киде. Танымаслык вәхши бер җанга әверелде.

— Син бит, хәшәрәт, алар арасында связной булгансың. Ну-ка, әйт әле, Кави белән Галимҗан сиңа нинди контрреволюцион йомышлар куштылар? Яле! Карталарыңны ач. Кави белән Галимҗан әллә кайчан инде җинаятьләрен өсләренә алдылар, и синең элемтәче булуыңны расладылар. Признавайся!

Аптырап калдым, нәрсәне танырга? Ул арада Бикчәнтәев йөгерә атлап минем янга чыкты.

— Я, признаваться итәсеңме, юкмы? — ул сугарга дип кулын күтәргәндә, күзем өстәлдәге мәрмәр пресс-папьега төште, ничек шуңар сузылганымны белмичә дә калдым. Бикчәнтаев сукканчы, мәрмәр пресс-папьены эләктереп алып, аның янагына бәрдем.

## IV

Бу елның уникенче мартында Галимҗан Ибраһимовка илле яшь тулды. Без, яшь язучылар, шул уңай белән Казанда, әдәбият дөньясында зур тантана булыр, дип өметләнгән идек. Гаҗәпкә, бу көннәр бик «тыныч» үтте. Хәтта газета-журнал битләрендә дә гадәттәге тәбрикләүләр, сәламләүләр күренмәде.

Аптырадык. Бу ни хәл? Галимҗан ага татар әдәбиятына зур хезмәт күрсәткән, тирән хис, фикер тулы әсәрләре белән меңләгән, йөз меңләгән укучыларның күңелләрен җәлеп иткән — сөендергән, көендергән әдип, галим, унҗиденче елга хәтле үк революцион хәрәкәттә катнашкан, шуның өчен төрмәләрдә утырган, әмма бу юлыннан тайпылмаган кыю большевик, җәмәгать эшлеклесе бит. Ул татар әдәбияты, культурасы, фән үсеше өчен бар көчен, гомерен һиба иткән талант иясе. Ничек инде шундый олы, фидакарь затның хезмәте, табыш-җимешләре игътибарсыз, ихтирамсыз кала?

Бу хәл мине аеруча борчый иде. Чөнки матур әдәбиятның беренче онытылмас ләззәтен мин аның әсәрләре аша татыдым, сихерләндем. Һәм шул тылсымлы дөньяга атларга, кулыма каләм алырга җөрьәт иттем. Канатландым. Акыл көче белән ныгытылмаган, алсу өметләр генә иде әле бу. Әмма ничек кенә булмасын, ул изге өмет-омтылышны Галимҗан аганың гүзәл музыкаль әсәрләре уятты һәм әдәбият мәйданына чыгарга өндәде.

Күкчәтау җидееллык мәктәбен тәмамлау белән тизрәк Казанга китәргә ашкынуымда да, һичшиксез, олы әдипнең тәэсире бар иде. Имеш, Казанга бару белән Галимҗан аганы күреп сөйләшәм, үземнең әсәрләремне — инде ике калын дәфтәргә күчерелгән шигырьләр, хикәяләремне күрсәтәм һәм... Аннан соң ни буласын, билгеле инде, күз алдына китерә алмыйм. Шулай да минем алда Олимп биеклегенә алып баручы салават күпере ачыла сыман иде. Һай, ул бала чаклар, гүзәл, самими һәм артык беркатлы уйланыла торган гамьсез чаклар!

Казанга килдем. Педагогия техникумына укырга урнаштым. Әмма... Әмма, кызганыч ки, Галимҗан аганы күрү сөенеченә ирешә алмадым. Ул, үпкә чире белән җәфаланып, Ялтага дәваланырга киткән иде.

Минем канатлар шиңде.

Җитмәсә, минә аның 50 еллыгын да игътибарсыз калдырдылар.

Билгеле инде, бу хәл мине генә түгел, башкаларны да, бигрәк тә яшь язучыларны бик пошындырды. Нәкъ шушы вакытта мин неврастения авыруына тарып, йокысызлыктан җәфалана башладым. Докторлар санаторийга барып дәваланырга киңәш иттеләр. Ә монда язгы имтиханнар башланды. Баш чатный, күз алларым караңгылана. Дәрестән өстендә калгып китәм... Ләм-мим башка кунмый. Нишләргә? Башны кран астына куеп, салкын суда туңдырам да имтиханга керәм.

Менә шулай җәфаланып йөргән көннәрнең берсендә Язучылар союзы идарәсенә чакырдылар. «Нинди мин, бик кирәкле кишер яфрагы»,— дип сукрана-сукрана барсам, сөенеч, бер түгел — ике!

— Ибраһим, сиңа неврастения белән авырый дип ишеттек. Менә Ялтадагы Сеченов исемендәге санаторийга путевка. Идарә бу путевканы сиңа бирергә карар чыгарды,— диде председатель Кави ага Нәҗми, мине бик хөрмәтләп каршы алып. Өнме? Төшме? Путевка! Ялтага! Ул арада Кави ага мине икенче хәбәре белән җиде кат күккә

күтәрде.— Үзең беләсең, быел Октябрьгә егерме яшь тула. Шул уңай белән Татарстан Язучылар союзы һәм Татиздат бәйрәмне бүләк белән каршыларга булдылар.

— Ул нинди бүләк, Кави ага? — дидем кызыксынып.

— Хәзер, хәзер,— диде Кави ага, гадәтенчә ашыкмыйча, хәрбиләрчә ачык-көр тавыш белән. Ул инде күптәннән союзда тыныч-гади эштә булуына карамастан, һаман әле хаки төсендәге гимнастеркадан, зәңгәр галифедан. Биле киң каеш белән буылган. Гимнастерканың чия кызыл петлицаларында икешәр «шпал» яна иде.— Дүрт альманах чыгарырга җыенабыз. Егерме ел эчендә татар прозасы, шигърияте, драматургиясе һәм балалар әдәбияты. Һичшиксез, бу альманахка иң яхшы әсәрләр тупланырга тиеш. Проза альманахын, без олы әдибебез Галимҗан ага Ибраһимов әсәре белән ачып җибәрергә уйлыйбыз. Ялтага бару белән аның янына кер — хәлен бел, безнең сәламне тапшыр һәм менә хәзер мин әйткән фикерне җиткер. Яңа әсәре өлгерсә, бигрәк әйбәт булыр иде, әгәр инде юк икән, Галимҗан ага үзе карап, басылганнардан берсен тәкъдим итсен. Кара,— Кави ага бусын тавышын күтәреп, кисәтеп әйтте.— Кара, Ялтадагы кызларга гашыйк булып, онытып җибәрмә,— Кави ага шук карап көлемсерәде. Мин кызардым.— Бу бик мөһим һәм ашыгыч эш. Галимҗан агага сәламебезне тапшыр һәм бик нык ихтирам итүебезне белгерт. Без аның тиз арада савыгып, яңадан сафка басуын көтәбез. Ярый, син әдәби фондка кереп, путевканы алатор. Китәр алдыннан тагын бер кереп чыгарсың.

Мин Галимҗан ага Ибраһимов янына барам! Мин Ялтага китәм! Бу көтелмәгән тау хәтле сөенечне кемгә булса да әйтергә, шатлыкны бүлешергә кирәк. Тизрәк! Тизрәк! Кабинеттан чыгуга, Матбугат йортының өченче катындагы «Кызыл яшьләр» редакциясенә йөгердем. Баскычта таеп егыла яздым, кемдер тотып калды. Ул рәхимле бәндәне күрмәдем дә, рәхмәт тә әйтмәдем — йөгердем. Сөенче! Сөенче!

Беренче очраткан кешем яшь шагыйрь, ахирәт дус Галимҗан Мөхәммәтшин булды. Ул газетаның оттискын укып-тикшереп утыра иде. Мин ишекне ачар-ачмас, кабалана-кабалана сөенечемне тезеп киттем.

— Менә шәп булган! Менә сөенеч! Әйдә,— Мөхәммәтшин сөйләп бетерүемне дә көтмичә, җиңемнән өстерәп, әдәби бүлек бүлмәсенә алып кереп китте һәм анда миннән дә көчлерәк ярсып-ташып сөйли башлады.— Ура! Ибраһим Ялтага бара. Әйдәгез, Галимҗан агага тәбрикләү хаты язабыз! Әйдәгез!

Мөхәммәтшин шундук, ишек янындагы озын өстәл янына утырып, алдына кәгазь салып, хатны яза да башлады. Бүлмәдә Ләбиб Гыйльми, Касыйм Шәйхетдинов, Сөббух Рафиков һәм тагын берничә яшь язучы — «Кызыл яшьләр» газетасы хезмәткәрләре бар иде. Алар да бу тәкъдимне хуплап каршыладылар. Мөхәммәтшин гомумән бик җиңел, хәрәкәтчән кеше иде. Утырып торырга яратмый — шигырьләрен дә аяк өсте йөреп, тавышланып яза иде. Хатны сырлап бетерүгә сикереп торды да бүлмә буенча арлы-бирле йөреп, кулларын бутап, рухланып укып чыкты.

Машинкада басарга әзерләнгән бу бер бит кәгазьгә язылган сәлам хатта Галимҗан аганың әсәрләрен яшьләрнең бик яратып укулары, өйрәнүләре, әдипне илле еллыгы белән тәбрикләүләре һәм аңа сәламәтлек, озын гомер теләүләре, яңадан-яңа әсәрләрен көтеп калулары, ихтирамнары әйтелгән иде. Бүлмәдәге иптәшләр хатны тулаем хуп күрсәләр дә, һәрбер җөмләсен кат-кат укып, җентекләп тикшерделәр — үзгәрттеләр, нидер алып ташладылар, нидер куштылар. Шундый олы әдипкә чиле-пешле хат язарга буламы!

— Октябрьнең егерме еллык тантанасына Галимҗан аганы кунакка чакырыйк,— диде иң ахырда Сөббух, сүзне очлап.

— Чакырабыз, чакырабыз! — дидек барыбыз да, бу тәкъдимне хуплап.

— Инде килегез, кул куегыз! — диде Мөхәммәтшин, хатны күчереп язып өстәлгә куйгач.— Галимҗан аганы бер сөендерик.

Бүлмәдәгеләр барысы да куана-куана кул куйдылар.

Мин Ялтага килеп төшкән көнне үк, хәтта юл буе сокланып килгән Кара дингезгә дә бармыйча, Галимҗан Ибраһимов торган йортны эзләп киттем.

1927 елда Г. Ибраһимовның кырык еллыгы уңае белән Күкчәтауда зур тантана оештырылган иде. Без мәктәп сәхнәсендә «Яңа кешеләр» драмасыннан күренешләр куйдык, башка әсәрләреннән өзекләр укыдык. Шул тантаналы җыелышта, Күкчәтау халкының теләге белән, җидееллык татар мәктәбенә Галимҗан Ибраһимов исеме бирелде. Менә шушы тантана алдыннан Казаннан бик күп яңа китаплар, җөмләдән Г. Ибраһимовның барлык әсәрләре һәм әдипнең зур портреты да алдырылган иде. Портрет мәктәп залының нәкъ түренә куелды. Мин, уку бетеп, балалар таралгач, берүзем залга кереп, портрет каршына туктыйм да аңа бик озак сокланып карап тора торган идем. Сокланмаслык та түгел — иңнәренә хәтле төшеп, кабарып торган ял-чәч. Киң маңгай, бер-берсенә кушыла язган, калын кара кашлар астында зур, уйчан күзләр. Борын астында гына калдырылган төймә мыек. Иреннәр каты кысылган. Баш аз гына, беленер-беленмәс кенә иелгән, уйга талган. Нindидер бер зур вакыйганы исенә төшерә — хәтереннән кичерә кебек. Күкрәк калку, иңнәр киң. Мөгаен, мәһабәт сынлы.

Ялтада мин менә шушы мәһабәт кешене, атаклы әдипне эзләп киттем.

Кара дингез, кояшның алтын нурларында чагылып, чайкалып, җәйрәп әллә кая аста ята. Ә мин аулак тыкрыктагы баскыч-баскыч ташларга басып, тауга, Виноград урамына күтәреләм. Урамның ике ягында төп-төз баскан биек, кырыс, тирән уйга талган кипарислар. Алар артында зөбәрҗәт йөземлекләр һәм күзнең явын алырдай гаҗәеп гүзәл-нәфис талгөлләр, алтын чәчәкләр.

Ниһаять, менә ул мин эзләгән йорт. Урамнан эчтә, бакча уртасында ике катлы агач бина. Якынлашам. Йорт инде кипарислар арасыннан ачыла төшә. Икенче катка урам яктан биек баскыч күтәрелә икән. Ул веранда ишеге төбендә туктый. Мин менә шушы баскычтан күтәрелергә тиеш.

Баскычтан җитез генә менсәм дә, веранда ишеге төбенә җиткәч, кинәт кенә каушый калдым. Эсселе-суыклы булып киттем.

«Нигә бу хәтле иртә авыру кешене борчып йөрим? Ул әле ял итә торгандыр. Мине генә күрәсе килеп торамы аның? Юк, китәргә кирәк. Тагын бер килермен».

— Иптәш, сез кемне эзлисез?

Сискәнеп киттем. Веранданың ишеге ачылып, бусагада җиңел чуар халаттан урта яшьләрдәге бер ханым күренде.

— Гафу итегез,— нигәдер, күтәрелү урынына, бер баскыч түбән төштем.— Мин язучы Ибраһимовны эзләп килгән идем.

— Рәхим итәсез,— хатын елмайды, аз гына артка чигенеп, юл бирде.— Югары үтегез. Без кунакларны яратабыз.

Мин чәчәкләр белән тулы ачык верандага кердем. Туфляларымны салдым, ашыгып, чак кына егылып китмәдем, роза гөле утыртылган зур мичкәгә таянып калдым. Ярый әле, анысы авып китмәде.

— Галимҗан, сөенче, сиңа кунак,— мине каршылаган хатын яңгыравык тавыш белән кычкырды һәм түр бүлмәнең ишеген ачты.— Узыгыз, менә агагыз торып та килә.

Мин бүлмәгә уздым. Тәрәзә каршына куелган зур язу өстәле янындагы камыш урындык-креслодан Галимҗан ага күтәрелде.

— Хуш килдегез.

Мин аптырап калдым. Тагын каушый башладым. Ул арада Галимҗан ага миңа якынлашып, үзенең озын, кан тамырлары күгәреп калкып

чыккан ябык кулларын сузды.— Исән-сау килдегезме? Узыгыз. Утырыгыз.

Мин шунда гына исемә килеп, тирләп-пешеп Галимҗан аганың сөякчел, салкын кулларын кыстым. «Җүләр, мин үзем алдан сәлам биреп күрешергә тиеш идем бит».

— Исәнмесез, Галимҗан ага! Хәлегез ничек?

— Әйдүк, әйдүк, энем. Менә бу урындыкка утыр.— Ул миңа да бер камыш кресло тартып куйды.— Хәл? Хәл зарланырлык түгел. Менә бүген сез килүгә, ахры, җиңеләеп, өстәл янына утырган идем.— Галимҗан ага минем кулымны каты гына кысты да акрын атлап, урындыгын аз гына миңа табанрак тарта төште. Утырды.

— Рәхмәт, онытмыйча зиафәт итүегезгә. Үзегезне кем дип таныйм? Кайсы яктан?

Әллә нәрсәгә телем бәйләнде. Югыйсә, әле поездда килгәндә үк, нәрсәләр әйтәсен, нинди сораулар бирәсен күңелдән ятлап килгән идем бит. Әйтерсең лә, абынып егылып, кулымдагы тәңкәләрне чәчтем.

Аның өстендә аксыл-сары иркен күлмәк һәм шул ук материалдан тегелгән чалбар. Аякларында да ак йоннан басылган йомшак каталар. Өстендәге киемнәре, нигәдер, гәүдәгә ятышмый, сәлберәп торалар. Йөзе озынча, яңак сөякләре калкып, битен тагын да суза төшәләр. Монда да кан тамырлары бүртеп, күгәреп, йөзен суытып-куыртып торалар. Чәчләр дә кабарып иңнәргә төшмәгән, сыланып ятканнар. Ара-тирә чал кылчыклар да күренә.

Тукта, кайда соң ул теге, мин Күкчәтау җидееллык мәктәбе залында сокланып караган, портрет кысасына сыймый, тулып, ташып торган мәһабәт ир? Каршымдагы камыш креслога чумып утырган кеше бик кечкенә, бик ябык бит, билләһи!

— Хәдичә, син самавырыңны шаулат. Кунакның авызы кипкәндер.— Менә шушы ягымлы, сабыр тавыш мине тәшвишләнүдән уятты һәм мин Галимҗан аганың сорауларын хәтерләдем.

Ул башта миңа нигәдер түбәннән йокымсырап карады — мөгаен, хәбәрләрем аны кызыксындырмыйдыр. Уйларым, фикерләрем чуала башлады. Ул моны сизде ахрысы, башын күтәрде.

— Гафу итегез, авыруым бераз борчыды. Шулай приступ булып ала. Хәзер менә үтте.— Галимҗан ага, ягымлы бер игътибар белән, миңа күз сирпеде. Зур соргылт күзләре ачылып, чаткыланып киттеләр, йөзе яктырды.

— Тәрәзәне дә ачып җибәрик әле, иртәнге һава шифалы ул.

Талгын гына җил исеп куйды — яфраклар кыштырдады, хуш ис — чәчәкләр исе аңкыды. Теплоход кычкырткан аваз ишетелде. Бухта монда якын гына бит. Күпме кораблар килә, күпме кораблар китә. Кара диңгез кочагы киң...

Галимҗан ага сораулар бирә башлады. Аптырап калдым. Башта ул мине тыңламый, авыруына борчылып, игътибарсыз калдыра дип, үпкәләп тә алган идем. Ә хәзер таң калдым — бер кәлимә сүземне дә ычкындырмаган — отып алган. Ул гынамы, Галимҗан ага авыру хәлендә Казанда басылган барлык китаплардан, газета-журналлардан хәбәрдар. Ул минем кебек әдәбиятка әле яңа кереп килгән яшь язучыларның әсәрләрен дә укып бара икән. Менә шул яшь каләмнәр хәзер нинди әсәрләр өстендә эшлиләр, укыйлармы? Кайда, ничек укыйлар — барысын да сорашты. Мин җавап биреп өлгерә алмыйм. Ә кулым костюм кесәсен капшый. Анда — хат. Ничек, сүзне-әңгәмәне бүлмичә генә, җайлап — тәкәллеф белән тапшырырга?

— Галимҗан, чәй әзер,— аш бүлмәсеннән Хәдичә апаның тавышы ишетелде. Соңыннан белдем, ул язучының хатыны икән.

Әңгәмә бүленде. Галимҗан ага мине чәйгә чакырды. Хәдичә апа бик тәмле вареньелар, хәтта үзебезнең милли ризык — чәк-чәкне дә әзерләгән икән.

— Кунак белән ризык тәмле була шул,— дип, Галимҗан ага чәйне бик яратып эчте.

— Сез инде, энем, көн дә килегез. Күрәсезме, сезнең белән агагыз ике касә чәй эчте,— дип, Хәдичә апа да куанып, мине кыстарга кереште.

Чәйдән соң без тагын түр бүлмәгә чыктык. Галимҗан аганың бите алсуланып, рухы күтәрелеп китте. Мена шул уңайдан файдаланып, аңа әлек Кави ага Нәҗминең сәламен, теләген тапшырдым, аннан, ниһаять, үзебезнең хатны бирдем.

— Яшь язучылардан?

Галимҗан ага хатны ашыкмыйча, игътибар белән укып чыкты да хөрмәт белән өстәлнең түренә — кулъязмалары янына сузып салды.

— Рәхмәт, бик күп рәхмәт яшьләргә,— диде Галимҗан ага ярыйсы ук дулкынланып,— онытмаганнар. Изге теләкләр белдергәннәр. Бу минем өчен зур сәгадәт. Әмма,— ул үрелеп хатны киредән кулына алды һәм күз йөртеп кенә әзләнә башлады,— кайда әле... Ә, менә, менә, «бөек әдип»,— Галимҗан ага башын күтәреп, миңа шелтәле карады,— нигә алай артык мәдех! Ә? Мин бит әле бөеклеккә житә алмаган әдип. Язган әсәрләремнең күбесеннән риза түгел, дөресрәге, канәгать түгел. Менә «Татар хатыны ниләр күрми», «Безнең көннәр»не яңадан төзәтеп язып чыктым. Әле дә канәгатьмен дип әйтә алмыйм. Юк, «бөек» сүзе артык.

Ул безнең, шул рәвештәге мәдхияләргә ризасызлык белдерде дә, ахырында хатны тагы әлекке урынына куеп елмайды:

— Яхшылыкка яманлык, дип рәнжи күрмәгез, яшь иптәшләргә ихлас күңелдән рәхмәт һәм сәлам. Мөгаен, сез илче буларак,— ул тагын бик ягымлы итеп елмайды,— бу тапшыруларымны яшь каләмнәргә житкерерсез.

— Һичшиксез, Галимҗан ага.

— Менә рәхмәт... Тик минем табигатем артык мәдхияне сөйми. Мин бөек түгел, бары тик эшче каләм — иҗат эшчесе. Авыр хезмәт ул каләм эше.

Октябрьнең егерме еллыгына дүрт альманах чыгарырга әзерләнү хәбәрен Галимҗан ага бик хуплады.

— Һичшиксез, бу зур һәм зарур мөкяфәт. Яхшы эш башланган. Алдыбыздагы егерме еллык — иң олы бәйрәмнәрнең берсе. Аның хөрмәтенә әзерләнә торган бүләк альманахта катнашуны мин үземә мартәбә дип саныйм. Адаш,— минем исемемне белеп алгач, ул миңа бары шулай «адаш» дип кенә эндәшә башлады,— сез әле тиз китмисездер?

— Июнь башында путевкамның срогы тула.

— Бик яхшы. Мин үземнең соңгы язмаларымны карап, берсен сайлап куярмын. Ә сез, адаш, вакытыгыз мөмкинлек бирсә, көн ара килеп торыгыз. Мин дә, Хәдичә апаң да кунакны яхшы күрәбез. Менә бүген сезнең белән ике касә чәй эчтем...

Минем әле тагын да утырасым килсә дә, Галимҗан аганың көйсезләнә башлавын (мөгаен, үпкәсе чәнчә) сизеп, саубуллашып чыгып киттем.

Санаулы көн тиз үтә, диләр. Дөрес икән, сизмичә дә калдым, китәр вакыт та житте. Әмма Ялтада үткән бу егерме дүрт көн һәрьяктан файдалы, шифалы булды миңа. Көн саен Шарко душы, диңгездә коену, яр буенда сәйран чигүләр барлык чирне кырып-юып алды. Рәхәтләнеп йоклыйм, кайвакытта йокым туймыйча да кала — торасы килмичә генә торам. Режим!

— Диңгез кешеләрнең барлык кайгыларын юа!— дип юкка әйтмәгәннәр икән борынгы юнанлылар. Алай да иң файдалысы һәм гомергә хәтердә кала торганы, һичшиксез, Галимҗан ага белән очрашулар, озак-озак сөйләшеп-әңгәмәләшеп утырулар. Бу очрашулар миңа иҗат хезмәтенең серле ишекләрен ачты, армый-талмый эшләргә, укырга — өйрәнергә, өйрәнергә, өйрәнергә кирәклеген төшендерде. Мин бер үпкә

белән генә яшәгән чирле әдипнең, һич аруны белмичә, үзен жәлләми, төннәр, көннәр буена әсәрләре өстендә эшләвен, кабат-кабат күчерүләрен үз күзләрем белән күрдем.

— Менә, адаш, Кызыл Армиядән кайтып, авылда яңа тәртип кору өчен көрәштә һәлак булган Гайфетдин турындагы хикәямне альманахка дип бирәм,— диде Галимҗан ага, соңгы тапкыр хушлашканда кулымны каты кысып.

Кичкырын иде. Ялта өстенә инде күләгә — Айпетри күләгәсе төшкән. Салкынча Босфор ягыннан җил кузгалган. Кара диңгез тынычсызлана — авыр дулкыннар ярга сугылалар. Аларның тонык тавышы, авыр сулышы монда, без басып торган верандага хәтле ишетелә.

Галимҗан ага өстенә җылы халат бөркәнгән дә диңгез ягына карап уйга талган.

Ә дулкыннар гүләп, ярсып, ярга сугылалар.

— Менә, адаш, тормыш та шулай. Диңгез шикелле. Бер тыныч була, ә бервакыт, менә хәзерге диңгез төсле, ярсып-дулап ярларга бәреләӘ кеше менә шушы упкын өстендә дә каушамыйча, югалмыйча, үз теләгенә барырга тиеш,— диде Галимҗан ага акрын гына пышылдап. Әллә миңа, әллә диңгезгә?

Ул тагын да кулымны кысты. Мин баскычтан төшеп киттем. Ул югарыда баскан килеш диңгез ягына карап калды. Ә дулкыннар һаман авыр көрсенделәр.

## V

— Үләксә!— Бикчәнтәев кара көеп, урындыгыннан сикереп торды да төкрекләрен чәчә-чәчә кычкыра башлады. Ул яңагындагы аркылыторкылы ябыштырылган тасма-пластырь — пресс-папье белән сугуымның тамгасы — бер өскә күтәрелә, бер түбән төшә.— Сволочь! Мин сиңа халык дошманы Ибраһимовның контрреволюцион йомышлары турында язарга куштым. Ә син...— ул минем төн буенча тырышып ихлас күңелдән язган биш табак язуны өстәлдән җыеп алды да ертыпертып почмактагы чүп-чар әрҗәсенә ташлады.— Менә аларның урыны.

— Иптәш следователь!

— Тик тор! Иптәшләрең Брян урманнарында нужа чигә,— ул ачуына чыдый алмыйча, тыпырдап, урындыгын аударды да бүлмә уртасына чыкты һәм арлы-бирле йөренә башлады. Хром итекләре шыгыршыгыр килә.— Тукта, мин сиңа әле күрәчәгеңне күрсәтермен. Бу пластырьлар бушка китмәс, кичә камерада егетләр аз биргәннәрдер... (Бирүен бирделәр, бөтен тәнем күгәргән. Көчкә күтәрелеп чыктым монда). Бүген тагын өстәрләр!

Тагын сугамы?

— Бас!

Мин язуларыма кул куяр өчен генә утырган идем. Аякларымның, тәнемнең сызлавыннан ыңгырашып, чайкалып, көч-хәл белән күтәрелдем.

— Син, падла, халык дошманы Ибраһимовның контрреволюцион эш кушуларын в конце концов ачасыңмы, юкмы, ә?

Төкерекләре битемә чәчрәде.

— Мин бит... Ихлас күңелдән...

— Ха-ха! Ха-ха-ха!— Тагын гасаби иблис көлүе башланды. Кызарды, бүртенде, пластырьлар кубып төште — кара янган тамга арлыбирле авышты.— Ха-ха! Мин синең ихласыңны фәлән итәм. Миңа ихласлык түгел, фаш итүең кирәк, фа-аш итүең! Төшендеңме?— Ул минем янымда өермә булып тузынырга-әйләнергә керештә.— Син нәрсә бәбәкләреңне шарландырдың? Следствиене бетерергә күптән вакыт. Эшне туктатып торасың, корткыч! Язасыңмы, юкмы?

— Нәрсәне...

Әйтеп тә бетерә алмадым, әле генә шыгырдап, үчекләп торган итекләрнең берсе очы белән тез астыма батып китте. Чалкан барып төштем.

— Дежурный!

Ул арада ишек ачылды да ике солдат йөгереп керде.

— Камерага! Карцер режимына. Кичә аз биргәнсез. Авызы ачылырлык итеп эшләгез. Алыгыз, нәрсә катып калдыгыз?!

Ике солдат ике аягымнан өстерәп алып та киттеләр.

— Ха-ха!— тагын Бикчәнтәевнең кыргый көлүе кабатланды.— Тукта, мин сиңа пресс-папьены хәтерләтермен әле...



### VI

«Кара козгын» чайкалып, әле бер, әле икенче якка авып-авып китә. Ниндидер чокыр-чакырлы урамнан барабыз. Мөгаен, Казанның кырый бистәсенә чыгабыз. Мин табут төсле озын, тар әрҗәдә утырам. Машинада шундый кысынкы — кузгалып та булмый, хәтта терсәкләрне куярга урын юк — кулларны күкрәгемә кушырырга мәҗбүрмен. «Табут» ауган саен мин дә авам, әмма әрҗәдән чыгып китеп булмый — ишек бик нык ябылган. Җитмәсә, теге якта — уртада мылтыклы солдат утыра. Саклап бара — качып китмәсеннәр! Кая алып баралар соң тагын? Нишләтмәкче булалар соң мине? Ни булса да булсын, тик Бикчәнтәевтән ераккарак алып китсәләр генә ярар иде. Каныкты бит, каһәр суккан. Менә инде тугызынчы тәүлек ни көндез, ни төнлә керфек кактырмый, тутый кош сыман, һаман бер сүзне кабатлый: «Халык дошманы Галимҗан Ибраһимов кушкан контрреволюцион эшләрне сөйләп бир!» Нинди эшләр? Һич төшенә алмыйм. Нинди тозакка төштем? Белмим. Әллә инде илдә контрреволюцион түңкәреш булган? Алай дисәң, ике сүзнең берендә: «Иптәш Сталин күрсәтмәләре»,— диләр. Ай-һай, иптәш Сталин бер гаепсез кешеләрне газапларга кушар микән? Булмас! Монда ниндидер өер үзләренең явыз ниятләренә юл салмакчы буладыр. Юк, ничек кенә кыйнасалар да, ялган күрсәтмәләр бирмәм, бигрәк тә Галимҗан ага турында. «Табут» тагын кыйшайды — маңгаем белән ишеккә бәрелдем. Шулай кыйшайганда, ичмасам, машинасы авып та китми. Я үләр идем, я качар идем... Тук-тук! Тук-тук! Чү, сул як стенадан кемдер чиртә кебек. Әнә тагын, тук-тук. Колагымны стенага куеп тыңлыйм.

— Кем чиртә?

— Бу мин, Галимҗан...

Тетрәнеп киттем.

— Галимҗан Ибраһимовмы?

— Юк, Мөхәммәтшин. Син кем?

Мин шашып калдым. Бу ни? Мөхәммәтшин дә мондамы?

— Син... Син дә мондамы?

— Кем, син кем?

— Мин... Ибраһим... Әллә переворот булдымы икән, ә?

— Белмим. Безнең камерада Ләбиб Гыйльми, Сөббух Рәфиков. Хатка кул куйганнарның барысын да алганнар... Мин инде унбиш тәүлек утырам. Көн дә сорау алырга китерәләр. Галимҗан аганы халык дошманы дип күрсәтергә кушалар. Бикчәнтәев әйтә, Салахов әллә кайчан таныды, ди... Кыйныйлар,— ул буылып йөткерде.— син инде кул куйдыңмыни?

— Юк, юк!— үз-үземне онытып кычкырып җибәргәнмен.— күрсәтмә бирмәдем.

— Пышылдашуны туктатыгыз,— сакчы ишеккә приклад белән сукты.— Еланнар! Хәшәрәтләр! Мин сезне хәзер үк карцерга...

«Кара козгын» тагын кыйшайды, авып китеп, чинап туктады.

Шыгырдап ниндидер капка ачылды. Машина кузгалып китеп бераз барды да тагын туктады. Капка шыгырдап ябылды.

Кемнәрдер арлы-бирле йөгереп үттеләр. «Кара козгын»ның уртасында утырып барган сакчы, тимер ишекне ачып, сикереп төште. Кемгәдер рапорт бирде:

— Сигез контрны китердек.

## VII

Ниһаять, мин — Пләтән төрмәсенең өченче катындагы арестантлар белән шыгрым тулы камераларның берсендә. Казанда ун ел торып, мондый төрмә булуын ишетеп тә белми идем. Менә, уйламаганда, аны белергә туры килде.

Следователь Бикчәнтәев алдында үрә катып торганда, бу шомлы шобага миңа гына төшкәндер, ниндидер бер аңлашылмаучылык белән бары тик мине генә «или» торганнардыр, дип пошына идем. Юк, миннән башкалар да онытылмаган икән. Житмәсә, камерадагы барлык «фатирчылар»— таныш-белеш яки газета-журналлар аша мәгълүм карт большевиклар, район, шәһәр, өлкә партия-совет оешмаларының житәкчеләре, профессорлар, укытучылар, студентлар.

Әмма камерага беренче тапкыр атлап кергәндә, бу «танышлар» котымны алды — жаным уч төбенә килде.

Тугыз тәүлек буена камерада япа-ялгыз ятып, бер кешене күрми, һичкем белән сөйләшми, бары тик тикшерүче Бикчәнтәев һәм аның чирүе белән көне-төне тартышу-сугышу мине чыгырдан чыгара язган иде инде. Тагын да берничә тәүлек бу хәл кабатланса, мөгаен, акылдан да шашар идем. Менә шуның өчен дә «кара козгын»ның ишеген ачып, төрмә ишегалдына төшергәч, куанып киттем, ичмасам, кешеләр күрермен, сөйләшермен.

Ул арада кара киемле, караңгы чырайлы, телсез надзирательләр, ым белән генә юллап, мине тар тимер баскычлардан төрмәнең югары катына алып менеп киттеләр.

Озыннан-озынга сузылган тар коридор. Бары тик ике очында гына тәрәзә. Алары да тимер челтәр белән киртәләнгән. Түшәмдә кызарып кына өч лампочка яна. Ике якта — тимер белән тышланган ишекләр. Барысына да калын тимер «билбау» каптырылган. Һәм ат башы хәтле йозаклар эленгән. Тынчу. Ярым караңгы. Шылт иткән тавыш та юк. Шомлы тынлык.

Алдан барган колга надзиратель, кулындагы бер кочак ачкычларны тәсбих төсле тартып барды да, бер камера алдына килеп туктады, нигәдер йозакны арлы-бирле тарткалады, аннан, бер ачкычны сайлап алып, йозакны ачты да ишекне тартты. Авыр тимер ишек чинап, акрын гына ачылды.

— Бар!

Мин бу сүзнең мәгънәсенә дә төшенеп житә алмадым, надзиратель аркамнан төртеп кертеп жибәрде:

— Бар, бар!

Ишек шалтырап шундук ябылды. Әллә төтен, әллә томан. Әллә инде мунча? Астылы-өстеле сәкеләрдә бер-берсенә укмашып тыгызланып утырган шыр ялангач кешеләр. Сакал-мыеклары житкән, күзләре акайган, үзләре шабыр тирдә. Әллә чынлап та мунча ләүкәсеме бу? Алай дисәң, ләгәннәре, себеркеләре күренми. Бәлкем, акылдан шашкан кешеләрдер? Бу уй мине бөтенләй чыгырымнан чыгарды — бизгәк тоткандагы кебек, туңа-дерелди башладым һәм, үзем дә сизмичә, ишекне аркам белән этеп, аякларым белән тибә башладым.

— Ачыгыз! Ачыгыз! Мин... Мин...

Арттан, коридордан, надзиратель ахры, ишеккә сукты:
— Шыпырт! Карцерга атлыгасыңмы әллә, корчаңгы?!
— Ибраһим,— алдагы сәкедән, томан эченнән кемдер миңа таба үрелде.— Ибраһим... бу син түгелме?
Иманеп киттем. Алдымда — институтның тел-әдәбият факультеты деканы, профессор Галимҗан Нигъмәти. Кафедрага ул һәрвакыт бик шома кырынып, пөхтә киенеп, галстук тагып килә торган иде. Хәзер минем алдымда сап-сары сакаллы, чәчләре тузган, бары тик трусиктан гына калган бер тоткын басып тора.
— Сине дә алдылармыни?— Тавыш үзгәрмәгән, нәкъ элеккечә йомшак, басынкы, бик ягымлы. Кинәт тынычлана калдым. Ишеккә тибүдән туктап, хәлсезләнеп, шуып төшеп идәнгә утырдым.
— Кайчан алдылар?
— Допроста булдыңмы?
— Газеталарда ни язалар?
— Амнистия турында сөйләмиләрме?
— Менә амнистия,— кемдер югары сәндерәдән калын тавыш белән кычкырып көлде.— Менә амнистия: ректор янына студентлар килә башладылар.
— Ташла әле, Шәйхи, иблислегеңне. Син бит райком секретаре.
— Төшерелгән!— диде каһкаһәле тавыш.
— Тсс...— ишектәге «күз» ачылды. Бүренекедәй кан баскан бер яман бәбәк карады.— Тагын бер тавыш ишетсәм, камераны карцер режимына куям.
— Ибраһим,— Галимҗан ага Нигъмәти минем яныма идәнгә утырып аркамнан какты.— Я, тавышланмыйча гына сөйлә әле... Институтта ни хәл? Тагын кемнәрне кулга алдылар?
Мин, ниһаять, аңыма килеп, белгәннәремне сөйләргә керештем.
Бу камера дүрт тоткын утыра торган бүлмә булган. Менә быел, «урып-җыю» артык «уңышлы» баргач, төрмәләрдәге комфортка — караватта ятуга чик куелган. Алар чыгарып ташланган, караватлар урынына камераның буеннан-буена ике катлы сәке-сәндерә эшләнгән. Хәзер инде монда дүрт түгел, егерме дүрт тоткын утыра. Ятканда кабыргага гына яталар икән. Сәке башкача сыйдырмый. Һава җитми. Шуның өчен мәхбүсләр үзләре тәрәзә өлгеләрен ватып бетергәннәр. Тимер рәшәткәле тәрәзә белән «калфак» арасында — кар. Хәзер аннан ишелеп суык керә. Ә камерада егерме дүрт җан. Алар сулый. Менә ни өчен монда тынчу һәм мунчадагы кебек пар, бу икән.
Сөйләшә торгач, камерага да, мәхбүсләргә дә ияләштем. Мин китергән «соңгы хәбәрләр» тәмамлангач, Галимҗан ага Нигъмәти мине култыклап торгызды да сәке кырыена утыртты. Кемдер торып, параша янына китеп, миңа урын бирде.
— Утыр, энем, бераз ял ит, бигрәк йончыгансың.
Өске сәкедән кемдер бер сынык икмәк сузды.
— Сез допростан бит... Бераз тамак ялгап алыгыз.
Мин чыннан да ачыккан идем. Өченче көнге насыйп булмаган ризыктан соң, мине карцер режимына куеп, тәүлеккә дүрт йөз грамм паек бирә башлаганнар иде. Бары тик куркуымнан гына онытып җибәргәнмен икән. Хәзер икмәк күргәч, йолкып диярлек алып, авызыма каптым — чәчәдем. Кемдер кружка төбендә калган чәен бирде. Бары ашап бетергәч кенә, рәхмәт әйтү исемә төште.
— Аптырама, Ибраһим, монда тәкәллефкә урын юк. Бераз хәл җый, ичмасам.
Миңа үз сыныгын сындырып биргән теге кеше югары сәкедән идәнгә сикереп төште. Түм-түгәрәк, кара сакаллы. Чандыр. Буйга миннән бик аз гына озынрак булыр, ахрысы. Ничектер таныш сыман. Бигрәк тә яңгырау, ачык тавышы. Һәм бик якты саргылт күзләре. Кайда күрдем соң бу кешене?

— Таныйсыңмы?— диде Галимҗан ага Нигъмәти, теге кешегә карап.— Бу бит иптәш Алкин, ВКП(б)ның Казан шәһәр комитеты секретаре.

Хәтерем ачылып китте. Әйе, әйе! Әле яз башында гына Академия театрында язучыларның һәм артистларның берләшкән җыелышында ул Октябрьнең егерме еллыгына әзерләнү, яңа әсәрләр язу, сәхнәгә кую турында бик дәртле, ялкынлы доклад сөйләгән иде бит. Бу чыгыш барлык тыңлаучыларда тирән эз — рухлану калдырган иде.

— Габдулла, син «бүре күзе»н каплап тор әле. Соңгы хәбәрне,— ул миңа карап елмайды,— шагыйрьнең килүен иптәшләргә белдерергә кирәк.

Мин хәйран калдым. Кемгә, ничек белдерергә? Ул арада Габдулла, бөтен камерада бердәнбер сакал-мыексыз яшь егет, тиз генә ишеккә таба атлап, аркасы белән «күз»не каплады. Ә Алкин, җәһәт кенә идәнгә чүгеп, су йөри торган җылыткыч торбага сак кына бер-ике тапкыр чиртте һәм шундук иелеп колагын куйды — тыңлады. Аннан тагын катырак чиртте. Камерадагы халык нигәдер арлы-бирле кузгала, сөйләшә, тавышлана башлады. Ә Габдулла кузгалмый, аркасы белән һаман «бүре күзе»н томалап тора.

Алкин идәнгә җайлабрак утырды да торбага янә чиртә башлады. Бер чиртә — пауза, ике чиртә — пауза. Әйтерсең лә, Морзе аппаратында телеграмма бирә.

Ә камерадагылар, тынычсызланып, күзләрен ишектән алмый.

Алкин аеруча бер дикъкать белән йодрык буыннарына карап чиртә.

— Тык, тык-тык, тык-тык, тык...

Ләкин мин аларны бүтән күзәтеп тора алмадым, сәкедә урын табылуга, изрәп йоклап киттем.

Камерада берничә көн торгач кына, мин бу серле чиртүнең Бестужев алфавиты дип аталуын, декабристлардан бирле төрмәләрдә бердәнбер сөйләшү-хәбәрләшү ысулы икәнен белдем. Нигездә Морзе ысулы. Рус алфавиты авазлары йодрык буыннары исәбеннән, бишәрләп юлларга бүленә. Артык күпкә китмәсен өчен, егерме дүрт аваз файдаланыла икән.

Баштагы чиртү — юл саны. Беренче, икенче, өченче юл. Икенче чиртү шул юлдагы авазның урынын белдерә. Мәсәлән, А хәрефе болай бирелә, башта бер чиртү — беренче юл, тагын бер чиртү — беренче юлдан беренче хәреф.

Шулай сүзләр, җөмләләр, исем-фамилияләр барлыкка килә икән. Алкин шулхәтле маһирланган бу сөйләшүгә. Аерым хәбәрләрне тапшыру белән генә канәгатьләнми, хәтта йөрергә яки параша түгәргә чыкканда кулга төшкән газета хәбәрләрен дә тапшыра һәм торба буенча бирелгән җавапларны бер ялгышусыз «укый».

Бу һөнәргә ул мине дә өйрәтә башлады. Әмма аны туктаусыз сорау алырга йөртүләр, аннан кыйналып килүләр бу «сабакны» тәртипле рәвештә дәвам итәргә мөмкинлек бирмәде. Шулай да Алкин юк вакытта «соңгы хәбәрләрне» мин тапшыра башладым.

## VIII

Алкин, әле яңа гына укырга өйрәнә башлаган бала сыман, иҗекләп «укый»:

— Га-лим-җан И-бра-һи-мов ка-ты а-вы-рый. Би-шен-че ка-мера-га Әб-җә-ли-мов-ны, Рес-пуб-ли-ка-нец-ны ки-тер-де-ләр... То-лым-бай-ский дүр-тен-че тәү-лек с-той-ка-да. Тин-чу-рин [1]...

[1] Толымбайский Г., Тинчурин К.— язучылар. Республиканец Г. И.— өлкә культура идарәсе башлыгы. Әбҗәлимов М.— ВЛКСМның Сталин райкомы секретаре.

— Тсс!— Ишек төбендә дежурда торган Габдулла баш бармагын авызына капты.— Тсс...

Коридорда ыгы-зыгы, йөгергән, ынгырашкан тавышлар ишетелде.

Алкин сикереп торып сәке кырыена утырды. Ул арада ишектәге йозак шалтырап ачылды. Кемнедер сөйрәп камерага керттеләр. Ишек шыгырдап ябылды. Габдулла белән Алкин идәнгә егылган кешене күтәреп алдылар.

— Урын!

Сәкедән ике кеше сикереп төште. Шул бушаган урынга — түбәндәгесенә, теге сорау алудан килгән кешене яткыздылар.

— Бу бит Мәхмүт Баһаутдинов,— диде Алкин янымa килеп.— Комсомолның өлкә комитеты секретаре. Мескен, аңын югалткан. Шул кадәр кыйнаганнар.

Тагын йозак шалтырады. Камера тып-тын калды. Кемнең чираты? Ишек ачылыр-ачылмас надзиратель башын суzды.

— Алкин, допроска!

Камера калтыранып киткәндәй булды — сулыш өзелде. Ә Алкин, сәйранга гына җыенгандай, пальтосын киеп, эшләпәсен кулына алды, елмайды.

— Я... пока!

Өстән бер йөк төшкәндәй җиңеләеп киттек.

— Булдыра алсаң, тикшерүчедән карандаш урларга тырыш...

— Тыңлыйм,— Алкин тагын ягымлы елмайды да тышка чыгып китте.

Камерадагылар, авыр сулап, үз урыннарына тарала башлаганнар гына иде, тагын йозак шалтырады. Әйтерсең лә, электр тогы сукты, калтырап, туктап калдык. Ишек ачылды, әмма нигәдер берәү дә кермәде. Бары тик пышылдап кына сөйләшкән тавыш ишетелде. Һәм шунда гаҗәеп бер хәл булды. Камерадагылар барысы да урыннарыннан торып ишеккә таба үрелделәр — йотылып иснәделәр.

Хуш ис! Шундый тәмле, тәнгә рәхәт бирүче хушбуй исе борынны кытыклый. Камера яктырып киткәндәй булды. Төрмә артында терәлеп торган, элек кадерен белмәгән гади тормыш, ә хәзер уй җитмәс еракгүзәл ирек үзе ишелеп монда керде, дөресрәге, төрмә ишеге ачылып китте сыман. Туя алмый үрелеп-үрелеп сулыйбыз. Рәхәт тә, күңелле дә, артык газаплы да булды бу көтелмәгән очрашу.

— Барлау!— Ачулы калын тавыш рәхәт халәттән уятты. Барыбыз параша янына тыгызландык. Сыймаганнар өске сәндерәгә утырдылар.

Ишек киңрәк ачылды.

Камерага ашыгып атлап төрмә башлыгының ярдәмчесе килеп керде. Озын буйлы, атлет гәүдәле яшь егет. Өстендә өр-яңа, үзенә ятышыпсыланып торган форма — кыек сырлы кара тукымадан тегелгән френч, галифе чалбар, ялт-йолт итеп торган хром итекләр. Аның йөзе түгәрәк, бит алмалары тулы, кызарып тора... Бар гәүдәсеннән хушбуй исе аңкып тора.

— Исәнмесез!— Аз гына елмая төшеп, тавышын күтәрмичә генә эндәште.— Ничек, жалобалар юкмы?

— Гражданин начальник,— Габдулла кысыла-кысыла алга чыкты,— камерада бик тыгыз, ятарга урын юк.

— Борчылмагыз.— Башлык ярдәмчесе тагын көлемсерәп, камерага күз йөртеп алды.— Чыннан да тыгызрак икән. Борчылмагыз. Бүген бушатырга тырышырбыз.— Ул бармагы белән төртеп саный башлады:— Бер, ике, өч, яле, атакай, син өскәрәк күтәрел... (миңа эндәшүе), дүрт, биш... егерме бер.

— Өч арестант допроста,— диде надзиратель кабаланып.

— Арестант түгел,— диде санаучы каты кисәтеп.— Тикшерелүчеләр.

Надзиратель кашларын җыерды, каралып китте.

— Хушыгыз.

Башлык ярдәмчесе тикшерү нәтиҗәсен блокнотына язды да кергәндәге кебек ашыгып атлап чыгып китте. Ә камерада хушбуй исе катыш ниндидер билгесез күтәренкелек калды.

— «Бушатырбыз», диде бит, ә?— диде Габдулла.

— Кем белә. Берсекөнгә бәйрәм. Бәлки егерме еллыкка амнистия булыр,— диде өске сәкедән карлыккан тавыш.

— Тот капчыгыңны!

— Юк, егетләр,— диде аскы сәкедән бераү өметләнеп,— иптәш Сталин безне бу хәлдә калдырмас.

Камерада шау-шу, бәхәс башланды.

## IX

Пләтән төрмәсендәге иң газаплы һәм куркынычлы төннәрнең берсе, һичшиксез, җиденче ноябрьгә каршы төн булды. Арестантлар арасындагы тынычсызлык инде ай башыннан ук кузгалган иде. Бәйрәм якынлашкан саен ул көчәя барды.

Бәйрәм алды һәрбер кешенең күңелен дулкынландыра, җилкендерә бит ул. Бәйрәм көнне ниндидер сөенечле бер үзгәреш булыр төсле тоела. Көтелмәгән яңалык-шатлык өмет итәсең. Яңа көн туган саен әнә шул сөенечкә якынлашкан кебек сабырсызланасың. Тизрәк-тизрәк бәйрәм житсә иде, дисең. Зарыгып көтәсең ул өметле көнне.

Ә төрмәдә? Бер гаепсез тоткынлыкка дучар булган кеше нишләргә тиеш бәйрәм алдыннан? Бигрәк тә Октябрь бәйрәме алдыннан? Октябрь революциясенә егерме яшь тулу көннәрендә, иң демократик Конституция — Сталин конституциясе кабул ителгән чорда?!

Нинди уйлар, нинди хисләр, нинди өметләр аны яктыртырга, хәл бирергә яки җәрәхәтләргә тиеш соң? Бу соңгы хәл итүче төндә. Я? Я?!

Гаҗәп икән ул тоткындагы кеше. Хәйран калдым. Элек әйтсәләр, һич ышанмас идем. Ә хәзер...

Тоткын ул бар гәүдәсе белән күрә, бар гәүдәсе белән ишетә, бар гәүдәсе белән тоя-сизә икән. Тәрәзәләре тимер рәшәткәләр белән ныгытылган, тимер ишекләре зур йозаклар белән бикләнгән, тышкы дөньядан биек, таш диварлар, чәнечкеле тимер чыбыклар, көне-төне йокысыз күзәтеп торучы уяу сакчылар, этләр, мылтыклар, пулеметлар белән аерылган, бүленеп алынган кап-караңгы төрмә камералары яңадан-яңа хәбәрләр белән тулып кына тора. Кайдан гына, ничек кенә килмиләр алар. Су йөри торган җылыткыч торбалар буйлап, калын, таш стеналар аша, югары каттан түбәнгесенә тегәрҗеп белән төшерелгән шырпы капларында, юынырга чыкканда бәдрәф диварларына беленер-беленмәс кенә сызгаланган «тавык тәпиләре» эзендә. Параша чыгарганда игътибарга алынган надзирательләрнең күз карашында, эндәшүләренең тонында, ниһаять, әле сөйләрлек хәле калган булса, сорау алудан кайтучылар аша һәм башка бик күп, ирекә бөтенләй игътибар бирелми торган, беренче карашка бөтенләй әһәмиятсез күренешләрдә, билгеләрдә.

Алкин сорау алудан көч-хәл белән кайтып керде. Бит-авызы күгәргән, сул күз кабагы канаган иде. Инде ул да, Баһаутдинов сыман, сәкегә егылып да камера тормышыннан ваз кичәр, дип уйлаган идем. Юк! Ул, сәкегә утырып, аз гына хәл җыйды да елмайды. Тезелеп торган ап-ак тешләр камераны яктыртып җибәрде. Тирә-яктагыларның йөзләре ачылды. Мин дә җиңеләеп киттем.

— Я, дуслар,— диде дә, елмая биреп, түбән иелде. Ахрысы, итеген салмакчы булды, әмма кире турайды, йөзе чытылды.— Булмый икән. Сул итекне салдырыгыз әле.— Мин йөгереп килеп итекне салдырырга омтылган идем, кая. Балтырлары шешеп, итегенең куныччын киергәннәр.

Тәнем тетрәнеп китте. Аны да тенозын бастырып тотканнар ахры, кансызлар.

— Булмаса, кунычын җөеннән сүтеп җибәрегез. Габдулла, теге пыяла кыйпылчыгы кайда?— диде Алкин, тирә-якка каранып.

Габдулла йоклый икән, уяттылар. Ул параша астына кыстырылган кыйпылчыкны алды. Көч-хәл кунычны сүттек.

— Менә, иптәшләр, гозерегезне үтәдем,— диде Алкин, итекләрен салдыргач, сул аягының чолгавы арасыннан чәнти бармак хәтле генә карандаш чыгарып.— Галимҗан ага, озынрагын алырга кулым җитмәде.

— Моңысына да...

Ул арада «күз» чайкалды. Алкин юри, ахры, аякларын сузып җибәреп, сүгенә башлады. «Күз» ябылды — надзиратель китте. Адәр, нигәдер, мәхбүсләрнең сүгенүләренә игътибар итмиләр генә түгел, «рәхимле» кул селтиләр иде.

Галимҗан ага Нигъмәти карандаш төпчеген ыштан бөрмәсенә яшерергә өлгермәде, күрше дивардан чакыру сигналы чирттеләр. Алкин шундук идәнгә шуып төшеп стенага колагын куйды. Камера тып-тын булып калды.

— Кружка!

Кружка бирделәр. Алкин кружканы стенага каплап тыңлый, теге яктан биргән хәбәрне ятлый башлады.

— Октябрьнең егерме еллыгы хөрмәтенә моңа кадәр һич күрелмәгән зур амнистия әзерләнә. Барлык сәяси тоткыннар азат ителәчәк. Указ җиденче ноябрьдә игълан ителәчәк.

— Ура!

— Әйттем бит була дип.

— Тавы-ыш! — «Күз» ачылды — кан сарган ачулы бәбәк күренде.— Бу нинди шау-шу?

Надзиратель, кисәтүен ныгытыр өчен ахрысы, ишеккә итеге белән бер-ике типте дә авыр атлап башка камераларга таба китте. Күрәсең, аларда да тынычлык юк.

Ә бездә — тантана. Камерадагыларның барысы да сөйли, һәр тоткын бу гадәттән тыш хәбәр турында нигезле фикерен ишеттереп калырга тырыша.

Дөресен әйткәндә, әле яңа гына Алкин кружка аша күрше камерадан алган хәбәр яңа түгел, ул инде ай буенча кабатлана. Әмма хәзер, бәйрәм алды төнендә! Октябрьнең егерме еллыгы тантанасы алдында! Бусы инде, һичшиксез, нигезле өметләнү.

Бөек Октябрьгә егерме ел тулганда, ничек инде шул революцияне үз куллары белән барлыкка китергән, аны саклап калу өчен кан түккән ветераннар, аларның эзбасарлары — яшьләр, комсомоллар төрмәдә утырсын? Акылга сыймый.

Бу хәбәр — амнистия турындагы сүзләрне, ничә генә тапкыр кабатланмасын, һәрвакыт, беренче тапкыр ишеткән сыман, тын алуны өзеп, онытылып тыңлыйбыз. Күңел яктыра, күзләр нурланып китә, хәтта сулган-саргайган йөзләргә алсулык сирпелә. Сулыш иркенәя.

Ирек! Азатлык! Синнән дә татлырак, синнән дә кадерлерәк, кыйммәтлерәк тагын нәрсә бар дөньяда? Әмма синең иксез-чиксез киң, җылы, мәрхәмәтле кочагында вакытта без кадереңне генә белмибез икән, бөек бәхет!

Инде күп калмады. Аз гына, бик аз гына түзәргә, сабыр итәргә кирәк. Озакламас, бу авыр ишекләр ачылып китәр. Без тагын да кешелекнең бөек куанычы — азатлык кочагына ташланырбыз һәм туйганчы иркәләнербез.

Барыбыз да ул көннең туарына ышана идек, иманыбыз камил иде. Без бит ят түгел, үги түгел. Барыбыз да совет иленең тугрылыклы, фидакарь балалары. Шулай булгач...

Тиздән! Тиздән!

Бөтен камера шушы изге уйлар белән дулкынланды:

— Дан-дон! Дан-дон!

Тоткыннарның йөрәген өшетә торган, нервларын өзелердәй итеп какшата, акылны томалый торган чаң! Шомлы, кара каргышлы чаң! Бу ни бу? Гадәттә бу чаң кичке чәйдән соң — тикшерү алдыннан сугыла иде. Хәзер бит әле сәгать, күп булса, биш-алты чамасында гынадыр.

— Дан-дон! Дан-дон!

Коридорда ыгы-зыгы. Әллә янгынмы? Әллә инде берәрсе качарга маташканмы? Хәер, тимер рәшәткә, калын тактадан эшләнгән «калфак», таш стена, чәнечкеле тимер чыбык, этләр, сакчылар, мылтык, пулеметлар киртәсе аша мөмкинмени бу?!

Әллә? Әллә берәрсе, бу хурлыкка чыдый алмый, асылынганмы? Бу хәлнең булуы бик мөмкин. Әмма бер тоткын асылынган өчен бу хәтле ыгы-зыгы тумас. Даңгылдау туктар-туктамас, камераның ишеге ачылып китте. Надзиратель бар тавышына акырды:

— Торыгыз! Басыгыз! Тикшерү. Тизрәк!

Упыр-тупыр бер-беребезне кысып, параша янына өерелдек.

Камерага атылып ике хәрби кеше керде. Өсләрендә — озын соры шинель, яка очларында янып торган берәр шпал, димәк, майорлар. Башларында өр-яңа колакчын бүрекләр. Икесе дә урта яшьләрдә, тулы гәүдәле. Йөзләре суык. Күзләре бораулап ачу белән карый. Әле күптән түгел генә барлау ясаган төрмә башлыгы урынбасары бусага төбендә «смирно» баскан, өлкән түрәләрнең боерыкларын көтә.

— Тикшерү,— диде майорларның берсе, камераны сөзеп карап, ачулы тавыш белән.— Тизрәк! Берәм-берәм минем алга басыгыз да исем-фамилиягезне, кулга алынганчы кайда, кем булып эшләвегезне әйтеп, сәкеләргә менеп капланып ятыгыз. Кара, монда бүтән карыйсы булмагыз. Я, я, башладык. Син?

— Алкин, ВКП(б)ның Казан шәһәр комитеты секретаре.

— Марш! Син?

— Галимҗан Нигъмәти, профессор.

— Марш! Син?

— Сөббух Рәфиков, шагыйрь.

— Иманкулов Зариф, беренче татар полкы комиссары.

— Син?

Түбәнге сәкедән озын буйлы, таза гәүдәле кеше күтәрелде. Майор сискәнеп артка чигенде, күрәсең, сугып җибәрер дип курыкты һәм икенче тапкыр, бу юлы инде акрын гына эндәште:

— Сез?

— Камай Гыйлем, профессор, Владимир Ильич Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты ректоры.

Майор тагын артка чигенде.

— Стенага карап басыгыз. Следующий?

— Сәләх Атнагулов, профессор.

— Өскә! Син?

— Баһаутдинов Мәхмүт, Татарстан өлкә комсомол комитеты секретаре.

— Өскә!

— Менә алмыйм. Аякларым шешкән.

— Ярар алайса,— майор нәфрәтле караш ташлады.— Ярар, түбәнгә ят. Син?

— Акимов Николай Васильевич — Татпросвет секретаре.

— Син?

— Нижегородцев Ардалион Михайлович — комсомол өлкә комитетының бүлек мөдире.

— Ә син нәрсә анда менеп кунакладың? Төш!

Өске сәкедән җиңел генә сикереп, атлет гәүдәле берәү төште.

— Чанышев.

Әле һаман артта басып торып, килүчеләрне блокнотына язып торган майор, кинәт блокнотын төшереп җибәрә язып, кабаланып алга атлады:
— Якуп?
— Юк. Ул минем абыем. Ул комдив. Мин җайдаклар эскадроны командиры.
— Өскә! — Алда торган майор кашларын җыерды, йөзен чытты: — Барыгыз да елан Тухачевскийның койрыклары.
Чанышев нәрсәдер әйтергә дип авызын ачкан иде, бусагада басып торган төрмә башлыгы ярдәмчесе бармак янады:
— Тсс! Дәшмә!
Чанышев башын чайкады да бер сикереп ик өске сәндерәгә менеп китте.
— Син?
— Гомәр Гали, әдәбиятчы, редактор.
— Ә син, чулак?
— Мыскыллламагыз,— Николай сул чулак кулын селкеп алды.— Тумыштан.
— Безгә барыбер. Фамилияң? Тизрәк.
— Борциковский Николай. Казан педагогия институты студенты.
— Син?
— Шәйхетдинов Касыйм — «Кызыл яшьләр» газетасы редакторы.
— Ильясов Гали — Татар академия театры режиссеры.
— Син нәрсә аптырап торасың?
Параша янында басып торган Габдулла сискәнеп китте.
— Мин? Мин бит комсомол райкомы секретаре. Мин...
— Ярар.— Майор әйтеп бетерергә бирмәде, бүлде:— Фамилияң?
— Әхмәдуллин Габдулла...
Аннан соң ике укытучы, бер прокурор, бер ВКП(б)ның авыл райкомы секретаре аваз бирде. Сәкедә урын булмагач, аларны стенага каратып бастырдылар. Мин дә шулар рәтенә эләктем. Башкалар әле сорау алудан кайтмаган иде.
Гадәттә барлауда саныйлар да чыгалар иде, болай мәсхәраләп яткырмыйлар, стенага терәмиләр иде бит. Бу ни бу? Бәйрәм алдыннан тагын нинди «яңа тәртип» күрсәтәләр монда?
— Отбой. Ятыгыз. Тавышланмагыз,— диде алдагы майор, тикшерүне төгәлләп, тагын бер тапкыр камераны сөзеп карап.
— Ә кичке аш? — кемдер югары сәкедән кычкыра салды.
— Бүген анысы юк,— диде дә башлык ярдәмчесе ишекне япты. Йозакны юри, ахрысы, шалтыр-шолтыр китереп бикләде. Уйны уйга сузып очларын бәйли алмыйча җәфаланганда, тагын ишек ачылды, ашыгып надзиратель керде дә елан төсле пышылдады:
— Ыш-ш-ш, «А» хәрефенә кем бар?
Бусага төбенә өч тоткын килеп фамилияләрен әйттеләр.
— Алкин.
— Керәкми.
— Акимов.
— Керәкми.
— Атнагулов.
Сәләх ага, болай да ябык, озын, әз генә шадра кеше, хәзер бөтенләй караңгыланып, хәлсезләнеп китте. Ул әле иртән генә сорау алудан ватылып, көч-хәл белән кайткан иде.
— «Б» хәрефенә?
Надзиратель әйтеп тә бетермәде, өске сәндерәдән Николай сикереп тә төште. Надзиратель чак тайпылып калды.
— Хәшәрәт! Баса яздың бит, чулак җен.
— Мин бит Борциковский,— диде Николай бер дә борчылмыйча. Ул әле сорау алуда булмаган, беренче чакырылуы иде.
— «Б»га тагын кем?

Югарыдан кемдер җавап бирде:

— Бәһаутдинов тора алмый. Яңа гына...

— Молчать! — Надзиратель ачуыннан сикереп китте. — Анысы миңа кагылмый. Торгызыгыз!

Тынлык. Беркем кузгалмый.

— Торгызыгыз, — дип надзиратель акырып җибәрде, — кабахәт контрлар! Кемгә әйтәм мин? Өстерәп төшерегез.

Тагын тынлык.

— Мин сезне акылга утыртырмын, анагызны... — надзиратель, кабахәт сүзләр белән сүгенеп, коридорга таба борылды. — Кирәгез әле!

Ишек артында көтеп кенә торганнар, ахры, ике дәү-дәү надзиратель атылып керде. Өлкән надзиратель түбәнге сәкедә ыңгырашып яткан Мәхмүткә ишарәләде:

— Әнә теге контрны алып чыгыгыз.

Бераздан Камайны, Галимҗан Нигъмәтине, Гомәр Галине, рәссам Зәбихне алдылар. Сәкедә урыннар бушады. Әмма бер генә тоткын да, аягүрә торудан хәлсезләнүләренә карамастан, ул урыннарны алырга ашыкмады.

Тынлык. Авыр, кара тынлык.

Ә коридорда һаман ыгы-зыгы. Нинди тынгысыз бу бәйрәм алды төне?

— Син, энем, минем якка борылып ят әле, бер эчемне бушатыйм. Юкса, болай уйлый-уйлый акылдан да шашарсың... Очы-очка житми,— диде сул ягымда яткан күршем. «Өч көнлек секретарь». Белмим, аны нигәдер шулай атыйлар. Үзе шул кушаматка өйрәнгән, рәнҗеми дә. Әмма хәзер мин аның кушаматы белән кызыксынудан яки сөйләшергә теләүдән ерак идем. Үз уйларым үземә җиткән — очы-кырые юк. Теге вакытта ялгыш кына кулга алулардыр, төрмәне күрсәтмичә генә чыгарып җибәрмәгәйләрә, дип борчылган идем. Инде менә төрмәне дә, андагы мәхбүсләрне дә күрдем. Моннан чыгу мөмкинлеге исә көннән-көн ерагая бара. Бөтен ышаныч амнистиядә... Анысы булыр да, булмас та төсле — су өстендәге калкавыч кебек, бер күренеп күңелне ярсыта да, тагын суга бата... Шуңа күрә әлеге иптәшкә:

— Эчне пошырма әле, — дидем дә борылып яттым.

— Юк, син тыңла әле, энем, — дип каныкты бу, — тыңласаң, кайгың таралыр. Күреп торам бит, син әле өйләнмәгән дә егет. Институтта сөйгәнең дә калгандыр. Ни өчен мине «өч көнлек секретарь» дип атыйлар, шуны сөйлим әле. Син шагыйрь бит. Теге «Кырык вәзир»дәге «Бер сәгатьлек хәлифә»не укыгансыңдыр, нәкъ шуның сыман.

— Алай бик кызык булгач, сөйлә инде.

Мин күршемә таба борылып яттым.

— Менә, энем, мин көч-хәл белән ТКУны тәмамладым. Аннан Казан артындагы авылларның берсендә райком инструкторы булып эшли башладым. Дөресен әйткәндә, миндә әллә ни оештыру таланты да кәперәеп күренмәде. Кушканны эшлим дә йөрим. Кушмаганга тыкшынмыйм. Үзем болай, энем, тумыштан барга канәгать. Күктән йолдызлар үрелеп алу өметем булмады. Дәрәҗә баскычларыннан күтәрелү турында да уйламыйм, чамамны беләм дә мыштым гына йөрим. Ул арада уртакул бер авыл кызына өйләнеп тә алдым. Җаныем да әллә кая үрелмәде, колхозда сыер сава башлады. Ә менә ел башыннан эшләр үзгәрде дә китте.

— Әйе, шуннан?

— Кызыгы әле алда, энем. Менә бит, язгы чәчү алдыннан гына, безнең беренче секретарьны һәм минем турыдан-туры башлык агитпроп мөдирен бер төндә алдылар да куйдылар. Обкомнан килгән вәкил: «Алар халык дошманнары», дигәч, ышанасы да килмәде. Ләкин, Казаннан килеп әйткәч, ышанмый кая барасың? Икенче секретарьны — беренче, мине мөдир итеп сайладылар да куйдылар. Җаваплы эшне кабул

итәргә дә өлгермәдем, бер төндә теге икенче секретарьны да алдылар. Аны да: «Дошман булган, астыртын корткычлык эшләгән», диделәр. Өченче секретарь авырып больницада ята иде... Обком вәкиле тотты да мине беренче секретарь итеп тәкъдим итте. Ис китте. Сайламаслар, дигән идем. Бюро членнарының берсе дә каршы кул күтәрмәде. Дөресен әйткәндә, былтыр конференциядә сайланган бюро членнарының яртысы юк — төрмәдә утыралар иде.

Менә мин беренче секретарь кабинетында. Ул арада Казаннан тагын вәкилләр килеп тулды. «Район оешмаларында корткычлар утыра, хәзер үк аппаратны алардан тазартырга кирәк, менә исемлек», — диделәр.

Аптырадым. Үзем белән бергә эшләгән иптәшләр. Һич тә корткычка охшамыйлар иде. Нишлисең, югарыдан кушкач, тыңларга кирәк. Бюро җыйдым. Өч көн район аппаратын корткычлардан тазарттым. Инде дүртенче көн, уф алла, үз эшемә тотыныйм дип җыенсам, райком ишеге төбендә ике адәм:

— Иптәш секретарь, безгә кереп чыгыгыз әле,— диделәр.

Киттем. Менә инде утыз тугызынчы тәүлек монда ятам. Әле һаман...

Шалтыр-шолтыр ишек ачылды. Барыбыз да сикереп тордык — кемдер сорау алудан кайтты, ахры. Юк икән. Надзиратель пышылдап:

— «Р» хәрефенә кем бар? — дип сорады.

Янымдагы «өч күнлек секретарь» идәнгә сикереп төште.

— Рамазанов Миңлегали.

— Киен.

Миңлегали пальтосын, фуражкасын таба алмый кабалана. Мин аларны баш очыннан суырып алып бирдем. Ул, ашык-пошык киенеп, чыгып китте. Әллә ничек йөрәгем сызылып калды. Беркатлы, риясыз шул кешене җәлләде күңелем.

Камерада тагын тынлык урнашты. Түшәмдәге корымланып беткән лампочка кызарып кына яна. Шуның өчен монда ярым караңгы. Кемдер буылып йөткерде. Кемдер авыр көрсенде һәм тавышланып рәнҗеде-газапланды:

— Я алла, бу нинди хаксызлык!

Чыннан да, нигә мондый гаделсезлек, ә? Иртәгә бит олы бәйрәм. Октябрь революциясенә егерме ел тула. Ә без менә монда, тынчу төрмәдә, бет, борча, кандала оясында ятарга урын таба алмый нахак газапланабыз.

Зәйтүнә хәзер нишли икән, ә? Җуләр, нишләсен, рәхәтләнеп караватында сузылып ятып йоклыйдыр. Иртәгә демонстрациягә барасы бар бит. Ә хәзер инде төн уртасы... Күңелем тулып китте — күзләремнән яшь коелды. Эре-эре тамчылар битемне пешерә. Капланып үкси башладым.

— Ибраһим, Ибраһим, сиңа ни булды, елама,— диде ниндидер йомшак тавыш.— Ярамый.

Ә мин тыела алмыйм, аның саен буылып-буылып үксим.

— Нигә мондый хаксызлык?..

— Ибраһим...

Артык йомшак, якын, ягымлы тавыш. Кем соң ул минем өчен болай борчыла?

Торып утырдым.

— Елаудан файда юк,— диде Алкин, миңа якынрак шуышып утырып.— Ялгыз син генә түгел бит.

— Алай да... Мин нинди халык дошманы булыйм ди, Алкин абый? Мин бит балтачы малае. Совет хөкүмәте мине институтка кадәр китерде.

— Ә менә Гыйлем Камай? Ул кем? Фабрикант баласымы? Аның әтисе гомер-гомеренә бурлак булган, Идел буенча баржалар тартып йөргән. Гыйлем үзе пристаньнәрдә йөк бушатып йөргән. Совет хөкүмәте аркасында гына укып, утыз яшендә профессор дәрәҗәсенә күтәрелгән. Аның ачышлары фәнгә зур казаныш китерде һәм илебезне дөнья күләмендә югары дәрәҗәгә күтәрде. Ул...

— Шундый галимне нигә соң төрмәгә япканнар?

— Бу сорау мине дә борчый,— диде Алкин көрсенеп, сүздән язып. Аннары өстәде:— Иптәш Сталин бу башбаштаклыкка юл куймас, тикшерер.

Алкин сакалын тарап, уйланып торды да тагын кабатлады:

— Тикшерер. Башкача һич мөмкин түгел. Менә, татар әдәбиятының ерак тарихын җанландыручы, бүгенгесен үстерү өчен армый-талмый эшләүче галимнәр — Галимҗан Нигъмәти, Сәләх Атнагулов та ярлы крестьян гаиләсеннән.

— Ә сез?

— Минем эти дә ярлы крестьян булган. Үзем Казанда бер олаучы абыйда ат карап, «барабыз» булып эшләп үстем. Аннан рабфакта укыдым.

— Ә шулай да, абый... Нигә болай чын-чын коммунистларны, Совет хөкүмәте өчен сугышкан кешеләрне төрмәләргә тутыралар, ә? Әллә инде фетнә кузгалып, хөкүмәт эсерлар кулына күчкәнме? Бәлкем, иптәш Сталин да хәзер төрмәдә утыра торгандыр, ә?

— Юк, анысы ук булмас, булмас,— диде күршем, сагышлы тавыш белән.

Тагын ишек шалтырады. Ачылды. Ниндидер шинельле бер кешене төртеп керттеләр.

Без түбән төштек. Таныш түгел, яңа кеше иде ул.

— Иптәш, сезне әллә яңа гына кулга алдылармы? Тукта, сез... сез Беренче татар полкы командиры Тупиков түгелме?

— Алкин!

Кочаклаштылар. Бер-берсеннән аерыла алмыйлар. «Күз» ачылды. Ачулы ялгыз бәбәк карады. Ябылды. Ә Алкин белән Тупиков һаман әле кочаклашып, аптырап, куанып, борчылып, бер-берсенә сораулар яудыралар.

— Я, ярар,— диде Алкин, ниһаять, үзеннән байтак озын, таза командирның кочагыннан чыгып.— Әйдә, утыр. Син кайдан килеп төштең?

— Эх, әйтмә инде!— Тупиков сәке кырыена утырды.— Өч көн инде сорау алалар. «Имәнкулов белән бергә контрреволюцион оешмада торгансыз. Ул инде гаебен таныды», ди тикшерүче.

— Ялганлый,— Алкин утырган урыныннан сикереп торды.— Ялган. Зарифны әле бүген генә сорау алырга чакырдылар. Ул һичбер документка кул куймый, шуның өчен барган саен кыйныйлар.

— Ә мин инде, тикшерүчегә ышанып, Имәнкуловны яла ягуда гаепли башлаган идем.

— Юк, юк, ышанма. Зарифны инде бер атна илиләр. Сорау алудан кайтып егылырга өлгерми, тагын күтәрәләр. Кыйныйлар. Коры сөяккә генә калып бара. Тагын нинди яңалык?

— Менжинский клубында хәрби трибунал. Өченче көнне «Буа эшен» караганнар.

— Әйе, әйе, ишеткән идем. Нәрсәдә гаеплиләр, кемнәрне?

— Кемнәрне булсын, Буа районының барлык җитәкчеләрен. Райком секретарьларын, башкарма комитет председателен һәм башкаларны. Барысы уналты кешене. Имеш, корткычлык оештырганнар. Кичә хөкем карары укылган.

— Аклаганнармы?

— Аклаганнар: унбишен атарга, бары редактор Яушевка гына унбиш ел төрмә.

— Булмас!— Алкин кычкырып җибәрде.— Булмас!

— Кызганыч, ләкин бу дөрес,— диде Тупиков, авыр сулап.— Дөрес.

Алкин камера буенча арлы-бирле йөрде дә килеп туктады:

— Тагын?

— Бүген шунда ук бер төркем хәрбиләргә суд башланды. Анда дивизия командиры Дзент та бар, ахрысы. Шулай ук корткычлыкта,

фетнә әзерләүдә гаеплиләр, ди. Безне дә шул төркемгә тыгарга тырышалар. Анда кушсалар — бетәбез!

— Шулай уйлыйсыңмы?

— Башкача мөмкин түгел. Кара әле, Алкин,— Тупиков тавышын баса төште,— исемдә вакытта әйтеп калыйм. Зариф кайтса, болай диген...

Кинәт камераның ишеге ачылып китте, алжыган, мышнаган надзиратель башын такты:

— Тупиков мондамы?

— Монда.

— Уф алла!— Надзиратель гыжылдап сулап, ишекне ачып җибәрде: — Син сволочьны коридор бетереп эзләп йөрим, үз камераңны белмисеңмени?

— Үзең керттең ләбаса.

— «Үзең, үзең»! Сез монда төрмә тулы, ә мин — бер ялгызым. Әйдә тор, чык!

— Я, хушыгыз! — Тупиков, кулларыбызны каты итеп кысты да чыгып китте.

Тимер ишек шап итеп ябылды.

Алкин түбәндәге сәкегә, Бәһаутдинов урынына сузылып ятты. Мин икенче катка менеп киттем. Урын барда йоклап алырга иде. Сорау алудан кайтсалар, утырырга да урын калмас. Күзләремне йомдым, әмма йокы юк. Уйлар, уйлар. Бал корты төсле мыжылдыйлар. Бу ни хәл, ә? Армиядән кайтуыма әле дүрт ел да юк. Мин өч ел Казанда Беренче татар полкында хезмәт иттем. Полкның командиры Тупиков, комиссары Иманкулов иде. Мин аларга сокланып карый идем. Алар икесе дә Гражданнар сугышында катнашкан, каннарын, җаннарын аямыйча, Совет хөкүмәте өчен сугышкан кешеләр. Иманкулов Зарифның күкрәгендә Кызыл Байрак ордены. Аны Реввоенсовет председателе иптәш Фрунзе үзе бүләкләгән — Төркестанда басмачылар белән сугышта күрсәткән батырлыклары өчен. Ә хәзер? Алар икесе дә төрмәдә. Нигә? Нигә? Артык арылган, ахрысы, күзләрем йомылып китте.

Зәйтүнә белән утырып көймәдә Кабан күлендә йөзә идек. Мин мандолина уйныйм, Зәйтүнә җырлый, «Агыйдел» көенә, минем шигырьне җырлый:

Агыйдел алкын икән,
Сулары салкын икән;
Агыйделкәй кызларының
Йөрәге ялкын икән.

Зәйтүнә кинәт җырны бүлә дә миңа карый — бармак яный.

— Ә син каян беләсең?

— Нәрсәне? — Аптырап ишүемнән туктыйм, төшенмим.

Зәйтүнә бик җитди.

— Ник, үзең язгансын бит. Агыйдел кызларының йөрәге ялкын икән, дип. Кем әйтте? Я, җавап бир әле?

Мин көләм.

— Кем булсын. Синең йөрәк. Бөре кызының йөрәге.— Үзем, ишкәкләремне ташлап, аның иреннәренә үреләм.

Шул чак көймәбез чайкалып китте.

...Ниндидер шау-шудан сискәнеп, күзләремне ачтым. Камерадагылар барысы да торып утырганнар — үрелеп тыңлыйлар. Алкин ишек төбендә колагын ишек ярыгына куйган.

Мин дә торып утырдым.

Коридорда тагын ниндидер ыгы-зыгы. Ашыгып атлап, коридорны дер селкетеп, әле бер, әле икенче якка узалар. Берәү, икәү генә түгел, күбәүләр. Пышылдап сөйләшкән, сүгенгән тавышлар. Инде бит таң алдыдыр. Бу нинди вакытсыз ыгы-зыгы? Барыбыз да сулыш алуны кисеп тыңлыйбыз: нәрсәгә бу хәтле йөгерешәләр анда — коридорда?

Кинәт безнең камераның ишегендәге йозак та шалтырады. Алкин парашага таба авышты. Әллә инде сорау алудан китерделәр. Йөрәк сызлана, сыкрый, сыгылып-сыгылып китә.

— Дөп-дөп! Дөп-дөп!

Бу нинди тавыш? Дөп-дөп... Чү, бу бит минем үз йөрәгем шулай тавышланып суга — тынычсызлана. Ярсый. Әйтерсең лә, менә-менә ниндидер коточкыч фаҗига булырга тиеш. Йозак тагын шалтырады. Ишек тартылды. Берничә дагалы итек допылдап килеп туктады. Китерделәр. Мөгаен, сорау алуда изгәннәр, култыклап китерделәр...

Пышылдау. Ишек каты итеп этелде. Дагалы итекләр дөп-дөп итеп алдагы камераларга таба уздылар. Алкин тагын ишек төбенә чүгәләде.

— Каршыдагы камера ачылды,— ди ул.— Бер, ике, өч... Өч кешене алып чыктылар.

Ишек шыгырдап ябылды. Йозак шалтырады. Алты пар аяк адымы түбәнге катка төшә торган баскычка таба кузгалды. Дөп-дөп. Пышылдау. Кинәт «күз» ачылып китте. Ялгыз акайган бәбәк кадалып карады да акырып җибәрде:

— Ятыгыз, контрлар!

Ишеккә ике тапкыр типтеләр. Тагын теге карлыккан тавыш колакны тондырды.

— Ятыгыз, дим, этләр, ятыгыз!

Барыбыз да сәкегә сузылдык. Аяк тавышлары ераклашты. Коридор тып-тын булып калды.

Без дә тынычлана башладык. Әмма игътибарыбыз әле һаман ишектә. «Күз» ачылды да ябылды. Алкин әле һаман бусагага чүккән килеш тыңлый. Тынлык. Инде ул да арып, китәргә дип кузгала башлаган иде, баскыч ягыннан ашыгып атлаган дагалы итекләр тавышы ишетелде. Якынлашты. Узды. Туктады.

— Сизәсезме,— диде Алкин,— үлем камерасына килделәр.

Барыбыз да сикереп торып утырдык. Сулыш киселде, йөрәк тибүдән туктады. Ни була? Нинди җинаять эшләргә җыеналар анда, бәйрәм алды таңында?

Шыгырдап каршыдагы үлем камерасының ишеге ачылды. Корыч тавыш чыңлап китте. Мөгаен, ашыгып кергәндә штыклар бер-берсенә сугылдылар. Ишек шыгырдап ябылды. Тынлык. Үлемгә хөкем ителгәннәрне киендерәләр иде, ахры. Ишек ачылды. Ыгы-зыгы. Баскыч ягыннан тагын берничә пар дагалы итек бу камерага таба ашыгып атлады. Ыңгырашу. Ниндидер кагылу-сугылу. Өстериләр иде, ахры. Кемдер гөп итеп идәнгә егылды. Тагын ыгы-зыгы.

— Ип-тәш-ләр... Буа-лар...

Җан тетрәткеч ачы тавыш бөтен төрмәне телгәләде. Әйтерсең лә, ток сукты. Барыбыз да сәкедән сикереп төштек. Ишеккә өелдек. Коридордагы ыгы-зыгы көчәйгәннән-көчәя бара. Сугылу, гөрселдәү, ыңгырашу, чырылдау. Тынлык. Аяк адымнары. Кузгалдылар.

— ...Ип-тәш-ләр,— тагын гырылдап, буылып чыккан тавыш.— А... атар-га а-лып ба-ра-лар... Без га-еп-сез... Сталин... Сталинга...

Тавыш гырылдап киселде.

Нижегородцев ике кулы белән ишекне кыйный башлады:

— Сез нишлисез, палачлар!

Күрше камераларның да ишекләренә типкәли, кычкыра башладылар.

— Палачлар!

— Сталинга язабыз!

— Бүген Октябрьгә егерме ел тула, ә сез большевикларны атасыз!

Шау-шу. Дөбердәү. Акыру. Бөтен коридор, бөтен Пләтән төрмәсе дөрләп кабынды-кузгалды, гөр килде.

Ул арада тагын коридордан ыңгырашу, буылып, гырылдап чыккан тавыш:

— Яшә-сен... Ста-лин!...
— Сук авызына!
— А-а...
Коточкыч ыңгырашу.
— Авызына чүпрәк тыгыгыз.
Тагы алышу. Бернична кеше тартышып барып идәнгә егылды, күрә-сең. Коридор селкенеп киткәндәй булды.
Төрмә артында мылтык аткан тавыш ишетелде.
Этләр буылып-буылып өрә башладылар.
Без барыбыз да ишеккә барып ябырылдык.

## X

Ниһаять, зарыгып, сабырсызланып, өметләнеп көткән бәйрәм көне. Октябрь революциясенең егерме еллык тантанасы көне — жиденче ноябрь.

Бу иртәдә беренче сюрприз — безнең камераны иртәнге баландадан мәхрүм итү булды. Үткән кичке баланданы бирмәүне дә онытa алмый идек әле. Менә сиңа кирәк булса — «бәйрәм бүләге».

Болай да буш корсаклар тагын кысылды һәм быкырдап-кычкырып ашарга сорады. Ә баланда мичкәсе бүген безнең камера янына туктaлмады.

Сәбәп?

Сәбәбе дә аның әллә ничек, ак күңеллелектән, беркатлылыктан килеп чыкты.

Гадәттәгечә, бүген иртә белән дә йокыдан торырга (кем йоклады икән бу фаҗигале төндә!) чаң суктылар.

— Даң-доң! Даң-доң!

Без әле урыннардан сикереп торырга өлгермәдек, ишек ачылды, ашыгып төрмә башлыгының ярдәмчесе килеп керде.

Ул көндәгечә бик пөхтә киенгән — киеменең бер җирендә җыерчык юк. Җиңел, шат, күркәм, рәхимле, мөгаен, бәйрәм тәэсирендәдер. Без дә җиңеләеп киттек. Камера яктыргандай булды. Мин үземнең беркатлылыгым белән ул әле безне бүгенге олы бәйрәм, Октябрьнең егерме еллыгы белән тәбрик итәр, дип тә өметләнгән идем. Аныcы ук булмады. Алай да, ул бүген башка вакыттагы кебек ачулы кычкырмады, елмаеп кына эндәште:

— Әйдәгез, барлашып алыйк.

Без өйрәнгән гадәт белән параша янына кысылдык. Көяз түрә бармагы белән һәрберебезнең күкрәгенә төртеп санады — сәкегә чыгарды.

— Бер, ике, өч... уналты.

— Башкалар сорау алуда, гражданин начальник,— дип рапорт бирде камера старостасы Алкин.

— Бик яхшы,— диде ул елмаеп, кесәсеннән блокнотын алды, язарга омтылды — карандашы юк. Әле бер, әле икенче кесәсен актарды — борчылды.

— Ах, шайтан алгыры, кабинетта онытып калдырганмын,— ул үтенү белән безгә карады.— Бәлки, берәрегездә карандаш кисәге бардыр?

Әле генә сорау алудан кайткан Галимҗан ага Нигъмәти аның янында тора иде. Ул карашны үзенә кабул итте. Уңайсыз хәлдә калган түрәгә ярдәм күрсәтергә ашыкты.

— Миндә бер бик кечкенә генә карандаш кисәге бар иде...

Бу сүзләрне ишетүгә, Алкин калтыранып китте, күзләре белән Нигъмәтигә ниндидер ишарәләр ясады. Әмма Нигъмәти аңа игътибар итмәде.

— Менә, менә,— көяз түрә хәтта нелә төште, елмаюдан бите

балкып китте. Без дә елмайдык,— нинди әйбәт, үз кеше.— Миңа кеч-кенә булса да ярый.

Галимҗан ага Нигъмәти чалбарын ычкындырып ыштан бөрмәсен-нән кичә Алкин алып кайтып биргән карандаш сыныгын алып бирде.

— Рәхмәт, коткардыгыз,— түрә блокнотына барлау санын язды да теге карандаш сыныгын кесәсенә салып куйды.

— Гражданин начальник,— Галимҗан ага хәтта кулын сузды.— Сез ялгыштыгыз...

— Юк,— диде түрә рәсми һәм коры гына. Шундук йөзе дә ага-рып, суынып китте:— Бу карандаш монда урлап алып килengән. Аны миңа тапшыруыгыз өчен, профессор әфәнде, сезгә күп рәхмәт. Ә камера, тәртипне бозган өчен, карцер режимына куела. Надзиратель, әмерне алырсыз. Пока иртәнге ашны бу камерага бирмәгез.

Ул, кергәндәге кебек үк, ашыгып атлап чыгып китте. Ишек ябылды. Камерада хушбуй исе һәм тирән ачыну калды.

— Сволочь! — Сорау алудан кайтуга аскы сәкедә керпе төсле бөгәрләнеп ятып, камерадагылар белән ләм-мим сөйләшми торган тәбәнәк юан кеше — район прокуроры, берәү үзен тибеп җибәргәндәй, чәчрәп сикереп торды да Галимҗан агага сугарга кизәнде:— синең аркаңда ач калдым!

— Акрын,— якында гына торган Сөббух Рафиков тегенең кулын тотып калды, этеп җибәрде.— Син генә түгел, барыбыз да ач. Галим-җан ага әнә үзе дә нишләргә белми...

Чыннан да, Галимҗан ага битен ике кулы белән каплап, бөгелеп төшкән иде.

— Син, малай, миңа кул сузма,— прокурор тагын әтәчләнә баш-лады.

— Кул сузу түгел,— Сөббух кызарынып-бүртенеп, аңа таба үрелде,— буып үк ташлармын.

— Каравыл! — Прокурор акырып ишеккә ташланды.— Каравыл, ишекне ачыгыз!

«Күз» чайкалды, аннан акайган сыңар бәбәк карады. Ишек ачылды.

— Нигә акырасың?

— Үтерәләр.

— Ха-ха...— надзиратель кычкырып көлә башлады.— Юк, үтергәндә болай кычкырмыйлар, прокурор әфәнде...

— Мин... мин... честный. Мондагылар барысы да дошманнар, халык дошманнары.

— Утыр яхшы гына,— надзиратель чыннан да керпе сыман тырпай-ган, коридорга чыгарга омтылып, төкерекләрен чәчә-чәчә пышылдаган прокурорны этеп җибәрде.— Кем честный, кем юк — аны тикшерү ачык-лар. Кит!

Прокурор идәнгә тәгәрәде. Кемдер арттан аяк чалды, ахрысы. Ишек ябылды. Прокурор киредән урынына менеп ятмакчы иде, шау-шуга уян-ган Камай (ул әле таң алдыннан гына сорау алудан кайткан иде) прокурорны җилкәсеннән алып күтәрде дә, арт ягына тибеп, сәке астына кертеп җибәрде.

— Ят шунда, чыксаң, инде чынлап үтерәм,— диде тыныч кына.

Бераздан ишек ачылып, таныш булмаган берәүне керттеләр. Күн тужурка, шундый ук күн фуражка кигән. Аякларында балтырларын кысып торган, күннән эшләнгән куныч — крагилар һәм сары ботинка-лар. Яшь егет. Йөзендә ару, борчылу. Аңа прокурорның урынын бир-деләр. Егет берәүгә дә карамыйча, эндәшмичә, күрсәтелгән урынга утырды. Бераздан Алкин аның янына килеп:

— Син кайдан, иптәш? Нинди яңалык? — дип сүз башлады.

— Яңалык чамалы,— диде егет теләр-теләмәс кенә башын күтә-реп:— Бүген төнлә мин бер укытучы белән утырдым. Әлмәттән. Аны Атласов төркемендә судлыйлар икән.

— Нәрсә, инде суд та башланганмы?

— Инде икенче көн. Менжинский клубында трибунал хөкем итә, ди. Ябык суд. Берәүне дә кертмиләр. Клуб солдатлар, этләр белән саклана. Менә шул укытучы гаҗәпләнеп, хәвефләнеп сөйләде.

Мин дә, башкалар да, югары сәкеләрдән төшеп, крагилы егет янына өерелдек. Сөббух «күз»не капларга басты.

— Һади Атласов инде алтмышның аръягында булуына карамастан, таза, нык, җиңел сөякле, хәрәкәтчән кеше. Ул инде бер срок утырып кайткан. Соңгы елларда Бөгелмәдә укытучы булып эшли иде, ди. Үзе бик нәзакәтле, тәрбияле, югары белемле галим. Француз, немец, инглиз телләрендә яхшы сөйләшә, китаплар тәрҗемә итә иде, ди.

— Әйе, әйе, беләбез,— диде Камай ага,— талантлы кеше. Шуннан...

— Трибунал аны Бөгелмәдә контрреволюцион оешма төзеп, Совет хөкүмәтен җимерүгә әзерләнүдә гаепли. Бу оешманың актив членнары дип, Бөгелмәдән, аның тирәсендәге авыллардан алтмыштан артык мулла, мәзин, укытучыларны кулга алганнар. Минем янымда утырган укытучы да шул исәптән икән. «Дөресен әйткәндә, Һади аганы судта гына күрдем»,— ди үзе. Атласов судта менә ничек сөйләде, ди: «Бөек Ленин вафат булганнан соң, бигрәк тә соңгы елларда, Сталин милли сәясәтне Маркс-Энгельс тәгълиматларыннан ераклаштыра бара. Милли кадрларның үсүенә, аларның мөстәкыйль фикер йөртүләренә киртә куя. Совет илендәге көнчыгыш халыкларының гарәп алфавитыннан латинга күчүләрен алкышлап, Владимир Ильич: «Бу тарихи вакыйга — көнчыгыш халыкларын бөтен дөнья культурасына алып чыгуда күпер»,— дигән иде. Ләкин ул бу бөек борылышны үз күзләре белән күрә алмыйча калды. Әмма көнчыгыш халыклары, аның васыятьләрен истә тотып, аңа рәхмәт укыйлар һәм латин хәрефен киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә — укытырга көч салалар. Ә Сталин, һичбер нигезсез рәвештә, тагын алфавит алыштыру мәсьәләсен күтәрде һәм инде мәҗбүри рәвештә тормышка ашыра. Бер кеше гомерендә совет көнчыгыш милләтләре инде өченче алфавитка күчәләр. Безнең халыкның күбесе болай тик-томалдан надан калачак. Шулай ук телләрнең тууы, үсеше турындагы Сталинның соңгы тезислары Маркс тәгълиматына капма-каршы», дигән. Бу урында Атласов, немец һәм инглиз телләрендә Маркс хезмәтләреннән цитаталар китереп, үз фикерләрен дәлилләгән.

— Молодец,— диде кемдер, урта сәкедән.

Сөйләүче аңа игътибар итмәде, дәвам итте:

— Ахырда ул сүзен болай тәмамлаган: «Әгәр иптәш Сталинның кайбер фикерләре белән килешә алмау җинаять икән, мин сезнең хөкемдә. Әмма мин Совет дәүләтен җимерергә әзерләнмәдем һәм контрреволюцион оешма булдыру нияте белән мавыгу җүләрлегенә барып җитмәдем. Чөнки мин үзем хәл кадәре бу хөкүмәтне урынлаштыру өчен көрәштем, корал белән чехларга каршы сугыштым. Тарих — шаһит».

— Дөрес. Атласов Колчак тылында безнең өчен эшләде һәм бик кирәкле данныйлар бирде,— диде комиссар Имәнкулов.

— Бүлмәгез әле! Шуннан?

— «Әгәр дә,— дигән Һади ага, өстәл артындагы трибунал членнарына карап,— әгәр дә уйдырма гаепләү актыгызда күрсәтелгәнчә, мин контрреволюцион оешма торгызырга, Совет хөкүмәтен җимерергә уйлаган булсам,— тагын кабатлыйм, андый ният миндә булганы юк,— кемнәргә, нинди көчләргә таянган булыр идем? Гафу итегез, ярты ел нахакка төрмәдә утыруыма да карамастан, мин әле үз акылымда. Әгәр ул кара юлга бассам, сез алдыма китереп бастырган мулла-мунтагайларга түгел, яшь көчләргә таянган булыр идем. Шуның өчен, бу акылга-аңга сыймый торган уйдырма төркемне миңа бәйләмәгез. Мин аларны белмим, белергә дә теләмим». Ул укытучыны бүген тагын судка алып киттеләр. Мине...

Кинәт каерып ишек ачылды. Әңгәмәгә мавыгып, вакытның узганын да сизми калганбыз. Йозак шылтыраганын да ишетмәгәнбез.

— Төшке аш.

— Исебез китте. Ишек төбендә — ризык кисмәге. Пар чыгып тора — чумар. Аның исе дә борынны кытыклый. Инде тәүлеккә якын корсак буп-буш — «корыга» эшли бит. Кызыл балчык чүлмәкләр бирәр чүмеч баланда белән кулдан-кулга күчә башладылар. Миңа да чират җитте. Чүлмәк кулга тиюгә чөмерә башладым. Төбендә кашык белән бутарлык бер чумар да юк иде. Әллә чөмергәндә йотып куйганмын, тоймаганмын, әллә инде чумарның җисеме түгел, исеме генә булган. Иң соңгы чүлмәккә прокурорны тартып чыгардылар. Әмма ул чүлмәкне алуга тагын мүкәләп сәке астына кереп китте.

Тамак ялгаганнан соң теге крагилы егетне дә алып чыгып киттеләр. Ул Татпрофсоветта физкультура-спорт бүлеге мөдире булып эшләгән ди. Аңа да «корткычлык» ямаганнар. Әллә көләргә, әллә еларга?

Кичке аш алдыннан торбаны шакыдылар. Алкин «Бестужев әлифбасы»на күчте, идәнгә чүгеп, торбага колагын куйды һәм аннан килгән хәбәрне иҗекли башлады. Сулышны өзеп, Алкинга төбәлдек:

— Три-бу-нал Ат-ла-сов-лар тәр-ке-мен...— хәбәрне тапшыручы бу җиргә җиткәч, пауза эшләде... Әллә инде «күз» комачауладымы.— Атласовның үзен дә а-тар-га хө-кем ит-кән...

Алкин, хәбәрне әйтеп бетерер-бетермәс, идәнгә утырды. Электр тогы суккандай катып калдык. «Күз» чайкалды. Ачылды. Кан баскан ачулы бәбәк карый.

Йөрәк тибүдән туктады сыман. Күзләремә яшь килеп тыгылды.

— Я, алла, бу нинди бәйрәм бу?

Сабырсызланып, өметләнеп, соңгы ышанычларны бәйләп, дүрт күз белән көткән бөек бәйрәм — Октябрьнең егерме еллык тантанасы үтте дә китте. Ашыгыч процесслар, атулар, көне-төне туктаусыз сорау алулар, кыйнаулар, гарипләндерүләр, мәсхәрәләүләр белән узды. Ә без көткән, ышанып көткән амнистия телгә дә алынмады. Киресенчә, бәйрәм көннәрендә камерага яңадан-яңа арестантларны тыгызлап тутыра башладылар. Болар инде «өченче дулкын» кагылганнар. Өченче секретарь, өченче председатель, өченче зав, өченче ректор, өченче директорлар. Алар әле үзләре башкарасы эшнең эчтәлеге-юнәлеше белән танышу түгел, яңа кабинетларының нинди булуын хәтерләп калырга да өлгермәгәннәр.

Тукта, юкка зарланам бит, бәйрәмнең очы — ризыгы, соңга калып булса да, безнең камерага да килеп җитте ич.

Бу сөенечле хәл унынчы ноябрь көнне кичкә таба булды.

Камерада аеруча авыр бер тынлык иде — кайсы ятып, кайсы утырып-калгып уйга чумган. Пыяла күзләре ватылган рәшәткәле тәрәзәдән суык җил өрә, калфакка кар өя. Хәзер инде камерада ялангач берәү дә юк. Кемнең нинди киеме — чүпрәге бар, шуңа уранган. Төшке баланда инде корсакка кергән булуга карамастан, ул һаман буш. Төшенеп бетә алмыйсың, шундый вакытта тоткынның уенда әллә ирек, әллә ризык күбрәк урын ала. Менә шуның өчен сөйләшәсе килми — рәнҗүле тынлык.

Йозак шалтырады.

Төрмәдә утыра торгач, үзенең язмышына күнегә башлый тоткын, шулай булырга тиеш сыман. Ә менә чаң тавышына, йозак шалтырауга һич күнекми. Нәкъ беренче ишеткәндәге кебек, бар гәүдәсе белән чиркаnып, калтырап китә һәм сулышы киселә — ни була? Хәзер дә шулай сискәнеп, калтырап торып утырдык.

Ишек ачылды.

Гаҗәп! Ишектән кеше түгел, зур бер капчык керә башлады. Гомердә күрмәгән хәл — төрмә, камерага иләмсез зур капчык керә. Аптырап

калдык — ни булыр? Берәр хәтәр булмаса ярый инде. Төрмәдә һәрнәрсәгә шикләнеп карыйсың бит.

Менә капчык шыгырдап камерага керде, шап итеп идәнгә утырды. Аның артыннан капчыкның хуҗасы күренде. Әллә инде кыш бабай. Менә сиңа кирәк булса, берсеннән-берсе гаҗәбрәк. Бөрмәле ак тун, озын колаклы куян бүрек. Ак йоннан басылган киез итекләр...

Ишек ябылды.

— Исәнмесез, иптәшләр,— диде көр тавыш һәм куян бүрек селкенеп куйды, тирә-якка кар чәчрәде.— бәйрәм котлы булсын.

Камера аптыраудан телсез калды.

Ниһаять, куян бүрек баштан кулга күчте. Урта яшьләрдәге түгәрәк йөзле ир. Сары чәч. Зур яшькелт күзләр. Үзе бик тыныч күренә. Тагын көр тавыш.

— Нигә сәламне алмыйсыз? Менә сезгә бәйрәм күчтәнәче алып килдем,— кунак иелеп, капчыкның авызын бәйләгән җепне ычкындырып җибәрде, бүлмәгә тәмле икмәк исе аңкыды.— Староста бардыр сездә? Мә, бар, иптәшләргә дә бүлеп бир. Бәйрәм ашы тигез булсын. Мәгез.

Алкин алгарак чыгып кул бирде.

— Таныш булыйк, бу камераның старостасы Алкин.

— Тукта, тукта әле,— кунак Алкинның кулын җибәрмичә селеккәләде,— кара әле, син теге Казан шәһәр комитеты секретаре түгелме, күрермен, дип уйламаган идем,— көлеп тә җибәрде.— Ә бит «Кызыл Татарстан»да үзеңне бик селеккәләгәннәр иде, корткыч дип. Үзең болай...— ул бик җентекләп-игътибар белән Алкинны баштанаяк карап чыкты,— үзең болай корткычка охшамыйсың... Ха-ха! Ха-ха!

Камера бердәм шаркылдап көлеп җибәрде.

— Ярар, егетләр, башта тамак ялгап алыгыз, кая, менә бу сәкегә төшерик. Берәр нәрсә җәегез әле...— Сөббухның одеалы яңарак, тазарак икән, ул шуны сәке буена җәеп җибәрде. Хуҗа капчыкны шунда аударды. Күзләр дүрт булды: ап-ак күмәчтән киптерелгән сохари, түгәрәк тукачлар. Гәрәбә сары өрек төсле бавырсаклар тау булып өелделәр.

— Рәхим итегез. Хәзинәдә бары.

Менә бит көтмәгәндә...

Алкин — староста авыз сулары корып, күчтәнәчне «кортлап» торган без тоткыннарга әүвәле берәм-берәм сохарины, тукачны, бавырсакны өләшеп чыкты, аннары шуны сорау алудан тагын урлап кайткан карандаш үзәге белән учына язды. Һәрбер ризыкны егерме дүрткә бүлде, сорау алырга чакырылган иптәшләрнекен аерым алып куйды.

Ниһаять, корсаклар чын-чынлап тулдылар. Үзебез дә туендык. Әмма, нәфес — шайтан, диләр бит, туюын туйсак та, күңел туймый, кесәләргә — алдагы көннәргә дип яшереп куйган сохариларны да андасанда «урлап» алып кетердәтәбез.

«Кыш бабай», колакчын бүреген, тунын салып ташлап, сәкегә утырды да, безнең сөенә-сөенә кетер-кетер китерүгә куанып, сорашканны да көтмәстән, көр тавыш белән сөйләп китте:

— Мин Мөхәммәтгали Мөхәммәтзариф улы булам. Район башкарма комитеты председателе идем. Гөнаһ шомлыгы, июль аенда «Кызыл Татарстан» газетасында «Корткычлар» дигән мәкалә чыкмасынмы. Шунда менә мине дә телгә алганнар. Бу газета районга килеп житүнең икенче көнендә абзагызны райкомга чакырдылар да, әүвәле партбилетны алдылар, аннан эштән «азат» иттеләр. Өйгә кайттым да, «Гөлҗиһан, җаным,— мин әйтәм,— әйдә хәзерлән. Сохари киптер. Анда әллә ни сыйламыйлардыр. Андагы дус-иш тә йөрәк ялгар, мулрак булсын, дим. Инде Казанда безнең ике райком секретаре, ике башкарма комитет председателе һәм аларның урынбасарлары, шулай ук районның башка житәкчеләре утыралар иде. Әлхасил, шулай булгач, мине алуларына шик-шөбһә юк иде...

— Авылдашларыгызны очратмадыгызмы әле? — диде Сөббух, авызындагы тукачны кетердәтеп.

— Юк. Юк, энем,— дип бик рәхәтләнеп елмайды кунак.— Иншалла, очратырмын әле.

— Бүлдермәгез инде, кешегә сөйләргә ирек бирегез. Шуннан?

— Карчык минем зиһенле җан. Укытучы. Аларны да «чүпләделәр» бит. Артык тавыш-тын чыгармыйча гына пешеренә башлады. Ул пешерә, мин турап мичкә куям. Төн җиттеме — кетәбез. Әнә киләләр, менә киләләр. Йокыдан калдык. Менә шулай көтә торгач, дүрт ай үтте.

«Карчык, мин әйтәм, әллә капчыкны күтәреп, үзем барыйммы икән, бик зарыктырдылар»,— дип омтылып та куйгаладым. «Кит, җүләр, өйдә утыру туйдырдымы? Бәлки, синең бәхеткә, безнең бәхеткә кулга алулар туктар»,— ди. Шулай итеп тынычландык. Бәйрәм җитте. Бәйрәмдә инде кузгатмаслар, дибез.

— Бәйрәм ничек узды, Мөхәммәтгали абзый? — диде Сөббух.

— Ничек дим, дус-иш безгә керергә шүрли. Газетада исемем аталгач, билгеле инде, халык дошманы булабыз. Без аларга керергә базмыйбыз. Кәсәфәтебез тиеп-нитеп калмасын дип. Карчык белән берәр йөзне төшереп, кочаклашып кына яткан идек, ишекне шакыйлар бит хәерсезләр...

Без көлешә башладык.

Ул арада стенага чиртә башладылар. Мөхәммәтзариф улы Мөхәммәтгалинең әңгәмәсе өзелде. Алкин, кружкасын алып, «телефон»га күчте.

— ...Га-лим-җан Иб-ра-һи-мов ка-ты а-вы-рый. Төр-мә больни-ца-сына сал-ды-лар...

— Воль-фо-вич ял-ган по-ка-за-ние-ләр би-рә...

— То-лым-бай-ский доп-рос-та а-кыл-дан яз-ган.

— Ка-юм Аб-ра-мов [1] доп-рос-тан чык-кан-да бас-кыч-тан таш-лан-ган.

— Мө-хәм-мәт-җа-нов про-во-ка-тор.

— Бү-ген ун ке-ше-не ат-ты-лар.

Тек-тек, тек-тек... «Бестужев» тәүлек буенча тынмый — берсеннән-берсе авыр, шомлы, хәвефле хәбәрләр биреп кенә тора.

Камера ишекләре ачыла да ябыла.

Сорау алырга. Сорау алудан.

## XI

Яңа ел алды төне.

Ниндидер серле, тылсымлы ул. Кем генә булмасын, ирме, хатынкызмы, яшьме-картмы, һичшиксез, бу төндә ул кинәт тукталып кала — уйлана, хыяллана, өметләнә. Алдагы туасы уникe айда, алай гына да түгел, нәкъ менә шушы төн уртасында, яңа ел туган минутларда, ниндидер бер могҗиза пәйда булыр — «күк капусы» ачылыр да барлык теләкләр кабул булыр төсле. Бер кешегә генә түгел, күп кешегә, бар адәм баласына, бөтен җиһанга, галәмгә. Шуның өчен һәрбер кеше бу төндә, бигрәк тә сәгать уклары уникегә якынлашканда дулкынлана, каушый һәм... әле булмаган, әмма булачак, һичшиксез, булачак сөенеч өчен елмая!

Тиздән 1938 ел туачак.

Бөтен камералар, бөтен төрмә хәзер шушы тантаналы, тылсымлы мизгел алдында.

Тиздән... Утыз җиденче ел капкалары ябылып, яңа елга аяк басабыз. Тиздән...

[1] Каюм Абрамов — Татарстан халык комиссарлары советы председателе.

Утыз жиденче ел бөтен ниятләрне туздырып ташлады. Барлык якты өметләрне туплап, ашкынып, ашыгып көткән бәйрәм — Октябрьнең егерме еллыгы тантанасы да узып китте.

Өмет өзелде.

Юк, өзелми икән ул тоткын өмете. Аның бүгенге көне нинди генә авыр, фаҗигале булмасын, ул әле иртәгә якты сибеләсенә ышана.

Нигә?

Бу сорауга һичбер мәхбүс-тоткын җавап бирә алмый. Чөнки аның ышандырып-инандырып әйтерлек дәлилләре юк. Әмма ул ышана, күңеле белән, җаны-тәне белән инана, өметләнә.

Ул көн килер.

Ирек-азатлык килер, һичшиксез, менә бу туасы елда. Яңа елда!..

Тиздән Кремль куранты даң-доң итеп уникене тапкыр сугар да Советлар Союзы Гимны яңгырар. Ирекътәге кешеләр бу мизгелдә шатланып шәраб тулы бокалларын күтәрерләр һәм бер-берсенә бәхет теләрләр.

Йозак шалтырады. Шыгырдап-чинап ишек ачылды һәм кемнедер камера эченә этеп кертеп җибәрделәр. Ул идәнгә капланып төште. Мин, үзем дә сизмичә, сикереп төшеп, идәндәге кешене күтәреп сәкегә утырттым.

— Мәхмүт... Мәхмүт, бу синме?

Нижегородцев йөгереп килде. Икәүләп күтәреп аны урынга салдык.

Мәхмүт Баһаутдинов, нәрсәдер әйтергә теләп, авызын ачкан иде — авызыннан кара кан атылды.

Бераздан тагын ишек ачылды, көчкә-көчкә атлап Алкин керде.

Бу камерага килгәннән бирле, мин аны беренче тапкыр шундый хәлсез, ватылган хәлдә күрәм. Күз төпләре кара янган.

— Мөхәммәтҗанов белән йөзгә-йөз китереп сорау алдылар,— диде Алкин, бераз утырып исен җыйгач.— Ул, күзен дә йоммыйча: «Ни язсалар, шуңа кул куй. Оешма исемлегенә кешеләрне күбрәк язарга тырыш. Ни хәтле күп кешене бутасак, шул хәтле тизрәк тикшерерләр»,— ди хаин. Үзем утырган урындыкны алып башына суктым. Шуның өчен мине изделәр. Су... су... бирегез әле...

Камерада нинди су?

Мин ишекне кыйный башладым. Рәхимле бер надзиратель икән, бер кружка су бирде. Алкин бер-ике йотты. Калган су белән Мәхмүтнең битен юып, аның беразын авызына тамыздык.

Ә тәрәзә артыннан ерактан Кремль сәгатенең сукканы ишетелде.

Бераздан Лебедев-Кумачның «Нинди иркен минем туган илем» җыры яңгырады:

> Я другой такой страны не знаю,
> Где так вольно дышит человек...

## XII

Башта, бу камерага кергәннең беренче көннәрендә, мондагы тоткыннар барысы да бер төсле, авыр язмышларын бердәй кичерәләр-хафаланалар, дип уйлаган идем.

Алай түгел икән.

Әйтик, менә Алкин. Ул ничектер бу язмышына һич бирешми, алай гына да түгел, камерадагы башка мәхбүсләрне дә моңа игътибар итмәскә, күңел төшенкелегенә бирелмәскә өнди. Кайчан гына булмасын, хәтта сорау алудан кыйналып-ватылып, хәлдән таеп кайтканда да, аһ-ваһ килеп, камераның рухын төшерми, эченнән кичерә. Хәл алу белән, «җәмәгать» эшенә тотына. Я хәбәр ала, я үзе башка камераларга яңа ишеткән хәбәрләрен тапшыра. Я «балык ауларга» тотына.

Папирос кәгазенә берәр хәбәр яки берәр сорау язып, шырпы кабына сала да җеп белән тәрәзәдән түбән камера калфагына төшерә яки шундый ук почтаны ала. Ул эш тә бетсә, мәзәк сөйли башлый — грузин, әрмән, яһүд, украин акцентлары белән. Көлә-көлә эчең ката.

— Ибраһим, ашыкма, сабыр ит. «Сабыр төбе — саф алтын», дип, борынгылар белмичә әйтмәгән...— ди Галимҗан ага Нигъмәти бик акрын пышылдап кына. Нәкъ кафедрадагы кебек тыныч һәм ягымлы итеп. Ул урыннан тормый, ятып, күзләрен йомып уйланырга ярата. Нәрсә уйлый торгандыр инде ул көне-төне.

Тәбәнәк, чандыр, әмма хәрәкәтчән Гомәр Гали:

— Юк, бу һич мөмкин түгел. Монда бер корткычлык бар. Моны иптәш Сталинга җиткерергә кирәк,— дип көннәр буе ишек төбендә надзирательләрдән кәгазь-карандаш сорый.

— Миңа иптәш Сталинга язарга кирәк,— ди ул, ишек ачылуга. Аны кире этәләр.

— Кәгазь-карандашны следовательдән сора.

Гыйлем Камай:

— Егетләр, вакыт әрәм үтмәсен, мин фән дөньясыннан бер-ике кызыклы мисал китерим,— дип, чыннан да, химия яңалыклары белән мавыктыра. Онытылып тыңлыйбыз.

Мәхмүт Баһаутдинов капланып ята да үз-үзе белән сөйләшә:

— Кайда ялгыштым? Кайда?

Ә теге прокурор бер кешегә дә кушылмый, сөйләшми, сәке астында посып утыра да берәр төрмә хезмәткәре керсә:

— Гражданин начальник, монда барысы да халык дошманнары. Мине монда ялгыш утырткannар. Башка камерага күчерегез,— ди. Елый, сүгенә, ишек кага. Аны инде ике тапкыр ризыктан мәхрүм иттеләр. Тик ул һаман үз «эшендә».

Ардалион Михайлович Нижегородцев туктаусыз елый һәм зарлана:

— Сез төшенмисез. Төрмәгә алыныр алдыннан гына өйләнгән идем. Минем инде балам булырга тиеш. Ә мин аны күрмим. Нигә? Юк, мин бит үз баламны күрергә хаклы! Нинди гаделсезлек бу?

Әхмәт авыз эченнән генә җырлый, сызгыра. Инде берничә тапкыр карцер белән куркыттылар, ә ул һаман җырлый:

Карурманнан чыккан чакта,
Кисеп алдым пар каен...

Яңа ел үтте.

Менә инде җилле-давыллы февраль килде. Сорау алулар көчәйде. Киткәннәрнең күбесе кайтмый. Әллә шулай озак бастырып торалар, әллә башка камераларга күчерәләр, әллә?..

Менә инде Мәхмүт Баһаутдинов та юк. Гыйлем Камай өченче тәүлек күренми. Безне бәйрәм күчтәнәче белән сыйлаган теге «кыш бабай»ны шул ук төнне алганнар иде — әле күренми. Әллә инде безне сөендерер өчен генә килгән Хозер булды микән ул?

Ә «чыбыксыз телефон» һаман тек-тек итеп берсеннән-берсе хәвефле хәбәрләр бирә:

— Га-лим-җан Иб-ра-һи-мов төр-мә боль-ни-ца-сын-да ул-де. Кәрим Тин-чу-рин ач-лык игъ-лан ит-те. Би-шен-че көн па-ек-тан баш тар-та. Мәх-мүт Ба-һа-ут-ди-нов а-кыл-дан шаш-кан. Үт-кән төн-дә е-гер-ме җи-де ке-ше-не ат-кан-нар. Ба-ры-сы да хәр-би-ләр. Га-зе-та-лар-да «и-рек-ле, и-рек-сез дош-ман-нар» ди-гән я-ңа фра-за-лар оч-рый баш-ла-ды...

Яз килде.

Зәңгәр күзле күлләр, елгалар белән, аллы-гөлле чәчәкләр, хуш исле болыннар белән, зөбәрҗәт урманнар, сандугачлы таннар белән яз килде, 1938 елның язы.

Ә төрмәләр? Камералар? Ә мәхбүсләр? Аларга да язмы?

Тимер рәшәткәләр, биек, калын таш стеналар, чәнечкеле тимер чыбыклар, мылтыгын тотып, бертуктаусыз әйләнеп йөргән сакчылар, туктаусыз абалап-улап өргән этләр белән уратылып алынган төрмә артындагы яз бет, бөрчә, кандала тулы тынчу, сасы камераларда тилмереп утырган гаепсездән гаепле мәхбүсләр өчен дә язмы? Алар да яз хисләре белән дулкынланалар микән?

Еракта, Идел-Ослан ягыннан, пароходларның бер-берсе белән очрашып, сәламләшү-хушлашу гудоклары анда-санда ишетелеп, озак яңгырап, күңелләргә сагыш, моң өсти. Очынып, шаярып очкан чыпчыклар калфакка килеп куналар да «чык-чык» дип, тоткыннарны үчекләп китәләр.

Кай көннәрдә җылы яңгыр — ләйсән яңгыры явып үтә. Камерадагы тынчу һава алышынып, күкрәкләр-үпкәләр җиңеләя.

Күңел ярсый, тыпырчына, канатлана һәм оча. Ирекка, Иделгә, өзелеп сагынган изге мәхәббәт кочагына!

Бүген инде унберенче май. Былтыргы бишенче ноябрьдән бирле мин менә шушы Пләтән төрмәсендә. Өченче каттагы тар камерада. Әле бер тапкыр да төрмә ишегалдына атлап чыкканым юк. Әллә оныттылар инде, сорау алырга да чакырмыйлар. Камерадагы мәхбүсләр дә алышынды. Мин кергән вакытта утырган тоткыннарның берсе дә юк. Киттәләр. Кайтмыйлар. Алар урынына башкаларны, яшьрәкләрне — «1938 елгы набор»ны китерәләр. Камерада мин инде карт арестант — староста.

Ә шулай да нигә мине сорау алырга чакырмыйлар икән, нигә?

— Йозак шалтырады. Ишек ачылды.

— «С» хәрефенә кем?

— Салахов Ибраһим Низамович.

— Әйберләреңне ала чык.

Әйбер дигәннәре — итек кунычыма кыстырылган китек агач кашык.

— Хушыгыз, иптәшләр.

Камерадагылар ашыгып кулымны кысалар.

— Хәерле белән.

— Бәлки ирекkәдер.

Мин ишеккә атлыйм. Я хода, нинди язмыш көтә мине алда — яктылыкмы, әллә инде дөм караңгылыкмы?..

## Кояшлы бүлмә

Билгеле инде, мине, түбәнге катка төшү белән, коридорның эченә үк кереп торган ябык машинага — «кара козгын»га этеп тыктылар. Тоткыннарны көне-төне сорау алырга ташучы бу тулаесез таксиның эчке төзелеше миңа бик таныш. Анда кара-каршы өчәр-өчәрдән алты кеше көчкә сыеп утыра торган, бастырып куелган табут төсле, тап-тар бүлмә, тоткыннар керер-кермәс ишек шап итеп ябыла да бикләнә — тын да ала алмыйсың.

Бүлмәләр арасында уртада — сакчы. Мине соңгы, алтынчы табутка тыктылар. Димәк, калган биш бүлмә инде тулган.

Гаҗәеп бер хәл. Әгәр дә адәм баласы маңгай күзләре белән күрү мөмкинлегеннән мәхрүм ителсә, күңел күзләре белән тоеп, күрә башлый икән. Менә мин хәзер дөм караңгыда. Ә шулай да машинаның кайсы җирдән, кайсы якка, хәтта кайсы урамнан баруын беләм-тоям. Менә аз гына барды да туктады. Капка. Шалдыр-шолдыр тимер чыңы — йозакларны ачалар.

Машина капка төбендәге чокырга уң тәгәрмәче белән төшеп китеп көчәнеп чыкты да уңга борылды — Печән базарына таба юл тотты. Шул чак күрше «табут»тан чирткәләп аваз бирә башладылар. Стенага авызымны куеп эндәштем:

— Син кем?

— Галимҗан Мөхәммәтшин.
— Син... син исәнмени?
— Әһе-әһе.
Күршем буылып йөткергәндә машина чаттан борылды — Болак күперенә таба барабыз.
— Бездән Ләбибне, Сөббухны алдылар. Галимҗан Ибраһимов инде яңа ел башында ук төрмә больницасында үлгән. Толымбайский сорау алганда акылдан шашкан Галимҗан Нигъмәти...
— Шыш, контрлар! — ишеккә приклад белән суктылар. Башым чыңлап китте.— Еланнар, монда да пышылдаша башладыгызмы?
Күрше табут ишегенә дә приклад төште.
«Козгын» чинап-улап күтәрелә башлады. Бауман урамын үтеп, тауга — Чернышевский урамына күтәреләбез. Аннары кинәт ашыгып җилдерде — түбән төшәбез. Хәзер машина туктарга тиеш. Шыгыр-шыгыр капка ачылды. Уздык.
— Чык, җәфа!— Конвой табутның ишеген ачты: — Төш, контрик!
Озынлыгы өч, киңлеге ике метр чамасындагы камера. Тәрәзәсе юк, җир астында ул. Түшәмдә челтәр эчендә кечкенә бер лампочка яна. Цемент идәнгә беркетелгән карават. Аның өстендә — киез. Сары одеал, ап-ак җәймә. Ак тышлы мендәр. Аптырап калдым. Сигез ай буе Пләтән төрмәсендә тыгыз камераның идәнендә ятарга урын таба алмый, күп төннәрне ишек төбендә яки параша өстендә калгып үткәргән тоткынга бу урын-җир оҗмах күрсие булып күренде. Караватка утырдым. Тордым. Тагын утырдым, сузылып ятып карадым — нинди рәхәт. Бер кеше кысмый-этми, сүгенми, теләгәнчә сузыл...
Йозак шалтырады. Ишек ачылды. Надзиратель белән бергә камерага ак халат кигән берәү керде. Врач! Ялгыштым, халатлының кулында чәч алу машинкасы. Сигез ай буена бритва күрмәгән сакал-мыек, гәрчә үзем күрмәсәм дә, бер ел мәгарәдә ятып чыккан Әбүгалисинаныкыннан калышырлык түгел иде, мөгаен.
Сакал-мыекны алдырып, җиңеләеп, кәефләнеп утыра гына идем, тагын ишек ачылды.
— Чык! — дип ымлады надзиратель, матур гына яшь егет. Мөгаен, әле күптән түгел генә эчке гаскәр сафына алынган солдат.
Ярым караңгы коридор буенча барып сулга борылдым — ачык ишектән кердем. Душ. Тагын рәхәт: сигез айда беренче тапкыр җылы су белән сабынлап юындым. Бер кат тирем кубып төште, ахрысы. Камерага кайтсам, тумбочкада ике җамаяк. Берсендә итле токмач, икенчесендә — бәрәңге боламыгы белән ике зур котлет йомарламы. Ул гынамы. Күзләремә ышанмыйм, бармакларым белән капшап карадым — өч папирос! Бу нинди җәннәт?
Ниһаять, сигез ай дигәндә кырынып, юынып, этешмичә, төртешмичә, сүгенмичә таза урын-җир өстенә утырып чиста эмаль савыттан ашый башладым. Токмачлы шулпа шундый тәмле, телеңне йотарсың. Әни мәрхүмә шулай тәмле итеп пешерә иде токмачлы ашны. Аштан соң бер папиросны кабыздым. Билгеле инде, монда утырган тоткынга шырпы хәтле шырпыны ышанып бирә алмыйлар. Тимер ишекнең форточкасын шакыдым, коридордагы надзиратель «күз»не ачып карады да, кулымдагы папиросны күргәч, ни гаҗәп, бер дә ачуланмыйча йозакны, ишекне ачты һәм шырпы сызды.
Бу да беренче тапкыр. Әче тәмле зәңгәр төтенне суырган саен җаным рәхәтләнә, башым әйләнә. Нинди рәхәт! Кайгы дигәннең әсәре дә калмады. Мөгаен, мине иреккә чыгарырга әзерлиләрдер.
Тәмәкемне тартып бетереп, төпчеген парашага ташладым да, чишенеп, караватка яттым — бер рәхәтләнеп йоклыйм әле. Мондый йомшак иркен урынга да ятасы бар икән!
Күзләрем эленеп кенә бара иде, шалтыр-шолтыр ишек ачылды һәм шунда ук надзирательнең ачулы тавышы колакны кисте.

— Тор!

Аптырап аягүрә басарга өлгермәдем, камерага хәрби киемдә ике кеше атлады. Алдагысы ишеккә көчкә сыеп, кысылып, бөкерәеп керде. Мәһабәт. Камера тап-тар булып калды. Шинеленең петлицаларында икешәр ромба. Арттагысы аның култык астыннан гына. Петлицаларында — шакмаклар.

— Мин — хәрби прокурор,— диде ромбалы ир калын тавыш белән миңа ачулы төбәлеп.— Жалоба бармы?

— Мин үземнең нигә монда булуымны төшенмим,— дидем исемне җыеп.

— Капитан, сез аңа гаепләү кәгазен бирегез,— диде артта папка күтәреп торган ябык кешегә кырын карап. Теге, папкадан бер бит кәгазь алып, миңа сузды.— Прокурор ишеккә атлады һәм инде миңа бөтенләй карамыйча гөрелдәде: — Укы! Нигә утыруыңны төшенерсең.

Ишек шыгырдап чинап ябылды.

Мин бер генә табак кәгазь дип уйлаган идем — монда машинкада интервалсыз басылган өч битле гаепләү акты. Укый башлауга — чәчләрем үрә торды.

«...Контрреволюцион милләтче оешманың актив члены. Оешма совет хөкүмәтен җимереп, Бөек Туран дәүләте төзергә әзерлек алып барган. Мәкерле максатларына ирешү өчен бу явыз милләтчеләр партия житәкчеләрен, беренче чиратта, иптәш Сталинны физик юк итәргә план корганнар. Шушы явыз ниятне тормышка ашыру юлында оешманың актив әгъзасы Салахов Ибраһим Низамович яшь язучылар, студентлар арасында контрреволюцион үгет җәелдергән»... һәм башкалар.

Ахырда — статья, пунктлар.

«Явыз ниятләрен, контрреволюцион эшләрен өстенә алмаса да, студент Алмакаевның күрсәтүләре белән аның җинаятьләре исбат ителә һәм ул РСФСР Җинаять кодексының иллe сигезенче статьясы нигезендә гаепләнә».

— Бу ни бу? Һич төшенә алмыйм. Куркыныч төшме, әллә?

Төн буена камерада арлы-бирле йөреп чыктым. Поклау түгел, утырып тора алмыйм. Йөрәк ярсый, сызлый, сыгыла.

— Бу нинди хаксызлык?

— Кайда, кайда син, дөреслек?!

Камера караңгылана. Соры, таш стеналар чайкалып өстемә авып килгәндәй була. Мин, сикереп торып, тимер ишеккә ябышам. «Күз» ачыла, кан сауган бәбәк карый һәм ачулы тавыш:

— Ишектән кит! — дип боера.

Әлсерәп, хәлсезләнеп караватка килеп егылам.

Мин нигә бу тынчу камерада? Хәзер бит май уртасы, табигатьнең иң гүзәл чагы. Күкчәтау даласы хәзер шау чәчәктә балкыйдыр. Ә мин? Кинәт бит алмаларым көеп китте, кайнар яшь коела.

Син — хыянәтче! Халык дошманы! Син туган иленә хыянәт кылган өчен каты җәзаланырга тиеш! Сиңа үлем җәзасы көтә.

Бу коточкыч авазлардан колагым тона, йөрәгем сулкылдый. Соңгы көчемне җыеп күтәреләм һәм, акылдан шашкан кебек, кычкырам:

— Ялган! Ял-ган! Мин һичбер вакытта да, һичбер вакытта да туган илемә хыянәт итмәдем! Хыянәт итмәдем, ишетә-сез-ме...

Хәлсезләнеп цемент идәнгә егылдым.

Шалтырап камера ишеге ачылды. Бары тик озак вакыт төрмәдә утырган арестантларга гына хас бер сизенү-куркыну белән сикереп тордым. Күзләрем әле ачылмаган.

— Чык! — Уянып киттем. Күзләремдәге томан таралды. Надзиратель камерада. Ишек төбендә тагын ике яшь солдат.

— Нәрсә катып калдың, атла!

Ниһаять, исемә килеп, камерадан коридорга чыктым.

Бер конвоир алга чыкты, икенчесе артта.

— Атла!

Атлыйм. Тар гына коридор. Бер якта тимер ишекләр, икенче якта — таш стена.

— Уңга борыл!

Борылдым. Тар гына таш баскыч өскә күтәрелә.

— Алга, марш!

Тагын борылдык, тагын күтәрелдек.

— Туры алга!

— Тирә-якка каранмаска! Тавышланмаска!

Нәрсәгәдер сөртендем. Шундук мәсхәрәле тавыш:

— Корсаклы хатын, тизрәк!

Бер-ике борылып күтәрелгәч, озыннан-озынга сузылган коридорга чыктык. Идәндә йомшак палас.

Коридорның ике ягында ниндидер кечкенә-кечкенә ишекләр, мөгаен, кием шкафлары. Алдан барган конвоир кинәт туктап, шул ишекләрнең берсен ачты.

— Кер!

Мин бу сүзгә төшенеп тә житмәдем, артымнан килгән конвоир кулындагы мылтыгының приклады белән этеп жибәрде. Мин сөртенеп шкаф эченә кердем. Ишек ябылды.

Бу ни бу? Табутмы? Ләхетме?

Нигә әле мине монда яптылар? Нишләмәкче булалар? Чү! Янымдагы икенче әржәнең ишеге ачылды. «Чык!» диделәр. Димәк, анда да минем төсле бер мәхбүс камалган булган. Ишек ябылды. «Атла!» Берьюлы берничә дагалы итек дык-дык китеп барды. Ниһаять, ярты елга якын төрмәдә әүмәкләнгән токыньның зиһене ачылды, бу «тыз-быз»ның хикмәтенә төшенә башладым, ахрысы. Коридорның ике ягы буйлап тезелеп киткән бу ишекләр кием шкафларыныкы түгел — яшерен туктагычлар. Коридорның ике башыннан арлы-бирле йөртелә торган токыннар үзара очрашмасын, күрешмәсен өчен берсе узып киткәнче икенчесен шушы төрмә-табутка ябып торалар икән. Үзенә күрә «мини-камера».

— Чык! Алга атла!

Ярым караңгы коридор буенча дүрт-биш адым үтәргә өлгермәдем, тагын әмер:

— Тукта!

Каршыда ике кеше буеннан биек, өлгеләп эшләнгән, ак буяуга буялган куш ишек. Алдан барган конвоир аларны ачып жибәрде.

— Кер!

Бусагадан атлауга, күзләрем чагылып, чайкалып киттем — егыла яздым. Ишек янагына тотынып калдым.

— Тизрәк!

Бик зур бүлмә. Ике якта өчәрдән дәү-дәү алты тәрәзә. Күтәрелеп килгән язгы кояш әнә шул тәрәзәләрдән бу бүлмәгә үрелгән.

— Нәрсә катып калдың, атла! Атла!

Күзләремне кулларым белән уа-уа атладым.

— Тукта!

Алдымда озыннан-озынга сузылган, кызыл постау ябылган өстәл. Кояш нурларында ул янып-ялкынланып торган учак булып чагылды. Аның артында өч кеше утыра. Өчесе дә хәрби киемнән. Әле «энәдән генә төшкән» хаки төсендәге постау гимнастеркалар. Яка кыекларындагы петлицаларда — очкынланып торган ромбалар. Димәк, иң югары чиннар. Уртадагысы юан, гимнастеркасына көчкә сыеп тора. Кара сакал. Пеләш баш. Ике яктагылары гәүдәгә кечерәк,ябыграк. Сакал-мыек пөхтәләп кырылган. Уң яктагысы жирән чәчле. Сул яктагысының чәче сүс сыман — дулкынланып тора. Өчесе дә алларында өелеп торган папкаларны актаралар. Күз кабаклары төшкән, йөзләре суык.

— Конвой, коридорга! — диде кинәт калын бас белән уртада утыручы пеләш башлы юаны, алдындагы бер папканы ачып-ябып.

Мине камерадан монда, бинаның югары катындагы бу якты бүлмәгә алып килгән конвоирлар ялт борылып чыгып та киттеләр. Ишек ябылды.

— Гаепләү кәгазен алдыгызмы?

Төксе эндәшү. Кайсысы сорады, аптыраудан абайламый да калдым. Алай да җавап бирергә ашыктым.

— Мин халык дошманы түгел, бер вакытта да...

— Җитәр!

Әйтерсең лә, кылыч белән чаптылар, иңге-миңге булып киттем.

— Кара,— уртада утырган хәрбинең кара сакалы сикереп китте, тавышы гасабиланды,— кара, син әле суд алдында да җинаятьче булуыңны танырга теләмисең!

— Мин...

— Молчать!

Өстәлдәге кыңгырау чыңлап китте. Күз алларым караңгыланды.

— Судка нинди үтенечегез бар?

Тагын ачулы бас. Уянып киттем. Суд! Язмышымның соңгы күпере. Я ирек. Я зиндан. Хәзер менә шушында, шушы мизгелдә бөтен киләчәгем хәл ителәчәк. Димәк, ашыгырга! Акылны, зиһенне җыярга. Һәм үземнең гөнаһсыз булуымны, ялгышлык белән генә кулга алынуымны сөйләргә. Яла белән чын җинаятьне аерырлар һәм гадел хөкем чыгарырлар. Шулай булгач, барсын да, барсын да яшермичә әйтергә — тикшерүченең кыйнауларын, уйдырма документларга кул куйдырырга тырышуларын, ялган шаһитлар китерүләрен... Үземнең балта остасы баласы булуымны. Пионерда, комсомолда, партия сафларында тәрбияләнүемне, барлык иҗатымны Совет иленә багышлавымны...

— Соңгы тапкыр сорыйм: судка үтенечегез бармы?

— Мин... мин... — нигәдер калтыранам. Тешем-тешкә сугыла.— Мин... гаеп-гаепле тү-гел... Мин... Совет...

— Җитәр! — Калын бас башыма тукмак белән ордымыни, күз алларым караңгыланды.— Соңгы тапкыр сорыйм: җинаятегезне танысызмы?

— Мин... мин... гаеп-сез...

— Конвой! — бүлмә калтыранып китте. Ишек ачылды. Аяк адымнары.— Алып китегез.

Уртадагы юан хәрби кеше кулындагы папканы — минем «гамәл дәфтәрен» сулга ташлады.

Ике конвоир ике кулымнан алып, борып-кысып ишеккә таба эттеләр.

— Тиз! Тиз!

Мине коридорга алып чыгып, тагын теге табутка яптылар. Әллә нәрсә булды — хәлем китте. Ярый әле ишек ябык, кысып тора. Зиһенем таралды. Уйның очын-очка бәйли алмыйм. Бу ни? Чыннан да, бу шул суд дигәннәре... Хәрби коллегия дигәннәре шушымы? Мин бит судта сорашырлар, аз булса да сүзләремә дә колак салырлар, хакыйкатьне ачарга тырышырлар, дип өметләнгән идем ләбаса.

— Чык!

Ишек ачылып китте.

Мине тагын теге якты бүлмәгә — суд залына китереп, кызыл постау ябылган зур өстәл алдына — салкын, чытык йөзле хәрбиләр каршына бастырдылар. Конвоирлар ашыгып чыгып киттеләр. Шундук өстәл артындагылар аягүрә басып кадалып калдылар. Уртадагы хәрби кеше алдында яткан кәгазьне үрелеп алды да боз төсле салкын бас белән сүзне сүзгә бәреп, ашыгып укый башлады:

— «СССР Югары суды Хәрби коллегиясенең күчмә сессиясе председатель...., әгъзалар... (исем-фамилияләре хәтеремдә калмаган — башта алар кайгысы идемени!) составында Совет Социалистик Республикалар Союзы исеменнән...»

Тезеп китте — аяз көндә боз явамыни. Ә ачык форточкадан тынлы

оркестр тавышы ишетелә. Танго. Салмак. Тыныч. Әйтерсең лә, кечке йомшак җилдә назлы чайкалучы диңгез йомшак кына ярларга сугыла. Күңелне, хәтта бөтен тәнне иркәләүче сихри музыка. Мин бу тылсымлы моң астында Зәйтүнә белән онытылып-сөенеп әйләнергә бик ярата идем бит.

Каршыда — бакча. Бу сихри музыка шуннан агыла. Мөгаен, бүген ял көне — кордашлар илаһи моң астында берсен-берсе кочып, гамьсез тирбәләләрдер. Гүзәл танго! Иркәләүче, назлы ритмнар! Анда минем кордашларым. Нигә мин алар белән бергә рәхәт диңгезендә тирбәлмим? Нигә?!

Музыка тынды.

Мин уянып киттем. Ә суд рәисе һаман борынын тарта-тарта укый:

— «Илле сигезенче статьяның беренче, җиденче, сигезенче, унынчы, унберенче, унҗиденче пунктлары буенча гаепләнеп, ун ел аерым режимдагы төрмәгә ябылу һәм, төрмә срогын тутырганнан соң, биш елга барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм калдыруга хөкем ителә».

## Алла йортында

### I

Судтан соң мине икенче төрмә каршындагы кызыл чиркәүгә күчерделәр. Ни өчен чиркәүгә, диярсез. Шәһәрнең барлык төрмәләре тоткыннар белән лык тулган. Тоткыннарның шактыен атарга хөкем итәләр. Төрмә ишегалдындагы баганага беркетелгән «кара табак» — радио бертуктаусыз сәфәр юнәлешләрен игълан итә:

— Котласка! Ак диңгез каналына! Норильскига!

— Соловкига! Тайшет — Абакан юлына!.. Колымага!

Шул тарафларга Казаннан эшелоннар, баржалар, столыпин вагоннары агыла.

Шулай да шәһәр төрмәләрендә халык дошманнарына урын житешми. Ә Кремль астындагы икенче төрмәнең нәкъ каршында, урам аркылы гына чиркәү бар. Стеналары колач житмәс калын, идәннәре, ишекләре тимердән, тәрәзәләре шулай ук тимер рәшәткәле. Әйтерсең лә, ходай үзе әзерләп куйган!

Тоткыннарның бер бригадасы атна-ун көн эчендә бу чиркәүне такта киртә белән әйләндереп, койма өстеннән чәнечкеле тимер чыбыклар сузып, чат-чатка биек манаралар утыртып бирәләр.

Төрмә башлыгы, надзирательләр һәм бер взвод конвой — яңа төрмә әзер. Рәхим итегез!

Менә шушы өр-яңа төрмәнең — кызыл чиркәүнең бихисап өлкән, авыр тимер ишекләре шыгырдап-чинап ачылгач, «алла йорты»на беренче атлап кергәндә хәйран калдым.

Я ходай, бу нинди мәхшәр!

Ыгы-зыгы, шау-шу. Камера түгел, ниндидер зур ярминкә! Кайдан бу хәтле халык?

— Кара әле, Ибраһим, бу синме?

Кемдер җилкәмә төртте. Таныш тавыш. Борылдым.

— Әй! — дип кочаклаштык. Бик озак бер-беребездән аерыла алмыйбыз.— Кара, бу синме, Сөббухмы?

— Ә мин сине атканнардыр дип уйлаган идем.

Сөякләр чытырдый...

— Әлегә без исән! Исән!!!

— Әйдә, аулаграк җиргә барыйк әле, мин сиңа бер нәрсә сөйлим,— дип, Сөббух мине алтарьга таба алып китте. Кайда монда аулаграк урын — һәр җирдә кырмыска оясы. Шулай да түрдәге бер почмакка чүктек.

— Судтан соң мине подвалга алып төштеләр дә зур гына бер камерага керттеләр,— дип Сөббух пышылдап кына сөйли башлады.— Исем китте. Безнең обком секретарьлары, наркомнар барысы да шунда...

— Беренче секретарь да бармы?

— Ул да, Лепа да, Разумов та. Безнең Ләбиб, Фатих ага Казанлы, Шамил Госманов, тагын әллә кемнәр. Мин каушап калдым. Кайсы елый, кайсы: «Бу нинди хаксызлык, Сталинга, Сталинга язам»,— дип кычкыра. Ләбиб йөгереп килеп мине кочаклап балавыз сыга башлады: «Сөббух, җан кисәгем, сине дә атарга хөкем иттеләрме?» — ди. Ул арада камераның ишеге ачылды да мине киредән тартып алдылар.

— Доң-доң! Доң-доң!

Кызыл чиркәүнең бу чаңы бүген инде гыйбадәткә түгел, тоткыннар качмаганнармы, асылынып үлмәгәннәрме икәнен белер өчен кичке барлауга — сафка тезелергә куша. Кыямәт көнемени, чиркәү эче өстеастына килде. Ыгы-зыгы, шау-шу, сүгенү, акыру, елау. Ул арада шалдыр-шолдыр ишекләр ачылды — уелап надзиратель һәм бозау хәтле өч эт ишелеп керде. Тоткыннарны күрүгә, этләр тагын да ярсып-үрсәләнеп өрә, абалый башладылар. Якыннанрак узган берничә мәхбүснең җиңнәрен-балакларын да талап алдылар.

— Җитәр, шау-шуны бетерегез! — Конвой башлыгы бар тавышына кычкырып җикеренү өстенә, үтемлерәк булсын өчен, ахры, нәкъ блатнойларча, өч-дүрт катлы итеп сүгенеп тә куйды.

Йөзәр-йөзәрдән биш сафка тезелдек. Надзирательләр һәр сафны икешәр-өчәр тапкыр санап чыктылар, аннары сәндерәләргә менеп, барлык хәзинәләрне туздырдылар — берничә капчыктан карта, инә, биш тиенлек бакыр акчадан кисеп, шомартып эшләнгән бритва, күзге кебек чүп-чарны казып чыгардылар. Конвой башлыгы:

— Төрмә тәртибен бозган өчен, иртәгә барыгызны да прогулкадан мәхрүм итәм. Әгәр дә кәгазь-карандаш табылса, карцер режимына куям! — дип каты гына кисәтте һәм тагын бер кат сүгенде дә командасын алып чыгып китте. Этләр өрүне онытып алдан атылдылар, күрәсең, камерадагы һава аларга ошамады. Чиркәү кинәт чайкалып киткәндәй булды — биш йөз мәхбүс берьюлы кузгалып, берсеннән-берсе алданрак урын алып калырга тырышып, сәкеләргә үрмәләде. Тагын ыгы-зыгы, сүгенү, этү-төртү китте. Ул арада берәүне бишенче кат сәндерәдән атып та бәрделәр. Тимер идәнгә кан җәелде.

Ишек ачылды. Тагын этләр, надзирательләр...

Теге мәетне алып чыгып, бераз шау-шу тынгач, Сөббух минем янга килеп:

— Ә без кая ятырбыз икән? — диде.

Чиркәүне йөреп чыктык, бер буш урын юк.

— Әйдә, булмаса, сәке астына — идәнгә ятыйк! Салкынчарак та булыр.

Сөббухның биштәрендә әле бер җәймә кисәге дә бар икән. Мүкәләп сәке астына кердек тә, җәймәне җәеп, икәү янәшә яттык. Инде икеөч көн рәтләп йокламаганлыктан, ятуга күзләр-керфекләр бәйләнә башлады. Әмма Сөббух та, мин дә йоклап китә алмыйбыз, арлы-бирле әйләнәбез. Өстәге сәкедән нәрсәдер ком төсле шыбыр-шабыр коела. Бөтен тән кызышып кычыта.

— Син йоклыйсыңмы?

— Кайда йоклау, әллә нәрсә чеметә.

— Мин дә чыдый алмыйм. Кашысаң, нәрсәдер сытыла. Кулдан сасы ис килә.

— Юк, булмас, әйдә ишек төбенә барып бераз утырыйк.

— Синдә тартырга юкмы?

— Мин суд алдыннан бирелгән папиросның берсен кесәгә төреп салган идем.

— Булдыргансың!

Сәке астыннан үрмәләп чыгып, җәймәбезне тартып алсак — исебез китте. Ул кып-кызыл төскә кергән! Сәкедән ком түгел, кандала коелган икән. Менә кем безне йоклатмаган.

Камера гырылдый, мышный, сүгенә, саташа. Ә без Сөббух белән икәү параша төбендә утырып икебезгә бер папиросны төтәтәбез. Шулай да монда апа-ялгыз камерада ятуга караганда күңеллерәк.

Кемнәр генә юк, ниләр генә эшләмиләр бу гыйбадәтханәдә.

Алтарь почмагындагы сәке-сәндерәләрнең иң түбәнгесендә җирән чәчләре иңнәренә хәтле төшеп торган бер поп тезләнгән дә, таш диварда-гы Гайсә пәйгамбәрнең тәрегә кадакланган сурәтенә карап, бер туктау-сыз чукына, ял-чәчләре әле бер, әле икенче якка чайкала. Сөйләүләренә караганда, поп, ял-чәчләрен кырдырмас өчен әллә никадәр җәфалар чиккән — кыйналган, атнадан артык карцерда утырган. Әмма чәчен алдырырга бирмәгән. Иртәгә ул этапка озатылачак, ди. Хәзер менә ихлас чукынып, Гайсәдән озын-озак юлга көч-мәдәт ялвара, күрәсең.

Язмышның мыскыллап көлүеме, нәкъ менә шул поп чукынып яткан сәке өстендәге сәндерәдә ап-ак сакаллы бер татар карты, тастымалын намазлык итеп җәеп утырган да, кулларын күкрәгенә кушырып, күзлә-рен йома төшеп — бу дөнья шау-шуыннан китеп, пышылдап кына дога укый, ара-тирә сәҗдәгә китә. Ә алар өстендәге сәкедә бер төркем күлмәк-ыштансыз тоткын акырып-бакырып карта суга. Киемнәр оттырыл-ган инде, банкта — ун, унбиш көн алда биреләчәк паек, баландалар... Ә каршыдагы бер сәкедә карт партизан үзенең Гражданнар сугышында-гы маҗараларын сөйли. Берәүләр йоклый, икенчеләр елый, өченчеләр тыела алмый көлә. Кайсы акылдан язган — һич төшенерлек түгел.

Алтарь каршындагы мәйданда алыш-биреш, сәүдә. Ни генә сатмый-лар! Тәүлеккә бирелә торган биш йөз граммлы паек икмәк — «кибән башы» дисеңме, суынган арыш чумары — баланда дисеңме. Каяндыр шикәр, конфет, хәлвә кебек ләззәтле нигъмәтләр дә тапканнар. Тәмәке, папирос берәмләп, учлап, төремләп — җаның ниндиен тели. Монда күл-мәк-ыштан, гимнастерка, итек, ботинка, оек, тәмәке янчыгы кебек кирәк-яраклар да алырга була. Бу базарның бәһа нигезе доллар да түгел, фунт стерлинг та түгел, сум да түгел. Төп үлчәү — паек. Бер паек, ярты паек, чирек паек... Менә шулай сатулашалар һәм шушы бәягә алыш-биреш ясыйлар.

Тәрәзәгә якынрак төштә — көнкүреш хезмәтен күрсәтүчеләр: ямау-чылар, тегүчеләр, итекчеләр. Хәтта монда бер төрем тәмәкегә сакал-мыегыңны кырып, яшәртеп җибәрәләр.

Монда үтенеч язып бирүче адвокатлар да, законны яттан белүче прокурорлар да бар.

Җырчылар, биючеләр, таракта уйнаучы музыкантлар...

Бу соңгылар — һәвәскәр артистлар күбрәк түрдәге иң киң, иң якты сәке тирәсендә әйләнә. Чөнки монда камераның патшасы — староста ята, урта буйлы, тыгыз бәдәнле, кап-кара сакаллы, тузган бөдрә чәчле чегән — ат карагы. Унбиш елны алган. Төрмә түрәләренең таянычы. Ул монда хуҗа — теләсә, хөкем итә: яткызып суктыра яки туйганчы икмәк, баланда белән сыйлый ала. Старостага аш-суны ашханәдән аерым са-вытта, капкачлы кечерәк җамаякта китерәләр.

## II

Сагыну!

Татлы да, ачы да син, сагышлы сагыну. Синнән качам, сине оны-тырга тырышам. Әмма... Әмма үзем тагын-тагын кочагыңа — кайнар, назлы, гөлләп куагы төсле гүзәл, чәнечкеле кочагыңа омтылам. Көнба-

гыш чәчәге төсле сокландыргыч син, сары сагыну. Синдә кояш чаткылары һәм эрем тәме. Сәкедән берәр арестант төшеп, урыны бушады исә, мин тиз генә аның урынына менеп ятам да, пальтом белән томаланып, уранып, күзләремне йомам. Биш йөз тоткынлы камерада болай да тынчу. Чиркәүнең гыйбадәт үзәгендә. Уранып яткач, тын кысыла, сулыш ала алмый башлыйм, шабыр тиргә батам. Алай да битемне ачмыйм. Уранып яткач тыныч: камера, андагы ыгы-зыгы ераклаша, югала, үземне кеше юк, аулак бер җирдә хис итәм. Рәхәт, тылсымлы бер дөньяга күчәм һәм сине күз алдыма китерәм.

...Исәнме, Зәйтүнә! Я сөйлә әле, зачетлар ничек бара? «Койрыклар» юкмы? Хәзер бит институтта «урак өсте», курстан курска күчүне хәл итә торган язгы зачетлар. Менә бит, борынгы тарихтан, истматтан, диаматтан былтыргы шикелле үзем генә булышкан булыр идем дә, жәл, көтмәгәндә хәлләрем болай булып китте. Ә шулай да, өметсез шайтан, диләр бит, бу караңгы төн мәңге булмас әле.

Хәтерлисеңме, Зәйтүн гөлем, былтыр язгы зачетларга ничек әзерләнгән идек икебез? Ул һаман әле минем күз алдымда.

...Ботакларын киң җәйгән нәфис алма агачлары, мәһабәт юкәләр шау чәчәктә. Хуш ис! Ә без шул агачлар күләгәсендә — йомшак чирәмдә бер кочак китапларны, конспектларны чәчеп ташлап, аунап укыйбыз, укыйбыз. Башлар томалана башлый — сугышып китәбез. Кыйнашабыз.

— Житәр! Әнә, кулым кара көеп чыкты! — дип үпкәләп, елаган булып, китә башлыйсың. Мин йөгереп барып кочаклыйм һәм кайнар иреңнә үреләм. Әле менә хәзер дә аның сихерле-дәртләндерүче тәме иреннәремдә... Аннан, култыклашып, көлешә-көлешә аллеяда йөрибез. Яр астында куаклыкта яшеренеп утырган энҗе таҗлы миләүшә чәчәге табып бирәм — күкрәгеңә кадыйм. Хуш ис — әйтерсең лә, иң нәфис, иң кыйммәтле Париж хушбуе ягынгансың.

Төшкене ашап кайткач, тагын юкәләр астына киләбез. Кояш инде бая без яткан җирне кыздыра башлаган, төньякка, яр астына күчеп, сузылып ятабыз да, иртәнчәк укыган китаплар буенча бер-беребезгә сораулар бирә башлыйбыз. Алай күңелле, китап-конспект укыгандагы сыман ялыкмыйсың — хәтердә дә озаграк саклана. Зачетны да алдан бирәбез. Билгеләр дә иң югары. Башка студентлар безгә соклана, кайберәүләре хәтта көнләшә дә иде бит, әйеме? Бигрәк тә Фазыл. Ул гел безнең тирәдә чуала, әйтерсең, паркның башка җирендә аңа урын юк. Берәр сәбәп табып янибызга килә — «ашка таракан булып төшә». Я китабы юк, имеш, я конспекты югалган. Үзе һаман турсайган була. Ышанасыңмы, Зәйтүнә, менә шул дус булып йөргән Фазыл, турсаеп кына калмаган, өстемнән донослар да язып торган. Чын, чын! Кулъязмаларын, әләк хатларын үз күзләрем белән күрдем. Аның кулын әллә кайдан таныйм — кәкре-бөкре шайтан таяклары. Тикшерүче күрсәтте. Нәрсәләр язган бит әле, имеш, мин контрреволюцион оешмада член булганмын. Имеш, аны да шул оешмага керергә өндәгәнмен! Менә бит нинди җаһил!

Ничек инде дөньяда юкны язарга, үзеңнең иптәшеңә яла ягарга кирәк? Оятсыз. Вөҗдансыз! Мөгаен, анда вөҗдан булмаган да. Менә ул ни өчен турсаеп, кара көеп йөргән. Син, Зәйтүнә, аның белән сөйләшмә. Ул хаин! Ышанма! Их, жәл, син бит хәзер бу сүзләремне ишетә алмыйсың. Ә шулай да... Шулай да тоярсың, сизәрсең. Бер-берсен бик-бик яраткан кешеләрнең йөрәкләре бер ритмда тибә, бер-берсенең күңел авазларын ерактан да ишетәләр икән ди бөек Фирдәүси үзенең робагыйларында. Мөгаен, син дә ишетерсең бу кисәтүче, сине бәлагазадан сакларга тырышучы авазымны? Ишетерсең бит?

Их, белсәң иде, шундый-шундый сагындым үзеңне, бәгырьләрем өзелә.

Сызла, сызла, сызла, күңелем,
Сызла бер туктамыйча;
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча,

— дип Дәрдмәндннең сагышлы юлларын кабатлыйм.

Ә син, Зәйтүнә? Син дә сагынасыңмы мине? Әллә? Юк, юк! Әйттем исә кайттым — әлгаязе билләһи. Без бит ахирәт дуслар, ахирәт җаннар...

— Даң-доң! Даң-доң!

Чиркәү диварлары барлык аллалары, фәрештәләре, изгеләре белән чайкалып китте. Минем дә иң кыйммәтле, иң изге уйларым челпәрәмә килделәр. Ыгы-зыгы, шау-шу.

Биш йөз мәхбүс берьюлы сәке, сәндерәләреннән чуен плитә идәнгә сикерделәр. Мин дә.

Барлаудан соң түрдәге сәкеләрнең берсе астына чүктем дә — монда ишек төбе — параша янындагы кебек мәхшәр түгел, тынычрак — тагын уйланып бетмәгән уйларымны очларга тотындым.

— Бәй, син монда качкансың ич, эт белән эзләп тә таба алмассың. Чык әле, бер шигырь яздым, — дип Сөббух мине тартып-йолкып үзе янына чыгарды. — Әрәм калды уйларым, кайдан тапты, хәерсез. — Миңа тыңла.

Исем китте — дүрт юллык кына шигырь укыды — тирә-як яктырып китте. Идел, аккош кебек ак пароходлар һәм җыр. Маяк яндыручы кызның көймәдәге җыры.

— Син, кара әле, миннән нигә качасың? — диде Сөббух шигырен укып бетергәч, миңа үпкәләп карап. Ялганлый алмыйм, серемне ачтым, Зәйтүнәне сагынуымны әйттем.

— Әйдә, бүген икәү параша чыгарыйк. Бүгенге баш дежурный безнең авыл егете. Мин аннан Зәйтүнәне институттан телефон аша чакыртып, иртәгә күрешү оештыруын үтенермен, — диде Сөббух, бер дә көтмәгәндә мине канатландырып.

— Май кап! — дип сикереп тордым. — Әйдә, тизрәк старостага барыйк. Парашаны башкаларга биреп куймасын тагын!

## III

Әйтерсең лә, чиркәүнең барлык эреле-ваклы кыңгырауларын кактылар. Казан Кремле астындагы зур чиркәү — биш йөз тоткын утырган төрмә жу итте. Хәбәр яшен тизлеге белән телдән-телгә, сәкедән-сәндерәгә күчте.

— Күрешү!

— Очрашу рөхсәт иткәннәр.

Хәйран калмаслык та түгел бит, бу чиркәү төрмәгә әйләнгәннән бирле, мондый хәлнең һич булганы юк. Булуы да мөмкин түгел, чөнки бу камерада аеруча куркынычлы — илле сигезенче, илле тугызынчы статьялы арестантлар. Аларга нинди күрешү? Ә миңа көтмәгәндә — хәбәр! Илле сигезенче статьялы мәхбүскә күрешү биргәннәр.

Бу сөенечле хәбәрне ишетүгә, бөтен камера чират торып мине тәбрикләргә, үземне ничек тотарга, ничек сөйләшергә — очрашу вакытында нинди хәбәрләр алып калу кирәклеген өйрәтергә керешге! Хәтта берсе папирос кәгазе китереп бирде — «Бу кәгазьгә үзеңә кирәкле сүзләрне-үтенечеңне яз да бармак арасына кыстыр. Күрешкәндә кызның кулын гадәттәгедән озаграк кыс, чәнчә бармагың белән учын кытыкла һәм кәгазеңне аның кулында калдыр». Алдым. Яздым. Ятып калганчы — атып кал. «Зәйтүнә, минем нахак гаепләнүем турында Сталин иптәшкә хат яз». Кем белә, Сталинга барып җитсә, бәлки «Азат итәргә!» дигән фәрман килер. Тик миңа каушап, үзем идәнгә — надзирательләр күзе-

нә төшереп җибәрмәсәм генә ярар иде инде. Кәгазьне төкереклэп бармак арасына кыстырып йөри башладым — күнегергә кирәк.

— Беренче эшлисе эш,— диде камерадагы блатнойларның атамасы Папа Пий II,— үзенең аеруча булдыклы, ышанычлы «мөрит»ләрен җыеп алып,— көзге һәм каләм [1]. Егетебезне тулысынча тәртипкә китерү хаҗәт.

Шундук бер төркем шыр ялангач «мөрит»ләр идәнгә утырып ике биш тиенлек бакырны эшкәртә башладылар. Бер бакыр тәңкәне чуен идәнгә ышкыйлар — ул көзге булачак. Икенче бакыр тәңкәне кисеп шул ук идәнгә кайрый башладылар. Ул «каләм» (бритва) булачак. Ул арада әле кичә генә монда килеп эләккән бер «медвежатник» (фатир карагы) килеп, өстендәге өр-яңа күк сатин күлмәген салып бирде.

— Кыз алдында мескен күренмә!

Инде чалбар һәм итекләр кирәк иде. Армиядән киеп кайткан кыек сырлы күк тукымадан тегелгән галифе буй-буйга таралды да төште — бигрәк хәтәр туза икән. Ә итекләр кәвеш булып кына калганнар иде инде. Үрә бастырып куйганда балтырлар шешеп, сала алмагач, кунычларын телгәләгән идек. Бу якны да кайгыртучылар табылды.

— Карчыгам, бер дә кайгырма,— диде камера старостасы, капкара сакаллы, кара бөдрә чәчле чегән Роман (ат карагы!) һәм шундук сәкегә утырып, аягындагы хром итекләрен салып миңа тоттырды.— Ки, минем төсле биеп китәрсең... Чалбар да җәл түгел, ләкин, үзең күрәсең, бу чалбарга син башың белән кереп чумасың. Әй, Петушок,— дип ул яныбыздан узып барган ярдәмчесен,— минем чамалы блатной егетне туктатты һәм аны, ярминкәдә ат сайлаган сыман, әйләндереп-тулгандырып карады да: күгәрченем, яле, сал чалбарыңны,— диде.

— Ә мин?..— диде Петушок, аптырап,— минем трусик та юк ич.

— Ярамаган тагын, монда кызлар юк, бераз җилләрсең.

Ул минем трусикны аңа бирде дә, кара постау чалбарны миңа кидерде һәм сакалын дерелдәтә-дерелдәтә көлде:— Менә, карчыгам, бөтенләй бүтән кошка охшадың.

— Даң-доң!

— Барлау!

Камерага һау-һаулап этләр, алар артыннан сакчы солдатлар керде.

Барлаудан соң Папа Пий IIнең шәхси чәчтарашы «Чикерткә» мине тулы тәртипкә китерә — сакал-мыекны кыра, чәчне кырка башлады.

Эш байтак озакка сузылды: бер-ике сыздырып алган саен «каләм»не идәнгә кайрарга туры килде, юкса битнең тиресен каезлый башлый «Чикерткә», дөресен әйтергә кирәк, хәленнән килгәнчә авырттырмыйча, шома итеп, төкләрне калдырмый кырырга тырышты һәм нигездә бу теләгенә иреште дә бугай. Биттә, борын астында әллә ни күзгә чекерәеп торган кылчыклар күренми. Минем кулда әле генә барлыкка килгән «көзге»— шоп-шома ялтырап торган биш тиенлек бакыр тәңкә. Аны эш барышын күреп, тикшереп торыр өчен «Чикерткә» үзе бирде. Билгеле, биттә, ияк астында, муенда кәгазь өстенә кәгазь ябыштырылган «ямау»лар барлыкка килде. Әчетә, сызлый. Шулай да кыяфәт яхшы якка үзгәрде. «Ямау»лар иртәгәгә хәтле бөтәеп рәтләнер. Папа Пий II үзе килеп тикшереп, «Чикерткә»нең эшен яхшы дип тапты. Аннан соң староста, баш надзиратель белән сөйләшеп, бер чиләк су алдырды — ул кичләрен аяк-кулларын юып ята торган иде. Бу юлы да шул максат беләндер дип уйласам, мине чакырды:

— Карчыгам, кызың янына хуш исле булып бар, мә бер чиләк су: яхшылап юын.

Кемдер сабын белән мунчала да китерде. Суд алдыннан бер юын-

[1] Пәке (жаргон).

дырганнар иде, шуннан бирле тән су күрмәгән. Юыну түгел, эчәргә житми бит су.

Ә монда мөлдерәмә тулы бер чиләк!

Кичке аш вакытында староста миңа үз «хәзинә»сеннән (аерым жамаяктан) өстәмә рәвештә бер өлеш баланда, бер өлеш галушки бирде. Ашап бетерүгә тагын бер сюрприз.

— Кил, карчыгам, монда,— ул үзе янында гына йоклата торган Петушокны куып төшерде дә миңа шул урынны күрсәтте,— ят рәхәтләнеп, аяк сузып, йокла, кыз белән көрешер алдыннан сине идәндә аунатып булмас.

Мин чиркәү түрендәге изге такта түшәккә менеп, аягымны сузып яттым...

## IV

Иртәнге баландадан соң киенү байтак вакытны алды. Старостага берсе дә ошамый. Имеш, итек куныччлары көзге кебек ялтырамый, чалбарда жыерчыклар. Күлмәкнең ике төймәсе юк икән... Мөритләр ярдәмендә барысын да рәткә китерергә туры килде. Староста мине әйләндереп-тулгандырып карады да, ниһаять: «Кунак кызы кебексең,— диде.— Бар, бар, кит, ишек янында бөтерел, сакчы чакыруга әзер тор! Юкса, алар бер кычкырыр да, чыкмый дип, ишекне ябып та куяр. Бар, бөгелмә, төз тор. Төрмәгә төшүгә жебегән, димәсен! Бар инде!»

Ишек янында әйләнәм, хәзер үк чакырмасалар да ярар иде. Уйларым белән жыенып беткәнем юк. Юкса, төн буенча да гел шул турыда уйлап чыктым бит. Ә шулай да әйтеп каласы сүзләр уйлаган саен өстәлә бара. Көрешүгә бары ун минут вакыт бирәләр. Менә шул ун минутта, сигез ай буе жыелган бөтен уйларны, сагынуымны, сагышымны — барысын-барысын да әйтеп бетерергә кирәк. Юк, алай ярамый. Хисләр соңыннан. Иң элек менә бу бармак арасындагыны озатырга. Тукта, төшеп калмаганмы үзе? Юк әле, төшмәгән, бар. Кая, төкереклэп ябыштырыйм, ашыкканда шуып төшеп кала күрмәсен, тфү, тфү. Аннан өсбашны кайгырту кирәк бит. Радиодан, «Кызыл яшьләр», «Яшь ленинчы» газеталарыннан аласы гонорарлар бар иде, шуларны алырга дежурный алдында Зәйтүнә исеменә доверенность язармын. Бәлки, менә шушы доверенность язган арада язуны да бирергә? Алай уңайлырак булмасмы? Менә шул гонарарларга Зәйтүнә Печән базарыннан ботинкалар, костюм-чалбар, эчке киемнәр алсын. Тагын нәрсә? Ә-ә, башка фуражка да кирәк бит әле... Тагын нәрсә? Әйе, бер-ике передача да китерсен — ашамлыклар һәм тәмәке. Тәмәке күбрәк кирәк. Камерадагы иптәшләрне аз булса да сыйларга. Менә бит алар мине ничек ялт итеп киендерде. Бәйрәм ашы — кара-каршы. Аннары әле бит институт хәлләрен сорашмадым. Хатип Госмановның хәле ничек? Аны кулга алмадылар микән? Тагын нәрсә турында? Күкчәтаудан, әтиләрдән хат юк микән?

Йозакны шалтыраталар — ачалар!

Тукта, иң алдан нәрсәне әйтергә булдым әле? Әй, шайтан алгыры, онытып та өлгердем бит э. Хат! Хат!

Ишек ачылуга дежурный йөгереп керде дә мине этеп жибәрде:

— Кит моннан. Тыңлагыз, фамилиясе аталганнар әйберләрен алып ишек алдына! Староста! Монда кил, билге ясап тор.

— Иванов Иван Петрович!

— Мин!

— Рамазанов Сабир!

— Мин.— Уртадагы сәкедән сары сакаллы бер карт төште, ә капчыгы балкага кысылып калды, ала алмый.

— Чык! Нәрсә корсаклы хатын төсле тулганасың?

Мин капчыкны ычкындырып жибәрдем. Карт ишеккә йөгерде.

— Базарбаев Аманбай.

— ...

Башым әйләнеп китте. Аманбайдан — тагын бер якын дустан аерылдым бит. Кая алып китәрләр инде аны? Янә очрашырбыз микән?

— Джапаридзе...

— Хәсәнов...

Камерадан ике йөз иллеләп тоткынны этапка алдылар. Әйтүләренә караганда, Норильскига. Аннан каршыдагы — Кремль астындагы икенче төрмәдән тагын ике йөз иллеләп мәхбүсне безнең камерага китерделәр. Китте ыгы-зыгы, урын өчен талашу-сугышу. Ярый әле староста мине онытмады. Түрдәге икенче кат сәкедән урын бирде.

Ә көрәшү?

Мондый мәхшәрдә нинди көрәшү булсын, ди. Юкка гына жилкендем. Инде мин нишләргә дә белмим. Киемнәрне салып хуҗаларына тапшырырга кирәк.

— Ба-лан-да!

Кизү торучы унбашылар ишек төбенә җыелды. Ишек ачылды. Ике колагыннан ике мәхбүс күтәргән кисмәкләр камерага керә башлады. Әче кәбестә исе борынны ярып китте. Безнең унлыкка да миски килде. Мин дә консерва банкамны алып чиратка бастым.

— Салахов ишеккә!

Әллә инде бераү төртеп калды — банкам кулымнан төшеп китте.

— Күрешү вакыты биш минут. Очрашуга килгән кешеләргә якынлашырга — кул бирергә ярамый. Һичбер нәрсә алырга, бирергә рөхсәт юк. Бары минем аркылы. Политика турында сөйләшергә ярамый. Төшендеңме?

— Төшендем.

— Атла!

Кузгалдым — тез буыннарым калтырый. Я, алла, өнемме, төшемме? Чыннан да, хәзер мин аны... күрерменме? Зәйтүнә! Ни хәтле әйтелмәгән сүзләр, хисләр... йөрәктә. Шуңа, ахры, ул дөп-дөп итә. Юк, юк, каушамыйм. Каушама, күңелем! Син, син бәхетле. Ул, ул саф мәхәббәт, керсез-изге мәхәббәт бу ишек артында бит. Ул, мөгаен, минем кочагыма ташланыр. Аңа аны эшләмә, моны эшлә дип кисәтүче дежур надзиратель юк бит...

Ишек ачылып китте.

Мин бусагадан атладым да сын булып катып калдым.

Бу ни бу? Әллә инде күзләрем буыла? Юк, бу нинди оятсызлык һәм мәсхәрәләү?

— Нигә ул монда? — дип кычкырып җибәрдем ачуымнан-ярсуымнан калтыранып.

— Зәйтүнә минем хатыным,— диде Фазыл күзләрен тозландырып. Ә аның янында басып торган Зәйтүнә башын иде.

— Булмас, булмас! — бер-ике адым алга атладым да, бизгәк тоткандагы кебек туңып, чирканып, дерелди башладым.— Ул хаин! Ул минем өстән ялган әләк язган.

— Хатыным алдында хурлама! — диде Фазыл кара көеп.

— Ә-ә, хурламамы? — бүлмә уртасында миңа утырырга куелган табуретканы күтәреп алып Фазылның башына сугарга омтылган идем, надзиратель, йөгереп килеп, кулымнан тотып калды.

Зәйтүнә кычкырып елап җибәрде.

— Күрешү тәмамланды! — диде дежурный надзиратель, табуретканы идәнгә куеп.

Очрашу бүлмәсеннән мине туп-туры карцерга алып киттеләр.

## V

...Зәйтүнә белән вафасыз көрешүдән соң биш тәүлекне карцерда уздырдым, аннан чыгаргач тагын шушы йортка китерделәр.

Бердән ачлык, икенчедән сөйгән кызымның хыянәте мине ярыйсы ук йончыткан иде. Ашыйсым килә. Уйдан-гарьләнүдән баш чатный. Кайда, кемгә зарны түгәргә? Аптырагач, бердәнбер дус Сөббухны эзләп киттем, этапка кумаган булсалар гына ярый инде үзен. Алтарь тирәсендә каранып йөргәндә, өстән берәү кычкырды:

— Әй, күзлекле!

Туктадым. Баксам, өске сәндерәдә аякларын салындырып утырган кара сакал — староста бармагы белән ишарәләп, мине үзе янына чакыра икән.

— Кил әле монда, карчыгам. Хәлләр ничек?

— Ярый шунда.

— Яраса, кил, утыр.

Мин теләр-теләмәс кенә аның янына күтәрелдем. Ул бөтен йөзен каплап алган кара, кабарып торган куе сакал-мыегын ике куллап тарап-купшыланып алды да, сул күзен кысып, хәйләле бер караш белән сорау бирде:

— Сине китап яза, диләр, дөресме?

— Элек дөрес иде, хәзер юк!

— Ничего, хәзер дә була, батя... Мин сиңа бер эш таптым, үзе ашлы, үзе тузансыз, кичен яныма кил, туйганчы ботка ашарсың. Килештекме?

— Килештек.

Нинди эш тапты икән миңа бу ат карагы?

Менә бит уйламаганда эшләр җайланды да китте. Көн дә өстәмә бер паек икмәк. Аш та баланда түгел — ит шулпасы, ботка, кайвакытта котлет, староста казаныннан. Үземә генә түгел, Сөббухка да өлеш чыгар...

Ә эше? Эше, староста үзе әйтмешли, тузансыз да, өреле дә. Нәрсә эшлим дисезме? Сөйлим. Көн дә кичке баландадан соң, йокы алдындагы тикшерү-барлауга хәтле, хикәят сөйлим. Кече яшьтән үк «Әлфе ләйлә вә ләйлә», «Кырык вәзир», «Шаһнамә», «Әбугалисина», «Тутыйнамә», «Салсал» кебек гарәп әкиятләрен укып үскәнгә, запас җитәрлек. Менә хәзер ул ярап куйды. Көн дә бер яңа әкият сөйлим — тоткында утырган халык гарәп әкиятләренең гүзәллегенә, андагы батыр шаһзадәләргә, сылу кызларга, бигрәк тә тәмледән-тәмле «әнвәг-әнвәг нигъмәтләргә», шәраб-ларга хәйран калып, хыял дөньясында йөзеп, үзенең бүгенге кызганыч хәлен бик азга гына булса да онытып тора, шуның өчен минем әкият сөйләр вакытны көтеп җиткерә алмыйлар. Бу әкиятләрем бигрәк тә камераның хуҗасы — ат карагы чегәнгә ошый: йотылып тыңлый...

— Алтын кеше бит син, бөркетем. Авызыңнан энҗе-мәрҗәннәр коела. Синең урын монда түгел, җәннәттә бит, җаным,— дип аркамнан кагып, үсендереп куя.

Камерадагы биш йөз мәхбүс мине белә, килә башласам, торып, сәкесеннән урын бирә. Мин хәзер сәке астында — кандала оясында түгел, алтарьда, староста янында — якты, киң урында ятам.

Менә бит, бәхет киләм дисә, күктән төшә.

Сигез ай Пләтән төрмәсендә көне-төне сорау алуга йөреп, карцер паегында торып, коры сөяккә калган идем. Хәзер чиркәүдәге бер ай эчендә тазарып, тулып киттем.

— Сөбханалла,— ди Сөббух, әллә көлеп, әллә инде чынлап.— Син көннән-көн матураясың.

Ахрысы, Сөббух күз тидерде. Бер төнне мине уяттылар да ашыгыч рәвештә каршыдагы икенче төрмәгә алып киттеләр. Нәрсәгә? Билгесез.

— Сез җинаятьчеләрне төрмәдән качарга өндәгәнсез һәм, шул явыз ниятегезне тормышка ашырыр өчен, төркем туплагансыз, чиркәү идәне астыннан Казанка елгасына таба подкоп ясарга әзерләнгәнсез. Бу җинаятегезне таныйсызмы?

— Гражданин тикшерүче...— Өстәл артында ниндидер бер папка ачып, кәгазьләр актарган күзлекле кешегә аптырап карадым. Әллә инде башка берәү белән бутый?— Гафу итәсез, мин бернәрсә дә белмим. Нинди подкоп?

— Молчать!— Тикшерүче, берәү энә чәнчеп алгандай, кинәт чәчрәп торып кычкырып җибәрде, папкадан бер табак язылган кәгазь алды.— Менә гаебең! Сез берәү дә сизми дип уйлагансыздыр. Безнең күз җир астыннан да күрә. Номерыгыз барып чыкмады! Яндыгыз. Соңгы тапкыр сорыйм: җинаятегезне таныйсызмы, юкмы?

— Гражданин...

— Җитәр! Конвой!— Ишек ачылып, мине монда алып килгән солдатларның берсе атылып керде.— Менә бу адәм актыгын карцерга! Гаебен өстенә алганчы чыгармаска. Марш!

— Бар, бар!

Надзиратель этеп-төртеп карцерга тыкты да, тимер ишекне шалтыратып ябып, бикләде. Мин бусагада басып калдым — узарга урын юк. Озынлыгы биш, киңлеге өч метр чамасындагы таш капчык — тәрәзәсез дүрт цемент стена. Түшәмдә тузанга, пычракка катып беткән бер лампочка кызарып тора. Тынчу. Ярым караңгы. Бала-чага тавышы. Башта мин үземнең күзләремә дә, колакларыма да ышанмадым — саташам, ахры. Тора торгач бераз күз ияләште. Анадан тума ундүрт-унбиш яшьлек үсмер малайлар берсе өстенә берсе атланып тартышалар, сикерәләр, егылалар, сугышалар.

— Әфәнделәр!— Почмактан нечкә бер тавыш колакны кыеп китте һәм шуннан ук җирән сакаллы берәү күтәрелде. Бусы трусиктан. Күкрәгендә ялангач кыз сурәте һәм язу: «Мәхәббәт өчен җан фида!» Шаушу акрынлап тынды. Теге җирән сакал алга чыкты:— Әфәнделәр, безгә яңа барон килгән, баш иегез.

Җирән сакал алдымда яртылай сыгылып төште.

— Барон,— диде теге җирән сакал иелгән килеш,— безне гафу итегез, киләсегезне белмәгән идек!..

Арттан берсе кычкырып җибәрде.

— Баронга көзге кирәк, үзен күрәсе килә.

Ул арада минем алда басып торган бер пумала башлы малай ялт борылып, нәкъ минем борын төбендә туңкайды.

— Музыка!

Теге туңкайган малай шатыр-шотыр җил чыгара башлады.

— Ха-ха-ха!

Акылдан шашкан кебек акыру, хихылдау, кычкыру. Мин нишләргә белми аптырап торганда, теге җирән сакал тагын команда бирде:

— Парад!

Ул әйтеп тә бетермәде, әле генә минем алда туңкаеп торган малай сикереп җилкәмә менеп утырды, башкалар аның артыннан тезелделәр.

— Шагом а-арш!

Әмер иштелүгә, җилкәмдәге бала, аяклары белән күкрәгемә тибеп, кузгалырга боерды.

— Бер-ике, бер-ике.

Мин теге пумала башны күтәргән килеш алдан, калганнар арттан...

— Ходаем, падишаһны сакла...

Җилкәмә атланган малай нечкә кызлар тавышы белән патша дәүләте гимнын башлады, башкалар күтәреп алдылар. Алар улый, ә минем тыным

кысыла. Жилкәдәге пумала баш үзе албасты сыман авыр. житмәсә, ботлары белән муенны кысып, үкчәләре белән күкрәгемә тибеп куя: «Тизрәк!»

Кайда тизрәк, мин абына-сөртенә камераны ике тапкыр әйләндемме-юкмы, әлсерәп егылдым. Арттагылар барысы да минем өскә аудылар. Шаркылдап, хихылдап көлү, акыру. Ә мин, изелеп-ватылып, инде һуштан язам дигәндә генә, тагын әмер яңгырады:

— Житәр, баронны өйләндерергә вакыт!

Өстемдәгеләр этешә-төртешә тордылар.

Ә мин кузгала алмыйм.

— Кияү егет,— теге жирән сакал, алдыма тезләнеп мыскыллап көлә башлады,— поп сине кем дип чукындырган иде?

Минем телем дә әйләнми.

— Күсе, тукта әле,— жилкәмә атланып йөргән пумала баш миңа карап-карап торды да кычкырып жибәрде:— Бу бит чиркәүдәге әкиятче!

— Син каян беләсең?— Күсе чыннан да күсе сыман сузылып пыяла күзләре белән карады.— Бәлки, ул түгелдер?

— Үткән атнада мин үзем тыңладым. Менә дигән әкиятләр белә,— ул баш бармагын күтәреп телен шартлатты.— Да, ул язучы, яңа таныдым.

— Писарьмы?

— Юк ла, китаплар язган.

— Ә-ә-ә.— Жирән сакал миңа аптырап, икеләнеп карады да кинәт кычкырып жибәрде:— Тамаша бетте. Әкиятчегә урын бирергә!

Пумала баш йөгереп килеп мине күтәреп торгызды да Король утырган жиргә — түргә алып барып утыртты.

— Гафу итегез, язучы абый, мин башта сезне танымыйча калдым.

Ул арада тагын ишек шалтырады. Ачылды. Тагын ике кешене этеп-төртеп керттеләр — берсе ишектән көчкә сыеп керде,— дәү, юан, икенчесе — тәбәнәк, ябык.

Ишектән керүчеләр башларын да күтәрергә өлгермәделәр, шәрә үсмерләр алар өстенә ташланды. Алдарак торганы дәү жилкәләрен күтәреп, өстенә ташланганнарны атып бәргән иде, бөтен карцер аның өстенә ябырылды. Ектылар да таптый-изә башладылар.

Артта калган тәбәнәк буйлы моны күреп, куркуыннан, ахры, үзе егылды. Теге дәү озак көрәште, әле бер, әле икенче малайны алып атып карады, әмма жиңелде. Жирән сакал үзе аның өстенә менеп кунды. Калганнар параша капкачы белән суга-суга йөдәттеләр.

Дәү ахырда егылды.

Шуннан соң аны «өйләндерә» башладылар — поп кушкан исемен әйттерделәр, кайда, кем булып эшләвен ачыкладылар. Ул бер районда прокурор булып эшләгән имеш — жирән сакал үзе таныды. Менә ни өчен аңа каныгалар икән. Авыз-борыны кан булуга карамастан, прокурорны әүвәле утырттылар. Аннары чалбарын салдырдылар һәм һәр малай тимер кашык белән өч тапкыр аның «йомшак» жиренә сугып үтте.

Прокурор тәмам хәлдән таеп егылды. Шуннан соң гына «өйләндерү» тукталды. Тәбәнәк тоткын иректә укытучы булып эшләгән икән, аңа тимәделәр.

— Менә сиңа кадак, прокурор әфәнде,— дип Король параша өстендә көчкә утырган дәүгә зур бер кадак сузды. Пумала баш кадакны алып прокурорның борынына төртте, теге башын күтәрмичә генә алды. Карышырга жөрьәт итмәде, ахрысы. Король, күзләре белән бораулап, сүзен ялгады:— Подъемга хәтле ишекнең ике тупсасын казып чыгар. Ә син, «Пумала баш», карап тор. Казымый башласа, параша капкачы белән жиллэтеп ал.

Отбойдан соң кем кайда торса, шунда утырып, чүгәләп йоклап китте. Камера-карцерда бары Король, жирән сакал һәм мин «оста әкият-

че» генә сузылып яттык. Бары хәзер генә мин үсмер малайларның нигә шыр ялангач булуына төшендем. Бөтен киемне бет сарып алды. Күлмәк үзеннән-үзе кыймылдый. Шундый үзәккә үткәзеп тешлиләр, чыдап булмый. Аптырагач, мин дә чишенеп ташладым.

Ә ишек бусагасында кытыр-кытыр штукатур, кирпеч вагы коела. Прокурор карцер ишегенең тупсаларын чокый...

Җәй. Көмеш толымнары белән чайкалып-дулкынланып яткан дала. Еракта ап-ак киез өйләр күренә. Әчкелтем кымыз исе борынны кытыклый. Ә мин кылган эчендә сузылып ятып хәл җыям. Талгын гына җил исә. Нинди рәхәт... Менә кул астында гына кып-кызыл булып пешкән җир җиләге. Авыз итим әле, дип кулымны сузган гына идем, ниндидер тавышка сискәнеп уяндым.

Карцер буп-буш, бер кеше калмаган. Ишек каерылып ташланган. Коридорда яткан тимер ишек өстендә надзиратель басып тора: күзләре акайган, әле бер, әле икенче якка карый.

— Әй, мондагы тоткыннар кайда?

Мин аптырап сикереп тордым да ялангач икәнемне тоеп, янадан чүктем.

— Белмим.

— Ничек белмисең? Ишекне кем җимерде?!

Ул арада тагын берничә надзиратель йөгерәп килде дә сүгенә-сүгенә кире борылды.

Алдан килгән надзиратель аптыраудан, ахры, идәндә яткан ишекне бераз күтәреп торды да ташлады һәм мине кисәтте:

— Кара, әй син, беркая да китмә!

Мин киенә башладым.

Төрмә ишеге алдында шау-шу. Этләр өрә. Ике тапкыр мылтыктан аттылар.

Бераздан төрмәнең столяр цехында эшләүчеләр килеп, каерылып ташланган ишекне киредән урынына куя, цементлап ныгыта башладылар. Алар миңа надзиратель күрмәгәндә бер паек икмәк, өч-дүрт төремлек махорка бирделәр.

Озакламый карцердан качкан яшүсмерләрне берәм-берәм өстерәп кыйнап китерә башладылар. Прокурор белән укытучыны бәйләп бәдрәфкә ташлаган булганнар икән, аларны да китерделәр. Ишек, урынына куелып, тагын ябылды, аркылы тимер билбау-болт белән кысылып бикләнде. Карцер тагын тулды. Бары тик җирән сакал Король белән Пумала баш кына күренмәде. Әллә инде алар төрмәдән чыгып, качып өлгерделәр, әллә инде аларны башка җиргә яптылар. Кире китерелгән үсмерләрнең барысының да диярлек кул-аяклары яраланган, тәннәре кара көйгән иде. Әмма берсе дә еламый, бары тик сүгенәләр, ишекне кагалар. Ул арада карцерның түшәмендәге люк ачылды да шлангадан су сиптерә башладылар. Озакламый су билдән булды.

Төнозын бил тиңентен суда тоттылар. Каты кыйналудан җәрәхәтләнгән, хәлсезләнгән өч малай басып та тора алмыйлар. Аларны иптәшләре, алмаш-тилмәш, стенага сөяп, күтәреп тордылар. Бара-тора минем аякларны да көзән җыера башлады. Тагын бераз су эчендә калсам, егыла идем.

Ниһаять, подъемга чаң какканнан соң, карцерның ишеген ачтылар — су, буа ерылгандай, коридорга җәелде. Җиңеләеп киттек.

Надзирательләр мине алырга килгәннәр икән. Шул, юеш, өстән су саркып торган килеш, төрмә кәнсәсенә алып киттеләр. Өч тимер капка ачылып ябылды. Ниһаять, аскы каттагы тәрәзә рәшәткәсе күгәреп беткән озынча бүлмә. Ярым караңгы. Өстәл. Башын да күтәрми кәгазьгә төртелгән күзлекле тикшерүче миңа:

— Ничек, җинаятегезне таныйсызмы? — дип эндәште.

— Нинди җинаять?

Күзлекле урыныннан сикереп торды да акырды:

— Конвой, алып китегез, карцерда чересен!

Хәзер җәйнең иң матур чагы — июль уртасы. Мондый чакта кемнең генә күңеле табигатькә талпынмый. Тәнгә сихәт, күңелгә рәхәт бирүче яшел урманнарда, хуш исле чәчәкләр белән балкыган болыннарда кемнең буласы килмәс?

Ә мин менә инде сигезенче тәүлек тынчу карцерда җәфаланам. Көн дә тикшерүче чакырта. Хәзер инде төн уртасында, йокы басканда, төрмә шомлы тынлыкка батканда алдыра башлады. Һаман бер сорау.

— Төрмәдән качу чараларын кемнәр белән, ничек әзерләдең син, халык дошманы? Әллә кайчан инде сине атарга кирәк иде. Әгәр инде бу җинаятеңне дә өстеңә алмасаң, сиңа котылу юк! Әйт, төркемеңдә кемнәр бар иде?

Ә минем башым әйләнә, күз алдым караңгылана — нинди качу? Нинди төркем? Нинди җинаять?

Кинәт ишек ачылып китә. Ике таза егет — конвоирлар мине кыйнарга тотыналар. Ә тикшерүче һаман бер сүзне кабатлый:

— Әйт, төркемеңдә кемнәр бар? Кемнәр?

Менә бу карцерның калын таш стенасы артында өч-дүрт адымда гына урам. Кремль астындагы бу урамнан Казанкага коеныргa йөри идек без. Их, хәзер менә ичмасам бер генә тапкыр шул суга чумып чыксаң. Бөтен кер, бар кайгы юылыр иде...

Шалтырап ишек ачылды.

— Следовательгә!

Әүвәле ике тәүлек, бигрәк тә иртән паек һәм баланда алганда, ашказаным борып-авыртып теңкәгә тиде. Башкалар ашаганны күрмим дип, күзләремне йомып ятам. Староста: «Утыз тугызынчының паегын, баландасын кире алыгыз. Ул ачлык игълан итте»,— ди. Һәр иртәдә. Бүген инде дүртенче тәүлек. Инде ашыйсы килүдән бигрәк эчәсе килү җәфалый. Иреннәрем ярылды. Температурам күтәрелде. «Бер генә тамчы су...» Әмма мин, бирсәләр дә эчмим, үземне-үзем газаплыйм. Үлемгә дучар итәм. Авызда инде төкерек тә юк, ахрысы. Тел кабарган, эчәсе килә. Бер генә йотым...

Соңгы сорау алуда аңымны югалтканчы кыйнап, мине карцерга китереп ташладылар. Бөтен тәнем кара янган, сул кулымны күтәрә дә алмыйм — сызлый. Әллә сынган, әллә чатнаган. Бары соңгы сорау алуда гына «подкоп»ның кайдан килеп чыгуын төшендем. Чиркәүдә әкият сөйләгәндә мин, тыңлаучыларны мавыктырып өчен, пиратлар турында, аларның замоклардан, ныгытмалардан качуларын да тасвирлый идем. Кемдер «чирткән». Менә шуны инде «подкоп»ка хәтле күперткәннәр. Ә мин хәзер шул юк «подкоп»ны, «төркем»не табып бирергә тиеш.

— Табалмыйсың, яшерәсең икән — яңа срок!

Ун ел төрмә. Биш елга хокуктан мәхрүм булу! Инде өстәмә җинаять— төркем белән төрмәдән качуны җитәкләү... Караклар, кеше үтерүчеләрне генә түгел, ә хөкүмәтнең, халыкның кан дошманнарын төрмәдән алып чыгарга «җыенган» кеше бит мин... Ә бу җинаять тагын кимендә ун ел төрмә өстәячәк миңа. Булмаса — ату!

Менә ни өчен мин аңлы рәвештә ашау-эчүдән ваз кичтем. Бу — соңгы таянычым. Мин инде икенче яланы — нахак гаепне җентекләп тикшереп, аклауны таләп итәм.

Карцерда инде берничә тапкыр тоткыннар алышты. Әмма, дөресен әйтергә кирәк, мине бер генә карак та, бер генә рецидивист та рәнҗетмәде, киресенчә, миңа ятарга урын бирделәр. Паекларымны, ач булуларына карамастан, гадел рәвештә кире кайтаралар һәм хәзер чиратлашып ишекне кагалар:

— Кеше үлә, врач кирәк!

— Доктор!

Иреннәремдә — кан. Авызымда — тоз тәме. Их, бер генә йотым су...

— Мәгез, эчеп җибәрегез.

Бер стакан су, саф салкын су! Чайкалып, түгелеп мина килә.

— Башын күтәрегез.

Кемдер башымны күтәрде. Стакандагы салкын шифалы суның дымы инде иреннәремдә тоела, уф алла! Моны да күрер көн бар икән! Бар хәлемне җыеп үреләм. Өстәл! Өстәл артында — күзлекле кеше.

— Эчеп җибәрегез!

Сылык итеп кире егылдым. Стакандагы су чайкалып түгелеп китте. Мин аңымны югалттым.

— Ибраһим, ач күзенне. Менә, бераз су йот. Курыкма, мин, мин бу. Имәнкулов Зариф. Хәтерлисеңме, Беренче татар полкы комиссары, Имәнкулов. Йотып җибәр.

Су тамгач, иреннәрем җәелеп киткәндәй булды.

— Ибраһим, тагын, тагын бер йот.

Имәнкулов.... Имәнкулов... Бу фамилия каядыр, күктә әйләнеп йөрде дә сүнде. Мин тирән бер упкынга төшеп киттем.

Бу камерада әле Имәнкуловтан[1] башка, Татиздат буенча таныш журналистым Кәримов Хәмзә дә бар икән. Ул да, рәхмәт яугыры, ярдәмгә килгән — атнага якын мине кашыктан аз гына шикәрле суда изелгән икмәк ашатып, булышып торган.

## VII

— Безнең камерага алып килгән надзирательнең әйтүенә караганда, сине ике тапкыр следовательгә күтәреп алып барганнар. Ул сиңа су тәкъдим иткән. Син эчәргә дип омтылгансың да, аңыңа килеп, стаканны этеп җибәргәнсең. Тугызынчы тәүлектә температураң кырыкка күтәрелгән. Төрмә врачы сине карцердан алып, больницага салырга кушкан. Әмма тикшерүче, ул гаебен өстенә алмады, дип рөхсәт бирмәгән... Менә ни өчен безнең камерада син, Ибраһим,— диде Имәнкулов.

Мин әле, ваба авыруыннан арына башлаган кеше кебек, хәлсез, калтыранам. Ә шулай да аңым эшли — Имәнкулов! Чыннан да, бу минем янда яткан тоткын — шул Беренче татар полкының комиссары, Гражданнар сугышы батыры, күкрәгендә Кызыл Байрак ордены балкыган мәшһүр комиссармы?

— Ташла, ул турыда сорашма инде. Әнә ишек ачыла. Акрынлап саф һавага чыгып керик, хәл өстәлер үзенә.

Имәнкулов, култыклап, мине ишегалдына алып чыкты. Камера ишегеннән атлауга, күзләрем чагылды, башым әйләнә башлады.

— Булмаса, утыр монда,— Имәнкулов мине йөрү мәйданына чыга торган ишек төбенә утыртты да баш надзирательгә нидер әйтте. Тегесе кулын селкеде. Утырсын мәгънәсендә.

Ул арада икенче яктан һава алырга чыккан хатын-кызлар күренде. Гадәттә, бер камера кергәнче икенчесендәгеләрне тышка чыгармыйлар иде. Бу юлы надзирательләр вакытны бутаганнар, ахрысы.

Минем яннан, башларын иеп, кулларын артка куйган хатын-кыз тоткыннар уза. Йөзләре сулган, карашлары сүрән. Арада яшьләр дә, чал чәчле карт аналар да күренә.

— Чү, Ибраһим, бу синме?— кемдер үтеп барышлый пышылдап кына эндәште.— Исәнме.

— Сәрвәр апа![2]

---

[1] Имәнкулов Зариф — Гражданнар сугышы герое, беренче орден кавалеры, кулга алынганчы Беренче татар полкы комиссары.

[2] Сәрвәр Әдһәмова — язучы, К. Нәҗминең хатыны.

— Шаулама! Хәлең ничек?
— Әле генә карцердан.
— Ишеттем. Барысын да ишеттем. Тугыз тәүлек! Егет икәнсең! Инде бирешмә!
— Җыланнар, тагын пышылдаша башладыгызмы? Туктагыз! Иртәгә тагын сезнең камераны прогулкадан мәхрүм итәм,— надзиратель хатын ирләрчә өч-дүрт катлы итеп сүгенә, арттагыларны этә-төртә башлады.
Әле былтыр гына Сәрвәр апа язучылар җыелышында балалар әдәбиятының үсеше турында доклад белән чыккан иде. Тулы күркәм гәүдәле, шат чырайлы, кызлар кебек җыйнак, матур иде ул вакытта. Ә хәзер? Хәзер әнә танымаслык булып ябыккан, йөзе саргайган, әмма тавышы көр. Ул надзиратель хатынның сүгенүенә, куалавына да карамастан, миңа таба борылды һәм инде ачык тавыш белән кычкырды:
— Ибраһим, өметеңне өзмә! Бу караңгы төн мәңге булмас.— Ул тагын да нәрсәдер әйтмәкче иде, надзиратель хатын Сәрвәр апаны этеп җибәрде. Сәрвәр апа камера бусагасына абынып егылды.
Авыр тимер ишек шалтыр-шылдыр килеп ябылды.

## Ана тавышы

Бу фаҗигале вакыйгадан соң инде кырык елга якын вакыт үтте. Әмма ул йөрәк өзгеч тавыш, чегән хатынының баласын эзләп, зарлап елавы әле хәзер дә колагымда чыңлый. Кайвакыт баласын кочаклап перронда аунаган шул чегән хатыны төшемә керә. Кара тиргә батып куркып уянам.
1938 елның июне. Уфа. Тимер юл вокзалы. Перрон. Ул шомлы кичтә безне, бер төркем «халык дошманнарын», күп газаплар күреп, ниһаять, Уфа төрмәсенә килеп эләккән тоткыннарны тагын каядыр озатырга дип вокзалга китерделәр. Билгеле инде, «кара козгын» читлекләрендә. Шуның өчен юлда кем белән килүебезне белмәдек. Безне перронда ниндидер, каядыр китәргә торган поезд янына китереп төшерделәр һәм шундук бер столыпин вагоны алдында тезләндерделәр. Бу юлы төркем кечкенә, егермеләп кенә мәхбүс иде. Яңа гына яңгыр явып үткән, перрон пычрак. Җитмәсә, безне нәкъ пычракның күзенә тезләндерделәр. Чалбарлар шундук лычма су булды. Әмма аңа бер тоткын да игътибар итми. Уфаның тоткыннар белән шыгрым тулы, тынчу төрмәсеннән соң мондый саф һавада булу, иркенләп сулыш алу көтелмәгән рәхәт бит. Дөрес, вокзал-перрон һавасында төтен аралаш күмер, май исе сизелә. Әмма инде бу һаваны камераныкы белән чагыштырып булмый. Белмәгәнбез генә икән иректә вакытта: вокзалның һавасы да, тынгысыз ыгы-зыгысы да күңелгә ятышлы. Әнә ничек кайнап тора ул. Берәүләр чемоданнарын, капчыкларын, әрҗәләрен күтәреп, водокачка ягына таба абына-сөртенә йөгерә, икенчеләре нәкъ шулай тирләп-пешеп аларга каршы чаба. Барысы да ашыга. Тик без генә — тоткыннар гына сүлпән. Әйтерсең лә, теге дөнья кешеләре — пычрак суга тезләнеп, тынсыз утырабыз. Юк, бу тыштан гына шулай. Ә эчтә, менә бу пычрак суга тезләнгән ертык-керле киемле, ябык-сары, тутлы йөзле тоткыннар күңелендә — өермә. Алар үзләренең, нәкъ шушы пассажирлар төсле, теләсә кай якка бара алган чакларын хәтерли, туганнарын күз алдына китерә. Алай гына да түгел, күзләре белән интегеп якыннарын эзли, бәлкем... Бәлкем, менә шушы шашып йөгергән юлаучылар арасында атасы, хатыны, баласы бардыр... Бәлкем? Аһ, хәзер алар килеп чыкса...
Мин дә, тирә-ягымдагы иптәшләрем төсле үк, өзелеп вокзал ыгы-зыгысына карыйм. Көтәм. Кемне? Үзем дә белмим. Әмма ашыгып, ашкынып көтәм...
— Ә-ә, әү-әү...

Дерт итеп киттем. Якында гына бер яшь бала кычкырып елап җибәрде. Нинди нарасый? Кайда? Без инде һәрберебез елдан артык тоткында — гаиләдән аерылган. Шуның өчен бу тавыш, сабый бала тавышы, сәер дә, якын да, газаплы да.

Бала елый.

— Ә-әү... Ә-әү...

Кайда? Кем баласы? Мин башымны артка бордым. Гәүдә белән борылырга ярамый. Конвой һәр хәрәкәтне качарга әзерләнү дип исәпли һәм шундук ата. Артта, кырыйда, безнең кебек үк тезләнеп, бер чегән хатыны утыра — яланбаш, чәчләре тузгыган, яланаяк. Әмма өстендә кат-кат керле, ертылып беткән күлмәк һәм инде төсе уңган зур шәл. Ул шәлен иңенә салып уранган. Шул шәл эчендә кечкенә сабый күзләр — шомырт күзләр елтырый. Хатын шәлен бераз бушатты да, якасын ачып җибәреп, сабыйга имчәген каптырды. Елау басылды. Сабый чүпчүп итеп, тәмләп имә башлады. Күзләр йомылды.

Паровоз кычкырды. Буферлар бер-берсенә сугылып чыңладылар.

— Торыгыз!— Конвой башлыгының ачулы тавышы колакны ертып китте. Ул үзе кечкенә, чандыр. Борыныннан кыссаң, җаны чыгар. Мондый ачы тавыш кай җиреннән ургыладыр.— Басыгыз! Тезелегез! Тикшерү!

Безне төрмә конвоеннан юлныкына тапшыру башланды. Төрмә конвое башлыгы — озын буйлы, тулы гәүдәле, җәенке битле, кысык күзле башкорт егете янәшәсендәге солдатка күтәреп килгән зур күн сумкасын җиргә куярга боерды. Куйдылар. Ачтылар. Аннан зур-зур папкалар чыгара башладылар. Тоткынның формулярын, гамәл дәфтәренә язылган хөкем карары һәм башка кәгазьләрен.

— Иванов, бер адымга алга чыгып бас!

Уң яктагы ак сакаллы карт профессор әмерне үтәде һәм исемен, туган елын, ничә елга, нинди статья белән хөкем ителгәнен әйтте.

Юл конвое башлыгы формулярны алып, тоткынның әйткәннәрен тикшереп, формулярдагы язмалар белән чагыштырып тора.

Без барыбыз да бу гадәти, инде ел буена бер төрмәдән икенчесенә йөри-йөри күнегеп беткән «сират күпереннән» үтеп, столыпин вагоны алдына бастык. Иң соңгы булып чегән хатыны калды. Бая борылып караганда абайламаганмын икән. Беренчедән, анда мин күбрәк игътибарны сабый балага биргән идем. Икенчедән, хатын бөгелеп баласын имезә иде. Менә ул хәзер торып баскан. Иманеп киттем. Әллә инде Проспер Мерименың мәшһүр Кармены басып тора? Төз, зифа буй. Матур коелган килешле гәүдә. Чем кара, озын, калын толымнар тузып җилкәгә төшкән. Калын кыйгач кара кашлар. Карчыга борын. Хәзер каты кысылган юка иреннәр һәм аз гына алга омтылган ияк. Дөрес, бит алмалары янып тормый, аксыл, суырылган. Бу инде аңлаешлы, ул да безнең кебек тынчу камерадан чыккан, туяр-туймас паекта торган, житмәсә, бала имезә. Әгәр хәзер аны иркен таборга җибәрсәң, туйганчы ашарга бирсәң?.. Мине аеруча сокландырганы — зур шомырт кара күзләр. Алар ниндидер бер көч, ярсу белән бораулап карыйлар.
Ә торышы, нәкъ таборда биергә чыгарга әзерләнгән төсле, иркен, хәтта
аз гына куштан да. «Карагыз, сокланыгыз, мин нинди чибәр!»

Ул бер адым алга атлады да, горур бер караш белән, башын аз гына артка чөеп, шәлгә урап күкрәгенә бәйләгән бәбиен тирбәтә-тирбәтә аз гына чайкала, борын астыннан гына ниндидер бер көй шыңшый. Күрәсең, беренче баласы — сөенеп туя алмый.

— Әй, син нәрсә, Земфира!— Юл конвое башлыгы аңа мыскыллап карап, акырып җибәрде.— Нәрсә чайкаласың? Әллә камерада чәкеп алдыңмы? Сиңа аерым чакыру кирәкме, атла.— Ул төрмә конвое баш-
лыгына борылды.— Кайда аның формуляры?

— Чегән хатынның формуляры юк. Ул әле тикшерелә генә. Озату кәгазе генә бар.

— Бир монда,— диде дә теге түрә чегән хатынына кадалды.— Ә нәрсә ул шәлгә уралган? Әллә, багарга да өлгерденме? Нәрсә ул?

— Ул минем карчыгам.

— Җүләр, нинди карчыга тагын?

— Иптәш начальник,— диде башкорт егете,— ул балалы хатын.

— Нинди бала?!— Конвой башлыгы ачуыннан, елан чаккандай, сикереп китте:— Шул гына җитмәгән, юлга бала белән. Бир әле конвоирга, балалар бүлмәсенә тапшырсын.

— Миндә көчек юк!

— Молчать!— Түрә кеше акырып җибәрде.— Мин сиңа күрсәтермен тешләреңне. Иптәш Ващенко!— Ул чылбыр булып безне урап торган конвоирларның чегән хатынына якынрак торганына эндәште:— Ал баланы, вокзалдагы дежур милиционерга бир!

— Тыңлыйм!— Иващенко мылтыгын янындагы иптәшенә бирде дә чегән хатынына ташланды. Хатын ялт аркасы белән борылды. Солдат алга чыгып, хатынның күкрәгенә кул сузган иде, кинәт аның битенә шап итеп хатынның кулы төште.

— Ах, сволочь, син әле конвоирга сугасыңмы?— Гайрәтле түрә чыпчык кебек сикерә-сикерә килеп, балалы чегәннең аркасына төртте. Хатын перронга барып капланды, бәбие акырып елап җибәрде. Конвой башлыгы хатынны тагын бер тибеп әйләндерде дә баланы тартып алырга иелде һәм шундук, «А!..» дип яман тавыш белән акырып, артка чигенде. Аның уң кулыннан кан тамчылый иде.

Ике тапкыр кыңгырау чыңлады. Начальник кесәсеннән яулык алып, уң кулын урады да вагонга йөгерде, тамбурда басып торган проводницаны чакырып, колагына нидер пышылдады. Проводница ризалык белдереп, башын иде.

— Әйдә, үләксә, йөгер теге вагонга!— Түрә кеше чегән хатынын куа, ашыктыра башлады.— Тиз, тиз, падла!

Хатын, баласын кочаклаган килеш мүкәләп, егылган җиреннән торды. Үзе һаман «Ә-ә-ә» дип баласын тынычландыра. Аның әле бала имезеп утырган җирендә зур гына капчыгы да бар икән. Бер кулы белән баласын күкрәгенә кысып, икенчесе белән биштәрен өстерәп, яшел вагонга, конвой күрсәткән, проводница басып торган ишеккә таба йөгерә атлады. Начальник арттан аның саен кызулады.

— Тизрәк, тизрәк, үләксә! Поезд кузгала. Синең аркада әнә составны тотып торам, адәм актыгы!

Чегән хатыны абына-сөртенә капчыгын өстерәп баскыч төбенә килеп җитте. Үзе мышный, баласы елый.

— Әйдә, әйдә, мен вагонга.

Хатын бер кулы белән баласын кысып, икенчесе белән капчыгын өстерәп, вагонга күтәрелмәкче иде, баскыч биек, аягы җитми. Ул арада өстә басып торган проводница елмаеп:

— Бирегез балагызны, мин тотып торыйм,— диде.

— Рәхмәт.

Чегән хатыны баласын проводницага биреп, үзе ике куллап капчыгын күтәрде — вагонга менәргә азапланды. Шундук шап итеп эчке ишек ябылды. Хатын акырып җибәрде:

— Мишут-ка-а...

Ул арада күрше вагонның ишеге ачылды һәм аннан теге проводница кызыл чүпрәккә төрелгән баланы конвой башлыгына сузды.

— Иващенко!— Начальник конвоир солдатны чакырып алды да акырып елаган баланы сузды:— Мә, тизрәк вокзалга детприемникка илт.

Иващенко бик шыксыз-уңайсыз рәвештә төргәкне алып култык астына кыстырды да вокзалга таба йөгерде. Бала буылып, үксеп елый иде:

— Ә-әү... Әү...

Паровоз соңгы гудогын бирде.

Безне тиз генә этеп-төртеп вагонга кертteләр. Поезд кузгалды.

Столыпин вагонында торкыннар өчен дә комфорт житәрлек — купелы вагоннардагы кебек, аерым-аерым бүлмәләр. Бары тик тәрәзәләре, көзгеләре, радиосы, вентиляциясе генә юк. Аның каравы, ашау-эчү өчен ресторанга барып йөрисе юк — китереп торалар. Бу купе-камераның истәлекле, күзгә ташланып торган җиһазы — ишек. Ул тимер белән тышланган. Югары өлешендә ачыла-ябыла торган тимер рәшәткәле форточкасы бар. Ә форточкада сәгать телендәге сыман түгәрәк тимер кисәге — «медаль» асылынып тора. Бу — «күз». Коридорда кизүдә торучы конвоир һәрвакыт «күз» янында. Ул аны түргә үткәндә дә, ишеккә атлаганда да ачып карый — сыңар күз белән, әмма җентекләп. Башкача мөмкин дә түгел — устав куша. Ул купе-камерага бикләнгән җинаятьчеләрдән теләсә нинди «баш китәрлек» эшләр көтәргә була. Мәсәлән, иданне, түшәмне, стенаны тишеп качу яки хатмазар төшереп калдыру, яки асылыну... Шуның өчен «күз» һәр минут ачылып-ябылып тора.

Минә шушындый купе-камераның берсендә без — сигезәү. Янәбызда кырый камерага теге чегән хатынын япкан булганнар икән. Ул бертуктаусыз ишеккә суга, тибә, кычкыра.

— Ачыгыз! Ачыгыз дим, җен-пәриләр. Кайда минем улым? Кайда минем Мишуткам? Ачы-гыз! А-чы-гыз! Ишетәсезме, ерткычлар, ишетәсезме?

— Җүләр, кычкырма! Уфа инде әллә кайда калды,— ди кизүдәге Иващенко, форточканы шарт-шорт ачып-ябып.

— Улымны... Улымны кайда куйдыгыз?— Йөрәк өзгеч тавыш һәм акырып елау.

Бөтен вагон бу зардан, елау-каргаудан тетрәнә. Йөрәк әрни, ташый, түгелә. Ә чегән хатыны һаман ишекне шакый, тырный, суга, тибә һәм яман тавыш белән кычкыра:

— Улымны... Мишуткамны... Карчыгамны кая куйдыгыз!? Бирегез, бирегез...

Берәр сәгатьтән соң күрше вагонда баручы конвой башлыгының тавышы ишетелде. Ниндидер боерыклар бирде һәм кизү торучы солдатның чегән хатыны турындагы рапортына тыныч кына:

— Еласын, тамагы карлыккач, туктар әле,— диде.

Түрә чыгып китте. Форточка ачылды. Безгә берәр селедка, өч йөз грамм ипи бирделәр — кичке аш. Тамак ялгарга утырдык. Әмма нихәтле ач булыйк, ризык бугаздан үтми, тыгыла. Чөнки колакта чегән хатынының зарлы тавышы, ләгънәте, ялваруы. Өч-дүрт сәгатьтән ишеккә сугу, тибү тукталды, тавыш та акрынланды. Хәзер шыңшып елау, үксү һәм зар...

— Мишутка, бәгърем... җаным... карчыгам. Инде карының ачкандыр, имәсең киләдер. Минә имиләремә сөт төште, сызлый. Ми...шут...ка... Аһ...

Буферлар бер-берсенә сугылып шыңшый. Тәгәрмәчләр рельслар башына сугылып, бертуктаусыз шак-шок, шак-шок итә. Анда-санда паровоз кычкырып куя. Туктый. Перронда шау-шу, кыңгырау. Буферлар сугыла. Тагын шак-шок, шак-шок. Поезд каядыр ашыга. Кая? Безгә билгесез. Нинди язмыш, нинди яңа михнәтләр, газаплар көтә безне?

— Шак-шок, шак-шок.

Керфекләр эленә.

Яман бер тавышка сискәнеп уяндым.

— Мишутка, у-лым, син кай-да-а?..

Әйтерсең лә, йөрәкне телгәләп, тоз сибәләр, ул әрни, сызлый, сыгыла.

— Ми-шут-ка-а-а-а!

Карлыккан тавыш тагын тозлы күз яшенә тыгылып ялварды.

Төн. Шак-шок, шак-шок һәм кизүдәге конвойчының аяк адымнары. Аннан тагын күрше купеның ишегендә акыру, елау, шаку, тибү, теш шыгырдату һәм ләгънәтләү. Паравоз бөтен даланы шыңлатып кычкыра да чаба бирә.

— Җеннәр, пәриләр, кая куйдыгыз минем газиз улымны, бирегез!— инде тавыш акрын гырылдап чыга.

Ниһаять, таң алдыннан күрше камерадагы тавыш тынды.

— Бичара хатын. Йоклап китте, ахрысы,— диде авыр сулап күршем Мәхмүт Әбҗәлимов.

— Арыгандыр инде мескен. Әйдә, без дә йоклап алыйк ул уянганчы,— дидем дә, борылып яттым, күзләремне йомдым.

Коридорда пыш-пыш сөйләшү, арлы-бирле йөгерүгә уянып торып утырдык. Бар игътибарыбыз — коридорда. Нәрсә? Менә вагонның тышкы ишеге шарт итеп ябылды. Конвой башлыгының ачулы тавышы яңгырады:

— Ни булды?

— Иптәш... начальник... үлгән.

— Кем үлгән?

Тагын кизүдәге конвоирның хәвефле һәм пышылдау тавышы:

— Чегән хатыны, иптәш начальник. Асылынган...

*Дәвамы бар.*

# ПОЭЗИЯ

## Роберт Әхмәтҗанов

### Сибгат ага Хәкимгә элегия

I

Тукай мирас иткән пар ат
көтә иде үрдә,
ә ул үзе көпә-көндез
төшеп китте гүргә!..
(Үзен сагына идек бит
йөргән чакта җирдә!)

Гүя исе китмәгәндәй
еллар фасылына,
кулын кушырган,—
мөкиббән
яшәү асылына...

Кемне калдырасың, остаз,
шигърият багына
гаделлек сагына?

Яшәдең дә,
кайтып киттең...
Тукайлар янына.
Инде нишлик? Әйтә тор, дим,
Туфаннарга сәлам.
Шул көннән бит
өстәлеңдә
ятим калды каләм!

II

Әллә безнең авазларны
ишетмәдең бер дә,
Ятим итеп, көпә-көндез
төшеп киттең гүргә...

III

...Зәңгәр күк басуында,
ялгыз көнбагыштай,
Кояш тора иде балкып...
Таш стеналар артында
калды өзелеп
балалар чыр-чуы,
өзелеп калды Вакыт...
Кара кабер кырына киселеп
калды фани яшәү авазлары...
Шунда, ачынып,
бер яшь ана,
назлы бармаклары арасыннан
туфрак коеп
шыбыр-шыбыр,
кычкырды күңеленнән:
— Ышанмыйм!
...Йөрәктә калган хөрмәтем —
һәйкәлем шул сиңа.
Бер уч туфрак —
минем өлешем, Остаз,
Мәңгелек Йортыңа!
Ә мин шунда
тойдым чынлап,
(соңлап!)
кеше киткәч
аңа элегия язганчы,
кирәклеген
исән чакта
гимн багышларга!..

IV

...Менә кайттык...
сине җиргә биреп,—
туфрагына!
Тормыш шау-шулары өскә чыкты.
Каядыр еракта
Мәскәү чаңын сукты.

---

РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВ *(1935)— шагыйрь, «Егерменче яз», «Кызыл усаклар», «Идел-йорт» һ. б. исемдәге егермегә якын шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

тарайдылар нәшрият коридорларында
синең кулны көткән малайлар.
Ачылды, үзгәрде болытлар...
Бөтен сәгатьләрдә
сагышка җигелде минутлар...
Яуды яңгыр,
көн аязды.
Ялгыз кояш, ихлас,
синең кебек якты!
Утырдык без...
бокалларга тозлы яшьне
тутырдык без
мөлдерәмә:
«Кемнәр сине сөйгән,
кемнәр синең яклы...»
Шагыйрь, фронтовик, ата, остаз!
Синсез калды бу яз!
Эфирда, көндәгечә, соңгы хәбәрләр,
Һаман әле география үзгәрә.
Элеккечә
Никарагуада баш кисәләр,
президентлар юхалана...
Гомер шулай булыр,
Сибгат ага.
Эфирда яңгырый җырларың.
Ә бүген туган колхозың,
үтәде сөт планын.
Яшәрделәр тагын
Күлле-Киме үрләре,
моңланды кабат
Сезнең Тукай ягы...
Алары — бар!
(Ул көннән соң инде кем — бар,
кем — юк...)

Тик менә бүген
абындым мин
үзем тудырган бу җырга —
бөтен гомеремә.
Җир буйлап барам, Вакыт буйлап...
Бөтен дөньясында
Син — юк!..

## Аргы якка!

Уелып-уелып аккан елга аша
дер калтырап торган тар басма.
Җилфер-җилфер әби килде ярга,
ялвару бар сүнгән караштa...
И чабаклар сикерә, әйтерсең лә
шаулы җәйне күреп калырга!..
«Аргы якка чыгар әле, улым!»—
Чыктым аны каршы алырга.
«Аргы якка чыгыйм, аргы якка,
калсын бу яр сагынып сөйләргә»...
Шаулый июль, сары мәтрүшкәләр,
җырлый үзән бөтен көйләргә!
«Аргы якка, улым, аргы якка,
бирге якта бүтән моңлансын...»
Тар басмадан, икәү, дер калтырап,
кичтек гүя Әҗәл елгасын.
Чыгып життек менә, күңел булды!..
Арык кулын куеп кашына,
карап торды озак аргы якка,
колак салып гомер агышына.
Ә ул яклар гүзәл! Дәшә тагын,
туеп булмас анда мең яшәп!
Анда очынып сайрый сандугачлар,
ул шомыртлар тагын! Шау чәчәк!..
Яз «мәхшәре» кабат ул якларда.
Кирәк туя күреп калырга!
Яшьлеге дә теге ярда... Тагын
кемнәр килсен чыгып алырга?!.
Язлар гына кабатлана икән,
уртаклаштым ана сагышын...
Минем дә бит, җилләр, еллар аша
Аргы Якка чыгып барышым!

## «Марганцовка»

Камыт суккан канлы чи яралар,
корчаңгыдан койрык калган чукка...
Яраларын майлый Хәйбүш абый,
«әҗәл даруы» аның — марганцовка.
Тайлатканда кулланды ул шуны,
(даруы бер аның сумкасында)
Дүрт аяклы маллар чалкан төште,
үләт базында да — марганцовка!

Сугышка да китте ат җитәкләп,
тояклары — сугыш ызанында...
Дарулар әз — утлы сугыш җөе,—
атлар ауный юллар тузанында,
атлар күмелә туплар тузанына...

Янтауларын ярчык умырып ала
һөҗүмнәргә карап барган хутка.
Йомшак ялын сыйпап, яудашының
ярасына сөрткән — марганцовка.

Шул «тылсымны» күпме тидереп тә,—
шул тылсымны!— атның ярасына,
фәләненче биеклекне менеп,
җанын бирде тәртә арасында!

Кодрәтеннән килсә, әйтер иде лә:
«Атка атма, дошман, ат үземә!»
...Ак болытлар сыеп, тонып калган!—
карап булмый икән ат күзенә!..

Кичер мине, байтал, зинһар, кичер,
сиңа тиде үлем, соң нишләргә?..
Әле бит без, малкай, тиеш идек
Иделләргә кайтып су эчәргә!..

Обозлар һәм юллар — борма-борма,—
киноларда нәкъ без күргән сыман...
Чуар байтал, кичер, син һаман да
ут эчендә кешнәп йөргән сыман!..

Атлар белән туплар тартышкан ул,
дусларын ул гомер җәлләгән лә...
Йөрәгенә китереп суккан кургаш,
ак байталның башын бәйләгәндә...

Ат та елый икән — тамды яше...
Байтал китте алга, туплар сөйрәп.
Җиңүгәме, әллә үлемгәме
илткән юллар борма,
ята көйрәп...

Мәрхәмәтсез икән язмыш: юкса,
исән чыккан иде күпме уттан!..
...Тыныч авыл. Бүген аның улы
кушаматын йөртә—
«Марганцовка»...

Күзге кара төндә, мин, мосафир—
үзем белән калгач бергә-бер,
төн эченнән тавыш бирде бер кош,—
сәлам! диде гүя кемгәдер...

Шомлы җилдә шаулап куйды әрем,
җылымса җил урман куеныннан
абагалар исен алып килде,
мезозойлар чоры ягыннан...

Төн түренә очып барышы иде,—
юл сорадым иптәш коңгыздан.

Карадым мин шунда, нәкъ түбәмдә
чаткыланып янган йолдызга.

Танымыйсыңмы әллә, Сириус, мине?
Мәңгелекнең якты мизгеле
тып-тын гына балкый, ә күңелгә
кычкырып ла янган шикелле ул,
ерактагы Максат шикелле!..

Галәм коесында талир тәңкә
өмет бирде сүнгән күңелгә:
йөргән чакта шушы Яссылыкта
ялгыз түгел,
ялгыз түгел кеше бу җирдә!

## Орчык эрли Ана...

...Өйгә кайткан чакта, мин кичергән
шатлыкның иң зуры —
туган якны тутырып шаулый, әнкәй,
самоварың җыры!

Урман аша аны ишетәм мин—
Күңел шулай тоя!
Орчык эрли әни. Өй түрендә
тупыл мамык коя.

Иске сәгать йөри. Галәм буйлап
очалар егетләр...
Җирне ничә урар иде, әнкәй,
син эрләгән җепләр?!

Син бәйләгән бияләйләр күпме,
бәйләгән оеклар!
Киеп туздыралмас иде, булса
меңләгән оныклар!..

Син эрләгән җептәй, савылып, тормыш
акмады җай гына...
Ничә елга булыр иде җирдә
син эчкән кайгылар?!

Синең өмет иккән кырлар иңе –
таңнарга калырлык!
Күпме җанга җитәр иде икән
син иткән сабырлык?!

Учыбызга алма бүлеп бирдең,
моң бирдең кирәктә.
Күпме бәхет телеп бирдең безгә
бары бер йөрәктән!

Орчык эрли әнкәй — агара чәч.
Ак йон, тәрәш, каба...
Әйтерсең ул, эрләп, шул кабадан
ап-ак чәчен сава...
Орчык эрли ана — үз урынында
туган нигез тора.
Орчык эрли ана — чайкалмыйча
дөнья тигез тора.
Орчык эрли ана ничә еллар —
җанга рәхәт, җылы...
Әнкәй исән —
галәм имин, якты!
Җирдә — Орчык җыры!

# ПРОЗА

**Батулла**

# ЮЛ БУЕНДА ЗӘҢГӘР ЧӘЧӘК

ПОВЕСТЬ

## Алиһә



Жир башына житкәч, Айдаш баба атларны чирәмгә жибәрде. Үзе басу кырыенда моңаеп торучы урак машинасын көйли башлады. Атлар, ара-тирә пошкыра-пошкыра, салмак кына печән кыркый. Маллар тирәсендә канга сусаган бөҗәкләр кайнаша. Хайваннар ач — чирәм чемчергә тели, бөҗәкләр ач — кан эчәргә тели. Бичара малкайлар тибенә, койрыклары белән үз тәннәренә сыдырып-сыдырып алалар. Кигәвеннәр бигрәк тә Рикәкәгә каныга. Рикәкә — күтәрәмнән мантып килүче карт алаша, канэчкечләр белән көрәшүе аңа үтә кыен. Чебенгә атның әллә ни исе китми китүен, кигәвененә дә түзәр иде әле, әмма да бөгәлчәнгә чыдый алмый бичара хайван. Бөгәлчән ябышса, хәле беткән атны түгел, үлеп ята торган хайванны да сикертеп торгызыр, валлаһи! Ярмөхәммәт үлән себеркесе белән атның ике бот арасын чаба, корсак асларыннан бөгәлчәннәрне куа, чебен-черки, кигәвеннәрне сыдырып төшерә. Бичара мал шул чакта рәхәтләнеп куя, тибенүеннән туктап, рәхмәт йөзеннән Ярмөхәммәткә карап ала да ишетелер-ишетелмәс кешни.

Айдаш баба машинаны көйләп бетерде дә арыш арасына кереп китте. Ул зәңгәр чәчәк өзеп алды.

— Һәй, Айдулла абзый! — дип кычкыра уракчылар.— Сузма-а! Вакыт яна, арыш яна! Әнә, көлтә бәйләүчеләр килә-ә!

Айдаш карт ишетмәде дә шикелле. Ул, чәчәктән карашын аермыйча, арыш арасыннан чыгып Ярмөхәммәт янына килде.

— Улым, менә кара! — диде Айдаш баба.— Бу һиндыба чәчәге. Синең кулыңда да һиндыбалар...

Ярмөхәммәт бабасы кулындагы чәчәккә карады: зәңгәр чәчәк касәсендә чык тамчысы күрде ул. Әллә чык тамчысы, әллә чәчәкнең күз яше...

— Әнә,— диде Айдаш карт.— Басу кырыенда да һиндыбалар үсә...

Ярмөхәммәтнең карашы юл буендагы саф-таза зәңгәр чәчәккә күчте: үсеп утыручы чәчәкләр елмая иде шикелле...

— Син озак карап тор, күзеңне йоммыйча кара! — диде бабай.

Бабасының ни әйтергә теләгәнен Ярмөхәммәт аңламады.

---

*Журнал варианты*



*Татарстанның Зәй төбәгендә туып-үскән Роберт Батулла, зур тормыш мәктәбе узып, алтмышынчы елларда әдәбият мәйданына килеп кергән иде.*

*Укытучы, актер, режиссер, педагог, әдип — Роберт Батулланың иҗтимагый һәм әдәби эшчәнлеге әнә шулай күпкырлы. Балалар өчен язылган повесть һәм хикәяләре, мавыктыргыч әкиятләре белән ул әдәбиятта үзенең ныклы урыны барлыгын раслады. Р. Батулла әдәбият сөючеләргә юмор-сатира әсәрләре авторы һәм үзенчәлекле драматург буларак та яхшы билгеле. Аның «Исемем минем Дүрткүз», «Серле сандык», «Чебен гөмбәсе», «Алып батыр маҗаралары» һ. б. күп кенә китаплары укучылар тарафыннан яратып укыла.*

*Бүгенге көндә Р. Батулла Республика драма һәм комедия театрында баш режиссер булып эшли.*

*Шушы елның мартында Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе язучы Роберт Батуллага 50 яшь тулды. Аны күркәм юбилее белән котлыйбыз һәм иҗатында яңа уңышлар телибез.*

Вакытлар узар, еллар артта калыр, соңыннан ул барысына да төшенер. Бабасы аңар:

—Һиндыба чәчәгенә озак карап тор, күзеңне йоммыйча озак кара дигән сүзе астына: бу чәчәкне чәчәккә дә санамыйлар, бу чәчәктән такыя да үрмиләр, бу чәчәкне өзеп, өстәлгә дә утыртмыйлар. Шулай да син, Ярмөхәммәт улым, игътибар белән, күңел күзең белән кара һиндыба чәчәгенә! Шунда син һиндыбаның серле матурлыгын күрерсең! — дигән мәгънә салып әйткән булган икән.

«Матурлыкка тел тидерергә ярамый. Матурлык турында сөйләшергә дә ярамый. Матурлыкка карап, сүзсез генә сокланалар».— дигән мәгънәдә булган икән Айдаш картның шушы ике авыз сүзе.

— Күңел күзең белән кара, улым, күңел күзең белән!

Ярмөхәммәт бабасы әйткәннәрне ишетми иде инде. Ул могҗизалар дөньясына керә барганын тойды.

Юл буйларында, арыш басуы эчендә үсеп утыручы озын сабаклы, сирәк чәчәкле бу үсемлекне мең тапкыр күргән Ярмөхәммәт, мең тапкыр күреп тә аңа игътибарсыз узган Ярмөхәммәт бүген бер ачыш ясады: һиндыба иң матур чәчәк икән ләбаса!

Ярмөхәммәт башта сыек зәңгәр төстәге унҗиде касә-яфрак санады. Чәчәк касәләре кинәт зурая башлады. Чәчәкнең төсе күз алдында үзгәрә, тагын да ачыклана бара. Җанлы нәрсә кебек, чәчәк сулый. Касәләрдә миһербан нуры балкый. Чәчәк тагын да зурая. Бөтен дөнья зәңгәрсу ефәккә уранган да Ярмөхәммәтне — ихтыярсыз Ярмөхәммәтне салмак кына бөтереп — үзенең салкынча нәфис касәләренә төреп, эчкә, серле чәчәк дөньясына алып керә.

Әллә чәчәк зурая, әллә Ярмөхәммәт бәләкәйләнә: бер мизгелдән соң Ярмөхәммәт, чәчәк саршыны җыеп йөрүче кырмыска кебек, эчкә узды.

Чәчәк дөньясына килеп эләккәч, Ярмөхәммәт башта каушап калды. Бу дөнья шулкадәр зур икән, зур да, таныш та түгел. Кая барырга белмичә, байтак аптырап торды Ярмөхәммәт. Ул сыек зәңгәр табигать эченә кергәнен аңлады. Бу матур төсне чагыштырыр өчен бүтән төс юк. Күк йөзенә охшаш табигать бу. Ләкин күк йөзе тоныграк була бит ул.

Бала чыгарганнан соң сыерчык ватык йомырка кабыкларын тышка ташлый. Яз көне ул кабыкларны Ярмөхәммәт җыеп алган иде. Җыеп алды да, өйгә алып кереп, бергә кушып ялгады — бербөтен йомырка барлыкка килде. Куша алмаганнарын ул гөл савытындагы туфракка каплап куйды. Гөлнең ямь-яшел сабаклары астында, кап-кара туфрак

өстендә зәңгәрсу күкәйләр тезелешеп утыра. Шулай ошый Ярмөхәммәткә. Шулай матур була.

Чәчәк эчендәге бөтен табигать әнә шул зәңгәрлектә иде.

Монда җиләс, салкынча зәңгәрсу һава. Зәңгәрсу тавыш чыгарып, зәңгәрсу чишмә ага. Зәңгәрсу чәчәкләр өстендә зәңгәрсу күбәләкләр оча. «Адәм заты бармы икән бу дөньяда?»— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Шулчак:

— Мин монда-а! — дигән тавыш ишетелде.

Ярмөхәммәт як-ягына каранып алды, ләкин берәүне дә күрмәде.

— Игътибарлырак кара-а,— диде кемдер.

Ярмөхәммәт тавыш ягына текәлебрәк карады. Чишмә янында бер кыз басып тора. Кызның өстендә зәңгәрсу күлмәк. Әйтерсең лә бу күлмәкне юл буендагы һиндыба чәчәгеннән теккәннәр.

Зәңгәрсу кыз Ярмөхәммәткә таба атлады. Ул кыймылдамаган булса, Ярмөхәммәт аны бөтенләй күрмәс иде. Зәңгәрсу болын эчендә, зәңгәрсу чишмә янында зәңгәрсу күлмәк кигән бу кыз күренмәскә әйләнә.

— Ярмөхәммәт! — диде зәңгәрсу күлмәк кигән кыз.— Син бәхетле кеше. Син чәчәк эченә үтә алдың. Бирегә үзу теләсә кемгә тәтеми. Син табигатьнең иң матур почмагын күрәсең. Син табигатьтәге иң матур төс — зәңгәрсу төснең серенә төшендең.

— Кайдадыр күргәнем бар,— дип уйлады Ярмөхәммәт.— Кемгә охшаган соң чәчәк эчендәге бу кыз?

Күпме генә хәтерләргә тырышса да, Ярмөхәммәт чәчкә кызның кемгә охшаганлыгын исенә төшерә алмады.

— Кем син? — дип сорамакчы иде Ярмөхәммәт, әмма сулыш алырга да өлгермәде, чәчәк кыз:

— Мин Алиһә булам! — диде.— Син мондагы зәңгәр таулар, зәңгәр болыннар, зәңгәр урманнарда һич курыкмыйча йөри аласың. Зәп-зәңгәр диңгезләрдә туйганчы су коена аласың... Бу дөнья синеке, синеке генә... Зәңгәр диңгез ярыннан сине берәү дә кумас.

— Нигә минеке генә? Ә син? — диде Ярмөхәммәт.

Чәчәк Алиһәсе елмайды. Аның ике бит очында чокырчыклар хасил булды. Алиһәнең тешләре шулкадәр ак, хәтта озак карап торсаң, алар зәңгәрсу төскә керә башлый.

— Ничек алай икән ул? — дип уйлады Ярмөхәммәт.— Артык ак булганга шулай зәңгәр төс сирпеләме аларга? Караңгыда озак яткан нәрсәләр кинәт яктылыкка, һавага чыкса, тиз үзгәрә. Әллә бу чәчәк кызы бик сирәк елмаямы икән?

Бит очлары чокырлы апа бар бит ул. Үзебезнең авылда бар, тешләре дә шулай ап-ак, зәңгәрсу ак дип һаман баш вата Ярмөхәммәт. Факия апа! Ә, юк... Факия апаның бит алмаларында чокыр бар, тик Факия апаның тешләре болай ак та, тигез дә түгел. Факия апаның азау тешләре сары. Факия апа шул азауларын чистарта-чистарта иза чигә. Күмер белән дә агартып карады, киндер белән дә ышкыды. Юк, булмады. Бабай: юк белән маташма, кызым, ул тешләр шулай туган инде, аларны агарта алмассың, дигәч, Факия апа утырып бер елады да кабат теш чистартмас булды.

Юк, чәчкә кыз Факия апага гел дә охшамаган!

— Мин чәчәкнең җаны! — диде Алиһә.— Ә син кеше. Син чәчәк

эчендә берүзең. Берүзең генә булырга тиеш син!

— Мин монда Галимхан белән Рәүфне дә алып керсәм...— дип

башлады Ярмөхәммәт.— Без монда өчәү булыр идек.

Чәчәк Алиһәсе тагын елмайды. Елмаю белән берочтан, колакларга гаҗәеп матур бер тавыш сирпелеп узды. Шул кадәр саф-чиста тавыш иде ул. Песнәкнең сайравында да, сандугач җырының бер өлешендә дә, тургайда да бар ул тавыш, ләкин бу хатын-кыз тавышы, назлы, миһербанлы, мәхәббәтле тавыш иде ул.

Ярмөхәммәт Алиһәнең көлгәнен ишетте. Бит очындагы чокырчыклар бу юлы тирәнрәк күренде.

Алиһә чалкан ятып, елмайган килеш йоклый торгандыр дип уйлады Ярмөхәммәт. Их, аның чалкан, ятып йоклаганын күрсәң иде! Күрсәң иде дә, озак итеп, рәхәтләнеп карап торсаң иде. Әгәр дә Алиһә йоклаганда аның бит чокырчыкларына чәчәктәге чык тамчыларын салсаң, түгелер идеме икән? Түгелмәс иде. Билләһи түгелмәс иде. Түгелә калса, чык тамчыларын Ярмөхәммәт җиргә төшермәс иде.

— Бер чәчәк эченә бер генә кеше сыя ала! — диде Алиһә.— Бик теләсәң дә, синең дусларың монда үтеп керә алмаслар иде. Бер чәчәкнең бары тик бер генә алиһәсе, бары тик бер генә хуҗасы була ала... Син хәзер үз дөньягызда юл кырыендагы зәңгәр чәчәккә карап торасың. Анда сезнең үз дөньягыз, үз вакытыгыз. Син караган чәчәккә берьюлы өч түгел, ике кеше дә карый алмый. Хәзер син минем вакытым — чәчәк вакыты белән яшисең.

Алиһә кулын сузды. Ярмөхәммәтнең кулы ирексездән Алиһәгә таба тартылды. Ике кул тоташты. Ярмөхәммәтнең тәне буйлап кайнар кан йөгерде. Башта ул аны чишмә тавышыдыр дип уйлаган иде. Соңра аңлады, ул үз канының акканын ишетеп тора икән.

Алар җитәкләшеп зәңгәр тауга менеп киттеләр. Тау башыннан бөтен табигать күренә. Болыннар, тугайлар, урманнар, елгалар — барысы да зәңгәр. Күп төрле зәңгәр. Болыннарда меңләгән чәчәк бар. Бөтенесе дә зәңгәр, зәңгәр булсалар да, бер-беренә тач охшаш түгел. Күк төслесе, күе зәңгәр, сыек зәңгәр, зәңгәрсу, төтен төслесе; аларның һәммәсеннән дә тагын күп төсмерле буяулар аерылып чыга. Меңләгән зәңгәр күбәләкләр дә бер-береннән нык аерыла.

Таудан алар урманга таба китте.

— Табигатьтә җиде төс бар,— диде Алиһә урман юлы буйлап барганда.— Ләкин җиде төснең һәрберсе бихисап күп төсмерләргә аерыла ала. Игътибарсыз карасаң, бөтен дөнья зәңгәр төстән генә тора кебек. Янәшә куйсаң, син күрерсең: ике бер төсле күбәләк тә, ике бер төсле чәчәк тә юк монда.

Шулай хозурланып алар озак йөрде. Алиһә Ярмөхәммәтне үз өенә алып кайтты. Алиһәнең ханәкәсе, ягъни ял өе, урман белән елга тоташкан тугайда иде. Алиһә бердәнбер кунагын чәчәк касәләренә җыелган чык белән сыйлады. Шушы бербөтен гүзәллек әтрафында алар икәүдән-икәү генә татлы ширбәт эчеп утыра. Һәр хәрәкәтеннән тәм табып, Алиһә ашыкмыйча гына, озак итеп, аеруча бер канәгатьлек белән чык тамчыларыннан чәй әзерләде. Чәйне ул изге эш башкаручы фәрештәдәй тәфсилләп, бер касәдән икенчесенә авыштыра-авыштыра ниндидер тылсым догалары укыгандай, сөйләнә-сөйләнә пешерде. Аннан соң янә чәчәк-касәләргә бүлеп чыкты. Әзер булгач, иң беренче касәне Ярмөхәммәткә сузды. Изге вә олы кешегә сузган кебек, зурлап, түбәнчелек белән тез йөгенеп, баш иеп тәкъзим ясап, ике куллап сузды Алиһә касәне. Ярмөхәммәт ике куллап касәне алды. Алды да рәхмәт йөзеннән җиңелчә генә баш какты. Ярмөхәммәт касәне иреннәренә китереп җиткергәч кенә Алиһә үз касәсен тотты. Ләкин эчәргә ашыкмады. Ул Ярмөхәммәтнең эчә башлавын көтә иде. Ярмөхәммәт сакланып кына иреннәрен касәгә тигезде, сизелер-сизелмәс кенә ике куллап касәне авыштырды да бер йотым чәй уртлап куйды. Ярмөхәммәт иләһи тәм татыды. Шунда гына Алиһә үз чәеннән авыз итеп куйды. Ярмөхәммәтнең ләззәт тойганын Алиһә күрде. Ул ясаган чәйне, ул әзерләгән ризыкны аның бердәнбер кунагы бик тә ошатты. Чәй әзерләүчегә шуннан да зур шатлык юктыр ул.

Чәйнең бик тә тәмле икәнлеге, Ярмөхәммәткә бик тә ошаганлыгы күренеп тора; күренеп торса да, Ярмөхәммәт чәчәк-кызның тагы да күңеле булсын дигәндәй, әйтеп куйды:

— Чәең тәмле! — диде.

Алиһә елмайды.

— Мин бик шат...

Ярмөхәммәт бу сүздә ике мәгънә барлыгын сизде. Ни өчен Алиһә шат? Ул ясаган чәйнең Ярмөхәммәткә ошавыннанмы? Әллә менә шулай Ярмөхәммәт белән икәүдән-икәү генә чәй эчеп утыргангамы?

— Минем сыем сиңа ошаганга! — диде Алиһә, әйтерсең лә ул Ярмөхәммәтнең ни уйлаганын укып утырган.— Әгәр ошамаган булса, мин хәсрәттә калыр идем. Кешегә шатлык китерүдән тәм табу адәмнәрнең максаты.

— Димәк, адәмнәр үзләренә шатлык-тәм табу өчен генә бүтәннәргә яхшылык кыла? — диде Ярмөхәммәт үзе дә сизмәстән.

Алиһә, тамагына кылчык кадалгандай, кинәт төртелеп калды. Елмаюы юк булды. Ярмөхәммәт аның йөзендә каушап калу билгеләре күрде. Ләкин Алиһә тиз генә үзен кулга алды, уңайсыз итеп елмайды.

— Дөрес бит инде,— диде Ярмөхәммәт аклангандай.— Миңа ошасын өчен син чәй тәмләдең, чәй миңа ошады. Чәй миңа шатлык китергәнгә син шатландың. Син шатланганга мин сөendем. Мин сөенгәнгә син куандың...

— Дөрес! — диде чәчәк-кыз.— Син куанганга мин, мин куанганга син бәхетле. Бәхет түгәрәк булсын өчен шулай кирәк. Бәхет чылбырының бер бөҗрасы өзелсә, бәхет мөкәммәл була алмый, Ярмөхәммәт. Синең яшь зиһенең катлаулы мәсьәләләргә яшьтәшләреңнән иртәрәк тотынган. Аңладым... Яхшылык кылуның төбендә дә алыш-биреш ятамы, юкмы дигән фикер килде синең башыңа. Ягъни үзеңә сөенеч эзләп, мин сиңа сөенеч бирәм. Булсын! Кешегә тән җәзасы, кайгы-хәсрәт китереп, үзеңә рәхәт тапканчы, кешегә сөенеч биреп, ләззәт алу бихисап мәртәбә яхшырак.

Ярмөхәммәтнең җыерылган кашы язылды. Алиһә елмайды. Ярмөхәммәт, артык эчкәре кереп адашканлыгын аңлады да сүзне икенчегә борды:

— Матур апа, син нигә ялгызың гына яшисең?

— Син миңа «апа» димә, Ярмөхәммәт. Мин Алиһә булсам да, бары тик шушы чәчәк эчендә генә баш җан. Ә син миннән олы. Син чәчәктәге мохиткә дә, миңа да хуҗа.

Алиһә бу сүзләрне бик зур кыенсыну белән әйтте сыман. Теләмичә әйтте кебек. Алиһә күңелендәге билгесез бер сагыш Ярмөхәммәтнең күңеленә дә төште. Ямансу мохит барлыкка килгәнне Алиһә сизенде. Ярмөхәммәт Алиһәнең елмаюын тели иде.

Алиһә елмайды.

Менә болай рәхәт Ярмөхәммәткә.

— Ә кем дип дәшим соң мин сиңа? — диде ул кыюланып.

— Чәчкәм диген. Яки Алиһәм дип әйт!

— «Чәчкә» белән «Алиһә» азагына «м» авазы кушсаң, «минем чәчкәм», «минем Алиһәм» килеп чыга бит, алай ярыймы соң.

— Ярый, Ярмөхәммәт, ярый. Нәкъ шулай әйтергә зарури. Син хуҗа монда.

— Күпме яшисең син чәчәк эчендә?

— Минем яшем юк... Мин һәлак булсам, башка чәчәктә яралам. Мин сине бик озак көттем... Шулай да син бик вакытында килдең минем янга.

— Тугыз ел элек мин бит әле дөньяда да юк идем, матур апа!

— Минем өчен син бар идең инде, Ярмөхәммәт. Менә син хәзер бардан да баррак. Мин ялгыз түгел. Минем бу дөньямны күрүче бар. Ул син — Ярмөхәммәт. Чәй әзерләргә, шербәт куярга минем сердәшем бар. Ул син.

— Ә нигә мин? Монда башка бер кеше кергән булса...— диде дә Ярмөхәммәт кинәт туктап калды. Ул:

«...Син барыбер бәхетле булыр идеңме?»— дип сорамакчы иде.

Алиһә Ярмөхәммәтнең ни өчен төртелеп калганын аңлады, ахрысы, аның битендәге чокырчыклар тигезләнде. Ул күкрәгенә төшкән толымнарын берәм-берәм артка чөйде. Алиһәнең чәче чем-кара икән лә. Шул кадәр кара, шул кара толымнарның зәңгәр булып күренгәнен Ярмөхәммәт шунда гына күрде, аңлады. Моңарчы ул Алиһәнең битенә генә карап утырган икән.

— Димәк, сиңа барыбер... чәчәккә кем үтеп керсә дә барыбер...— дип уйлады Ярмөхәммәт. Шулай уйлады да, шундук ник уйлаганына үкенде дә. Чөнки аның иреннәре аның уйларын пышылдап тора икән.

Алиһә дәшмәде. Бу пышылдау сорау идеме, әллә Ярмөхәммәт үз уйларын раслап әйттеме бу сүзләрне — Алиһә аермады шикелле. Шуңа күрә, ишетмәмешкә салышты. Ярмөхәммәт Алиһәнең шулай дәшми утыруын үзенчә шәрехләде. Алиһә:

— Әйе, Ярмөхәммәт, минем янга кем үзса да барыбер. Аның белән дә мин бәхетле булыр идем! — дип әйтте кебек.

Шулчак Алиһә телгә килде.

— ...ләкин чәчәкне күңел күзе белән күрүчеләр бик аз. Юк дип әйтерлек: күрүче булса да, чәчәк эченә узарлык шигъри куәткә ия адәмнәр күп түгел. Чәчәк эченә узу ихтималияте шулкадәр аз ки, меңләгән чәчәк алиһәләре картаеп, ялгыз гына дөнья куя. Язлар килгәч, алар зур өметләр белән тагын терелә. Үз адәмнәрен көтә-көтә саргаеп, корып янә дөньядан китәләр.

— Мин сиңа: синең чәчәк дөньясына миннән башка берәү дә кермәсен! дип әйтә аламмы, Алиһә апа?

— «Апа» димә, зинһар!

Ярмөхәммәт Алиһәнең кырыс була алганын да төшенде. Бер мизгелгә генә җыерылып алган кашлар кире язылды, Алиһәнең бит очында сизелер-сизелмәс кенә чокыр хасил булды.

— Әйтә аласың... Ләкин мин чәчәкне бикләп куя алмыйм. Серне белеп, чәчәк эченә узарга тели икән, ул кешегә дә бу дөнья ишеге ачык.

Алиһә бу сүзләрне суынып беткән чәйгә карап әйтте. Эчелеп бетмәгән чәй касә төбендә чайпала да чайпала. Шул сыеклыкны чайпалдыру нигә кирәк булды икән Алиһәгә?

— Ә мин? — диде Ярмөхәммәт Алиһә әйткәннәрне башыннан кичергәч.— Мин башка чәчәкләргә керә аламмы соң?

Алиһә җанланып китте, ул башын күтәрде, эчелеп бетмәгән касәне келәмгә куйды да матур итеп елмайды.

— Әлбәттә, керә аласың, Ярмөхәммәт. Бу бары тик синең ихтыярыңнан гына тора. Син, һичшиксез, шулай эшләргә тиешсең. Болыныгызда, урманнарыгызда бихисап чәчәкләр. Эчләрендә сине зарыгып көтүче алиһәләр...

— Нигә шулай соң ул, Чәчкәм? Берәүләргә йөзләгән алиһә дә, икенчеләргә берәү дә юк.

— Аяныч ки, Ярмөхәммәт, күп адәмнәрнең күзе чәчәкләргә төшми. Күзе төшсә, күңеле төшми. Кешеләрнең күңел күзләре сукыр булганга алиһәләр, чәчәкләр гаепле түгел, Ярмөхәммәт...

Ярмөхәммәт артык сорашмады. Алиһә дә сүзсез калды.

Дөнья тулы меңләгән чәчәкләр, чәчәк саен бер алиһә. Алиһә саен серле матур дөнья. Җиһан тулы адәм балалары. Мәшәкатьләрдән аерылып, бер мизгелгә генә, бер мәлгә генә туктап, чәчәккә иелергә башларына да килми бәндәләрнең. Күпме алиһә көннәрнең берендә чәчәкләр эчендә корып һәлак була. Күпме адәм шул матурлыкны ача алмыйча дөнья куя.

Ярмөхәммәт Алиһәгә төбәп карады. Алиһә дә күптәннән инде Ярмөхәммәтне күзли иде. Ярмөхәммәтнең һәр хәрәкәтен ул күрә, хәрәкәтен генә түгел, сулыш алганын да саный кебек. Ике караш туп-

туры килеп бер-беренә бәрелде. Карашлар очрашкан мәлне үк нидер булды. Ярмөхәммәт үзенең кем икәнен онытты, колаклары ишетмәс булды. Аның өчен әйләнә-тирә бушлык иде. Бернәрсә күзгә чалынмый. Алиһә үзе дә юкка чыкты. Бары тик зәңгәр керфекләр урап алган күл уртасындагы зәңгәрсу утрау гына бар иде. Ул утрау — Алиһәнең күз алмасы. Күз алмасы коега әверелде. Әнә шул төпсез кое, упкын кебек тирәнлек Ярмөхәммәтне әкренләп йота. Зәңгәрсу төпсезлек тирәнәйгәннән-тирәнәя, киңәйгәннән-киңәя. Ярмөхәммәт үзенең кеше булудан туктаганын чамалады. Ул вак бөрчекләргә әверелеп, күз эчендә таралганын тойды. Бәхеттән шашып көләсе килә. Рәхәттән үкереп елыйсы килә. Сүз белән аңлатып бетерә алмый торган бу ләззәтне бөтен дөньяга кычкырасы, аңлатасы килә. Соңра аңлатасы килү теләге дә эреде. Ярмөхәммәт бардан юкка әйләнде.

Шушы серле мохиттә ул озак булгандырмы, юкмы, әйтә алмас иде, бардан юк булган Ярмөхәммәт инде яңадан үз хәленә кайттым дигәндә тавыш ишетте:

— Улым, ат башын тот!

Ярмөхәммәт, чәчәктән аерылып, бабасына карады. Карады да сәерсенеп китте. Ул әле дә булса Алиһә кулларының дымлы җылысын тоя иде. Ә монда челлә эссесе. Ә монда кыр, бабай, урак машинасы. Машинага җигелгән атлар...

— Аллага тапшырып, урак башларга вакыт! — диде Айдаш карт.— Син Юрга башыннан тотып барырсың. Ул ызан аңлый торган хайван түгел, бичара.

— Айдаш бабай! — дип кычкыра хатыннар.— Башла-а! Башла-а!

Ярмөхәммәт зәңгәр чәчәккә янә карады: аның каршысында гаплади бер кыр үләне, һиндыба чәчәге, искән җилдә салмак кына атынып утыра.

Кайда күрде соң ул чәчәк Алиһәсен? Кайда? Бәлки, төшендә күргәндер? Ихтимал!

— Әйдә, Ярмөхәммәт улым, аллага тапшырдык! — диде бабасы.

Ярмөхәммәт кигәвеннәр көенә биеп торучы атның тезгенен алды.

— Һәйдә-ә, малкайлар! — дип кычкырды Айдаш баба. Вәлүк шалтыраган тавыш ишетелде. Ярмай авылында урак башланды.

Йөз атлам җир киткәч, Ярмөхәммәт артына борылды. Алар артыннан диярлек үк икенче лобогрейка да арыш урып килә.

— Һәйдә, малкайлар! — дип кычкыра Айдаш баба.

Ярмөхәммәтнең колагы төбендә үк атның авыр мышнап машина тартканы ишетелә. Ярмөхәммәт аяк астына карый.

Зәңгәр һиндыбалар ат тояклары астында таптала. Кайберләре янтаеп, кыйгаеп кала. Уракка эләккәннәре киселеп, арыш учмалары белән җиргә ята. Уракка эләкмәгәннәре, исән калганнарына сөенгәндәй, чайкала. Арттан килүче урак машинасы аларны да кисәчәк. Бары тик арыш басуыннан читтә, юл кырыенда үскән зәңгәр чәчәкләр генә озын булып, тырпаеп калачаклар.

## Айдаш баба

Айдаш карт бер алашага, бер биягә карап торды да тирән итеп көрсенде. Көрсенү түгел иде бу, ыңгырашу иде. Кутәрәмнән тернәкләнеп җитмәгән малларны кызганамы ул шулай авыр сулап? Үткән гомерен искә төшереп торучы Рикәкә белән Юргатка караган саен ул, үзе дә сизмәстән, әнә шулай пошаманга кала.

Мисбахетдин агасының карап торган шушы ике тае бар иде колхоз оешканда. Аксакал дөньяның кая барганын тиз аңлады.

— Бар, улым,— диде ул баш баласы Мәснәвигә,— Икесен дә сәвиткә илтеп бир. Юргатны да, Рикәкәне дә...

Икесе дә юртаклар нәселеннән. Казан ягыннан, Ишморатовлар заводыннан Мисбахетдин үзе кайтарткан иде. Рикәкә тирә-юньдә бер чаптар иде. Сыртлы чанага утырып та өлгермисең, урыныннан алып оча. Рикәкә арт санын сикертеп чапмый, ул юырта гына. Аның йөрешенә карап сокланмаган кеше юк иде заманасында. Күкрәк кагып чаба, капканы күкрәге белән яки тәртә башы белән генә бәреп, ишегалдына керә торган иде. Җил инде, җил! Аңлы хайван, үз кешеләренә генә йөгән кигездерә. Ят кеше килә башласа, шомрая, күзләрен акайта, танау тишекләрен киерә дә арты белән борыла, гүя ул:

— Якын килмә! Тибеп үтерәм! — ди иде.

Рикәкә белән Мисбах абзыйның улы Мәснәви Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайтты. Аклар ягына разведкага гел аны җибәрә торган булганнар. Акларның каравылы сизенеп алса да, куып җитә алмыйлар икән чаптарны. Менә шуннан соң инде айгырга Рикәкә исеме ябышып калды.

Айдаш карт аңа аеруча ягымлы итеп:

— Ривәлүтсия аты ул Рикәкә! — ди.

Атларын да бирде Мисбахетдин карт, сыерын да тапшырды, шулай да аны барыбер авылдан сөрделәр. Сабирның кулы уйнады инде монда. Җаен таптылар. Имеш, Мисбахетдиннең өе ярлы крәстияннекеннән биегрәк булган. Ике ат тоткан. Димәк, кулак!

— Кызык бу дөнья, кызык. Җиргә берегеп үскән тырыш кешенең өе җимерек булырга тиеш идеме икән? Андый кеше атсыз җир сөрергә тиеш идеме икәнни соң?

Аңлаганнары дәшмәде, аңламаганнары иске чабата ата-ата Мисбахетдинне, хатынын, балаларын авылдан куды.

Хуҗасы киткәч, Рикәкә бер җанына урын таба алмады бичара. Араталарны тибеп сындырды, күкрәге белән араннарны җимереп, ялан-нарга чыгып, урам-тыкрыклардан хуҗасын эзләде. Анасыннан аерылган колындай, кызганыч итеп кешни-кешни тилмерде. Үзе һичкемне якын җибәрми. Шуннан Сабир әйтте:

— Айдулла абзый, теге җен айгырны тотып бир әле! — диде.

Айдулла тотты айгырны, тотты да җигеп тә бирде Сабирга. Ләкин Рикәкә авызлыгын тешләп, дулап, тарантасларны җимереп, Сабирны баганага сылап, үз ишегалдына — ятим калган йортка кайтты.

Аны тагын тотып карарга булдылар. Айгырга карарга куркыныч иде: күзләрен кан баскан, ул буйсынырга теләми, тотарга кысрыкласалар, ярдан сикерер, үзен-үзе ташуга ташлар кебек җенләнгән иде. Юк, тоттырмады, тотсалар да, тәртә арасына кермәде, тәртәгә кертсәләр дә, Сабирны, аның куштаннарын тартып йөрергә теләмәде. Тешләште, тибеште, аякларын имгәтеп, иреннәре авызлыктан ертылып бетте.

Айдаш өйдә юкта айгырны унлап кеше, лапаска кысрыклап, печкәннәр. Шуннан соң Рикәкә тынды. Күзләрендә ярсу ут чагылып китсә дә, ул тиз генә ыргып чабу уеннан ваз кичә, мескен кыяфәттә башын җиргә ия торган булып китте. Аның бу кыяфәтен күреп, Айдулла белән Хисбулла тыела алмыйча еладылар.

Кызык бу дөнья, кызык.

Колхозга тапшырылса да, атлардан, сыерлардан хуҗаларының үчен алу гадәткә кергән иде ул чагында. Мисбахетдин белән Мәснәви үчен Рикәкә белән Юргаттан алды Сабир. Урта хәллеләрдән алынган ат колхоз милке түгел, фәлән байның аты, шуңа күрә, аны «бизәфчәки» җигәргә, хәлдән тайганчы эшләтергә тырышалар иде.

Бу караш Сабирда әле һаман да яшәп килә. Ул әле һаман да бу атларга Мисбахныкылар дип карый бугай. Күтәрәмгә калсалар да, фураж бирми, бирдерсә дә, чеметемләп кенә эләгә. Айдулла карт аркасында гына бу ике ат җан саклап килә. Агасының атлары булганга түгел, Айдулла аларга үзе «киндек бабасы» булган иде. Шуңа якын итте ул аларны. Икесен дә үзе дөньяга кабул итте.

Ярмөхәммәт тә атларны сөя, аларны тәрбия итәргә тырыша.

Айдаш карт бик канәгать иде онытынан.

Гомере буе елмаюның ни икәнен татымаган Айдулла, гомере гел сагыш-моң эчендә узган Айдулла бүген шат. Ләкин аның шатлыгы йөзенә чыкмады. Ул ни өчендер кинәт кенә күккә карады, кулын куеп, кояшка карап торды да әйтте:

— Яңгыр явар, ахрысы,— диде.

Ярмөхәммәт аның бу сүзләрен ишетмәде. Ул сарут себеркесе жыя башлады. Кыска ялга туктагач, Айдаш карт онытына дәште:

— Улым, атлар бик тынгысызлана, кигәвеннәрен куа тор! — диде.

Ярмөхәммәт, алаша белән биягә ябышкан канәчкечләрне сыдырып төшерергә ниятләп, маллар янына килде. Мунчада чапкан кебек итеп, ул атларны алмаш-тилмәш чәбәкли башлады. Рикәкә аңлатып бетергесез рәхәт кичерә иде. Бичара хайван ашавын онытып, оеп тора. Ат иплән кенә кешнәп куйды.

— Ай рәхмәт, Ярмөхәммәт, алтын кулларыңның игелеген күр, мин мәхлукның җәфаларын аңлаганың өчен аллаң сиңа олы бәхет бирсен! — дигән сүзе иде, ахрысы.

Рикәкәдән Ярмөхәммәт Юргатка күчте. Юрга бия шарт-шорт тибенә, холыксызлана.

— Сабы-ыр,— диде Ярмөхәммәт.— Күрмисеңмени, дошманнарыңны куам.

Бераз сулыш алгач, тагын ура башладылар. Бик күп урган булырлар иде дә, урак машинасы ватылды. Әлек үк чатнаган уракның бер теше сынып чыкты да эш тукталды.

— Ярый әле ватылды,— диде Айдаш карт үзалдына.— Атлар аяктан егыла иде. Рәхмәт төшкере. Вакытында ватылды. Юкса ат кызганып урактан туктасаң, теге Чучка Сабир әлә-танагыңны калдырмас.

Айдаш карт утыргычыннан төште.

— Улым Ярмөхәммәт, кайтып китәргә туры килер. Берочтан анаңа да, Факиягә дә әйт, әбәтне бүген өйдә генә ашарбыз.

— Нигә, бабай? Уракны аны Рәван абый хәзер төзәтеп бирә! — диде Ярмөхәммәт.

— Урак төзәлсә дә, урып булмаячак, улым!

— Ни өчен?

— Озакламый яңгыр явар. Төштән соң урып булмас.

Бабасы әйтсә шулай була да куя инде ул. Күк йөзендә бер уч болыт юк, бабай, әнә, яңгыр булачак, ди.

Айдаш карт атларны тугарды да, сынган уракны салдырып, кулны кисмәс өчен уртасын иске чүпрә белән урады:

— Бар, улым, уракны алачыкка илт! — диде.

— Аннан тиз генә монда чабыйммы? — дип сорады Ярмөхәммәт.— Әбәт ашарбыз да бу алны урып бетерербез.

— Әбәтне өйдә ашарбыз. Юргатны дывурга менгез,— диде Айдаш карт.

— Көн чалт аяз бит, бабай, бер болыт юк,— дип аптырады бала.

— Шулай инде, явачак,— дип, бабай малайны атка менгезде дә урак белән ачкычлар төрелгән янчыкны тоттырды.

Малай бер кулы белән тезгенне тотып, икенче кулы белән уракны, янчыкны кочаклап, авылга таба китте.

Айдаш карт тирә-якка карап алды. Күк йөзе зәңгәр. Кояш өскә менә, өскә менгән саен челлә зеңли. Торган саен зеңгелдәү арта, көчәя. Арыш арасында чикерткәләр колак яргыч итеп чырлый. Балкортлары, шөпшәләр, төклетуралар, бөҗәннәр үтә көчле аваз чыгарып кайнаша. Бөҗәкләр кабалана. Кемдер аларны артларыннан ашыктырып, куркытып тора кебек. Бөтен табигать борсызлексез зеңли. Җир башындагы күлдә бакалар кинәт беравыздан бакылдый башлады. Тирә-юнь мең төрле тавышлар белән мөлдерәмә тулды. Кинәт башланган бакалар

хоры кинәт кенә өзелде. Юан тавыш белән фырылдап «маржа көянтәсе» очып китте. Кибеп беткән чыпчык борчагы шартлап ярылды. Орлыклары сабактан читкә сибелде. Орлыктан бушагач, кузак кабыгы ике якка аерылып, сырлы мөгез шикелле бөгәрләнеп калды.

— Кыздыра-а, ява-ар... — диде дә Айдаш баба урак машинасының тәртәсен, вәлүкләрен күтәртеп куйды. Берәр ачкыч-мазар калмаганмы дигәндәй, ул машина тирәли әйләнеп чыкты да авылга таба юл алды.

Рикәкә хуҗасы артыннан ияргән. Бу аңлы хайванны тезгеннән җитәкләп йөртмәсәң дә була, тезгене сагалдырыкка бәйләнгән. Ат үзе шулай тыңлаучан.

Картның уйлары явачак яңгырда түгел. Ул Ярмөхәммәт турында уйлый. Айдулла карт оныгы Ярмөхәммәтнең табигатькә, җиргә мәңге бирелгәнлеген аңлады бүген. Шуңа күрә ул егетләрчә җиңел атлый. Айдаш артыннан ат көчкә өлгерә.

Айдаш бабаның куанычын берkem дә сизә алмас иде. Өйгә кайткач та ул кычкырып көлмәде, сикереп төшеп биемәде.

— Килен, мунча ягарга кирәк! Факия, су ташып куй! — дип тә кычкырмады.

Җилтерәтеп кайтып керде дә, кул очына чиләк асып, уникe тапкыр суга барды. Инештән генә, бакча башыннан гына булса да, туксан яшьлек картка тыкрык тавыннан менү бик тә хәтәр икәнен белеп, кайнатасына булышырга дип, Нурлыгаян ишегалдына чыкты. Чыкты да, авызын яулык почмагына яшереп, кулын Айдаш карт кулындагы буш чиләккә сузды. Бу аның:

— Әткәй, куй бу эшеңне! Өйдә хатын-кыз юкмы? — дип әйтүе иде.

Килене тел яшергәнне Айдаш карт бик ошата, чүтеки ата итә, биатасын зурлый дигән яшерен уй картны гомере буе куандыра килде. Айдаш баба каршысында Нурлыгаян кычкырып сөйләшсә дә, яулык капламыйча, авыз күтәреп, акырып кычкырса да булдыра ала. Бу эш аның үз иркендә хәзер. Бүгенге хатыннарга: авызыңны каплап йөр, кайнатаң алдында сөйләшмә дип әйтеп кара син! Ник әйткәнеңә үкенерсең. Әнә, башкаларның киленнәре биата, биана дип тормый, үз аталарына да акыралар, сүгенүләре дә гадәткә кереп бара инде. Хәерлегә генә булсын, хатын-кыз аза. Кайнатасын түгел, үз ата-анасын кыйнаучылар да бар диләр. Шуңа күрә Айдаш баба гомере буе киленен якын күрде.

— Синең үз эшең дә җитәрлек, килен! — диде карт.— Үзем ташыйм әле бүген. Үзем ташыйм да, үзем ягам. Хәтәр эссесенә үзем керәм Ярмөхәммәт белән. Шулай!

Нурлыгаян сузган кулын кире алмады, капкага таба ымтынган кайнатасының каршысына төште. Бу аның:

— Әткәй, кешеләрдән уңайсыз бит! Оятын кая куярбыз? Туксанга җиткән аталарына су ташыталар дип сөйләрләр. Әнә, һич югы Факия ташыр, китер чиләкләреңне! — дигән сүзе иде.

Ул арада өйдән Факиһә йөгереп чыкты. Ул оекбаштан гына иде. Шуңа күрә җиргә төшмичә, болдырда басып, бабасына таба ике кулын сузды:

— Бабай! Бир чиләкләрне! Ату ачуланам! Хәзер чәемне генә эчеп бетерәм дә, суга йөгерәм! — дисә дә Айдаш карт риза булмады.

— Шулай! Үзем ташыйм! Бетте! Шулай! — дип, чиләкләрен кул очыннан тотып, Айдаш капкадан чыкты.

Карт кулындагы чиләкләр чыек-чыек чикылдашып суга китте.

— Бабаң мунча ягарга йөри. Суны үзе ташый. Гомердә булмаганны. Хәерлегә генә булсын инде,— диде Нурлыгаян.

— Хәле киткәч туктар әле, аннары үзем ташып бетерермен,— диде Факиһә.

Ана белән кыз өйгә узды.

Ләкин Айдаш бабаның хәле китәргә уйламады. Ул егет-жиләндәй житез иде. Аның күз алмалары елтырый, ут чәчеп тора. Уникe юл суга барса да, үзе мышнамый, тигез-тирән итеп сулый.

— Бабаңа әллә ни булган, күңеле бик көр бүген,— диде Нурлыгаян.

Факиһә җавап бирмәде. Җавап алыр өчен әйтмәде ана бу сүзне. Болай гына, үзалдына сөйләнүе иде Нурлыгаянның.

Айдаш карт шатлыгын биеп шатланмады, кайгысын елап кайгырмады. Шуңа күрә аны төксе кешегә санады авыл халкы. Бии-бии шатланырлык зур сөенеч тә күргәне булмады Айдаш картның. Ләкин ул үзе өчен кечкенә генә нәрсәләрдән дә куаныч таба белә иде. Үкереп еларлык кара кайгысы да булмады аның. Кара кайгы килсә дә, сыгылып төшә торганнардан түгел иде Айдаш баба. Хәзер аның иң зур кайгысы — улы. Сугышка китеп хәбәрсез югалган җан парчасы — улы Хисбулла. Үлем кәгазе килсә дә, карт Айдаш моңа әзер. Тере килеш менә бүген кайтып төшсә дә, шатлыгыннан Айдаш карт егылып үлмәс.

«Әткәй! Нурлыгаян! Балаларым Факиһә белән Ярмөхәммәт! Озын язарга вакыт тар. Сугышка керәбез. Догагыздан ташламагыз! Хисбулла.»

Бетте-китте. Шуның белән вәссәлам вә кәлләм. Беренче хаты, соңгы хаты. Кайда ул бала? Үлеп калганмы? Әсир эләккәнме? Өч ел бит инде, бер хәбәре юк. Меңләгән кешедер бит инде анда. Тузан бөртеге кебек юкка чыксын инде адәм тикле адәм баласы. Айдаш карт сизә, күптәннән сизә инде: Хисбулла исән түгел. Сизә аның сизгер күңеле. Сизә, шулай да өмет дигән бер алдавыч хис ымсындырып яшәтә дә яшәтә. Юк аның бердәнбер улы, күптән юк инде. Тере булса, Хисбулла бер хәбәр бирә алмаслык мәхлук түгел. Алданганын белеп, үзен-үзе алдап, алданасы килеп җан саклый карт. Улы үлсә, оныклары бар, шөкер.

Дөресен генә әйткәндә, киленен башта бик өнәп бетермәгән иде Айдаш баба. Шуңа күрә улы Хисбулланың Нурлыгаян тирәсендә чуалуын бик хупламады. Хисбулла каты торды:

— Әткәй, Нурлыгаяннан башка миңа патша кызы да кирәк түгел,— дигәч, сүз әйтмәде тагы.

Нурлыгаян бик ипле, бик тәртипле, югыйсә, шулай да Айдаш картка киленнең наданрак булуы ошамый иде. Наданлыкны ул үзенчә аңлата. Күңел күзе белән күрә белүчеләрне хуплый карт. Эчке бер мәгънәле булганнарга тартыла ул. Күңел күзе сукырларны, мәгънәсезләрне ул наданнар рәтенә кертә.

Әмма Айдаш карт бу турыда улына да, килененә дә авыз ачып сүз әйтмәде.

Нурлыгаян исә кайнатасыннан шүрли, аның төкселегән күрә. Шулай да ул кайнатасын олы итә. Хисбулланың атасы булганга гына түгел, сәер кеше булганга шүрли иде Нурлыгаян кайнатасыннан. Хисбулланың атасы яман холыклы булса да, түзәр иде ул. Атаның холкы ошамый дип кенә балалар ташлап, иреннән аерылып йөри торган дуадак нәрсә түгел иде Нурлыгаян.

Айдаш карт килене Нурлыгаянны кеше алдында мактамый, әмма кеше хурласа, яклый торган кайната булып чыкты. Кеше алдында килене турында бер генә яман сүз дә сөйләшмәде Айдаш баба. Менә шушы сыйфатлары өчен бик хөрмәт итә Нурлыгаян кайнатасын.

Онык-кызы Факиһәне дә Айдаш баба өзелеп сөйми иде шикелле. Ул Факиһәгә өмет бagламый. Үсеп буйга җиттеме, кыз кеше үз нәселеңнеке булмый инде ул, кыз кеше — чит кеше. Кыз кеше чит нәселгә кан бирәчәк.

Картның бөтен өмете Ярмөхәммәттә. Хисбулла үзе кайтмас инде. Нәселдән нәселгә күчеп килгән изгеләр сәләте, Хисбулла вафат булгач төкәнеп калыр да, мәңгегә юкка чыгыр микәнни?

Җир-туфракның серен белеп, табигатькә табынып яшәүче кешесе калмас микәнни Айдаш бабаның?

Шуңа күрә, сөенечләр килгәләсә дә, елмайганы булмады Айдаш бабаның.

— Сәер кеше ул Айдулла абзый,— ди авыл халкы аның турында.
— Андыйлар төксе була. Андыйлар кеше белән аралашмый. Кешегә йомыш белән керми,— диләр.

Чыннан да, Айдашлар нәселе гомер буе күршеләргә әйбер сорап кермәде. Тозлары булмаса, Айдашлар тозсыз ашадылар. Иләкләре булмаса, Айдаш карт ясап бетергәнне көттеләр. Йомыш белән кергән кешегә юмарт иде алар. Шулай да бер алган әйберне күршеләр үзләре кертеп бирмәсә, кире сорап та йөрмәделәр, янә шул кешеләр тагын бер-бер йомыш белән керсә, сүзсез генә кире борып чыгара иделәр.

Ярмөхәммәт артык йомыкый булмады. Бик тере, иптәшләре белән уйнап үсә. Әнә шулай аралашчан булганы өчен Айдаш бабаның эче поша. Күп сөйләүчән, йөремсәк кеше тирән фикерле булмый. Андый кеше җигелеп бер генә эшне тарта алмый. Ары сугыла, бире бәрелә дә төпле, тамырлы бер эш майтара алмыйча үлеп тә китә. Аннары соң кеше турында ни әйбәт, ни яман сүз сөйли алмыйлар. Әллә булган ул кеше, әллә булмаган дөньяда. Ярмөхәммәт тә шулай җилбәзәк булыр дип бик пошынган иде Айдаш баба.

Нурлыгаян кайнатасының төкселегенә, айлар буе сүз катмавына күнегеп беткән иде инде. Үзе дә кайнатасыннан тел яшергәч, ул сөйләнүләрнең һич тә кирәге юк иде шикелле. Кайнатасының шундый аз сүзле булуы Нурлыгаянга бик тә ошый.

— Мунча ягыгыз! Малларны ябыгыз! Тоз кайткан анда! — дип Айдаш карт бик сирәк чакта гына кычкыргалый.

Картның кәефе юклыгын шул кычкырыштан аңлап була. Килененә әйтәсе сүзне Айдаш карт балалар аша йөртте. Нурлыгаян да кайнатасына бер-бер сүзе, йомышы булса, я Факиһә, я улы Ярмөхәммәт аркылы әйттерә. Балалар өйдә булмаса, килененә әйтәсе сүзен карт үзалдына сөйләнеп җиткезә, һич югында, малларга кычкырып, килене колагына төшерә торган иде.

Айдаш баба әйткән сүздән соң:

— Ярар, бабай, шулай итәрбез! — дип торыш юк.

Үтәргә, бетте-китте! Шулай кирәк. Йортка бердәнбер ир хуҗа — Айдаш карт. Аның әйткән сүзе генә түгел, тамак кырганы да, күз карашы да — закон.

Әнә шул законның башлыгы, шушы йортның хуҗасы бүген, кеше көлдереп, карт башы белән су ташып йөри. Нурлыгаян кайнатасының кәефле икәнен сиземләде, ләкин акылы белән моның сәбәбенә төшенмәде, төшенергә азапланмады да. Картайган кеше ни кыланмас. Айдаш карт яшендәгеләр инде әллә кайчан гүр иясе. Яки әллә кайчан түшәк өстендә. Аның яшендәгеләргә күптән инде балалар акылы ингән. Айдаш баба җир җимертеп колхоз эшендә икешәр нәүбәт эшләп кайта. Әнә, урактан кайткач, чәй дә эчеп тормастан, мунча ягып җибәрде. Әнә, тыз да быз су ташымыш көне.

— Шөкер әле,— диде Нурлыгаян,— шөкер. Аяк-кулдан калып, урынга егылса, ни кылыр идең? Үзен-үзе йөртә. Каралты-курасын рәтләп тора. Шөкер. Ул булмаса, ни кылыр идең дә, ничек яшәр идең? Аллага шөкер.

Мунчадагы бөтен кисмәк-тәпәннәрне, комган-ләгәннәрне су белән тутыргач, Айдаш карт өйгә керде.

— Килен, чишмә суы белән самавыр куеп җибәр!

Кайнатасының гадәттәгедән артыграк сөйләшүен ишеткәч, Нурлыгаян аптырап, моның сәбәбенә төшенергә теләгәндәй, астан гына картка бакты. Юк, кайнатасында артык үзгәреш күренми. Бары тик Айдаш бабаның керфек очлары гына елмая иде. Чәй өлгергәнче Айдаш карт сүз катмады. Нурлыгаян шаулап торган самавырны өстәлгә китереп утыртты. Яулык очын иреннәре белән капкан килеш, кайнатасына янбашы белән торып, чәй пешерергә кереште.

Факиһә киштәдән тустаганнар алды.

Ниһаять, чәй әзер. Айдаш карт рәхәтләнеп чәй эчә. Өстәлдә бер генә дә чәй тәме күренми. Сугыш башланып, Хисбулла киткәннән бирле бу йортта шикәрнең булганы юк. Булганына шөкрана кылып, бар күгеннән тәм-рәхәт табып, Айдаш карт озаклап чәй эчте.

Аннан соң ул мунча томаларга китте. Ләкин мунчага аз ягылган сыман тоеп, ул тагын бер кочак утын өстәде.

— Колак пешәрлек булмагач, мунча буламыни ул? — дип сөйләнә-сөйләнә, лапас тирәсен әйләнеп чыкты.— Себеркегә калгач, кайнар булмый инде ул мунча. Яхшы мунчада себерке тәмле ис чыгарыр өчен генә кирәк ул.

Шулай да карт бер каен себеркесе, бер туйра бәйләме алып кереп, олы ләгәндәге суга батырып куйды.—

— Иске себеркесе тора торсын. Анысы да артмас. Өр-яңа яшь каен белән туйра алып төшәрбез, аллаһы боерса...

Бер кочак утын янып беткәнче, ул абзарны тазартып чыкты. Утынлыктагы түмәрләрне ватып-чәрдәкләп ташлады. Ишегалларын себереп, матурлап куйды. Хәтта урам як капка алдын да ялт иттереп җыештырды. Аннан соң мунчаны томалады.

— Өч сәгатьтән соң мунча әзер булыр! — диде карт өйгә керәкерешли.— Бик шәп яктым...

Нурлыгаянга бу сүзләр:

— Килен, миңа мунчадан соң кияргә чиста күлмәк-ыштан әзерлә! — булып ишетелде.

Кайнатасы мунча турында сүз кузгаткач та, Нурлыгаян сөлге-сабын, күлмәк-ыштан хәстәрләгән иде инде. Хуҗа хатын шул нәрсәләрне ишек катындагы бәләкәй сәкегә китереп куйды.

— Ә, юк, килен,— диде карт.— Бу ямаулы алачаларыңны ал! Миңа ситсы ыштан белән теге күлмәкне куй!

«Уттай эш өстендә бәйрәмчә киенеп, ни кылырга йөри бу карт?» — дип уйлады Нурлыгаян, үзе карусыз гына сәкедәге күлмәк-ыштанны алып, киштәгә ташлады. Түр сәкегә менеп китте. Мендәр-ястыкны ишеп төшерде дә, сандыктан бабайның саклап кына кия торган рәеш киемнәрен алды. Сандыкны ябып, янә ястык-мендәрләрне өеп-кабартып куйды. Аннан соң сәкедән төште, рәеш киемнәрен алып, мунчага китте.

Килене чыгып китүгә, карт түр сәкегә таба атлады. Әле яңа гына җилтерәп йөрүче дәртле карт кинәт бөкшәйде, кечерәеп калды, атлавының да рәте-юне юк. Айдаш карт сәкегә таянды, әкрен генә йөзлеккә утырды, артына каерылып, җитәр-җитмәс кулы белән сандык өстендәге ястык почмагыннан тартты. Мендәрләр сәке киезенә тәгәрәде. Ястык та сандык белән янәшә генә килеп төште. Айдаш карт ястык өстенә ауды. Сизелер-сизелмәс кенә ыңгырашып, тын калды.

Факиһә бабасының кинәт үзгәрүен күреп, башта ни әйтергә белми аптырады, бабасы сәкегә аугач, кыюсыз гына килеп:

— Бабай... бабай, сиңа ни булды? — дип сорады.

Карт дәшмәде.

— Әллә чирлисеңме, бабай? — дип Факиһә сәкегә үрмәләде, бабасының йөзенә бакты. Әллә ничек сәер тоелды аңа бабасының чырае, кыз чигенә-чигенә үрмәләп сәкедән төште дә өйдән чыгып йөгерде.

— Әнкәй! Бабай! — дип кычкырды Факиһә ишегалдына чыккач, аннан мунчага томырылды.

Кызының борчулы тавышын ишеткәч, Нурлыгаян сораштырып тормады, шөбһәле хәл барын сизенеп, тиз-тиз атлап өйгә керде. Факиһә аңа иярде. Нурлыгаян түр сәке йөзлегенә ике кулы белән таянып, кайнатасының чыраена карады: карт тыныч кына сулый, әйтерсең лә ул сәламәт йокыда иде.

— Факия,— дип пышылдады Нурлыгаян.— Син сора, ни булды икән бабаңа?

Факиһә Айдаш картның икенче ягыннан сәкегә үрмәләде. Ул бабасының иңсәсе аша карап:

— Бабай, сиңа ни булды? Әллә чирлисеңме? — дип сорады.

Картның керфек очлары калтыранып куйды.

— Бабай,— дип кабатлады кыз.— Бабай, хәлең авырмы әллә?

Айдаш карт күзен ачмыйча гына башын боргандай итте. Ихтыярсыз яткан кулын хәлсез генә кыймылдатып, аптыратма инде, барыгыз, хәл алырга ирек куегыз дигәндәй, ишарәләде дә чак ишетелерлек итеп:

— Ярмөхәммәт кайтмадымы? — дип сорады.

— Юк әле, бабай, кайтмады,— диде Факиһә.

«Мунча алдыннан хәл жыюыдыр,— дип уйлады Нурлыгаян. Аннары: — Ял итсен бабаң, кагылма!» — дигәндәй Факиһәгә китәргә ишарәләде.

Кыз, аяк очларына гына басып, сәкедән төште дә өйалдына чыкты.

— Кызым, бакча башыннан гына кычыткан җыеп кер! — диде Нурлыгаян.

Факиһә, өй алдындагы буш кәрҗинне алып, ишегалдына чыгып китте. Нурлыгаян бүлмәгә кереп, тавыш-тын чыгармаска тырышып, бәрәңге әрчи башлады.

«Мунчадан соң эткәй бер самавыр чәй эчә дә ятып тора. Бераз ятып торганнан соң ашарга эзләнә башлый, биш-алты бәрәңге белән, бер уч арыш оны тугылап, кычыткан ашы пешерергә кирәк булыр,— дип уйлый Нурлыгаян.— Нәрсәдер булган инде бүген бабайга. Башта бик жаскаһып йөрде, җегет диярсең. Хәзер сәкегә сузылып ятты. Гомергә булмаган кыланышы. Беркайчан да ястыкка ятмаганны, бүген баш астына ястык аударган.»

Ул арада Факиһә кычыткан җыеп керде.

— Менә, әнкәй, җыйдым,— дип кыз кәрҗинне кертеп куйды.— Картайган инде... кычыткан да...

«Картайган» сүзен әллә ничек итеп әйтте кыз. Картайган инде кычыткан да... Тагын кем картайган? Бабасының картлыгына кинаямы идеме бу? Әллә уйламыйча гына, ялгыш кына шулай әйттеме кыз?

— Картайса да, кысыр аш тәмләргә ярый әле,— диде Нурлыгаян.

Шул чак түр өйдән Айдаш картның тавышы ишетелде:

— Карале, кем бар анда? Ярмөхәммәт кайттымы әллә?

— Юк әле, бабай, юк, кайтмады,— диде Факиһә.

— Ярмөхәммәт сынган уракның бер тешен алыштырырга дип, тимерчелеккә киткән иде. Тимерче Рәванны табалмыймы икән соң?

Карт сөякләр сызлап тора, яңгыр килгәнен сизә сөяк-санак. Сулыш алуы да авырайганнан-авырая сыман тоелды Айдаш картка. Явып китсә, бераз җиңеләер иде дә бит. Әллә яумыйча гына, читләтеп китәргә инде исәбе... Кайда йөри соң бу бала? Соңгармагае, соңгармагае Айдаш карт сүзен әйтергә.

— Кайтыр, тәккә трай тибеп йөри торган бала түгел... Кулыннан эш киләчәк малайның, насыйп булса. Эше бетсә, менә кайтып житәр,— дип үз-үзен юатып алды карт.

Ул тирән итеп сулыш алды. Салкынча саф һава үпкәгә түгел, йөрәктән узды сыман. Күпме сыя ала, шуның чаклы мул итеп һава йотты да карт, тынын кысып, байтак суламый ятты. Саф һаваны йөрәк янында озаграк тотып, Айдаш карт кан тибешенә колак салды. Кан тамырлары ашыкмыйча гына тибә, аннан соң, тыны бетә башлагач, ул салмак кына, сизелер-сизелмәс кенә сулышын чыгара башлады. Сулышы төкәнгәч, тагын тын алды.

— Шулай да озаклады бу,— дип уйлады карт.— Ашыгарак төшсә ярар иде, вакыт күп калмады...

Нинди вакыт күп калмады? Кояш баергамы вакыт аз? Төш җитеп килә. Мунча өлгерергәме вакыт бетте? Мунча өлгерер өчен әле тагын ике-өч сәгать вакыт кирәк.

— Торыйк булмаса,— диде карт,— ләкин кузгалырга ашыкмады.— Шулай! Шулай булырга тиеш иде, шулай булачак!

Бүлмәдәге оныкъкыз белән килене аның бу сүзләрен ишетте, ләкин кыз да, ана да моңа игътибар итмәде. Игътибар иткән булсалар да, картның ни уйлаганын, бу сүзләр артында ни нәрсә ятканын аңламаслар иде. Колакларга тияр-тимәс кенә кагылып узган бу сүзләрнең мәгънәсен ана белән кыз соңыннан гына аңлар.

## Яңгыр

— Торыйк булмаса,— диде дә Айдаш баба җиңел генә кузгалып, ястыкны сандык капкачына ыргытты. Сәкедән төшкәндә ул тәрәзәгә карады: Ярмөхәммәт кайтып килмиме, янәсе. Яңгыр сибәли башламадымы икән?

Ул җилтерәп чыгып китте.

— Бабай әллә нишләгән бүген,— диде Факиһә, ул кече бакча ягына ачыла торган тәрәзәгә карады.— Мунчага кереп китте...

Бәйрәм түгел, җомга түгел, гомердә булмаганны, мунча дип тызлап йөри,— диде Нурлыгаян шелтәсез генә.

— Арыш кылчыгы кычыттырадыр аны, әнкәй!

— Әллә ниләр кычыттырса да, эш бетермичән мунча яктырмый иде ул. Бакчы, безгә дә кушып тормады, үзе чабып йөри,— диде ана.

Айдаш баба мунчаның ишеген шар ачып куйды да, таш өстендәге капкачны алып, ике тапкыр эссе салды. Кайнар пар мунча тәрәзәсе яктылыгындагы сыек зәңгәр исне куып ишеккә таба алып китте. Бераздан соң Айдаш таш капкачын төшереп, мунча ишеген ябып, ачылмаслык итеп, утын агачы белән терәтеп куйды. Ул эшеннән риза иде бугай.

— Шулай!— диде дә мунча өйалдыннан ишегалдына чыкты.

Бабай бәләкәй бакчага керде. Кытай алмагачы янында бик озак басып торды. Вак алмаларны бармаклары белән сыпыргалады. Үз гәүдәсеннән ике тапкыр биегрәк үскән баяргөлгә карап сөйләнеп алды. Аннан соң ул пәйгамбәр тырнагына иелде. Сукмак туфрагына бер тезен куйды да чәчәккә карап:

— Башка чәчәкләргә караганда син озын гомерле,— диде.

Аннары ул түтәлгә коелган пәйгамбәр тырнакларын берәмләп учына җыйды.

— Иртәрәк өлгергәнсез шул, ашыккансыз,— дип, Айдаш баба аягүрә басты.

Учындагы пәйгамбәр тырнакларын өйалдына алып керде. Матчадагы кадакта эленеп торучы алача янчыкны үрелеп алды.

— Рас өлгергәнсез икән, орлыкка калырсыз,— дип сөйләнә-сөйләнә, чәчәк орлыкларын бөрмәле янчыкка салып, янә матчага элеп куйды. Нидер исенә төшкәндәй, Айдаш карт капыл өйалдыннан тагын ишегалдына чыкты.

— Шулай,— диде ул күк йөзенә карап алгач.— Шулай. Яңгыр килә.

Сулышын кысып, карт тын калды. Бая гына ышылдап, шаулап утырган тупыллар кинәт сагаеп, шаулаудан туктады. Бакча башындагы ерак тирәслектә тырнанучы әтәч-тавык халкы да каралты-курага таба йөгерә башлады.

«Озак яумас, болыты зур түгел. Шулай да чылатып китәр»,— дип уйлады карт.

Әтәч-генерал тибенүдән туктап, килеп җитә язган яңгыр болытына кыйгаеп бер карады да коңгырт, тук күкрәк тавышы белән бик шәплән кычкырды.

— Ки-икри-ик-кү-үк! Яңгыр килә-ә! — янәсе. Мин вазифамны үтәдем, хәзер миңа да кайтырга ярый, шәт, дигән сымак, әтәч җан-фәрман чабып, ишегалдына кайтып керде. Кайтып керде дә тагын бер кычкырды.

Шул чак кинәт яшен яшьнәде, чатырдап күк күкрәде, сулыш кинәеп киткәндәй булды. Күк күкрәүдән өйнең тәрәзә пыялалары зеңгелдәп куйды. Юк жирдән бар булып, кинәт көчле жил исә башлады.

Айдаш карт яшенле яңгырны бәләкәй чактан ук ярата. Чатырдатып яшен сукканны, йөрәк тетрәткеч күк күкрәгәнне, коеп яңгыр яуганны карау аның сөекле шөгыле.

— Яшьнә, яшен! Күкрә, күк! Кой, яңгыр!

— Чистармасмы фани дөнья!

Яшенле яңгыр вакытында, якынында кешеләр булса да, Айдаш карт ишетелер-ишетелмәс кенә шулай әйтә торган иде. Күп кеше аның бу пышылдавын иман китерү, дога кылу, белгәннәрен уку дип уйлый инде. Юк! Дога кылмый Айдаш. Табигатьнең бөек көченә соклана ул, кеше акылы житмәстәй куәтле болытка табына.

— Көчле яңгыр килә, хәерлегә булсын, балалар! — дип тикмәгә генә пышылдамый аның иреннәре.

Кара-кучкыл болытта ут-янгын чыгарырдай, малларны, адәмнәрне сугып үтерерлек, меңьяшәр имәннәрне урталай ярырдай көч барын белеп әйтелә торган ялвару сүзләре дә болыттан миһербан көтүе дә шулай аның; жиргә, терекләккә, ярым-ач адәмнәргә жан бирүче болыт икәнен белеп, теләк теләве.

— Озак яумас, иншалла! — диде карт.— Кодрәт чәчеп килгән болыт тиз шиңә ул.

Әтәч, тавыкларын ияртеп, лапаска кереп китте. Яшен күк йөзен ялмап-ямап алды да күктә тоташ гөрелте булып, «ходай арбасы» Салават күпере аша чабып йөри башлады. Эре тамчылар белән шыбырдап яңгыр яварга тотынды. Күк кавузын ачканнармыни — һавадан су ишелә.

Айдаш карт чыланганын сизмичәме, әллә юри чыланасы килепме, аягындагы йон оекбашларын, мунчала белән бәйләп куйган ертык кәлүшен салып, өйалды астына тыгып куйды да, түбәтәен култык астына кыстырып, яланаяк килеш мунчага китте.

— Яшьнә, яшен! Күкрә, күк! Кой, яңгыр! Чистармасмы фани дөнья! Хәере белән килсен, балалар! — дип сөйләнә-сөйләнә Айдаш баба мунча ишеген ачты.

— Әһем-әһем,— дип тамак кырды Айдаш.

Мунчага кергәндә дә, лапаска, амбарга якынлашканда да жиде адым кала тамак кырырга кирәк. Биш адым калгач, тагын бер. Ишеккә, капкага тотынганда тагын шулай «әһем»ләргә куша борынгы гадәт.

Бер тапкыр Ярмөхәммәт:

— Бабай, ни өчен алай итәсең син? — дип сораган иде.

— Мунчага, лапаска, амбарга кергәндә тавыш бирмичә керергә ярамый,— дигән иде Айдаш.— Эчтә кеше булса, кинәт ишек ачылуга куркып, тотлыга торган булып кала. Яшерен эшләр өстенә килеп кереп, кешене дә, үзеңне дә оятлы итүең бар...

— Син бит кеше булмаганын беләсең дә тамак кырасың, бабай!

— Кеше булмаса да тамак кыру кирәк, улым,— диде карт.— Эчтә өй иясе, мунча иясе, абзар иясе була. Әнә шул ияләрне сискәндермәс өчен шулай эшлиләр. Кинәт кереп, абзар иясен яки мунча иясен сискәндерсәң, синең зәхмәт кагыла. Әһем-әһем, мунчага кеше килә. Курыкмагыз, яшеренеп өлгерегез дигән сүз ул тамак кыру. Әдәп саклау ул тамак кыру. Абзар ияләрен дә, мунча ияләрен дә кеше күрергә тиеш түгел. Югалган мал эзләп йөргәндә печән кибәннәре, арыш эскертләре янына килеп чыкканда да жиде адым кала тавыш бирергә кирәк. Кешеләрне сискәндерергә ярамый, улым.

Айдаш баба терәүне алып, ишекне ачты. Мунчага эссе төшмәгән иде әле. Тәрәзәдән кергән яктылыкта сыек зәңгәр һава күренә.

— Исе бетмәгән әле,— диде карт.

Ташка янә дүрт тапкыр эссе салды да, ике себерке белән исле һаваны ишеккә таба куарга тотынды. Тагын эссе салды, тагын һаваны ку-

ды. Өйалдына чыгып, мунча эченә, тәрәзә ягына бакты: зәңгәрсу һава күренмәде. Ишекне тыгызлап, терәтеп куйды да коеп яуган яңгыр астына чыкты. Яңгыр аяк астындагы туфракны үзләндереп өлгергән иде инде. Җиргә баскач, картның аяк бармаклары арасыннан лыҗырдап юеш саз чыкты. Яңгыр Айдаш картның такыр башына, арык җилкәсенә коя.

— Бәрәкәтле яңгыр булсын, тиз яусын, арышны җыеп өлгерергә ирек бирсен!

Айдаш картның изге теләге шул булды.

Яңгырдан качып өйгә кермәде ул, юри әкрен атлап китте. Кәлүшләрен, оекбашларын алырга дип өйалды астына иелде, шул мәлне үк капка келәсенә бастылар. Капка ачылды. Бу Ярмөхәммәт иде. Ул да, нәкъ бабасы шикелле, түбәтәен култык астына кыстырган, чабатасын салган. Пычракта рәхәтләнеп яланаяк йөри.

— Озак йөрдең, улым,— диде карт.

— Рәван абыйга булышып тордым. Сөләйман абыйның бозавын бүре буган. Башы белән аяклары гына калган ди. Сөләйман абый шуларны алырга киткән... — дип сөйләнә башлады Ярмөхәммәт.

— Алай икән,— диде карт.— Бер килгәнгә өелеп килә инде ул бәла. Чирле карчык өйләрендә. Хатыны Хәбирә дә бүсерле. Өч бала — нишләрләр инде бичаракайлар. Мал була дип өметләнеп торганда гына... Бар карап торганнары шул башмак иде. Үзәкләре өзелер инде.

— Рәван абый уракның ике тешен дә рәтләрмен диде. Икенче теше дә чатнаган булган аның, бабай... Яңгыр гына комачаулый.

— Яңгыр тиз узар! Әнә, арттан ачыла килә! — дип, карт борылып карамыйча гына офыкка ымлады.

Чыннан да, яңгыр болыты нәкъ авыл өстендә асылынып тора. Ә болыт арты аяз, урман белән елга арасына салават күпере чыгарга өлгергән.

— Һур-ра, бабай! — диде Ярмөхәммәт күлмәк итәген сыга-сыга.— Җилләсә, бүген кичкә таба урып карарга була.

— Юк, улым,— диде Айдаш.— Арыш арасы юеш булыр. Атлар тарталмас.

Бабалы-оныклы алар өйалдына уздылар. Кара өйнең ишеге ачылды, ишектән агач ләгән күтәреп Факиһә чыкты.

— Аякларыгызны юып керегез,— дип, кыз ләгәнне идәнгә куйды. Аннары җәһәт кенә тагын өйгә кереп китте.

— Башта син ю! — диде карт.

Ярмөхәммәт җылымса суга кереп басты.

— Бабай, син яңгыр явасын каян белдең, ә? — диде Ярмөхәммәт.— Күктә бер болыт та юк иде бит.

— Карлыгачлар очуыннан... — диде аксакал.— Чикерткәләр чырлавыннан... Күңел сизүеннән...

Бабасы аңа яңгыр алды галәмәтләрен сөйләде.

Ишек тагын ачылды, кулына комган-чүпрәк тотып, тагын Факиһә күренде:

— Бүкәнгә утыр, Ярмөхәммәт, хәзер аягыңны чайкап төшерәм,— диде кыз.

Ярмөхәммәт бүкәнгә утырып, ике аягын ләгән өстенә күтәрде. Факиһә комганнан җылы су койды.

— Ярмөхәммәт энем, син менә бу чүпрәккә бас. Бабай, син аякларыңны ләгәнгә тык.

— Һәй, кызым, озакламый мунчага барасы бар бит,— дип караган иде карт...

— Мунча үзенә, аяк юып өйгә керү үзенә,— дип Факиһә бүкәнгә утыртты да, картның аякларын юа башлады.

— Бабай, тәпиләреңне чүпрәккә куй! — диде Факиһә, үзе коры чүпрәк белән бабасының аякларын сөртә башлады. Аннан соң ул өйалды ишеген ачып, юынтык суны ишегалдына сипте.

Айдаш карт белән Ярмөхәммәт өйгә узды. Ишекне ачуга тәмлеләрдән тәмле аш исе бөркелде.

— Ашка кычыткан, бәрәңге, суган, бер уч арыш оны салып пешергәнсең, әнкәй,— диде Ярмөхәммәт.

Нурлыгаян казаннан аш бушатып яткан җиреннән ишек катына күз ташлады.

— Ике сабый,— диде ул үзалдына.— Янәмәсе, икәүләшеп яланаяк йөриләр.

— Кайгырма, килен,— диде Айдаш карт, әйтерсең лә ул Нурлыгаянның ни уйлаганын ишетте.— Кайгырма, җәйге яңгыр шифалы була ул.

Карт белән оныгы ак өйгә узып китте. Нурлыгаян агач табак белән ашны өстәлгә китереп куйды.

— Табын янына утырышыгыз!— диде Нурлыгаян тыштан килеп керүче кызына.— Бабаң белән Ярмөхәммәткә әйт, чыксыннар.

Кулындагы комган-ләгәнне мич авызына куеп, Факиһә алгы өйгә узды.

— Бабай! Ярмөхәммәт! Ашарга чыгыгыз!— диде ул ак өйгә керәкерешли.— Бабай, мә, аягыңа оекбашыңны ки,— дип бабасының ямаулы оекбашларын сәке йөзлегенә куеп, кире чыкты.

Ярмөхәммәт, чакырган җиргә бар, куган җирдән кит, дигән шикелле, теге өйгә чыгарга дип, урыныннан торган иде, аны бабасы туктатты.

— Монда утыр!— дип ул Ярмөхәммәтне үз янына, сәке түренә чакырып кул изәде.

Ярмөхәммәт, тау кәҗәседәй, идәннән сәкегә сикерде. Ул бабасы сыман, аякларын чалыштырып, Айдаш карт әйтмешли, түрәдәй түрә корып, байлардай мыек борып, түргә менеп утырды.

— Карагыз әле, килен! Факиһә кызым!— дип кычкырды Айдаш карт урта ишеккә карап.— Шулпагызны монда гына кертегез булмаса.

— Бәйрәм көннәрне генә түр башына утырып ашый иде бу әткәй,— дип, Нурлыгаян янә тагын бер гаҗәпләнде.— Бар, кызым,— диде ул Факиһәгә,— алларына кертеп куй.

Факиһә кечерәк табакларга бүлеп, үзләренә өлеш калдырып, зуррак табакны, ике агач кашык алып, ак өйгә узды. Нурлыгаян агач касәгә салынган әче катыкны ала керде.

Факиһә сәке киезе өстенә алача ашъяулык җәйгәндә:

— Ашканиләр салынганын белеп бетермәдең,— диде.— Ашка әнкәй ике күкәй сытты. Ашта тагын яшел суган кыягы да бар.

— Алары соңыннан салынган, мин иснәгәндә алары юк иде,— диде Ярмөхәммәт.

— Танауларыгызны бака яласын!— диде Айдаш баба.— Борын яргыч иң шәп исле тагын бер үлән салган әле анагыз. Иң беренче шуны атарга кирәк иде.

— Әнис!— дип кычкырды Ярмөхәммәт.— Әнис исе бар.

Нурлыгаян елмайды, бу елмаю:

— Дөрес, улым, ашта әнис бар!— дигән сүз иде.

— Уф, әнис барлыгы истән дә чыккан,— диде Факиһә.

Табак-савытларны ашъяулык өстенә куеп, хатын-кызлар ак өйдән чыкты. Айдаш карт касәдән әче катык алып, ашка салды. Катык каткач, кычыткан шулпасының тәме унлата арта диләр.

— Бисмилла!— дип әйтте дә карт, доганың калган өлешен авыз эченнән генә мыгырдап, ашны бик һәйбәтләп кенә болгатып җибәрде. Аннан соң:

— Җә, улым, житешик ризыктан,— дип шулпа алып капты.

Шуннан соң гына Ярмөхәммәт ашка үрелде.

Шулпа сыек, әмма иллә дә тәмле иде. Алар сөйләшмичә генә ашый. Ашаганда сөйләшмәскә куша бабай. Ашаганда эш турында, башка мәшәкатьләр турында да, кайгы-хәсрәт, шатлык-куаныч турында да

уйларга ярамый икән. Ашаганда бары тик ризык турында гына уйларга, алдыңа гына карап, ризыкка рәхмәт укып, йоткан азыкның үңәч буйлый ашказанына барып ирешкәнен күңелдән күреп, сизеп ашарга куша Айдаш баба.

— Йоткан ризык ашказанына төшеп урнашмыйча, авызга яңа ризык кабарга ярамый,— ди ул.

Ашаганда, чәй эчкәндә пешеләнмәскә, ашыкмаска кирәк ди. Ашап бетергәч, кашыкның эчен дә, тышын да ялап куярга кирәк.

— Табак төбендә, кашыкта бәхет орлыгы ябышып калучан була. Әнә шул бәхетеңне ычкындырмас өчен ашны әрәм итмәскә, бөртеген дә, валчыгын да җибәрмәскә,— ди торган иде Айдаш баба.

Ярмөхәммәт бәләкәйрәк чакта бабасыннан болай сораган иде:

— Ни өчен син, бабай, ашар алдыннан кашыкка тотынмыйча, ашка карап торасың, аннан соң күзеңне йомасың? Син дога укыйсыңмы, бабай? Ашап бетергәч тә буш табакка карап утырасың, тамагың туймагангамы, бабай?

— Юк, улым,— дигән иде бабасы.— Мин ризыкка рәхмәт укыйм. Безне туйдырганы өчен тәгамгә рәхмәт әйтәм. Шул ризыкны безгә биргән җиргә рәхмәт укыйм. Ашап бетергәч, бар булганына шөкрана кылып, тагын тәгам булсын, балаларымны, оныкларымны ач итмә дип, изге теләкләр телим,— дигән иде бабасы.

Табак ялау бәхете Ярмөхәммәткә эләкте.

— Ялап куй, улым!— диде бабасы.

Кашыгын ялап чистартканнан соң, Ярмөхәммәт табакны күтәреп яларга тотынды. Чыннан да, табак төбендәге берән-сәрән калган умач кисәкләре, изелгән кычыткан, катык таплары, бер-ике бөртек бүрткән арыш шулкадәр тәмле иде. Табак ялауны бәхет дими, ни диярсең!

Тора-бара, тормышлар көрәйгәч, Ярмөхәммәт аңлар: табак ялау әдәпсезлеккә керә икән. Ләкин шунысын гына аңламас, ни өчен? Ни өчен ризыкка табыну әдәпсезлек санала соң? Бай тормышта яшәгәндә дә табак ялау теләге Ярмөхәммәттән калмас.

Шул көннән соң Ярмөхәммәт, бабасына ияреп, гел генә ризыкка рәхмәт укый башлады.

Яңгыр койды-койды да узып китте. Ялтырап кояш чыкты. Түбәдән пычтыр-пычтыр су ага; ишегалдында, урамда гөрләвекләр акканы ишетелә. Еракта-еракта күк гөрелтесе ишетелгәләп куя. Табигатькә тынлык иңә. Шул тынлыкта урам якта бала-чаганың кычкыру-көлү тавышлары яңгырый.

Ярмөхәммәт табактан аерылып, тәрәзәгә карады. Малайлар балак сызганып, урамга чыккан. Ерганакта буа буып азаплана Галимхан. Рәуф тә шунда. Вакыйф гөрләвеккә су тегермәне көйләп маташа.

«Кайдадыр кырылыш, суеш бара,— дип уйлады Айдаш карт.— Монда ач балалар үзләренә кызык табып уйный. Галимханның атасы үлгәнгә ике ел инде. Сугышка киткәндә бу бала тәпи йөри генә башлаган иде әле. Вакыйфның атасы да фронтта, анысы нишләп бетәр тагын? Рәуфнең атасы күптән вафат. Ярмөхәммәтнең этисе дә үләндер инде...»

Һай, дөнья! Ә балалар ачлык дими, ялангачлык дими, әнә, ерганакта шаулаша.

— Бабай,— диде Ярмөхәммәт.— Бабай дим, мин дә гөрләвекле уйнарга чыгыйм әле.

— Юк, улым, бүген син гөрләвекле уйнамассың,— диде карт.

Эш югында беркайчан да уйнаудан тыймаган бабасының кинәт кенә «юк» дип әйтүе сабыйны аптырашта калдырды. Ләкин Ярмөхәммәт дәшмәде. Чыгыйм инде, бабай, дип ялынмады.

— Әйдәле, улым Ярмөхәммәт,— дип Айдаш карт өскә калыкты.— Килен! Факия кызым, ашыгыз бик тәмле булган. Бик рәхмәт, кулларыгызның игелеге күрегез.

— Шифага, сихәткә булсын, бабай!— диде Факиһә.

Айдаш карт иске кәвешен элеп, ишегалдына чыкты. Ярмөхәммәт, балакларын сызганып, ялан тәпи бабасына иярде. Айдаш карт капка келәсенә басты. Келә үзенә генә хас тавыш чыгарып шалтырады:

— Зең-гел-лә...

Болай итеп бары тик Ярмөхәммәтләр капкасының келәсе генә шалтырый. Галимханнарның җил капка. Аларның капкасында тимер келә юк. Ул капканың ачылып-ябылганын әллә каян белеп була. Ачылганда нечкә итеп шыгырдый, ябылганда юан тавыш белән үкерә. Капка: «Гали-и-им»,— дип ачыла, «ханн»,— дип ябыла. Рәүфләр капкасының келәсе: «Рә-ү-е-ефф Гафу-урыфф»,— дип әйтәдер сыман. Ярмөхәммәтнең ни уйлаганын сизенгәндәй, Айдаш карт сүз башлады.

— Беләсеңме, улым, капка келәсе ни өчен шалтырарга тиеш?

— Тимер булгангадыр,— диде Ярмөхәммәт.

— Капка келәсе ул — кыңгырау. Кеше кергәнне, кеше чыкканны хуҗаларга белгертеп торыр өчен келәләр шулай матур тавышлы итеп ясала. Борын заман тимерчеләре икесе бер төрле тавыш чыгара торган капка келәсе ясамаган. Һәр капканың келәсе аерым тавышлы булырга тиеш. Кем капкасы ачылганын бөтен күрше-күлән ишетеп тора. Үзенә күрә звонок.

Капканы чыккач, Айдаш карт түбәночка борылды.

— Әй, Ярмый, әйдә буалы уйныйбыз!— дип кычкырды Галимхан.

— Вакыт тар!— диде Ярмөхәммәт.

— Кая барасың?— дип кычкырды Галимхан.

Ярмөхәммәт җавап бирмәде. Галимхан үпкәләгәндер инде. Үпкәләсә үпкәли инде. Кая бара дип әйтсен соң инде Ярмөхәммәт, кая барганын үзе дә белми әле.

— Тау башына менәбез, улым,— диде Айдаш карт.— Авылны тау башыннан карыйсым бик килә.

— Мунча кала бит...

— Мунча өлгерергә иртә әле. Яхшы мунча, томалагач, өч сәгатьтән соң гына өлгерә ул.

## Аждаһатау

Алар сөйләшмичә генә авылны чыкты. Басма аша елганы уздылар. Карт белән сабый алдында биек, текә тау басып тора. Айдаш карт, егетләрчә атлап, таyга менеп китте. Ярмөхәммәт тә бабасыннан калышмаска тырыша. Ярый әле тау сукмагы җилләп өлгергән. Туктап ял итә-итә бабай белән онычы, ниһаять, тау түбәсенә менеп җитте... Шәмәй качкын ташына утырып, Айдаш карт хәл җыйды.

— Бу Шәмәй бабаң ташы булыр, улым,— диде Айдаш бераз сулыш алгач.— Тимеркул дип атыйлар иде аны. Шаһимәрдән Тимеркуловны тирә-юньдә белмәгән кеше юк иде. Бик куәтле адәм иде, мәрхүм. Шаһимәрдән агам минем әти белән бертуган; икесе дә Акбарыш балалары. Акбарыш Напалиун сугышында өч тимер тәре алган кеше. Тәреләрен такмый торган ие, мәрхүмкәй. Кешегә күрсәтмичә, әбигә, әтиләргә күрсәтмичә, сандык төбендә, җиде кат алачага төреп асрый торган ие. Напалиун сугышыннан бер аяксыз, бер кулсыз кайткан кеше. Сугышка китәр алдыннан бик куәтле, таза егет булган, имеш, үгезнең ике мөгезе арасына йодырыгы белән сугып үтерә ала торган булган, дип сөйлиләр. Бабай карт иде инде. Берзаманны безнең авылда фетнә чыкты. Учавылдан килеп, өй борынча кереп, налук салып йөрделәр. Имеш, Учавылда чиркәү салалар икән, шул чиркәү акчасын күрше-тирә татар авылларыннан җыялар икән, чиркәүгә алып кереп барча мөселманнарны да чукындыралар икән, дип бөтен авыл шау килде. Исправникны, сотникны, старостаны авылдан куып җибәрделәр. Шуннан соң гаскәр китерделәр безнең авылга. Гаскәр килә икән дигәч, Акбарыш баба солдаттан кайт-

кан киемнәрен киеп, гомер такмаган өч тәресен түшенә кадап, мәйданга китте. Имеш, сугыш каһарманы, патша өчен кан койган карт солдатны тыңларлар, аңа кагылмаслар. Иң алда Акбарыш баба аксый-туксый бара. Старшина кычкыра:

— Туктагыз! Туктамасагыз, атабыз!— ди.

Пристав кычкыра:

— Уберите старика-солдата!— ди.

Старшина белән ике солдат килеп, Акбарыш бабайга тотынмакчы булганнар иде, Шаһимәрдән абый йодрыгы белән беренче килгәненең маңгаена сукты. Теге солдат шундук егылып үлде. Китте атыш, китте кычкырыш, без базларга кереп качтык. Шуннан атлы казаклар китерттеләр авылга. Биш кеше үлгән иде. Ике солдат белән бер старшинаны үтергәннәр ие. Бу яктан бер үсмер белән Гыйлаж Хәлиулласы үлде. Бөтен авылны суктырдылар. Акбарыш бабайга йөз чыбык. Патша өчен бер аягын, бер кулын калдырган Ватан сугышы каһарманы, өч тәре таккан гарип картны да кызганмадылар, кансызлар. Иман юк икән үзләрендә, бәдбәхетләр. Әнә, теге тегермән янындан яшь тал чыбыгы ташыттылар. Чыбыкны тозлы суга батырып пешекләделәр. Шулай иткәч, тал чыбыгы сынмый, катырак төшә. Акбарыш баба шуннан озак тормады. Ике көннән соң үлде. Тимеркул Шаһимәрдән абзый урманга качты. Аны тота алмадылар. Илле егетне катыр сөрделәр авылдан. Унлабын өтерменгә җибәрделәр. Калганнарының барысына да йөзәр, өчәр йөз чыбык. Суктырудан ун кеше үлде. Атлы казаклар җәй буе безнең авылда торды. Тавык калмады, сыер-тана калмады. Барысын да суеп ашадылар, бирәннәр. Ул хатын-кызларны мәсхәрәләп бетерделәр. Бер килен асылынып үлде. Ике кыз суга ташланды. Ике кыз акылдан язды. Кайнап торган, күкрәп торган авылдан кот качты. Казаклар киткәч тә кешеләр өйдән чыгарга куркып ятты әле. Алты урам иде безнең авылда. Әнә, теге арыш басуында бер урам иде. Шул елны ук таралып бетте. Аркылы урам егерме беренче елгы ачлыкта янып юкка чыкты... Шаһимәрдән абзый кич саен урманнан чыгып, шушы ташка утырып җыру башлар иде. Кичен тып-тын була. Көтү кайткач, мал-туарны япкач, капка төбенә чыгып утырыр идек. Шул чакны тау башыннан Шәмәй качкынның матур, моңлы тавышы ишетелер иде. Һай матур җырлар иде! Без, балалар, хатын-кызлар — рәхәтләнеп елый идек. Өч ел тота алмадылар Шәмәй качкынны. Дүртенче елда сирәк күренә башлады ул тау башында. Аның яшеренеп яткан урынына мин ашарга илтә идем. Чир басты аны урманда. Соңгы баруымда ул инде суынып беткән иде...

Шулай да чиркәүне салмадылар. Күрше-тирә авылларында да кайнаш булмагае дип шүрләгәннәрдер инде. Менә, улым, Шаһимәрдән Тимеркул бабаңның ташы шушы булыр.

Бабай тынып калды. Бераз моңаеп алды. Ярмөхәммәт тау астына карады. Аста Зәйчә инеше елтырап ята. Авыл уртасына буа җәелгән. Ямь-яшел бакчалар, зират таллары мәктәп картасындагы кебек җәелеп ята. Арыш басулары сап-сары. Ямь-яшел болыннар, кап-кара сөрелгән җирләр, зәңгәрсу такыр басу — барысы да ап-ачык. Ә-әнә, ындыр табагыннан уң якта, басу кырында урак машинасы, моңаеп, Айдаш карт белән Ярмөхәммәтне көтә. Машина артында бәйләнмәгән арыш учмалары тезелешеп ята. Болар бар да Ярмәй авылының табигате.

— Улым,— диде Айдаш карт.— Син бүген чәчәк матурлыгын күрдең. Ләкин ул чәчәк үсемлекнең дәвамы гына. Тамырның очы гына. Дөньяны, кешеләрне аңлыйсың килсә, син тамырга төшәргә тиешсең.

— Әнә, безнең авыл. Борынгыдан безнең нәсел шушы урман, шушы болын, шушы тау янында гомер кичергән. Әллә нинди җәзалар да, ачлыклар да, сугышлар да, көчләп чукындырышлар да бу авылның тамырын корыта алмаган... Бу тау сиңа кала, Ярмөхәммәт. Бу таш сиңа кала, улым. Авыл сиңа кала, балам. Тормыш мәшәкатьләре белән тауны онытма. Иң авыр вакытта да мин син тау башына. Иң куанычлы чагыңда

да мен син монда. Тау башына мен дә моңай. Борынгы бабаң Тимеркул Шәмәй качкынның җырын җырла:

Мендем тауга-лай, бастым ташкай,
Ташның киртләчләренәй.
Бер сызгырам, бер кычкырам,
Калдым иптәшләремнән...

Аннан соң менә шулай аска кара. Ләкин шуны онытма, улым, биектән караганда сиңа бары тик зур нәрсәләр генә күренер, син башкаларын да күрергә тырыш...

Бабасы әйтмәсә дә, Ярмөхәммәт тау башына менеп, аска карап торырга ярата. Бервакыт көтү алып кайтканда, шулай тау башыннан тирә-якка карап, дөньясын онытып, ул көтүне уҗымга керткән иде. Ярый әле председатель Сабир күрмәде. Күргән булса, валлаһи, өтермәнгә яптыра иде.

— Нигә безнең авыл Ярмай исемле?— дип сораган иде бервакыт Вакыйф укытучы Фәгыйлә ападан. Фәгыйлә апа:

— Ярмай дип ни өчен аталганын беләсегез килсә,— диде,— тау башына менеп карарбыз.

Икенче көнне апалары бөтен мәктәпне җыеп, тау башына экскурсиягә алып менеп китте.

— Күрәсезме?— диде Фәгыйлә апа.— Авыл урак кебек. Урак түгел, яңа туган айга охшаган. Ярым ай сурәтендә булганга «Ярмай» дип аталуы бер дә гаҗәп түгел.

Ярмөхәммәт шуннан соң, яңа туган ай күргәч, гел шул хакта уйлый башлады. Узган кыш төнлә урманнан утын алып кайтканда бабасы тау төшәр алдыннан чана астына күсәк тыгып куйды да, түбәнең нәкъ шушы урынына басып, озак кына авылга карап торды. Тау башында җил ыжгыра иде. Җил ыжгырса да Ярмөхәммәт: «Әйдә, бабай, кайтыйк инде»,— димәде. Чөнки ул шаккаткан иде. Шаккатуыннан телсез калган иде. Көмеш кебек ап-ак карга яңа туган ай яктысы төшкән. Киресенчә әйтсәң дә була: көмеш кебек яңа туган ай яктысы төшкәнгә, кар шулай көмеш төсенә кергән. Күктә кыйгач ай, тау астында кара-кучкыл ярымай — туган авыл йокымсырый.

Бишмәт асларына «кырмыскалар» керә башлагач, Айдаш карт:

— Туңдыра, алланың рәхмәте,— дип чана янына килде.

Чана астындагы күсәкне алып, баш бауны Ярмөхәммәткә тоттырды.

— Улым, син чана салуламасынга боргалап барырсың, мин күсәк белән тыеп төшәрмен,— диде карт.

Кызыл Тауның иң сөзәк жиреннән төшәсе булса да, йөкле чананы күсәк белән тыймасаң — баш бетте. Чана сине сытып китә, я салу якка бәрелеп, йөгең ава да, чана тәкмәрләп көрт эченә кереп чума. Менә шуннан соң сөйрәп чыгар инде син аны!..

Хәзер җәй, җылы җил исә. Яңа гына җылы яңгыр явып узды. Җиле дә яңгыр болыты артыннан бара, көньяктан исә. Җылы, рәхәт җил. Шул рәхәтлекне озаграк тотарга теләгәндәй, Айдаш карт ияген җилгә куйды. Ике тез өстендәге кулларын уч ягына әйләндерде. Үзе дә сизмәстән, Ярмөхәммәт тә нәкъ шулай эшләде. Шунда гына ул бабасының нинди рәхәт кичергәнен аңлады. Яңгыр болытын куып йөртүче көньяк җиле Ярмөхәммәтнең битен ялый, керфек очларына орынып-орынып ала, керфекләр җил кагылган саен зеңләп тавыш бирә.

Әйтерсең лә качкын Тимеркул Шәмәй бабайның сагышы чыңлый.

Узган елны Ярмөхәммәт Сабан туенда Хәмәт абыйның гармун уйнаганын озак тыңлап торган иде. Көрәшче Хәмәт абыйның бармаклары бәләкәй генә гармунның тар телләренә тияр-тимәс тора кебек. Әгәр дә Хәмәт абый бер бармагы белән кагылса, гармунның өч теле берьюлы батар сыман. Ярмөхәммәт күпме генә карап торса да, Хәмәт абыйның бармаклары ялгышмады. Гармун өздереп уйнады да уйнады.

Ярмөхәммәтнең керфекләренә кагылып, кояш жиле шул көйне чыгара иде. Кояш жиле аның ике уч төбенә килеп бәреләдә юкка чыга. Бераздан тагын сабыйның уч төбен кытыклый.

— Чын-дөрес исеме аның Ярмай-Урак, балам,— диде дә Айдаш карт күзен ачты.

Бабасы карашына ияреп, Ярмөхәммәт авылны югары очыннан түбән очына чаклы күздән кичерде. Караш Кызыл Тау артындагы урманга күчте. Ерак урманнарны, болыннарны, басу-кырларны әйләнеп, караш янә Ярмай авылы өстендә туктады. Тау башына менеп, тирә-якны мең тапкыр күзәтсәң дә караш божрасы, фикер тугымы барыбер Ярмай авылында килеп йомыла. Туган авыл шушында булмаса, табигать шулкадәр матур булмас иде. Ярмай авылы таусыз, сусыз, урмансыз такыр басу уртасында япа-ялгыз утырса, шулай якын булыр идеме икән?

— Ни өчен Ярмай-Урак соң ул, бабай?—

— Ярмай-Урак,— дип кабатлады бабай.— Борын заманда Ярмулла ыруы Идел буенда яшәгән. Кайбер риваятьләрдә аның исеме Ярмөхәммәт дип тә сөйләнә. Атаң сиңа әнә шул борынгы бабабызның исемен куйдырды. Ярмулла баба Аждаһадан качып, Чулман якларына күчеп китә. Кангырап йөри торгач, ул Зәйчә елгасына, шушы урынга килеп чыга. Тавы бар, болыннар, тугайлар мул, балыклы елгасына унбиш чишмә генә коя. Алары бер хәл, иң яхшысы — юл өсте түгел. Монда зур елга керми. Елга буйлап, гадәттә, кеше талаучылар, юл кисүчеләр йөри. Ярмулла ыруы шушы урынга йорт корып жибәрә. Ярмай авылы барлыкка килә.

Иске зиратның ташларына 1601, 1608 дип уелган. Ул ташлар һаман исән әле. Изгеләр зиратында янтаешып торалар. Шул саннардан, беренче үлүчеләр язуыннан авылның кайчан салынганын чамалап була.

Йорт салырга агач — өстеңә аварга торган урманнан. Амбар-койма торгызырга таш — таудан үзе тәгәрәп төшә. Астан жыя гына бар. Малтуар асрарга болыннар, жәйләүләр бар. Иген үстерергә басу-кырлар киң. Үрчи Ярмай токымы. Өч жиргә су тегермәне корып жибәрә бабайлар. Тау башына тагын тегермән салалар. Жил тегермәннәре. Әнә, берсенең жимерекләре һаман череп ята.

(Каршы тау башындагы иске жил тегермәне янында Ярмөхәммәтләр гел качыш уйный торганнар иде).

Жир жәннәте шушы урында була инде. Гөрли тормыш, ишәя нәсел. Шулай рәхәт кичеп ятмыш көннәрендә Ярмай халкына бәла килә. Аждаһа атлы явыз зат белеп ала: Ярмай нәселе бетмәгән икән әле, Ярмай токымы яңадан үрчегән, элеккегә караганда да тазарак тормыш корган. Су юлыннан көткән дошман такыр юлдан, һавадан килеп һөжүм итә Ярмай авылына.

— Ярмай халкы миңа салым түләргә тиеш, һәр йорт капкасыннан бер сыер, бер ат, ун сарык, йөз пот икмәк, бер чибәр кыз, бер батыр углан чыгарга тиеш! Шушыңа риза булмасагыз, эзегез булмасын бу урыннарда!— дип Аждаһа бик каты куя мәсьәләне.

— Юк, Аждаһа,— ди Ярмай бабай.— Без Иделебезне ташлап китәргә мәжбүр булдык, Чулман иләндә нигез кордык. Чулман якасыннан да безне кудылар. Бу жирдән без беркая да китмәячәкбез. Берәр ат, берәр чибәр кыз түгел, без сиңа аксак кәжә дә бирмәячәкбез!

— Алайса орыш?!— дип акыра Аждаһа.

— Орыш!— ди Ярмулла бабай.

Коточкыч орыш башлана. Ярмулла батыр Аждаһаны жиңә. Ул урагы белән Аждаһаның корсагын ярып төшерә. Үлем жәрәхәте алган явыз зат Аждаһа егылган жирендә жан бирә. Ярмай бабай да бу орышта үлем ярасы ала. Борынгы бабабыз урагын ташлап, соңгы сулышын ала да тынып кала. Жан бирердән алда ул васыять әйтеп калдыра:

— Токымнарым, минем урак кая төшсә, шул урынга урам салыгыз,— ди.

Менә шул заманнардан бирле бу авылны Ярмай-Урак дип беләләр.

— Ә-әнә,— диде Айдаш карт,— аның кулы ерак болынга таба сузылды.— Ә-әнә, Коргантау — Ярмулла батырның кабере булыр.

— Коргантау Ярмулла бабай кабере?— диде Ярмөхәммәт.— Ялгыз имән үскәнгә аны Коргантау дип йөртәләр, диде Фәгыйлә апа.

— Фәгыйлә апаң белми ул. Безнең авыл кешесе түгел бит ул. Монда укытучы булып килде дә, кияүгә чыгып калды. Элегрәк белүчеләр бар иде авыл турындагы хикмәтле хикәяләрне. Менә хәзер син дә беләсең инде, улым!

— Корыгантау башындагы имән мең яшьлек, диләр, дөресме ул, бабай?

— Корыгантау түгел аның исеме, Корган тау, ягъни корып куелган, кеше кулы белән ясалган тау дигән сүз. Элек патшаларны, изге кешеләрне, каһарманнарны җирләп, аның өстенә тау корып куя торган булганнар, улым. Шуңа күрә Коргантау дип калган ул. Имән мең еллык түгел. Өч йөз кырык дүрт яшьлек имән ул. Ярмай бабайны җирләгән көнне Коргантау өстенә ыру башлыклары утырткан имән.

— Имәнне кисеп, боҗраларын санасаң, Ярмай бабайның үлгән елын төгәл белеп булыр иде,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Айдаш онычының ни уйлаганын сизде, ахрысы:

— Ярамый!— диде.— Имәнгә кагылырга ярамый. Ул изге имән. Ул Ярмай батыр токымының терәге. Аңа карап сокланырга кирәк. Аңа, ул имәнгә, ул Коргантауга табынырга кирәк.

Узган җәй бөтен халык Ерак болынга печәнгә төшкәч, Айдаш карт белән Хәсәнша икесе — атлама таяк — мәргәл белән ал бүлеп йөрде. Айдаш баба җир үлчәгеч таякны «мәргәл» ди. Мәргәлнең ун атламы саен чөй кагып чыктылар. Хәсәнша бригадир шундый оста үлчи җирне, Ярмөхәммәт дөньясын онытып аның эшен карап йөрде. Хәсәнша абый һич туктамыйча атлый, ә мәргәл, үзе йөргәндәй, хуҗасына ияреп бара.

— Карале, кара, Хәсәнша абзыйның сажины үзе атлап йөри,— дип чыркылдаша кызлар.

— Берәү, икәү, өчәү... унау!— дип саный Хәсәнша.— Как чөеңне, Айдулла абзый!

Чөйләр кагылып беткәч, җирәбә салдылар. Бәхетеңә чыккач — ал, печәне куе булса да синең, гел сарут кына булса да синеке. Үпкәләш юк. Чүкелгән, кайралган, көйләнгән чалгыларын алып, һәркем үз бае алдына килеп басты. Ләкин беркем дә печән чаба башламады. Айдаш баба әйткәч кенә башлаячаклар. Гел шулай булган инде. Айдаш карттан башка бер генә күмәк эшкә дә тотынмаганнар. Бабай эш башларга бер дә ашыкмый. Коргантау астыннан тибеп чыккан Изге чишмәдә йөзенкулын юды, юеш кулы белән сакал-мыегын сыпыргалап чыкты да, тау түбәсенә менеп, карт имән күләгәсенә кереп тезләнде. Тезләнде дә күзен йомып тын калды.

— Һәй, Айдаш баба, ташла намазыңны!— дип кычкырды Саһия.— Чалгылар күгәрә башлады бит.

Кемдер көлеп куйды. Ләкин бу көлкене берәү дә күтәреп алмады. Мондый вакытта Айдаш карт беркемгә дә җавап бирми. Кычкырган кешене соңыннан ачуланып та йөрми. Күрәсең, бу вакытта ул беркемне дә ишетми торгандыр.

— Намаз укый дияр идең, намазлыгы юк,— диде Саһия чытлыкай.

— Тимә картка,— диде Хәсәнша.— Ул синнән-миннән күбрәкне күргән кеше. Нишләсен ул үзе белә.

Бабасының нишләгәнен Ярмөхәммәт менә хәзер генә, тау башында торганда гына аңлады: Айдаш карт борынгы имәнгә, Изге Ярмәй рухына табынган булган икән.

— Изге имәнгә кагылырга ярамый!— диде карт.— Имән борынгы

бабабыз Ярмулла батыр кабере өстендә үсә. Тау астыннан Изге чишмә бәреп чыга. Изгеләргә кагылсаң, нәселең корыр.

Бу чишмәгә, Коргантауга татарлар гына түгел, һәр җәйне марилар да, чувашлар да килә. Изге суы шифалы була дип, шул суны эчәләр, шул суны өйләренә алып кайтып китәләр.

— Шуңа күрә аны Изге чишмә дип атыйлармы икән?— дип күптәннән сорарга йөри иде Ярмөхәммәт.

— Бөтен халык җыелганга изге түгел ул, улым,— диде бабай.— Изге булганга анда бөтен халык җыела. Керәшеннәр аны Изге Җәрмәй чишмәсе, ди. Чувашларга ул Чурмай Патыр. Ярмай бабаны бөтен халык үзенеке саный. Тикмәгә генә түгел ул, балам. Ярмай батыр үз токымын гына явыз заттан коткарып калмаган, тирә-яктагы башка токымнарны да Аждаһадан коткарган. Коткарган, үзе һәлак булган. Борынгы риваятьне халык бүген әнә шулай күңелендә саклый.

Урта болынны гына түгел, Ерак болынны да Изге чишмә туендырып тора. Коры елларда, тирә-юньдәге болыннар кипкән чакларда да Изге чишмәнең суы кимеми. Изге димичә ничек башкача әйтәсең инде шундый чишмәгә!

— Чишмәләр күп безнең якта, бабай,— диде Ярмөхәммәт.

Һәр чишмәнең үз исеме, үз әкияте бар, шулар турында сөйлә әле, дигән сүз иде бу.

Айдаш карт оныгының сүзләрен шулай аңлады.

— Урман тавыннан элек өч чишмә чыга иде. Хәзер берәү генә. Әнә, Урман тавында ике яшькелт урынны күрәсеңме? Элеккеге чишмә урыннары ул. Берсе Юа чишмәсе, икенчесе Ак тәпән чишмәсе иде. Агып ята торганы Килен чишмәсе.

Су алып кайтырга дип беренче көнне үк яшь киленне шул чишмәгә җибәрәләр иде, дип уйлады Ярмөхәммәт. Тирәсендә юа күп үскәнгә, Юа чишмәсе дип аталганын да, тәпәне саргаймаганга Ак тәпән дип аталганын да Ярмөхәммәт белә, иң кызыгы, иң шомлысы — Зәһәр чишмә. Зәһәр чишмә турында сөйләтәсе килә Ярмөхәммәтнең. Айдаш карт та оныгын нәкъ менә шул Зәһәр чишмә турында сөйләргә дип алып менгән иде.

Бабай сүз башлады:

— Без Ярмай үтергән Аждаһа өстендә басып торабыз. Хәзер «Кызыл тау» диләр инде! Аждаһаның башы, әнә, тегермән буасына терәлгән. Әнә, мөгезе. Күзләре юк инде, мин бәләкәй чакта ике күзе дә бар иде. Бик каты давыл вакытында Аждаһа күзләре аска тәгәрәп төште. Берсе буага батты, икенчесе яр кырында тора.

Ярмөхәммәт:

— Таш бит алар, бабай,— дип әйтергә ымтынган иде, бабасы сөйләвен дәвам итте:

— Кемгә таш, кемгә баш. Дүрт йөз елга якын яткач, таш түгел, күмергә әйләнерсең. Әнә, муены буйлап сарык көтүе төшеп бара. Без Аждаһаның сыртында. Ике тау арасы Аждаһаның ярасы. Ул ярык без төшеп-менеп йөри торган сукмак, Ярмай батыр урагының эзе. Ике тау арасында Зәһәр чишмә. Ул — Аждаһаның агулы каны.

Ярмөхәммәт белә: бу чишмәдән кеше түгел, хайваннар да су эчми. Эчкән җан нясен чир баса. Шуннан соң берәү дә мантый алмый, озак еллар кибеп-корып йөри дә, сәламәтлеккә туя алмыйча җан бирә.

— Зәһәрле чишмәнең суы кимеми, улым,— диде карт.— Ага да ага. Зәйчә инеше буенда. Зәһәр чишмәдән түбән якта авыллар юк. Ярмайдан өстә авыллар чакрым саен урнашкан. Аскы якта, Зәһәр чишмәдән соң бер генә авыл да очрата алмассың. Би-ик ерак баргач кына сирәк-мирәк авыллар күренә башлый. Башка инешләр Зәйчәгә кушылып, Зәһәрле чишмәнең агуын сыегайталар. Су зыянсыз булып, саф чишмәләр белән катнашып беткән тирәләрдә авыллар күренә башлый.

Айдаш карт тынып калды. Аннан соң тиз генә әйтеп куйды:

— Хәзер Дәватау гына калды. Дәватауның да тарихы бар, улым...

— Ул тауда давалы үләннәр үскәнгә аны Дәватау дигәннәр, иеме, бабай! — диде Ярмөхәммәт.

— Дөрес, анда мәтрүшкә, җиләк күп була. Элек анда чия, гөлҗимеш бик уңа иде. Кавыннар тәгәрәшеп үсә торган ие. Гел бал гына була иде шул кавыннар. Бал гына ие...

— Бабай, нигә хәзер кавын үстермиләр?

— Сугышка хәтле дә, борын заманнарда да бик уңа ие кавын. Кая хәзер... Кавын кайгысымыни? Арыш-бәрәңге үстерә кеше. Их, ул Дәватау кавыннары мең чирдән дәва ие. Чияләр дә бетте. Гөлҗимеш тә юк. Кавын да корыды.

Кемгәдер үпкәләгәндәй, Айдаш карт турсаеп калды.

Үпкәләвеннән арынгач, ул Дәватауга ымлап:

— Яхшылабрак карале,— диде.— Нәрсәгә охшаган Дәватау?

— Дөягә! — диде сабый.

— Дөягә шул, дөягә. Дәва үләннәре өчен түгел, дөягә охшаганы өчен Дәватау ул.

— Нигә соң Дөятау түгел?

— Борынгы вакыт дөяне «дәвә» дигәннәр бабайлар... Әнә бит, муенын сузып җиргә яткан да йоклый дөя. Тегеләре үркәчләре... Ярмай токымыннан булган Чапак морза Кытай белән сәүдә иткән. Урта Азиягә кәрван йөрткән дип сөйли борынгылар. Шулай тынгысыз булгангадыр инде, исеме дә үзенә йогып тора — Чапак морза. Чапак моннан төлке, аю, кеш тиреләре алып китә икән дә, тегеннән халыкка кытай савытлары, тоз ташый икән, чәй алып кайтып сата икән, бик абруйлы адәм булган ул Чапак морза. Ташаяк, чинаяк, тоз, чәй алып кайтканы өчен халык аңа мең-мең рәхмәтләр укыган. Моннан кыйбатлы җәнлек тиреләре алып барганы өчен аны Урта Азия, Кытай түрәләре бик тә яраткан. Гомерләр узган. Чапак морза соңгы китүеннән кире кайтмаган. Юлбасарлар аның кәрванын талап, үзен суйганнар икән дип сөйләүчеләр дә була. Төрлечә юраганнар Чапак морзаның югалуын. Шул хәбәрләрдән соң күп тә узмый, Чапак морза кәрваны башында йөрүче карт дөя берүзе Ярмай-Уракка кайтып төшә. Кышкы әче бураннар башлана. Әшәке зәмһәрир суыклар килеп, Ярмай халкының байтагы кырыла. Бу салкыннарны Төньяктан, Котыптан җил алып килә икән. Чапак морзаның карт дөясе булмаса, Ярмай-Урак балалары бере дә калмый катып үлгән булыр иде. Теге бичара дөя саклап кала аларны. Дөя, әче салкын җилгә киртә булып, авылны ышыклап ята. Иртән торып карасалар, дөя үзе катып үлгән була. Шул заманнардан бирле Ярмай-Урак авылына Котып җилләре үтеп керә алмый икән. Әче җилләргә аркылы Чапак морзаның ике үркәчле карт дөясе — Дәватау ята.

— Ничек инде? Дөя бит аттан әз генә калку. Ә Дәватау әнә, дөнья хәтле! — диде Ярмөхәммәт.

— Йөзәр ел яткач, туфрак өелә. Туфракта үлән, агач үсә. Таулар, балам, тәбәнәкләнми. Тау-ташлар да үлән сыман үсә,— диде бабай.

Айдаш карт, гомер булмаганны, бик озак сөйләде бүген. Чәчәкләр, тамырлар турында риваятьләр, Салкын чишмәдәге табип балыкларының серләрен оныгы колагына ирештерде. Бабасын бүлдерергә шүрләп, Ярмөхәммәт тыңлады да тыңлады.

— Хәзер урманга киттек, урман аша кайтырбыз,— диде Айдаш.

Алар туры сукмактан, Зәһәрле чишмә буйлап та кайта ала иде югыйсә. Таудан төшү белән — авыл. Ни өчендер бабай оныгын әйләнеч юлдан, урман аша алып кайтырга булды.

## Урман иясе

Бабалы-оныклы ике кеше урманга кергәндә имән агачыннан бик матур бер кош очып китте. Үзе урманны яңгыратып кычкыра.

«Куркуыннан шулай кычкыра!»— дип уйлады Ярмөхәммәт.

— Күкшә! — диде карт.— Урман каравылчысы күкшә. Урманга кешеләр килә, урманга кешеләр килә дип кычкыра ул. Сак булыгыз, урманда кеше бар ди. Хәзер бөтен урман Айдулла карт белән оныгы Ярмөхәммәтнең урман авызына кергәнен белә инде. Керпе дә, елан да, Урман иясе дә белә. Шәмәй качкын юлыннан ике кеше урманга керде, сак булыгыз! — дип кисәтә күкшә. Качарга тиешле җәнлек кача. Яки куак артыннан безне күзәтә. Качасы килмәгәне үз гамендә булыр. Ә төлке якында гына йөри. Әнә бит, матуркай...

Юлдан аерылып, урман эченә кереп киткән сукмак аланчыгында елгыр төлке уйнаклый иде. Ул җәһәт кенә аска иелеп нәрсәдер эзли дә, башын күтәреп пуф-пуф иснәнә. Ләкин кешеләргә карамый. Кешеләр аның өчен юк кебек. Исе дә китми, һаман нидер эзли, иснәнә. Атласаң, нибары биш адымлап булыр. Сикерсәң, тиз генә койрыгыннан каптырырлык кебек.

— Безне үчекли,— диде карт.— Тотып кара, җитеп кара син аны. Тоталмыйсың, тоталмыйсың, менә генә бит минем матур койрыгым, я тотып кара, ди бит хәйләкәр.

Ярмөхәммәт кинәт сукмакка сикерде, төлке тавыш-тынсыз гына юк булды. Айдаш баба кеткелдәп көлде:

— Хе-хе-хе, тоттыңмы? Сине үрти ул, синнән көлә!

Күкшәдән соң кош тавышлары чак кына тынып калган иде. Хәзер исләрендә дә юк, ду килә урман халкы. Кошлар якында гына сайрый. Сайрый алганы сайрый, сайрый алмаганы кычкыра. Тиеннәр кул белән тотып алырлык арада гына. Аларга игътибар итмәгәнгә салышып барсаң, тиеннәр дә, кошлар да якында гына йөри. Әгәр дә син «их, тотып алырга» дип уйласаң, шундук атылып читкә китәләр. Әйтерсең, алар Ярмөхәммәтнең уен укыйлар.

— Уеңны укымыйлар алар, улым,— диде карт.— Синең күзеңнән синең теләгеңне күрәләр, синең муеның алар ягына борыла башлаганына кадәр күзәтә алар. Шул кечкенә хәрәкәтеңнән синең ниятеңне аңлый.

— Бабай, без бит аларга тимибез. Алар безнең начар кеше түгеллекне белә бит. Нигә алар бездән курка. Төлке, килеп, миңа сырпаланса, мин аңа зыян китермәм. Сыйпап-сөеп торыр идем дә кире җибәрер идем. Шунда берәр тиен минем иң башына утырса, ни булыр иде инде?

— Кошлар, киекләр яхшы кешеләрдән дә куркырга тиеш.

Җәнлекнең тиресе никадәр кыйбат булса, аның гомере шулкадәр кыска.

Кошның ите никадәр тәмле булса, ул токымга яшәве шулкадәр кыенрак.

Бу якларда кыр үрдәкләре бетте. Кыр казлары сирәгәйде. Чәүкә белән карга бихисап.

— Курыксыннар,— диде Айдаш карт.— Курыксыннар, шулай кирәк. Матурлыкны саклар өчен азатлык кирәк.

Айдаш карт оныгын урманның иң аулак җиренә алып керде. Күе агачлар ачыклыгында абагалык. Җил агач башларыннан гына исеп уза, аска төшә алмый. Урманда шомлы тынлык. Әллә ничек сәер. Якты дөньядан, кешеләрдән, авылдан аерылып, бүленеп калганнар да мәңге шушыннан чыга алмаслар кебек.

Айдаш карт абага арасына кереп китте, Ярмөхәммәт аңа иярде. Бераз баргач, бабасы әйтте:

— Әнә, кара! — диде.

Ярмөхәммәт күзенә сарган пәрәвезне бармаклары белән сыдырып алды. Күе абагалык уртасында кабергә охшаш калкулык, калкулык башында язулы таш басып тора иде.

— Шәмәй качкынның кабере шушы! — диде Айдаш карт.

Ярмөхәммәт өнсез калды. Аның башына утлы күсәк белән суккан кебек булды. Халык телендә жырлана торган Шәмәй качкын аңа экият батыры сыман тоела иде. Башка балалар да аны бары тик борынгы бәет итеп кенә беләләр.

— Качкын Тимеркул Шаһимәрдән дип үзем яздым... Ташы искергән инде. Комташ кына булды шул. Син, улым, яхшы таш куйдырырсың... Үскәч... Тулысы белән яздырырсың. Елына бер булса да килеп карап тормасаң, каберне урман басып үтәр. Менә шулай кабер янындагы абагаларны утап торыш кирәк...

Абагалар иле. Абага диңгезе монда. Шул диңгез уртасында кеч-кенә бер утрау — Шәмәй качкын кабере. Исән чакта да туганнарыннан аерылып, каңгырап йөрергә мәжбүр булган. Үлгәндә дә авызына су каптырыр кешесе булмаган. Инде кабере дә туганнарыннан ерак, кеше күзе күрмәс жирдә. Ятим кабер.

«Ятим» төшенчәсе күңеленнән сызылып узуга Ярмөхәммәт тетрәнеп куйды. Ятим качкын. Бәлки аның атасы да һәлак булгандыр. Һәлак булгандыр да, аның кабере дә шулай ятимдер!

Оныгының шундый газаплы, авыр уйлар кичергәнен Айдаш карт сизенде, ахрысы, сүзне гел икенчегә борды.

— Бүген төнлә абага чәчкә атарга тиеш иде дә...

Ярмөхәммәт аның тавышындагы көлемсерәүне сизми калды.

— Бүген? — диде ул гажәпләнүен яшерә алмыйча.

Абага ел буена бер генә чәчәк ата, диләр. Ихтимал, бәлки гомеренә бер генә тапкыр атадыр. Чәчәк атканда да абага яшеренеп кенә, төн уртасында гына ата. Яшерә ул чәчәген кешеләрдән. Кош-корт, киек-жәнлек адәмнәрдән курыккан кебек, абага да кешеләрдән курка. Ул үзенең токымын яшерә. Шуңа күрә абага урманның иң куркыныч жирендә, кеше сирәк килә торган куелыкта, сазлык, дымлы урында гына үсә. Шуңа күрә абаганың чәчәк атканын күргән кеше юк. Абага чәчәген күргән кеше булса да, без аны күрә алмас идек. Абага чәчәген өзеп, тел астына салсаң, кеше күзенә күренмәс буласың. Абага чәчәген өзгән кешене без беркайчан да белә алмаячакбыз. Кайсы тиле, мин абага чәчәге өзеп, күренмәс кешегә әйләнә алам, дип кычкырып йөрсен! Тиле булса, ул абага чәчәгенә кадәр барып та житә алмас иде.

— Абага хәзер бөтенләй чәчәк атмый шул,— дип дәвам итте Айдаш карт.— Элек чыннан да чәчәк аткан ул абага. Шул чәчәкләрне авызларына кабып, бик күп мәкерле кешеләр күренмәс булып, адәмнәргә зыян-зәхмәт кылып йөри башлаганнар. Шуннан соң абага чәчәген яшергән. Мәңгегә яшергән. Хәтта яхшы кешеләрдән дә яшергән...

Бәхет — ул абага чәчәге. Абага чәчәген өзсәң — син бәхетле.

Әмма абага беркайчан да чәчәк атмый.

Ялгыз кабер тирәсен бераз утап, жыештырганнан соң алар кайтырга чыктылар.

Туксан яшьлек Айдаш карт белән тугыз яшьлек Ярмөхәммәт — тугыз гына яшьлек булса да, кинәт олыгая төшкән Ярмөхәммәт урман аша кайтып килә. Айдаш карт ни өчендер алак-ялак карангалый. Юл буенда гына үскән агачларның яфракларын сыпыргалап ала. Очып киткән кошка карап кала. Ярмөхәммәт тә бертуктаусыз урманны күзәтә. Жентекләп, текәлеп караган саен урман ачыла, киңәя бара. Элек күрмичә йөгереп узган үсемлекләр, чәчәкләр, агачлар аңа зур булып күренә. Урман бай, урман матур. Шулай да урман шурләтә. Һәр агач артында кемдер бар кебек. Ул «кемдер» сине күзли кебек.

Син урманны ике күз белән генә күзәтәсең. Урман сиңа мең күз белән карый.

Алача киндер ыштанынннан пычагын чыгарып, Айдаш карт туйра кисеп алды. Адәм биеклеге булып үскән яшь имәннән бер ботак, икенчесеннән бер ботаклап, себерке җыйды.

— У-у, монда туйралык икән,— диде Ярмөхәммәт.

— Шул күкшә эше,— диде бабай.— Күкшә-тынгысыз урман ясый. Кышка дип җыйган урман чикләвекләрен кай җиргә күмелгәнен онытa да, чикләвекләр икенче язны тишелеп чыга, туйра була. Туйра имән булып үсә.

Айдаш карт имән себеркесен курыс белән бәйләп куйды.

— Хәзер бер минлек каен җыябыз! — диде ул. Айдаш карт култык астына туйра себерке, Ярмөхәммәт каен себеркесе кыстырып урманнан чыкты.

Алар урманны чыкканда юл җилләгән иде инде.

— Иртәгә иртән ура башларга була,— диде карт.

Кипшергән җирдән түбән таба атлавы җиңел. Айдаш карт җилтерәп кайта. Борын эченнән генә нидер көйли. Ул сәяхәттән бик канәгать иде бугай. Ул инде сөйләнми, юл буйлап авылга элдерә. Ярмөхәммәт аның артыннан көчкә өлгерә. Туксан яшьлек карт димәссең, билләһи.

— Әйдә, улым, вакыт аз калды,— диде карт борылмыйча гына.

Артта калган колын сыман, Ярмөхәммәт бабасын куып җитә дә тагын калыша. Аннан тагын йөгерә-юырта бабасын куып җитә. Шулай юрт-юрт атлап, терек-терек теркелдәп, алар авылга төшеп җитте.

Ни өчендер Айдаш карт туры өйгә кайтмады.

«Турыдан гына басма бар көе нигә югароч күпереннән әйләнергә булды икән бу бабай?»— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Аръяк урамында каршысына очраган һәр кешегә кычкырып сәлам биреп, сәлам алып йөрде Айдаш баба. Каз куучы әбиләрне сөйләндереп торды.

— Атың кем? Кем баласы син? — дип ыштансыз малайларның исемнәрен сораштырып китте.

Белә! Белә лә ул картлач кемнең кем баласы икәнен. Юри сорый. Әйттерер өчен, тел ачтырыр өчен шулай сораша ул.

Югароч күпереннән чыгып, алачыкка таба киттеләр. Йомышы булса булмаса да, Айдаш бабай тимерче алачыгы янынннан болай гына узып китә торганнардан түгел.

— Нихәлләр бар, Рәван? — диде бабай, күрек янында күмер көйрәтеп азапланучы тимерчегә. Ярмөхәммәткә бабасының шулай шат исәнләшүе сәер тоелды. Салмак-уйчан картны танымассың.

— Урагың әзер, Айдулла бабай,— диде Рәван.

Сөйләшеп куйганнар диярсең, Рәван да нәкъ бабай сыман шат тавыш белән җавап кайтарды. Рәван почмакка сөялгән уракны алып, тешләрен иске чүпрәкләр, чыпта белән урап, Айдаш картка тоттырды. Карт туйра минлеген онытына сузды.

— Артбасуны урып бетерергә чыдар! — диде Рәван.

— Артбасуны урып бетерергә чыдар ла ул...— диде Айдаш карт.

Ярмөхәммәт ике себеркене ике култык астына кыстырып, яңа төшкән сукмактан чәп-чәп атлап бабасы артыннан кайта.

— Син шушында утырып тор,— дип, Айдаш карт уракны коймага сөяп, Фәрхуннарга кереп китте.

«Бабайга анда ни калган икән?»— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Байтак торганнан соң Айдаш карт чыкты. Картның Фәрхун белән ни сөйләшкәнен беркем дә белмәде.

Шулай кайтып барганда алар каршысына көянтә-чиләк күтәргән Җәмига исемле хатын очрады.

— Килен чишмәсеннән кайтасыңмы, кызым? — диде бабай.

Килен чишмәсеннән кайтканын күрсә дә, шулай сорый бу якта халык. Үзләренчә сүз башлау, исәнләшү була инде ул.

— Ие, Айдулла абзый, менә әз-мәз ял тигәндә тәмле су белән чәй кайнатып эчик дигән иек тә...— диде Җәмига түти.

— Сафиулланың хәбәре юкмы?

— Юк, Айдулла абзый,— диде дә Җәмига яулык чите белән авызын каплады.— Кеше сугыштан да исән кайта. Исән булмаса, үле хәбәре килә. Безнекенең ни хаты, ни хәбәре. Исәндерме, юктырмы, бер алла белә.

— Озакламый син дә белерсең, килен. Озакламый хәбәр алырсың.

— Ходай кушсын инде, Айдулла абзый. Ике бала бит, аларны ничек үстермәк кирәк. Рәхмәт инде яхшы сүзеңә, хет син белешеп торасың.

— Исәнлегенә ышандыра алмыйм... Сабыр бул, килен, барына да әзер була күр. Бик бетерешмә.

— И-и аллам, ниләр генә күрергә язгандыр,— дип, Җәмига түти капкасыннан кереп китте.

Кайтып житкәндә аларны бригадир Хәсәнша каршылады.

— Фу, тәмам аяк калмады,— дип башлады ул кабынган сулышына төртелә-туктый.— Сабир иманны ала язды, Айдаш абзый. «Нигә иртә туктадыгыз? Нигә Айдаш карт урмый?»— дип кычкыра.

Айдаш бабай уракны Ярмөхәммәткә тапшырды. Бу: «Бар, улым, уракны, себеркеләрне алып керә тор»,— дигән сүз иде. Ярмөхәммәт ишегалдына узды.

— Сын, Хәсәнша улым, күрмисеңмени, урак сынды. Бер...

— Беләм лә мин, Айдаш абзый, бик беләм, урак сынганын да беләм. Ул аны аңлыймыни?

— Икенчедән, яңгыр яуды...

— Анысын да белә ул... Әнә, үзе килә... Бар инде, Айдаш абзый, күзенә күренмә, кереп кит, ул сине эзләп йөри.

Тыкрык борылмасында җигүле ат башы күренде. Баш артыннан гәүдә, тәртә, тарантас сузылып чыкты. Тарантаста киерелеп Сабир утыра.

Айдаш карт юри кереп китмәде шикелле. Урамда йомышы булмаса да, кузгалмады.

Килеп житәр-житмәс, Сабир тарантастан сикереп төште, кулындагы нечкә тал чыбыгы белән күнитек кунычына чат-чат сугып алды. Сабир-председательнең житәкләү ысулы чыбык-чыбыркы-йодрыктан гыйбарәт икәнен бөтен авыл белә. Тик Сабир беркайчан да Айдаш картка кизәнмәде. Эшәке теле белән хатын-кызларның, карт-коры, бала-чаганың котын алып бетерсә дә, Сабир-председатель Айдашка кычкырырга базмый торган иде. Айдашка әйтәсе сүзләрен ул бүген Хәсәнша бригадирга коеп бетергән иде инде. Шулай да бүгенге Сабир үзгә күренә.

Председатель:

— Нәрсә, Айдаш абзый,— дип эчке бер зәһәрлек белән сүз башлаган иде, Айдаш карт:

— Әссәләмегаләйкем, Сабирҗан! — дип аның сүзен кисте.

Бу сәлам: «Итагатьсез бала, мәдрәсәдә хәлфәң, йорт-жиреңдә атанаң булмадымыни синең? Олы кешегә сәлам бирергә өйрәтүче булмадымы? Иң башта кеше белән исәнләшергә кирәк!»— дигән мәгънәне үз эченә алган иде.

— Дәшми-дәшми бу прсидәтел Сабир дигәч тә, син дә узына башладың, Айдаш абзый,— дип кычкырды Сабир.— Урак төзәтергә дә вакыт булды, жир дә кипшерде, ә син тау башларында тасраеп йөрисең. Уттай эш өстендә кем мунча ягып, халыкны котырта? Син, Айдаш абзый!

— Кипмәде әле, Сабирҗан! — диде карт тыныч кына.

Бригадир Хәсәнша бер җай табып, шыпан-шыпан кыяклады.

— Арыш арасы кипмәгән әле, Сабиржан,— диде Айдаш карт.— Машинага уралачак, атларга авыр.

— Ике ат бер лабагри тартмаска! — диде Сабир.

— Кая ике ат? — диде Айдаш баба.— Рикәкәне атка санасаң, тавыклар көләр. Ул бит үзе көчкә йөри. Фураж бирмисең! Сабыр итик, Сабиржан. Бүген юеш басуга кереп, атны аяктан екканчы, машинаны ватканчы, көтик иртәнгә чаклы.

— Бернинди сабыр да юк, Сабир да юк. Хәзер үк басуга чыгасың!

— Бүген кул белән урырга куш. Мин бүген чыкмыйм...— диде дә карт капка келәсенә басты.

— Их, Айдаш карт, син камунис түгел, камунис булсаң, мин сине партиядән чыгартыр идем! — диде председатель.

— Синең шикелле камунис булудан камунис булмавың мең өлеш артык, Сабиржан,— диде Айдаш карт.

— Пад су-уд! Сабата-ажж! Нигезеңне корытам мин синең, Айдаш карт! — дип кычкырды-кычкырды да Сабир тарантасына утырып каядыр китеп барды.

Албакча артына поскан Хәсәнша Айдаш карт янына йөгереп килде.

— Харап иттең, Айдаш абзый,— диде бригадир үрсәләнеп,— нигә шулай әйтергә иде инде?

Айдаш баба ишегалдына узды, Хәсәнша аңа иярде. Амбарга сөялгән уракны алып, Айдаш карт Хәсәншага сузды:

— Менә, Хәсәнша, бу теше Рәван үзе тимер таптап ясаганы. Җир башына чыккан саен карап-тикшереп торсын урасы кеше. Иртәгә иртүк машинага уракны Рәван көйләп бирер.

Айдаш карт мунчага кереп китте. Бригадир ни әйтергә белмичә, уракны кочаклаган килеш, ишегалды уртасында басып калды.

— Нигә алай киреләнәсең, Айдаш бабай,— дип картны үгетләргә ымтынган иде дә, ак сакаллы бу карт ике сөйләшә торганнардан түгел дип, Хәсәнша уеннан кайтты. Уракны тоткан килеш капкадан чыкты.

Айдаш карт ташка эссе салып, мунча ишеген бераз ачык килеш тотты. Өр-яңа туйра белән каен миңлеген ләгәндәге суга батырды. Берничә тапкыр чайкаганнан соң, ике миңлек белән корым-ис-тузаннарны ачык ишеккә таба куып йөрде. Ике тапкыр шулай эшләгәннән соң, ишекне ябып, тагын эссе салды. Бер уч су таш өстенә килеп төшү белән мунча ишеге шартлап ачылды. Тагын бик каты эссе салгач, Айдаш ишегалдына чыкты.

Болдырдан ук күренеп тора, Факиһә өйалдын юып чыгарган, баскыч такталары сап-сары. Чабата-башмаклар, җепкә тезгән кебек, тора.

Тау-урманнарны әйләнеп кайткач, картка нәрсә кирәген өйдәгеләр бик яхшы белә. Чәй кирәк Айдаш бабага.

— Мунча шәп булган! — диде карт ишектән керешли.

Нурлыгаян эшкә киткән, ахрысы, өйдә күренми. Факиһә бабасына чәй хәстәрли.

— Үлеш анда, бабай! — диде кыз.— Колаклар пешәрлек булган. Мунча бүрәнәләренә кул тидерерлек түгел. Шырпы сызсаң, кабынып да китәр, билләһи! Тефү-тефү, алла сакласын!

— Шулай кирәк! — диде карт.

## Мунча

Карт исә Сабиржанны күптән оныткан иде инде. Ул мунча турында уйлый. Ашыкмыйча гына чәй эчкәннән соң:

— Әйдә, улым, киттек,— диде.

Ярмөхәммәт, кулындагы кечкенә тартмачыкны Факиһәгә күрсәтмәскә тырышып, бабасына иярде.

— Әй, кая алдың тартманы? — дип аны Факиһә тотып алды.

— Чакматаш белән ку кучкарда, миндә кабы гына,— диде Ярмөхәммәт.— Апа, валлаһи-билләһи, мин аны урынына куярмын.

— Нигә ул сиңа, малай?

— Бер эшкә, апа.

— Ут-күз чыгарыргамы, давай китер капны!

— Апа, чакма белән ку, әнә, кучкарда, миңа аның тартмасы гына кирәк. Билләһи, мин ут белән уйнамыйм, апа,— дигәч, Факиһә энесен ычкындырды.

Ярмөхәммәт, бу тартмачыкны кадерләп чүпрәккә төреп, мунча өйалдысының кечкенә тәрәзәсе төбенә куйды.

— Эһем-эһем,— дип ул нечкә генә аваз белән тамак кырды.

Эчтән бабасының тавышы ишетелде:

— Әйдә-әйдә, улым, кер! —

Малай җәһәт кенә киндер күлмәк эченнән шуып чыкты. Сүс киндерәнең кыска элмәгеннән тарткан иде, алача-киндер ыштан шуып төште. Ул күлмәк-ыштанын төреп сәкегә куйды да мунча ишеген ачты, маңгайга кап-кайнар һава килеп сыланды. Малайның тыны капланды.

— Ишегеңне катырак яп! — диде карт.

Ярмөхәммәт бабасы кушканны эшләп, ишек катындагы сәкегә утырды. Айдаш карт малайның җилкәсенә йомшак кына сугып:

— Түр сәкегә уз,— диде,— Кайнары ишек катында күбрәк була аның.

Ярмөхәммәт ике кулы белән битен каплады, күрсәтелгән урынга барып утырды. Мунча эче тын алгысыз эссе иде. Ишектән килеп керүгә Ярмөхәммәт тирли башлады. Тау башындагы җилдә, кояшта яргаланган маңгай әчетә. Тир ага. Кайнар тир маңгаендагы, каш араларындагы керне агызып, күзгә кертә.

— Әллә-лә,— диде Ярмөхәммәт.

— Башыңны ләгәндә чылатып ал! — диде карт.— Битеңне ю!

Ярмөхәммәт җылымса су белән башын-күзен юды. Сулышы иркенәеп китте. Айдаш бабаның исе дә китми, таш капкачын ачып әз-әз генә кайнар су сибә. Су салган саен кайнар һава шаулап бүрәнәләргә килеп бәрелә, аннан соң һава дулкыны ишеккә китереп ора. Ишек ыңгырашып-сыкрап куя. Ачылып китәр иде дә, ишек келәгә элэктерелгән.

— Әнә шулай ишек янына җыела ул эссе,— дип сөйләнә-сөйләнә кулындагы ике миннек белән бабай, кылыч айкап сугышучы батыр шикелле, болгана башлады.— Менә шулай иткәч, эссесе ләүкәгә китә аның.

Айдаш карт куып җибәргән кап-кайнар һава дулкыны Ярмөхәммәткә килеп бәрелә, маңгайны, бармакларны, иңсәләрне пешереп уза. Арыш кылчыклары кереп, чәнчеп йөдәткән урыннарда рәхәт бер кычыту уяна. Бабасы җилпегән саен эссе килеп бәрелә, тагын рәхәт булып китә.

Мунча эченә тәмле каен исе, туйрага уралган мәтрүшкә исе таралган. Тын юлын пешермәс өчен, Ярмөхәммәт миннекне битенә каплый да яфраклар арасыннан салмак кына сулый. Үпкәләр хуш исле кайнар һава белән тула. Айдаш карт тагын эссе өсти, тагын өсти, тагын өсти дә ике себерке белән эссене ишек катыннан тагын ләүкәгә куа. Аннан соң миннекләрне ләгәндәге кычыткан'лы суга батырып, үзе ләүкәгә менеп утыра.

— Менә шулай,— ди карт.— Эссесе булмаса гына себерке белән чабына кеше. Яхшы мунчада себерке чабынырга түгел, эссене әнә шулай ишекле-түрле куып йөртер өчен кирәк. Тәмле исе өчен генә кирәк.

Ярмөхәммәт идәндәге чүлмәктән бер-ике йотым салкынча әйрән эчте. Аягүрә бассаң, колак пешә. Шуңа күрә Ярмөхәммәт иелеп йөри. Ул янә түр сәкегә утырмакчы булды.

— Ләүкәгә мен!— диде бабасы.
— Анда чыдап булмый,— диде Ярмөхәммәт.
— Әйдә, әйдә,— дип Айдаш баба онын ләүкәгә яткызды.— Кайнарга түз, улым. Салкынга түз. Безгә түзем булырга кирәк. Безгә гел эссе була. Җә гел салкын була, җә... Безнең ише халыкка урталык юк.
Ярмөхәммәт бабасының нәрсә әйткәнен аңлап бетермәде.
Айдаш карт ике миннекне дә алып, иплән кенә Ярмөхәммәтнең гәүдәсе өстендә җилпи башлады. Туйра белән каен себеркесе бала җилкәсенә тияр-тимәс кенә үтеп китә. Кычыткан тәнгә кап-кайнар һава килеп бәрелә, тән пеште дип кычкырасы килә, ләкин тән пешеп өлгерми, илаһи ләззәт биреп, кайнар һава узып китә.
Бераз түзсәң, әрнү ләззәткә әверелә.
— Ә-ә-әх, хә-хә-хә-хә-әх! Менә шулай! — дип бабай себеркеләрне сизелер-сизелмәс кенә Ярмөхәммәт җилкәсенә якынайта бара.
Яфраклар тәнгә тиеп-тиеп ала.
Чәт-чәт итеп миннекләр алмаш-тилмәш җилкәгә куна башлады.
— Ә-әх, хә-хә-хә-хәх! — дип кычкыра бабай.
Кешегә ләззәт бирү аның үзенә дә рәхәт иде, күрәсең.
Шунда могҗиза башланганын сизде Ярмөхәммәт. Айдаш карт миннекләрне кычыткан суында чайкап ала да рәхәтләндереп, онын чаба. Ыштан бавы буып торган җирләргә яфраклар тиеп киткәндә рәхәтлеккә чыдый алмыйча кычкырасы килә. Ярмөхәммәт кычкыра да:
— Ә-әх! — дип куя.
Суккан саен суктырасы килә. Ә бабай шуны сизеп-белеп тора кебек. «Их, арыш кылчыклары талаган арканы чапсын иде»,— дип уйлады Ярмөхәммәт, кайнар себеркеләр шундук аның җилкәсендә бии башлады.
Биш-алты тапкыр чапканнан соң, Айдаш карт ике себеркене дә онының сыртына ябыштырып-басып торды. Кайнар пар тәнгә батып, сеңеп керә сыман.
— Икенче ягыңны әйлән, улым! — диде карт.
Ярмөхәммәт чалкан ятты.
— Шәҗәрәңне капла! — диде бабасы.
Шуннан соң Айдаш бертуктаусыз онын чапты. Мәхшәр иде бу Ярмөхәммәт өчен. Чаба торгач, миннек белән аркылыга-буйга ышкый торгач, Ярмөхәммәтнең тәне, йөзе килгән угыз дурычмагы төсле, кызгылт-сары булды. Бабай ләгәндәге калдык суны онының өстенә сипте:
— Җә, тор! Хәзер минем чират! — диде.— Син юына башла.
Кая ул юыну! Бала атылып өйалдына чыкты. Монда рәхәт, салкынча. Мунча эченнән Айдаш картның кайнашканы ишетелеп тора: ча-аж-жж! Бабай тагын эссе сала. Тагын чаж-ж! Бабай тагын ишек катыннан ләүкәгә пар куалый. Тагын ләүкәгә менеп ята да, бераздан соң, ахылдый-ухылдый чабына башлый.
—Әнә шулай! Ә-әх, хә-хә-хәх! Әйдәгез әле, яфраккайлар, сихәтегезне сөякләргә хәтле үзгарыгыз!
Бераздан атылып Айдаш карт та өйалдына чыга. Ул чыгу белән Ярмөхәммәт аңа урын бирә. Бабай сәкегә сузылып ята.
—Шә-әп! — ди бабай.— Шәп ягылган!
Ярмөхәммәт юынырга дип эчкә узды. Бабасы хәл алган арада ул мунчала белән күбек кабартып, юынып, коенып өлгерде. Шул чак Айдаш карт керде.
— Чыгасың дамыни, улым? — диде карт.
— Эссе! — диде Ярмөхәммәт.
— Мунча эрәм кала! Яккан-яккан, әйдә, тагын бер чабыныйк! — дип Айдаш карт онын янә ләүкәгә яткырды.
Ду китереп әйләндерә-әйләндерә чапканнан соң:
— Булды, җитте! — диде карт.— Бераз сулыш ал да, аннары мине чабарсың.

Ярмөхәммәт өстенә салкын су бөркеде дә атылып мунчадан чыкты. Айдаш карт тагын эссе салырга кереште. Мунча тәмам кызып, шартлар дәрәҗәгә житеп килә иде.

Бераздан Ярмөхәммәт иелеп кенә мунчага узды.

— Башыңа бүрек ки, бияләйләр дә шунда булыр! — диде бабай.

Ярмөхәммәт тәрәзә кашагасына кыстырган бияләйләрне, чөйгә эленгән иске бүрекне киде дә ике кулына ике миндлек тотты. Ярмөхәммәт бакча карачкысына охшап калды. «Бакча карачкысы» чалдыйболдый җилпенә башлаган иде. Айдаш карт аны туктатты:

— Яңа себеркеләреңне куй, улым, алары авыр, искеләрен ал!

Җиңел себеркеләрне алып, Ярмөхәммәт тагын җилпенә башлады. Бабай оныгы чапканны бик тә ярата шул. Бабасы үзен ничек чапкан булса, Ярмөхәммәт тә бабасын шулай чабарга тырыша. Берничә тапкыр җилпенгәннән соң, чәп иттереп себеркене бабасының җилкәсенә ябыштырып, басып куйды.

— Ә-әх,— дигән ләззәт аша ыңгырашу ишетелде.

Айдаш карт шулай ыңгыраша-ыңгыраша, ахылдый-ухылдый мунча керергә ярата.

— Менә шул төшне чап... бу җиргә сук,— ди Айдаш.

Ярмөхәммәт бабасына рәхәт булган саен ныграк чаба.

— Шә-әп! — ди карт.

Шуннан соң Ярмөхәммәт нишләсен белә. Хәзер хәлдән тайганчы бабайның җилкәсен, бөер турларын, аяк табаннарын чабарга кирәк.

Айдаш карт авызыннан:

— У-ух, житте, рәхмәт, балам! — дигән сүзнең ишетелүе булды, Ярмөхәммәт себеркеләрне бабасына ташлап, мунчадан чыкты. Хәзер бабай үзе чабыначак. Бераздан аның аркасын ышкырга булыр. Анысына гына түзәргә була.

Бабасының аркасын ышкыганда тышта нәзек кенә тамак кырган тавыш ишетелде:

— Эһем-эһем...

— Ни бар, кызым? — диде бабай.

— Мәтрүшкәле чәй китердем, бабай, өялдына куям.

Сырт ышкылганнан соң Ярмөхәммәтнең вазифасы бетә. Ул комгандагы салкын су белән коенды да алача сөлгегә уранып утырды.

— Ух, мунчасы ла мунчасы, чәе лә чәе,— ди бабай.—

Айдаш баба тагын мунчага кереп китте.

Ул тагын чабыначак. Дүрт себеркенең дүртесеннән чыбык-чабык кына калачак бабайдан соң. Өялдындагы чәйне берүзе эчеп бетерәчәк. Шушында суынып, корынып, кипшенеп, бәйрәм киемнәрен киеп өйгә кайтачак бабай.

Өйдә, чыннан да, бәйрәм исе аңкый иде. Самавыр яңадан куелган. Матур итеп, моңлы итеп салмак кына чыжлап-сайрап утыра. Казан өстеннән бу күтәрелә. Өй эче тулы коймак исе.

Бабасы мунчадан кайтып кергәч, онык-кыз сөйләнә башлады:

— Мунча булгач, мунча булсын; бәйрәм булгач, бәйрәм итсен бабаң, диде әнкәй. Шуңа күрә теге онны туглап, коймак пешерергә кушты.

— Үзем дә әйтермен дигән идем дә, онытылган. Ярый инде, үзегез сизенгәнсез,— диде карт.

Ул канәгать иде. Ярмөхәммәт белән Факиһә самавыр тирәли утырды. Ләкин Айдаш карт табын ягына борылып та карамады.

— Анагыз кайтканны көтик, балалар,— диде ул.— Бәйрәм ашы бергә-бергә тәмле була ул.

— Коймак суына бит,— диде кыз. Аның тавышында үпкә чаткысы сизелде.

— Суынмас, кызым, син аны тимер табакка салып, өстен каплап, казан астынарак куй!

Нурлыгаян эштән бик арып кайтты. Икешәр норма урак урып кем генә армас. Ул болдыр баскычына утырып, чабатасына иярә кайткан арыш орлыкларын җиргә какты. Тавык халкы берсен берсе басасыта өерелеп, орлык өчен талаша башлады.

— Үлешәсез бит инде,— диде Нурлыгаян ачусыз гына.

Өйгә кергәч, Нурлыгаянның күңеле күтәрелеп китте. Җелекләргә үтә торган тәмле ис таралган. Кайнатасы, балалары өстәл тирәли кайнаша-кайнаша аны көтә. Чәй көтә. Коймак көтә икән бит. Аннан башка табынга утырмасларын ул яхшы белә, белсә дә:

— Нигә ашамадыгыз инде? — дип кызына пышылдады.

— Бабай бит,— диде кыз,— сине көтәргә кушты.

Факиһә самавыр башындагы чәйнекне чак кына кыйшайтып куйды: самавыр, борынындагы чеплә чикерткәләре авазы чыгарып, яңара башлады.

Нурлыгаян яртылаш кына булса да бәхетле. Кызы белән улы — бер сөенеч. Үз атасыдай булып беткән кайнатасы да авыр чакта нык терәк, шөкер. Ни әйтсәң дә, өзелеп ачыкканнары бик сирәк булды. Айдаш карт балаларга ачтан шешенергә ирек бирмәде. Чабата ясап сатты. Нурлыгаян палас сугып, барыбер очын очка ялгап, җан сакладылар. Шулай да олы бәхет өчен бер генә кеше житми табынга — Хисбулла. Хисбулла житми...

Табын янында беркем дә бер сүз кузгатмады. Бер уч он туглап пешергән коймакны, бетә күрмәсен дигәндәй, тәмләп, озаклап ашадылар.

Чәйдән соң Нурлыгаян белән Факиһә мунчага җыена башлады. Ярмөхәммәт, мунча тәрәзәсе өстендәге буш тартмачыкны алып, бакча аша су буена төшеп китте.

Айдаш карт ак өйнең түр сәкесенә урмәләде. Тир корыткыч сөлгесен ул иншләптер өстәл башында, кара өйдә калдырмады. Сөлге сәер булып, карт артыннан сөйрәлеп бара. Айдаш карт ак өйгә кереп киткән инде, ә сөлге Айдаш карт артыннан еландай шуышып бара сыман тоелды Нурлыгаянга.

— Әткәй, сөлгеңне ташла! — дип кычкыра язды Нурлыгаян.

Аның урынына кызы өлгерде:

— Бабай, сөлгеңне калдыр,— дип көлә-көлә, Факиһә бабасы иңенә ябышкан сөлгене алып, чөйгә элде.

Аналы-кызлы мунчага киткәндә картның:

— Ерак китеп йөрмәгез,— дигән тавышы ишетелде.

## Абага чәчәге

Бабасы да, башкалар да Ярмөхәммәт уйнарга чыгып китте дип уйладылар. Уйнарга китмәде ул. Урманга китте. Чакматаштан бушаган тартмачыкны чүпрәккә төреп, абагалыкка китте. Бәлки абага Ярмөхәммәттән чәчәген яшермәс? Ятып калганчы атып кал. Ярмөхәммәт бәхетен сынап карарга булды. Бабай белән урманда рәхәт иде, ялгыз башың гына шүрләтә. Агач артында күзләр бар. Алар синең һәр адымыңны күзәтеп тора. Яман ният белән карыймы ул күзләр? Әллә болай гына карыймы? Бәлки, ул төлкедер? Бүре булуы да бик ихтимал. Барасың да барасың, ә билгесез караш һаман синнән калмый, ияреп бара. Ияреп бара, ә үзе күренми. Ул билгесез затның аяк тавышлары да ишетелми. Коры ботаклар да шартлап сынмый, кипкән яфраклар да чоштырдамый. Ярмөхәммәт шунда гына аңлады, бу караш — урман күзе. Дөресрәге, Урман иясенең карашы иде бу. Урман иясе Ярмөхәммәткә тимәс. Ярмөхәммәт урманга явыз ният белән килми. Бары тик абага чәчәге өчен генә. Тимәс аңа Урман иясе. Ә шулай да шүрләтә.

— Урманда кеше бар! Урманда кеше бар! Бәләкәй кеше абагалыкка таба бара! Сак булыгыз! Урманда кеше бар!— дип кычкырып узды күкшә.

Урманга керү белән карангы төште.

Күзгә күренмәс сукмак сабыйны абагалыкка китереп җиткерде.

Көндез үк сайлап куйган карт зирекка менеп, төн уртасын көтәргә булды Ярмөхәммәт. Ул чакматаш тартмасы төрелгән нәни төенчеген тешләп, җәһәт кенә зирекка үрмәләде. Зирекнең сөзәк ботагына менеп атланды. Җилкәсе белән агач кәүсәсенә сөялде. Арка яктан һөҗүм була алмый: аны зирекнең юан кәүсәсе саклый. Астан да куркыныч юк: бүренең, төлкенең буе җитмәс.

Тукран тавышы ишетелми. Көне буе агач чукып, мие чәчрәп чыга язгандыр да ял итәдер. Күкшә тавышы да яңгырамый. Көн кошлары әкренләп тына, төн кошлары бер-бер артлы уяна бара.

Аста коры яфракларны кыштырдатып керпе йөри.

— Һу-у, һу-у,— дип Сак белән Сок бер-беренә аваз сала.

Өстә, агач башларындагы зәңгәр ачыклыкта, ара-тирә ябалакларның тавышсыз-тынсыз очып киткәннәре күзгә чалынып кала. Ярканатларның күңелгә шом салып, тын гына очканнары күренеп куя. Алар шулкадәр тиз оча, күз иярми кала. Әйтерсең лә кемдер ыргыткан таш шулай атылып китә. Һичнинди тавыш юк, канат җилпегән, каурый сызгырган колакка ишетелми.

— Фуй-фу! Фуй-фу!— дип кайдадыр ябалак фуфылдый.

Бөтен урман зеңләп тора. Әллә колак шулай чыңлыймы? Ныклап яшеренгән булса, да, каһәр суккан черки халкы Ярмөхәммәтне тәки эзләп тапты бит. Әллә шул озынборыннар тавышымы теге зеңгелдәвек? Юк, черкиләр безлиләр, зеңгелдәмиләр. Хәзер Ярмөхәммәт тик кенә утыра алмый инде, чәбәләнә, кашына. Үз янагына сугып-сугып ала. Муенына да чат ябышалар, имансызлар. Ул чәбәләнә башлау белән әлеге зеңгелдәү юкка чыга. Колак янында черки безелдәве генә торып кала.

Тавыш-тынсыз гына тагын бер ярканат очып узды, аның артыннан, җепкә тагылгандай, ябалак атылды. Тагын бер кат мәче башлы ябалак фуфылдап алды. Аннан соң шәүләгән мияулаганы ишетелде.

Абагалыкның уртасында Шәмәй качкын кабере. Кабер күренми. Күренмәсә дә, ул төнге урманга тагын да шом өсти. Ярмөхәммәт бөрешеп килде.

Шулчак аста, абагалыкта, могҗиза булып алды. Әллә каян, читтән, карурман эченнән шулкадәр матур асылташ очып төште дә, абага сабагына кунды. Сабакка куну белән асылташ чәчәккә әверелде.

Ярмөхәммәт: «Төштер бу»,— дип уйларга да өлгермәде, шул тирәдән ерак түгел генә тагын бер чәчәк ачылды.

Бу чәчәкләрнең матурлыгын башка бер чәчәк белән дә чагыштырып булмас иде. Чәчәкләрнең берсе бирәзәнең сыеграк төсе белән балкый. Икенчесе алсу. Зәңгәрсу төслесенең уртасында алсу ут ялтырый. Балкый утлар, җем-җем җемелди. Күк йөзендәге йолдызлар кышкы салкын кичләрдә шулай төрле төсләр белән яна.

Ярмөхәммәт зиректән шуып төшкәнен сизми дә калды. Барган уңайдан ул төенчеген чишеп, тартмачыгын алды. Чәчәкнең иң беренчесенә якын килде. Йөрәк колак ярысына бәрә. Каушаган йөрәк тавышы бөтен урманны яңгыратып дулый. Ярмөхәммәт чәчәккә иелде. Якыннан ул тагын да матуррак күренде. Караган саен чәчәк Ярмөхәммәтне үзенә ныграк тарта. Күзне аннан аерып булмый. Күз кабагы белән бер сирпеп алсаң, чәчәк юкка чыгар сыман.

Кышкы кичләрдә казан астына яккан учактагы утлы күмергә карап утырырга ярата Ярмөхәммәт. Күмер өемендәге иң матур ялкынлысын, алсу катнаш зәңгәрсу күмерне сайлап ала да, өнен җуеп, учак янып беткәнче шуңа карап утыра. Утыра торгач, күмер шулкадәр матур дөнья булып ачыла ки, хәтта шул матурлык эченә керәсе килә башлый. Ул

матурлык пешермәс, яндырмас, тәнне көлгә әйләндермәс кебек тоела.

Абага чәчәге нәкъ менә шуның кебек балкый. Күзен йоммыйча Ярмөхәммәт матурлыкка карый. Шулчак күрше абагадагы ут кинәт һавага күтәрелде дә юк булды.

«Димәк, абага чәчәген үз сабагында сакламый! Димәк, чәчәк кайдадыр читтә, яшерен урында саклана! Вакыт җиткәч, чәчәк үзе очып килә дә, абаганы серкәләндергәч, кире китә. Янадан яшеренә, юкка чыга. Шуңа күрә кешеләр аның чәчәген табалмый аптырый»,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Бусы да очып китә күрмәсен дип, Ярмөхәммәт асылташка үрелде. Ләкин аның бармаклары матурлыкка кагылмады. Чәчәккә кул тигезүдән курыкты ул.

Матурлыкка кул тидерү, ихтимал, кешеләргә ләззәт бирә торгандыр.

Ә кеше кулы тигәннән матурлык үзе рәхәт аламы икән соң?

Үсемлек сабагын тырнагы белән өзеп, ул чәчәкне сабак белән бергә тартмачыкка салып, янә чүпрәк белән төрде. Төенчекне күкрәгенә кысып аягүрә баскан иде, егылып китә язды.

Күк йөзе меңләгән матур йолдызлары белән абагалыкка егылып төшкәнмени? Абага чәчәкләре шулкадәр күп төрле: берсе алсу, берсе яшькелт, икенчесе зәңгәрсу. Кайбер чәчәкләрдә бөтен төсләр дә бар. Ярмөхәммәт абагалыкта озак тормады. Үз чәчәге салынган тартмачыкны күкрәгенә кысып, артыннан йөз албасты кугандай, караңгы сукмакка томырылды.

Урманны чыккач та ул байтак чапты. Куып килүче юкмы дигәндәй, туктап артына борылды. Куа килүче юк иде. Артта кап-кара урман шәүләсе сузылып ята. Ярмөхәммәт бераз туктап сулыш алгач, тагын йөгерә башлады.

Алда кара-кучкыл булып авыл ята. Бер ут әсәре юк. Өйләр күренми. Әйтерсең лә авыл юк, кара шомлы шәүлә күзгә чалына. Ара-тирә этләр өргәне ишетелгәләп куймаса, бу караңгы шәүләне әрәмә дип уйларга мөмкин. Туры басмадан үз урамнарына чыккач кына Ярмөхәммәтнең эченә бераз җан керде.

Шулвакыт этләр ешрак өрә башлады. Түбәночта, Сафиҗан абыйлар тирәсендә эт улый. Сафиҗан абыйныкыннан башка уларлык эт юк анда. Алабай шулай улый. Башка этләр аңа өрә-өрә җавап бирде. Алабай тагын озын итеп улады.

Төн уртасында эт улавы зиһенне бораулап, бәгырьне чәнчеп узды. Ярмөхәммәтнең күнел почмагында шом яралды.

Шулчак Ярмөхәммәтләр тирәсендә капка келәсе шалтыраганы ишетелде.

— Рәүфләр капкасы,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Бераздан соң тагын бер капка келәсенә бастылар: монысы Ярмөхәммәтләр капкасы. Ярмөхәммәтне эзләп, әнкәсе Рәүфләргә кергәндер дә кире чыккандыр... Бераз кайта торгач, Ярмөхәммәт үзләренең тәрәзәсендә ут күрде.

— Мине эзлиләр!— диде ул ишетелерлек итеп.

Үз турларына җиткәндә Ярмөхәммәт сәер бер җанлылык, хәрәкәт, ыгы-зыгы барлыгын сизде. Рәүфләр капкасы тагын чылтырап ачылды, капкадан Рәүфнең анасы Мәрфуга апа чыкты.

— Һи-и, алланың рәхмәте,— дип шомлы тавыш белән сөйләнә-сөйләнә урам аркылы чыгып, Ярмөхәммәтләр капкасына таба китте.

— Ни булды, Мәрфуга апа?— диде Ярмөхәммәт караңгылык эченнән.— Әллә мине югалттыгызмы?

— Әстәгыфирулла! Ярмөхәммәт, синме бу?— диде хатын.— Кайда йөрисең син? Бабаң... бабаң бит...

Ярмөхәммәтнең йөрәге табанына төшкәндәй булды. Ике өйдә дә ут яна. Ул сәер бер шомлы халәттә кара өй ишеген ачты.

— И аллам, кичтән генә йөгереп йөрде югыйсә...— дип ярым елап, ярым пышылдап сөйләнә әнисе.

— Кая йөрисең син?— диде Факиһә.— Бабай...

Өй эчендә тагын күрше карчыклары бар иде. Ак өй ишеге ябык. Мәрфуга апа ак өйгә узды. Ярмөхәммәт, нишләргә белмичә аптырап, ишек катында басып калды.

— Менә, улым Ярмөхәммәт,— диде Маһибәдәр әби.— Бабасыз да калдың инде...

Анасы елавыннан туктап, тыңкышланган борынын тарта-тарта Ярмөхәммәт янына килде дә кочаклап алды.

— Бабаң дөнья куйды бит, балакаем,— диде дә, тавыш чыгармаска тырышып, тагын елый башлады.

Ярмөхәммәт берни аңламады. Ул, тартмасын кушучлап тоткан да, күкрәгенә кыскан килеш тик тора. Әбиләр пышын-пышын гына сөйләшә;

— И гомер диген, я алла, урыны оҗмахта булсын!

Әнкәсе аны ак өйгә алып керде. Түр сәкедә Айдаш баба чалкан ята иде. Аның ике кулы күкрәгендә кушырулы. Гәүдә ак чүпрәк белән капланган. Күкрәгенә Айдаш картның үз пычагы куелган. Бу — хәнҗәр. Айдаш карт аны шулай атый иде. Хәнҗәр бабасының иң кадерле әйберсе икәнен Ярмөхәммәт яхшы белә. Ул аны урманга барса да, печәнгә чыкса да, уракка төшсә дә — беркайчан да үзеннән калдырмый иде.

— Миннән соң бу хәнҗәр сиңа калыр, улым,— дигән иде бабасы. Ул чагында Ярмөхәммәт бик бәләкәй булгандыр шул:

— Кайчан үләсең соң син, бабай?— дип сораган иде.

Бабасы аны аркасыннан сөеп:

— Син бу хәнҗәрне йөртерлек булгач,— диде.

Сәке йөзлегендә Бәдигылҗамал әби утыра. Нурлыгаян аптырап калган баласын кайнатасы янына ук алып килде. Хатын иплән кенә каплавыч почмагын ачты. Каплавыч астында Айдаш карт йоклап ята иде.

Имәнгеч бер тойгы кичерде бу вакытта Ярмөхәммәт. Бабасы баба инде, ул гел шулай йоклый. Йоклаганда, Ярмөхәммәт гел аның янына елыша иде. Бабасы борылыр иде дә, тыштан туңып кергән оныгын йонлы, җылы күкрәгенә кысып, баланың ике аягын да ике бот арасына куеп ята иде. Җылы иде, кайнар иде аның бабасы. Менә хәзер дә җәймәне күтәреп, бабасы янына керең ятар төсле иде ул. Ләкин Ярмөхәммәт бабасына елышмады. Бабасының йөзен күрүгә үк ул имәнсенеп куйды. Бабасы, нәкъ бабасы булса да, сәер иде. Элеккеге бабасы шулай чалкан ятса гырлый иде. Гырламаганда, мыш-мыш килеп сулыш алыр иде. Яки аның борыны сызгыра торган иде. Я бабасы төшендә авыз чапылдатып нидер мыгырдана иде. Ә бу бабай тик ята. Ул тере түгел, аның җаны юк. Ярмөхәммәт шуны аңлады. Үзе дә сизмәстән бабасыннан читкә тартылды. Әнисе мәетнең йөзен каплап куйды, аннан соң дәшми-тынмый гына баласын ак өйдән алып чыкты. Бәдигылҗамал әби догасын ишеттеребрәк укый башлады...

— Гел уйламаганда диген, киһәт булган икән шул,— диде Маһибәдәр әби.— Урыны җәннәттә булсын, я раббем!

— Үзе су ташыды, үзе мунча якты, урманга барып, яңа себерке бәйләп кайтты. Җен кебек эшләде. Озак итеп мунча керде. Чиста киемнәрен киде. Ямаулы алачалар биргән ием дә, юк, килен, миңа теге күлмәк-ыштанны бир дип, үзе сорап алды.

— Сизенгәндер, бәгырькәй. Үлем шаукымы белән йөргән инде ул,— диде Маһибәдәр әби.— Бик җиңел әҗәл булган инде. Савaплы кеше иде, мәрхүм.

— Мунчадан чыктык Факия белән, ул-бу юк иде... Чакырып алды. Кая Ярмөхәммәт, ди. Уеннан кермәде әле, дибез. Кайда ул, ди. Факия әйтә, Ярмөхәммәт берәр җылы мунчада малайлар белән кич утыра тор-

гандыр, ди. Факияне эзләтеп кайтарды. Юк Ярмөхәммәт. Бик көтте инде Ярмөхәммәтне, ике сүзнең берендә, кая Ярмөхәммәт, дип сорады. Килен, вакыт житте миңа, ди. Хисбулла хәбәрсез. Исән булса, бер кайтыр әле. Хисбулла минем сүзгә карамады, сине сайлады. Дөрес, килен, мин сине алдырырга разый түгел идем. Шулай да син әйбәт килен булып чыктың. Рәхмәт! Өметем өзек иде. Шөкер, Ярмөхәммәт безнең сизгерлекне алган атасыннан. Ул дөньяның серенә төшенәчәк бала. Шуның өчен рәхмәт сиңа... Кайтмадымы Ярмөхәммәт, дип сорады тагын. Факия, син дә әйбәт күңелле бала, ди. Рәнжемәгез карт атагызга. Төрле чаклар булгандыр. Заманалар шундый килде бит безгә... Шулай дигәч, мин елый башладым... Жыла, килен, жыла, диде. Сүзең булса, килен, әйт. Хәзер тел яшерүнең мәгънәсе калмады, ди... Юкны сөйләмә, эткәй, сиңа үләргә иртәрәк әле, дидем... Мәнә шулай сөйләш син минем белән, ди... Тавышың матур бит синең, килен. Ишегалдында малларга дәшкәндә мин синең тавышыңны рәхәтләнеп тыңлый идем... Шулай дигәч, тыела алмыйча, жылап жибәрдем... Факия жылый, мин жылыйм. Эткәй әйтә: алай тавышлы жыламагыз, ди. Мәет янында күз яше күрсәтү килешмәс. Тавышлану, кычкырып жылау ярый торган эш түгел. Тып-тын гына минем яхшы эшләрем турында уйлап утырырсыз мәетем янында... Эткәй, үзең рәнжемә инде миңа, дидем дә тагын сыгылып төштем. Шулчак эткәй нидер әйтергә теләгән иде, ахрысы, иягән-сакалын күтәреп жиңел сулап куйгандай итте дә башы кыйгаеп төште... Кулымда жан бирде...

Ярмөхәммәт күзләрен зур ачып, бүлмә сәкесе өстендә утыра.

Мәет сакларга тагын бер-ике карчык керде. Карчыклар алмашлап ак өйдә Айдаш баба мәете янында утырып торалар да монда чыгалар. Факиһә самавыр куеп жибәрде.

Бәдигыльжамал әби бу якка чыгып, көйле китап укый башлады. Ишетелер-ишетелмәс моң да Ярмөхәммәтнең кинәт катып калган күңелен йомшартмады. Бер почмакта әнкәсе кемнәр беләндер кәфенлек, тастар башы, гүр сәдакасы турында пышылдаша.

— Абага чәчәге алып кайттым мин,— диде Ярмөхәммәт үзалдына.

Бәдигыльжамал әбинең гел бертөрле тавышы малайны изрәтте. Ул, чәчәк салынган тартмачыгын учлаган килеш, сәкегә ятып йокыга китте.

Айдаш картның мәетен гүргә индергәндә Ярмөхәммәт кабер якасыннан читтә басып торды. Кабер инде күптән әзер иде. Комсыз зират зур итеп авызын ачкан да, кайчан соң миңа ризыгымны каптырасыз, дигән сыман тын гына, шом белән мәет көтеп тора. Кабер авызы белән янәшә Айдаш бабаның гәүдәсе ята. Мулла абзыйның озак итеп мәет өстендә ясин чыгуы да, бабайны жирләргә килгән карт-корының ара-тирә ютәлләштергәләп утыруы да Ярмөхәммәт колагына кермәде.

Ярмөхәммәт әллә нинди сәер бер хәлдә тораташ булып каткан да күрше кабер өстендә котырып үскән сирень чәчәкләренә караган.

«Гажәп икән,— дип уйлады Ярмөхәммәт.— Сирин әллә кайчан чәчәк атып койды бит инде. Бу тиле куак нигә соңга калган?»

Сирень тәлгәшләре шулкадәр тыгыз, куе, әйтерсең лә Халит бабай кабере өстенә чәчәкләр кибәне өеп куйганнар.

Жил булмаса да, зират агачлары шаулап ала, югарыдан исеп киткән жилнең итәге агачларның иң очындагы берничә яфракны берберенә бәргәләштереп китә дә, яфраклар тагын ихтыярсыз шәлперәеп, асылынып кала.

Ярмөхәммәт еламый. Мәет өстендә еларга ярамый. Мәет өстендә хәтта кычкырып сөйләшергә дә кушмыйлар.

Айдаш картны юарга иртүк картлар килде. Ярмөхәммәт аларга сабын-сөлге, чиләк-су, комган ташып, ярдәм итеп торды. Мәетне өйдән алып чыктылар. Ун кеше күтәреп зиратка алып китте.

Ярмөхәммәтнең анасы, апасы Факиһә, күрше хатыннары капка

төбендә басып калды. Барысы да яулык очлары белән битләрен каплап елый иде. Ярмөхәммәт иң алдан йөгерергә дип башка чыккан иде, мулла абзый аны җиңелчә генә шелтәләгәндәй:

— Җеназа алдыннан барырга ярамый!— дип артка куды.

Шуннан соң ул җеназачылар сафының иң артына чыкты. Ул әледән-әле артка борылып карый. Күрше карчыклар, анасы, апасы һаман керәп китмәгәннәр. Зират борылмасына җиткәч, Ярмөхәммәт тагын артына борылды. Әбиләр, апалар таралып бара, капка төбендә анасы белән апасы һаман тора. Ярмөхәммәт белә: алар һаман елый...

Җеназа тыкрыкка керде. Тыкрык башында Галимхан белән Рәүф килеп кушылды.

Мәетне гүргә иңдерер вакыт җитте. Шул чак җил исеп куйды. Халит карт кабере өстендә үскән сирень тәлгәшләре атынып алды. Сирень исеннән Ярмөхәммәтнең тыны капланды. Куе, тынчу, авыр иде ул ис.

— Кил, улым Ярмөхәммәт!— диде мулла абзый.— Бабаң белән бәхилләш... Якынрак җибәрегез баланы.

Җеназачылар боек кына бер читтә торучы Ярмөхәммәтне мәет янына уздырдылар. Ярмөхәммәт бабасының таплана башлаган йөзенә карады. Кулы белән аның битен сыпырырга кушкан иде анасы. Ярмөхәммәтнең кулы тияр-тимәс булып бабасы йөзенә кагылды. Кагылды да Ярмөхәммәт имәнеп итте. Төн эчендә мәетнең яңак сакалы үсеп чыккан иде. Әлек Ярмөхәммәт шушы төртмә сакалга уч төбен ышкып шаяра иде.

Айдаш картны ләхеткә куеп, имән такталар белән каплаганнарын игътибар белән карап торды Ярмөхәммәт. Ләхетне бик яхшылап, ышанычлы итеп кадаклаганнан соң, агайлар берәм-берәм кабердән сикереп чыктылар. Картны җирләргә килгән авылның ир-заты, әле кичәлә-бүгенлә генә сугыштан кайткан абзыйлар, бер ымтынуда каберне күмеп тә куйдылар.

«Нигә шулай ашыгалар икән алар?»— дип уйлады Ярмөхәммәт. Әйтерсең лә Айдаш карт кабердән чыгарга гаугалаша. Бәлки шулай кирәктер? Үлгән кешене тизрәк җир куенына тапшырырга хәерләрәктер.

Еллар узгач, Ярмөхәммәт үз гомерендә бик күпләрне җирләгәнне күрер. Күргән саен ул нәкъ бүгенгедәй тагын уйлар: «Нигә шулай ашыга икән кешеләр?»— дияр.

Кулларына көрәк тоткан таза-таза ир-егетләр бер-берсе белән ярыша-ярыша кабергә туфрак иשә. Әйтерсең лә алар бу ярышта зур күрсәткечләргә ирешеп, беренче яки икенче урынны алырга җыена. Бу, бәлки, мәрхүмнең якыннары алдында яхшатланудыр?

Айдаш картның якын туганнары юк. Исәннәрдән аның иң кадерле кешесе — оныгы Ярмөхәммәт кенә. Ә сабый алдында кемгә кирәк яхшатлану? Җеназачылар эшне тиз тотты. Кабер балчыгын матурлап өеп, баш очына яңа гына кисеп алынган тупыл агачы утырттылар.


Көрәкләрен иңбашына салып, агайлар тарала да башлады. Бишәр, унбишәр тиен гүр сәдакасы эләктергән малай-шалай да зираттан чыкты. Мулла абзый гына бер ялгызы кабернең баш очына чүмәшеп калды. Ул сөаль фәрештәләренә ничек җавап бирергә икәнлеген Айдаш бабага әйтеп торыр өчен шулай утыра.

Зират капкасы янында Ярмөхәммәтне Галимхан белән Рәүф көтеп тора иде.

— Барыгыз, сез кайта торыгыз!— диде Ярмөхәммәт.— Мин мулла абзыйны көтәм әле.

— Нигә кирәк сиңа мулла абзый?— дип төпченеп тормадылар малайлар, учларындагы җып-җылы бакыр акчаларын кысып, авылга таба йөгерделәр.

Ялганлады Ярмөхәммәт. Мулла абзыйны көтми лә ул.



А. Тимергалина рәсеме.

Ярмөхәммәт тиз генә зират капкасыннан әчкә узды. Мулла абзый ашыкмыйча гына кайтып килә иде. Ярмөхәммәт якындагы чардуган артына посты. Мулла абзый чардуганны узып китте, зират капкасын яхшылап бикләде дә авылга таба атлады.

Поскан урыныннан чыгып, Ярмөхәммәт туп-туры бабасы кабере янына килде. Җеназачылар кабердән кырык адым киту белән сөаль фәрештәләре гүргә кереп, гүр иясеннән сорау алачак. Ярмөхәммәт шул сорау алганны ишетергә дип качып калды. Ул тынын кысып, колагын кабер туфрагына куйды.

Агачлар өстеннән җил исеп узды. Зират печәне арасындагы чикерткәләр җыры, җилдә лепердәшкән яфраклар тавышы гына калды зиратта. Тагын җил исеп куйды. Бүрек хәтле генә җил адашып, аска килеп төште дә, Халит бабай сиреневнән бер көлтә ис алып килеп, Ярмөхәммәтнең битенә сирпеде. Ярмөхәммәт бер мәлгә тын ала алмый торды. Куе, тыгыз сирень исе, бияләй-бияләй кисәкләр булып тамакка, үпкәләргә кереп тулды.

Шушы ис, сирень исе Ярмөхәммәткә гомер буе бабасын җирләгәнне искә төшереп торыр. Гомер буе Ярмөхәммәт сирень исле хушбуйларны сөймәс булыр. Гомере буе Ярмөхәммәт аңында сирень исе белән үлем төшенчәсе янәшә йөрер.

Җил узып киткәч, ул иркен сулыш алды да янә тынын кысты. Игътибарын җир астына төбәде. Зират агачлары арасында көндез дә куркыныч, шомлы. Әллә шулай киеренке тыңлаганга, әллә колак чыңлавы шулаймы: Ярмөхәммәткә кабер эченнән тавыш ишетелгәндәй булды.

Агачлар шаулавы көчәйде. Чикерткәләр тынып калды. Сирень кибәнендә чәчәк тәлгәшләре салмак кына атына башлады. Ярмөхәммәтнең күңеленә шом инде. Ул тар сукмак буйлап капкага таба элдерде. Әйтерсең лә аның артыннан Нәнкир белән Мөнкир куа. Койма аша ничек сикереп чыкканын да сизмәде ул. Зират артта калгач, тыкрык уртасына житкәч кенә, Ярмөхәммәт туктап артына борылды.

— Юкка курыктым,— диде Ярмөхәммәт.— Чурт та юк анда. Колакка гына ишетелгәндер ул...

Ярмөхәммәт тибешрәк атлый башлады.

Тыкрык башына житкәндә эперти-эрекмәннәр арасыннан ике гәүдә калыкты: бу Рәүф белән Галимхан иде. Авыр чакта дусларының янәшәдә булуына эчтән генә сөенде Ярмөхәммәт. Бер сүз әйтми-нитми, ул дусларын узып китте. Рәүф һәм Галимхан аның артыннан иярде. Рәүф бер яктан, Галимхан икенче ягыннан килеп, аның белән тигезләште. Беркем бер сүз әйтмәде. Ни дисең инде мондый чакта? Аларның шулай сүзсез атлавы Ярмөхәммәткә ошый. Юата башласалар, түзмәс иде, елап җибәрер иде. Олы кайгы төшкән Ярмөхәммәтне ике яктан тотып торучы ике багана кебек иде Рәүф белән Галимхан.

Тыкрык буйлап малайлар түгел, гүя хәсрәт баскан, дөньяның төчесенә караганда әчесен күбрәк татыган өч ир атлый иде.

Капка төбенә кайтып житкәч, Ярмөхәммәт кереп китте, ике дусты утыргычта калды.

— Ярмөхәммәт, озак торма, чык! Без сине көтәбез, бергә көлтә бәйләшергә барырбыз,— дип әйтергә теләгәннәрен ул яхшы аңлады.

Ләкин аның үз мәшәкатьләре бар иде шул. Ул туп-туры мунча ягына атлады. Мунчага житәрәк өч тапкыр тамак кырды. Мунча эченнән җавап ишетелмәде. Яшергән җиреннән тартмачыкны алды. Абага чәчәген ул ике дустына күрсәтергә җыенган иде. Иплап кенә тартмачыкны ачты. Тартма эчендә үлән сабагы гына күренде. Ярмөхәммәт сабакны әйләндерде. Сабакның аскы ягында нииндидер ямьсез бер корт бөгәрләнеп ята иде. Ул аны караңгы мунчага алып керде, әлеге кортның койрык өлеше матур ут булып җемелди башлады. Ярмөхәммәт шунда гына аңлады: «абага чәчәге»— яктырткыч коңгыз икән ләбаса.

Уткойрык исемле бөҗәк белән ул әнә шулай танышты.

Кинәт анын күнеле тулды. Ул тыела алмыйча елап җибәрде. Озак чыкмый торгач, Рәүф белән Галимхан ишегалдына узды. Алар ачык ишектән мунчага кермәкче булганнар иде, мунча эченнән Ярмөхәммәтнен үксегән тавышын ишетеп, нишләргә белмичә аптырап тордылар да иплэп кенә кире борылдылар.

Еласын әйдә, ялгызы гына иркенләп еласын!

## Сабак

Көз житте. Мәктәпкә йөрисе балалар шатланышып китап-дәфтәр, букча-каләмнәрен хәстәрләп куйдылар. Факиһә дә әзер. Ярмөхәммәт тә букчасына бар мөлкәтен: ике дәфтәр, бер каләмен салды. Нурлыгаян балаларының алдан ук мәктәпкә җыенуларын күз кырые белән генә күзәтеп йөрде. Үзе тыз да быз эш белән мәшгуль: казларга, тавыкларга жим сибеп, казан астына ягып җибәрде, күп итеп чыра телеп, кучкарга матурлап өйде. Аннан соң ике баласын сәкегә утыртты. Балалар сагаеп: «Әнкәй нәрсәдер әйтергә җыена, ахрысы»,— дигәндәй, сабыр гына көтеп утыра бирделәр.

— Улым,— диде ана.— Укырга алгысып торуың бик әйбәт тә бит... Икегез дә укысагыз, ничек көн күрербез икән? Ярмөхәммәт, син бит бөтен таянычым, син йортның бердәнбер ир-аты. Ат белән эшләвең дә бик әйбәт иде дә... Барый белән Мөҗип...

Нурлыгаян укуларын ташлап, чынлыгы белән колхоз эшенә йөрүче малайларны санап китте.

— Ярар, әнкәй,— диде Ярмөхәммәт.— Синеңчә булсын алайса...

Ярмөхәммәт әле генә кадерләп хәстәрләгән букчасыннан дәфтәрләрен, каләмен, кара савытын алып, апасына әйтте:

— Мә, сиңа булыр, апа!— диде.

Ярмөхәммәтнең кыяфәте бабасын җирләгән көндәге кебек боек, сагышлы иде. Мәктәпкә йөрү хыялы җимерелүдән ул бөкшәеп төшкән сыман булды. Улының сагышын күреп, Нурлыгаянның бәгыре өзелә язды. Ятимлек сөреме сарган улын кочаклап елар иде ул.

— Минем дә сине укытасым бик килә, улым...

Ананың тавышы калтыранып китте, елап җибәрмәс өчен ул туктап калды. Күз яшьләре белән тамагындагы әче төерне йотып, янә әйтте:

— Ярар, булмаса... ачка үлмәбез...

Бригадир Хәсәнша абзый атны Нәдершага тапшырырга кушты. Икенче көнне иртүк әнисе кәҗә саварга торганда Ярмөхәммәт тә уянды.

«Сикереп торып юынганчы ук бахбайны, Рикәкәне алып кайтырга кирәк»,— дип уйлады малай. Шулчак капка келәсе шалтырады. Ат пошкырганы ишетелде. Ишегалдында Нәдерша тавышы яңгырады.

— Исәнме, Нурлыгаян түти...

— Әйбәт кенә әле, Нәдерша,— диде әнисе.

Ярмөхәммәт атылып ишегалдына чыкты. Шунда гына ул Рикәкәне үзеннән алып, Нәдершага биргәннәрен исенә төшерде. Бүгеннән ул «ат җигүче җегет» түгел, сабакка йөрүче малай.

Яшь хуҗасы Ярмөхәммәтне күргәч, ат ишетелер-ишетелмәс кенә кешнәп куйды. Кешнәү түгел, ыңгырашу иде бу. Бу кешнәүне Ярмөхәммәт үзенчә аңлады.

— Нигә син мине чит кешегә бирдең? Нигә үзең җикмисең?— дигән мәгънә бар иде бу ыңгырашуда.

— Таныйсыңмы хуҗаңны?— диде Нәдер.— Танысаң, танымасаң да хәзер ул сиңа хуҗа түгел инде. Синең хуҗаң хәзер мин, бахбай,— дип сөйләнә-сөйләнә, Нәдер ат җигә башлады.

Нурлыгаян көндәгечә Рикәкәгә аз-маз, калдык-постык көрпә болгатылган җылы су эчерде. Нурлыгаянның өйдән ләгән күтәреп чыкканын күргәч, ат тагын кешнәгәндәй итте.

— Кая, йөгәнен чыгар!— диде Нәдер.

— Йөгәнен бирмим, Нәдерша абый,— диде Ярмөхәммәт.— Ул бабай төсе.

Ярмөхәммәт дирбияләрне ишегалдына алып чыкты. Ләкин жиз тәңкәләр белән бизәлгән каеш йөгән ызбруй арасында юк иде.

— Бирмим дисең инде алайса...

— Бирмим, Нәдерша абый... Ул йөгән тәңкәләренә йөз ел. Айдаш бабаның атасы Гозәер баба йөгәне ул...

— Ярар бирмәсәң,— диде Нәдер.— Кадалып кит шул иске-москың белән...

Ул шундук чалбар каешын салып, йөгән урынына борынчык ясап, атка кигезде, як-ягына сүс дилбегә бәйләде.

— Аптырамабыз, анысы... Менә дигән йөгән бу, агайне...

Нәдер арбага сикереп менде.

— Ач капкаңны! Киттек! — дип кычкырды атның яңа хуҗасы.

Бахбай күзен мөлдерәтеп Ярмөхәммәткә карады. «Нигә син җикмисен бүген? Нигә чит кеше мине куалый?»— дигәндәй иде бу караш.

Ярмөхәммәт атның ялын сыпыргалады, муенын шапылдатып сөйде. «Кичер мине, малкай! Шулай туры килде инде!»— дип әйтү иде бу сыпырулар.

— Әйдә, сугышка китми атың! Җегет белән кыздай авыр саубуллашасыз!— диде яңа хуҗа.

Нәдер тавышын ишетеп, Рикәкә ике колагын артка борып, «дерт» итеп тиресен калтыратты. Нәдернең тупас тавышыннан атның тәне чымырдап куйды бугай.

— Ашыкма, Нәдер абый,— дип Ярмөхәммәт аркалыкны тартып, камыт белән ат муены арасына куш бармак тыкты.— Артык күтәргәнсен...— Ярмөхәммәт аркалыкны бераз бушатты.— Карап кына йөр инде, Нәдерша абый...

— Өйрәтмәсәнә!— дип кычкырды Нәдерша.— Ат күрмәгәнме? Бабаң гомере буе акыл сатты, хәзер сиңа калган өйрәтергә!

Моңа каршы Ярмөхәммәт җавап кайтармады, дәшмичә генә капканы ачты.

— На-а, әйдә, бахбай!

Арба сыкранып кына кузгалды. Урамга чыккач, Нәдер аягүрә басып, дилбегәне баш очында болгап, әче итеп тагын бер сызгырды, шалт итеп дилбегә очы белән атка сукты.

— На-на, әйдә...

Бичара ат адымнарын тизләтте, юырткандай тиз-тиз атлап китте. Арба төбенә җәелгән такталарның дыңгырдавы, чәкүшкә калайларының чылтыравы, Нәдернең ара-тирә сүгенүе Ярмөхәммәт күңелендә гомерлеккә уелып калыр.

Олы капканы япканда да, юынганда да һич нәрсә күрмәде ул, күңегелгәнгә генә, һәр көн эшли торган эшләрне башкарды. Маңгай күзләре белән ул алдындагы нәрсәләрне күрсә дә, күңел күзе белән әллә кайларга карый, аның күңеле ераклаша баручы бичара ат янында иде.

Мәхлук хайван да күңеле белән сизә иде, ахрысы: Айдаш карттан ул гомерлеккә аерылды. Үзен сөеп, иркәләп эшләткән яшь хуҗасы Ярмөхәммәттән дә мәңгегә киткәнлеген тоя. Ул мәгънәсез, тупас бер бәндә кулына эләккәнен дә белә иде кебек.

Ат карашыннан, моңсу гына керфек шапылдатуыннан, ыңгырашкандай шыпырт кына кешнәвеннән Ярмөхәммәтнең бәгырендә ниндидер бер ачыну, зәһәр катнаш бер әче хис яралды. Таланган бәгыренә чыдаша алмыйча, Ярмөхәммәт салкын мунчага кереп, тын гына елады. Ул үзе өчен генә еламый иде. Ярмөхәммәт атасы Хисбулла өчен дә, бабасы Айдулла өчен дә, борынгы бабалары Гозәер, Акбарыш, Шәмәй өчен дә елый. Аларның төсе булган, бердәнбер җан иясе Рикәкә өчен дә елый.

Әче сагыштан бераз бушангач, Ярмөхәммәт кап-кайнар башын салкын суга тыкты. Кат-кат юынып, корытып сөртенсә дә, аның кызарган күзләрен, шешенгән күз төпләрен анасы күрде, сизде улының күңелендә ниләр барын.

— Балалар,— диде ана чәйләп алганнан соң.— Үзегезне үзегез карарсыз инде. Мин киндерчеләрдән калам. Сез сабакка соңламагыз. Укыгач-укыгач юньләп укырга кирәк!

Сәкегә юган, чиста күлмәкләр куеп, Нурлыгаян эшкә китте.

Балигъ булмастан мөстәкыйльлеккә бик иртә кергән ике сабый тиз-тиз генә йорт эшләрен караштырдылар. Ярмөхәммәт казларны буага куды. Тавыкларга җим сипте. Факиһә табак-савыт юды, тиз генә бәрәңге әрчеп, салкын суга салып куйды: әнисе эшкә кайткач, җәһәт кенә пешереп ашар.

Чиста күлмәкләр киеп, алар мәктәпкә китте.

— Бабай да, әнкәй дә «мәктәпкә» дими, «сабакка» ди... Нигә олылар укырга йөрүне «сабакка йөрү» ди икән, ә?

Апасы Факиһәнең көтелмәгәндә шулай соравы Ярмөхәммәтне уйларыннан аерды.

«Чыннан да, ни өчен сабакка»,— дип уйлады Ярмөхәммәт, аннан соң үзалдына сөйләнгәндәй, фикерли башлады:

— Сабак алырга — үрнәк алырга... Яхшы укучыдан өйрәнергә... Китап укып сабак алырга, гыйбрәт алырга... Сабаксыз үсемлек булмый. Сабаксыз кеше — буынсыз кеше...

— Алайса без гыйбрәткә барабыз,— дип көлде Факиһә.

Ярмөхәммәт аның көлүенә игътибар итмәде. Ул әле һаман сөйләнеп уйлый иде.

— ...сабак үсемлекнең терәге, умырткасы. Белемсез кеше дә умырткасыз була бит. Сабакны элек кызлар абыстайдан, малайлар хәлфәдән алган. Ә безгә сабакны укытучылар бирә.

— Бабай әйттеме?— диде Факиһә.

— Юк,— диде Ярмөхәммәт.— Үзем шулай уйлыйм.

Бер-бер ярамаган эш эшләсәң, бабай: «Матри, бала, кабат сабак булсын»,— ди торган иде.

— Синең башыңда әллә ниләр бар, Ярмый, син укытучы булып китәрсең, билләһи...

Балалар зират тыкрыгына борылды. Алардан алда да, артта да төркем-төркем, берән-сәрән балалар сабакка бара. Аръяклар мәчет-клуб тыкрыгыннан туры мәктәпкә килә. Түбәночлар зират юлыннан атлый. Югарочлар ындыр артлатып төшә. Шаяралар, көләләр, төрткәләшеп алалар, куышып та китәләр. Рәсүлнең тавышы әллә каян яңгырый. Армия белән җитәкчелек итәмени, үз очларын бер сафка тезгән. «Рас, два!»— белән балаларны мәктәпкә алып төшә.

Бакча башына җиткәч, Факиһә белән Ярмөхәммәткә Рәүф, Галимхан, Исламнур, алар артыннан бертуганнар Әхнәф белән Кәримулла килеп кушылды. «Безнең очтан Барый белән Мөҗип юк»,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Ул белә: алар икесе дә мәктәпкә йөрмәячәк. Икесе дә баш бала, калганнары бәләкәй. Икесенең дә аталары сугышта үлгән. Аларны аналары сабакка җибәрми. Хәер, алар үзләре дә бик атлыгып тормый бугай. Аларга эш булсын. Мәктәпкә йөрү бәхетеннән мәхрүм бер алар гына түгел авылда, байтак. Алар инде колхоз эшенә йөри.

Ислам ниндидер яңалык сөйли. Әхнәф букчасын күтәреп болгый. Факиһә арткарак калып, кызларга кушылды. Ярмөхәммәт аларга игътибар бирми.

Бәрәңге бакчалары артына җиткәч, мәктәп юлы зират капкасыннан сулга борыла.

Ярмөхәммәт бабасын җирләгән көнне исенә төшерде. Зират ягыннан сирень исе ургылып килә сыман тоелды аңа. Әйтерсең лә һавага

дыңгычлап сирень тутырганнар. Сирень инде әллә кайчан чәчәк койды. Ә исе зиратка сеңеп калган. Әллә инде үлем шәһәре — зиратны күргәч, сирень исе килгәндәй булды. Әллә сирень исе килгәнгәме, ул бабасының үлеп яткан кыяфәтен күрде.

Ярмөхәммәт мәктәп юлына борылды. Сирень исе бетте.

Бакча киртәсе буена үскән карт алабута, карт кычытканлык арасыннан мәктәпкә бара торган сукмак уза. Сукмакның уң ягында такыр басу. Басу кырында зәңгәр чәчәк — һиндыбалар атынып утыра. Ярмөхәммәтнең карашы һиндыбада төртелеп туктады. Башка балалар чәчәкләргә игътибар ташламый. Ярмөхәммәт күзенә дә чәчәкләр чалынып-чалынмас кына күренгәлиләр иде, аның күзе, күңел күзе кинәт ачылып китте дә, Ярмөхәммәт алдында гаҗәеп матур дөнья пәйда булды. Чәчәкләр ап-ачык төскә керде. Алар күзгә күренеп балкый, яна башлады. Ничек инде Ярмөхәммәт моңарчы бу гүзәл һиндыбаларны күрмәгән? Ничек күрмәскә мөмкин соң бу матурлыкны? Югыйсә, әнә бит, бар нәрсәләрдән дә ачык-матур булып чәчәкләр генә нур сибә. Калган үсемлекләр дә, барлык матдәләр дә артта, томанда, игътибардан еракта. Дөньяда чәчәк кенә үсә кебек.

Ярмөхәммәт дөньяны күрми дә, ишетми дә. Ул бер чәчәкне, иң ачык төслесен сайлап, шуңа текәлде. Янә могҗиза башланды. Җиһандагы барлык чәчәкләр дә игътибардан читтә калды. Бары тик бер генә чәчәк, Ярмөхәммәт сайлаган чәчәк кенә балкый. Ярмөхәммәт күз карашы белән чәчәк сутын эчә. Һиндыба чәчәге исә Ярмөхәммәтне үзенә суыра. Бу тартылыш шулкадәр куәтле иде ки, чәчәк Ярмөхәммәткә, Ярмөхәммәт чәчәк эченә керә башлады. Тыштагы вакыт туктап калды.

Ярмөхәммәт чәчәк дөньясында пәйда булды.

Зәңгәрсу матурлык эченә килеп эләгүгә үк, ул Алиһәне эзләргә керешә. Ярмөхәммәтнең күзләре тышта калган иде. Ул Алиһәне тиз генә таба алмады. Шул мәлне үк челтерәп көлгән тавыш ишетелде. Бу Алиһә тавышы иде. Күзе зәңгәрлеккә күнеккәч, Ярмөхәммәт Алиһәне күрде.

— Һи-һи, мин монда ич! Синең каршыңда гына!

— Исән-саумы, Алиһә!

— Син мине каян беләсең?— диде Алиһә.

— Бәрәкәт!— диде Ярмөхәммәт.— Мин сине әллә кайчаннан бирле беләм бит.

Шунда гына ул төшенде: һәр һиндыбаның үз алиһәсе аерым, бөтен алиһәләр дә су тамчыларыдай бер-беренә охшаш була икән.

— Баштагы Алиһә мине көткәндер-көткәндер дә, картаеп үлгәндер,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

Чыннан да, ике алиһә шулкадәр охшаш иде, Ярмөхәммәт аларны аерырлык тамга да тапмады.

— Ник аптырадың, җегет?— диде Алиһә.— Уз әйдә, уз! Кунак булырсың!

«Кунак булырсың»— диде, алайса, мин монда вакытлыча гына, дип уйлады Ярмөхәммәт, кызык, бөтенләйгә калырга буламы икән чәчәк эчендә? Калырга мөмкин булса, азагы ни белән бетәр иде икән?

— Сыйлан син, җегетем, сыйлан!— дип, Алиһә каушап калган Ярмөхәммәтне кыстый башлады.

«Җегетем»— диде, тугыз яшьлек җегет буламы икәнни? Шулай да Алиһәнең «җегетем» дип әйтүе аңа бик тә ошады. Ул, чыннан да, үзен егет итеп тоя башлады.

Шул чак Алиһә Ярмөхәммәтнең баштагы уйларына җавап кайтарды:

— Чәчәк эчендә син, җегетем, рәхәтләнеп яши аласың... Тик гомергә монда кала алмыйсың... Ярамый... Син эш кешесе... Сиңа монда авыр эш юк... Ләззәтләр, рәхәтләнүләр озакка сузылса, кеше үзгәрә... Начар якка үзгәрә... Ә мин җегетемнең начар якка үзгәрүен теләмим... Син начар якка үзгәрсәң, мондагы каршылык-куәт сине һәлак итәчәк... Шулай да фани дөньядан аерылып, син минем янга еш килә аласың...

Ярмөхәммәт тыштагы дөньясын онытты. Алар, күптәнге танышлар кебек, бер-берсенә сөеп карый, әйтерсең лә бер-берсен күрмичә еллар буе аерылышып торганнар. Ике арада тарсыну юк. Әйтерсең лә алар гомерләре буе сөешкәннәр. Алиһәнең эче тулы шатлык, йөзе тулы сөенеч чаткысы. Еллар буе сагыш эчендә яшәгән кешегә кинәттән генә олы куаныч килсә, нишләргә белмичә каушап кала. Алиһә дә нәкъ шундый халәттә иде, күрәсең: ул я очынып нидер сөйли, я табын хәстәрләргә керешә, табынга яңадан-яңа ашамлыклар китерә, Ярмөхәммәткә ярарга тырыша.

Таулар, урманнарны карап йөргәннән соң, зәңгәр күлләрдә рәхәтләнеп су коенгач, ханәкәгә кайтып егылдылар. Алар икесе дә бәхетле рәвештә арганнар иде. Һәрберсенең хәлсез елмаюында канәгатьләнү нурланышы...

Табында ниләр генә юк иде: зәңгәр йөзем, күк төсендәге алмалар, куе зәңгәр ширбәтләр... Бик озак шулай күңел ачып ятканда Ярмөхәммәтнең күңеленә борчу инде. Ханәкә идәнендәге келәмдә ул үзенең букчасын күрде.

— Нәрсә соң әле бу?— дип кашын җыерды.— Ә-ә, дәфтәр-каләм бит ул букчада...

Сабакка йөрер өчен ул иң яраткан атын Нәдершага бирде. Сабакка бармыйча калса, ни йөзе белән ул өйгә кайтыр да анасы алдында ни әйтер?

— Дөньяңны онытып, кайда йөрдең, оятсыз!— дип сугәр әнисе.

Ә Ярмөхәммәт ни җавап бирер? Һиндыба чәчәгендәге Алиһә белән рәхәт кичердем диярме? Аңа кем ышансын? Бу бит төш кебек...

Ярмөхәммәтнең тынычсызлануын Алиһә шундук сизде:

— Син ашыгасың, Ярмөхәммәт,— диде Алиһә.— Чыннан да, мин сине артык тоткарладым бугай. Кичер мине, җегетем!

— Дөрес,— диде Ярмөхәммәт,— мин ашыгам... Мин дөньямны оныттым. Синең белән рәхәт... рәхәттән дә рәхәтрәк... Тик чәчәк эчендә генә яшәп булмый бит инде...

Алиһә сагышлы елмайды.

— Кил, җегетем,— диде Алиһә кинәт үзгәреп,— кил! Үз дөньягызга кайту өчен, син күзләремә бак!

Алиһә җиңелчә генә итеп Ярмөхәммәтне үзенә тартты. Ярмөхәммәтнең карашы Алиһә күзләре белән очрашты. Алиһәнең күз алмасы үзенә бер дөнья булып, киңәя-ачыла-тирәнәя башлады. Ярмөхәммәт үзенең йотыла барганын сизде. Әкренләп ул күз алмасына кереп-сыеп бетте. Ярмөхәммәт авырлыгын тоймый. Ул эреп юкка чыкты. Бер мизгелдә ул авырту катыш илаһи рәхәтлек татыды...

— Ни күрдең анда?— диде кемдер.— Соңга калабыз!

Бу Фәүзел иде. Ярмөхәммәт, чәчәктән аерылып, Фәүзел артыннан мәктәпкә элдерде.

## Валия

Уку башланганга бер атна узды. Беренче ял көне дә килеп җитте. «Ял көне» дип атала гына инде ул. «Сабакка бармый торган эш көне» дисәләр, дөресрәк булыр иде. Ата-ана, әби-баба бу көнне атлыгып көтеп ала: утынга барасы, камыл алып кайтасы, мал-туар карыйсы, бәрәңге аласы — мең төрле авыр эш сагалый бичара сабыйларны, уйнарга да вакытлары юк.

Ярмөхәммәт әнисенә охшаган, бер дә тик тормый, бөтерелә дә бөтерелә. Әйтерсең лә ул авыр хезмәт өчен махсус яратылган бәндә. Шулай кирәк. Сугыш барганда башкача яшәп булмый, күрәсең. Сабыйларның сабыйлыгын алды сугыш, сабыйларның уеннарын тартып алды сугыш. Сабыйларга бары сагыш бирде.

Ярмөхәммәт әнисе кушканнарны да, кушмаганнарны да җиренә җиткезеп, тәфсилләп эшли. Эш белән ул нииндидер кайгысын онытырга, нииндидер исәбен басарга тырыша сыман. Аның шулай армый-талмый эшләгәнен әнисе сиздермичә генә күзәтә. Бер карый да улына соклана: бигрәк тырыш бала, дөнья көтәр, алла боерса, ди. Икенче карый да, бәгыре өзгәләнә ананың: ятимлектә үсә бала, атасы да, бабасы да юк...

Кызы Факиһә өчен кайгырмый Нурлыгаян:

— Кыз бала, үсәр дә кияүгә чыгар. Аңа укымаса да була. Ярмөхәммәткә бераз укымыйча булмас. Һич югында җиденчене бетерсен инде, ходай кушса,— дип уйлый.

Ярмөхәммәтнең бу арада уйчан йөрүе атасын сагынудан гына түгел, бабасын юксынудан гына да түгел иде шул. Аның башка сәбәбе бар.

Чәчәк эчендәге Алиһәнең кемгә охшаганлыгы турында Ярмөхәммәт менә инде ничәмә көннәр баш вата.

Көннәрдән бер көнне ул ачыш ясады.

Чәчәк Алиһәсе урысча укытучы белорус кызы Валия Галайга охшаган бит! Юк, алай түгел! Валия апа Алиһәгә охшаган! Юк, алай да түгел! Алиһә белән Валия икесе бер кыз дип уйлады Ярмөхәммәт.

— Кызык икән!— диде Фәүзел.— Фамилиясе Галай!

Бөтен бала кытыкланып Валентина Галайны көтә. Барысының да урысча өйрәнәсе килә. Бу мөлаем белорус кызын бөтен авыл яратып, үз итеп өлгергән иде инде. Аның ягымлы елмаеп сөйләшүе, бигрәк тә татарча сөйләшүе авыл кешесен әсир итте. Күчеп килгән елны ук ул татарча сөйләшергә өйрәнде. Авылда аны якын итмәгән бер генә кеше дә юктыр. Хәтта шартамак Сабир да, акырып сүгенүче фронтовиклар да аның белән юаш сөйләшә. Шуңа күрә дә һәр малай, бөтен кызлар Валия классына эләгүләрен зур бәхет саный. Шуңа күрә дә бөтен класс дулкынланып, куанып аны көтә.

— Килә!— диде ишек ярыгыннан карап, сакта торучы Исламнур.

Балалар шыбырдашып үз урыннарына барып басты.

Ишектә Валентина Галай күренде.

— Исән-саулармысез, балалар!— диде ул саф татарча.

Класс аптырашта калды. Валия апаның бик тиз татарча сөйләшә башлаганын һәркем белә, ләкин рус теле сәгатендә класска кергәндә аның урысча исәнләшүен көтәләр иде. Аның урысча исәнләшүенә җавап кайтарырга дип: «Драстуйте!»— сүзен кабатлап, өйрәнеп куйганнар иде.

— Әллә телегез беттеме? Нигә исәнләшмисез?— дип елмайды укытучы. Валиянең бит очларында матур чокырчыклар барлыкка килде.

Шул чак балаларның бер өлеше:

— Исәнмесез!— дип, икенче өлеше:

— Драстуйте!— дип кычкырды.

Ярмөхәммәт исә:

— Алиһә-ә!— диде.— Зәңгәр чәчәктәге Алиһә!

Алиһә журналны ачты. Ручкасын журнал уртасындагы ялгашка куйды да сайрар кош тавышы белән сөйли башлады. Татар сүзләрен бераз бозып сөйләшүе аның үзенә бик тә килешеп тора, аны гел татарча гына сөйләтеп торасы килә.

— Мин сезнең белән татарча исәнләштем, ә сезнең күбегез минем белән русча исәнләште. Кайсысы дөрес, ә? Җә, әйтеп карале, Исламнур!

Исламнур тук сыер мышнагандай пуфылдап урынынннан торды. Тук-лыктан мышнавы түгел иде аның, сорауга җавап бирү авырлыгыннан пошкыруы иде.

— Нәстә әйтим?— диде Ислам.

— Нәстә,— диде Валия.— Дөресме дим, исәнләшү, кайсысы?

— Урыс теле булгач, урысчасы дөрестер инде,— диде Ислам.

— И-и,— диде Валия йомшак кына.— Тәрәзәгә карап сөйләшмә, Исламнур. Миңа карап сөйләш.

Исламнур Валиягә карап алды да, башын тәрәзәгә таба борды.

— Минемчә,— диде Валия,— нинди телдә сезгә сәлам әйтсәләр, шул телдә җавап итәргә кирәк. Ә мин сезнең белән татарча исәнләштем.

— Бу бит татар теле дәресе түгел!— диде Исламнур.

— Булмаса сун!— диде Валия.— А ведь минем татарча үрәнәсем килә. Әйдәгез болай сөйләшик. Мин сезне русчага үрәтәм, ә сез мине татарчага яхшы үрәтәсез.

Валия бөтен йөзе белән елмайды да:

— Здравствуйте, дети!— диде.

Балалар дәррәү:

— Драстуйте!— диде.

— Исәнмесез, балалар,— диде Валия.

Балалар:

— Исәнмесез!— диде.

Дәрес башланды. Укытучы исемлек тикшерергә тотынды. Ярмөхәммәт аннан күзен алмады. Тик Валия аңа карамый да карамый. Аның ягына караганда да Ярмөхәммәтне Валия күрми, күрсә дә, карашы тиз генә шуып китә. Ниһаять, Валия кулындагы каләм исемлекнең ахырына төшеп җитте.

— Хәйруллин Ярмухамет!

Үз исемен ишеткәнче басты Ярмөхәммәт. Басты да укытучысының йөзенә туры карады.

— Ярмухамет юкмы әллә?— дип карашы белән эзләнә башлады Валия.

— Мин монда, Алиһә апа!— диде Ярмөхәммәт.

Класс берьюлы шартлап көлде. Укытучы Ярмөхәммәткә карады. Аннан соң Ярмөхәммәт исеме турысына билге куеп, аягүрә басты. Бер адым Ярмөхәммәткә таба атлады. Атлады да кинәт туктады. Ярмөхәммәт укытучысының күз алмасына бакты. Шунда шиге калмады: аның каршысында чәчәк алиһәсе басып тора!

Укытучы Валия исеме аталган балага йөгерек караш ташлап:

— Утыр, балам!— дип алга таба исемнәр атый иде.

Ярмөхәммәткә ул озаграк карап торды. Балалар моны үзләренчә юрады: «Валия апа» диясе урында Ярмөхәммәт нишләптер «Алиһә апа» диде. Шул ялгышы өчен Ярмөхәммәткә карап тора, янәсе.

«Чәчәк Алиһәсе сине таныды»,— дип уйлады Ярмөхәммәт.

— Син ни дидең? Алихэ диденме?— дип сорады укытучы.

Ярмөхәммәт тиз генә:

— Мин ялгыштым, Валия апа,— диде.

Валия тагын елмайды. Елмайганда аның керфекләре кысылды, күз кабагы тарайды. Бу елмаю Ярмөхәммәткә:

— Дөрес, Ярмөхәммәт, мин синең Алиһәң. Изге серебез ике арада гына калсын,— булып аңлашылды.

— Утыр... Ярмухамет!— диде укытучы.

Башкалар игътибар иткәндерме, юкмы, Ярмөхәммәт уйлап куйды: «Бөтенесенә «утыр, балам» дигән укытучы аңа «утыр, Ярмөхәммәт» диде...»

Бу кечкенә аерманы егермеләп баланың берсе дә сизми калды.

Дәрестән соң котыра-чаба таралганда Альберт белән Ярмөхәммәт атлап кына кайта иде.

— Күрше,— диде Альберт.— Укытучы апа сине һәрвакыт яклаячак.

Ярмөхәммәт сагаеп, туктады. Альберт та туктады.

— Өченки (Альберт ни өчендер сүзләрне үзенчә үзгәртеп әйтә), өченки шулай булачак...

— Ни өчен шулай булачак?— диде Ярмөхәммәт.

— Өченки һәр укытучының сөйгән укучысы була, сөймәгәне була. Тегеләй дә, болай да түгеле була. Урта хәллеләре, ягъни мәсәлән, ызначыт. Кайбер укытучылар присидәтел баласын яклый... Агайнесен яклый...

— Мин аның туганы түгел, присидәтел малае да түгел...

— Ә син прусты аның күңеленә хуш киләсең...

Сүз шушында өзелде. Укытучылар төркеме аларны куып җитеп килә иде.

Ярмөхәммәт кыланчык сыман Альбертны бик өнәп бетерми. Күп сүзле, буш башлы малай дип белә. Бүген уйлап куйды: «Бу шаталак Альберт алай ук буш гөбе түгел икән. Сизенә бит, очлы күз. Башкаларга таратмаса ярар иде...»

Альберт авызыннан беркайчан да андый сүз чыкмады. Шуннан соң Ярмөхәммәт аның белән якынаеп китте. Ни әйтсәң дә, алар арасында ачыкланып бетмәгән булса да, сер бар. Уртак сер һәрвакыт кешеләрне якынайта.

Ул сер шулай гомергә сер булып калды.

Укытучы Валия белән укучы малай Ярмөхәммәт арасындагы мөнәсәбәт, кеше күзенә күренмәсә дә, аерым төсмер ала башлады. Моны ике кеше генә белә иде. Альберт белән Ярмөхәммәт. Бөтен кешегә дә ягымлы бу миһербан алиһәсе Валия Ярмөхәммәткә аеруча йомшак мөгамәләдә иде кебек. Ярмөхәммәт тә Валия апасы тавышында үзенә генә аталган наз аһәңе тоя иде.

Ярмөхәммәт өчен һәр дәрес, мәктәптән соң һәр очрашу сөенечбәхет алып килә. Ләкин Ярмөхәммәт һаман да ачыклый алмый әле: Алиһә белән Валия икесе бер затмы, әллә ул төш кенәме, саташу гынамы?

Бервакыт дәрестән соң калгач, Ярмөхәммәт һиндыба чәчәге турында сүз кузгатырга уйлады.

— Алиһәм! Бу син бит! Син зәңгәр чәчәк эчендәге кыз!

Юк! Әйтә алмады Ярмөхәммәт! Валия аны аңламаса, кинәт кенә:

— Юк, үскәнем, син саташасың!— дисә, дөнья челпәрәмә киләчәк. Хыяллар, ләззәт диңгезләре юкка чыгачак. Чыннан да, ул чәчәк-кыз икән, үзе әйтер, һичшиксез, әйтергә тиеш.

Шулай да бер мәлне Ярмөхәммәт авызыннан очты чыкты шул сүз:

— Алиһәм!

Ярмөхәммәт дәрестән соң калып, эчке тәртип кагыйдәләре өчен рам ясый иде, класска Валия килеп керде.

— Ярмухамет!— диде укытучы.— Син миңа шушы плакатларны элергә таяк ясап бирә алмассыңмы? Без аны менә шушылай чөйгә эләрбез, юкса бөтәрләнеп бетәләр...

— Өйдә эшләп килермен, Алиһә...— диде Ярмөхәммәт, аннан өстәп куйды:— Валия апа...

— Син икенче тапкырында нииндидер исем әйтәсең,— диде Валия.— Кем ул? Нинди исем?

— Алиһә ул чәчәк кызы,— диде Ярмөхәммәт.— Һәр чәчәк эчендә чәчәк хуҗасы — бер чибәр кыз була. Ул кыз чәчәк алиһәсе. Сез... син... һиндыба чәчәгенең Алиһәсенә охшагансың... Юк, дөрес әйтмәдем... Алиһә сиңа охшаган...

— Фантазер син, Ярмухамет!— диде Валия.

Валиянең йөзе тагын да яктырып куйды. Ул челтерәп көлде. Аннан соң һич тарсынмыйча, Ярмөхәммәтнең ике иңеннән тотып, үз яңагын үсмер битенә куйды, кысты. Бик тиз булып алды ул кочаклау. Ефәк кебек нәфис, салкынча иде Валиянең бите. Ярмөхәммәт бардан юк була язды. Валия Ярмөхәммәтне ычкындырып, ишеккә юнәлде. Ишек тоткасына ябышып борылды да, әйтте:

— Ә нәрсә ул хиндыба?

— Һиндыба ул зәңгәр чәчәк,— диде Ярмөхәммәт.— Юл кырында, арыш арасында...

— А-а, цикориймы? Хиндыба! Очень интересно!— дип, Валия Галай класстан чыкты.

*Ахыры бар.*

## Мәхмүт Хөсәен

# ТУГАН ЯГЫМ — ГОМЕР ТАҢЫМ

### Абай моңнары

Ялга туктый кичен бар кәрван,
(Әлсерәгән кара дөяләр.)
Думбра уйный берәү арадан:
Кыллар тибрәп телгә киләләр.

Дәрман бирә җыр дәү олауга,
Дәррәү оча бөтен якка ул.
Исе китми буран улауга,
Җырны тыңлый хәтта саксаул.

Иксез-чиксез казакъ даласы
Булган төпсез газап дәрьясы...
Дәү акынның йөрәк авазы
Булган илгә йөрәк давасы.

Сары дулкын — дала комнары,
Яшәрткеч яз — Абай моңнары.

### Пар канатым

Тукай белән таныштым мин
Абай теле аркылы...
Шуннан бирле йөрәгемдә
Дөрли Тукай ялкыны.

Тукай, Абай —пар канатым.
Юлдашым — абынганда...
Иҗат юлымда — илһамчым,
Кояшым — давылларда.

---

МӘХМҮТ ХӨСӘЕН *(1923)— шагыйрь, «Лирика», «Җир мәрҗәннәре» (Сонетлар), «Әнием миләше» һ. б. исемдәге күп санлы шигырь һәм публицистика китаплары авторы. Татарстанның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

## Семипалат

Иске йортларыңа карап,
Искә алам сине кабат:
Ком каласы идең бит син
Мин яшь чакта, Семипалат.

Су өстендә балык аулап,
Акчарлаклар җилпи канат.
Алар, ахры, миңа шулай
Сәлам бирә, Семипалат.

Таллар толымнарын тарап,
Көлемсери миңа карап.
Алар да гүя үз итеп,
Баш изиләр, Семипалат.

Керәшәле ярга карап
Уйлыйм: портың тулы кораб...
Иртеш буйлап сәяхәтем
Татлы төш ул, Семипалат.

Ком бураны тузмый кабат,
Урамыңда — сирень, нарат...
Танып булмый хәзер сине,
Яшь син, яңа, Семипалат.

## Иртеш ага

Иртеш ага,
Ярга дулкын кага,
Ә мин эзлим яшьлек эземне...
Абай бабам,
Туып-үскән далам,
Сез ачтыгыз минем күземне.

Иртеш ага...
Җаннарыма дәва —
Бодай исе, чирәм һавасы...
Суын эчсәм, кабат яшәрәм күк,
Җырларымның туа яңасы.

## Соңгы туп

Саргылт үлән сарган тын далада
Пыр тузып без футбол уйныйбыз.
Өс-баш тузан, тештә ком чытырдый...
Ә без һаман уйнап туймыйбыз.

Туп — күн тышлы, резин эчле түгел,
Тутырылган чүпрәк аңарга.
Тәгәрәми дә ул, сикерми дә,
Типсәң генә оча һавага.

Уендашым уң яктан пас биргәч,
Инде җиңәбез дип шатландым.
Әйбәт кенә әйдәгәндә тупны,
Абынып, йөзтүбән капландым.

Каршы якның капкасына, күрәм,
Бер сикереш ара калганын...
Гарьләндерде — абынуым түгел,
Соңгы тупны кертә алмавым...

Кинәт афәт!
Туган туфрак яна...
Көек исе каба сулышка...
Ил ирекен яклап аугач әткәй,
Үзем теләп киттем сугышка.

Күренсә дә малай-шалайларча
Минем төсем, тышкы килешем,
Башта укчы, аннан тупчы булып,
Утка кердем туган ил өчен.

Тубым белән фашист танкын ваткач,
Дулкынланып, сүзсез калганмын...
Искә төште шул мәл балачакта
Соңгы тупны кертә алмавым...

## Кул кысыштык Җиңүдән соң...

*Рафаил Төхфәтуллинга*

Мин жырладым казах далаларын,
Син зурладың Арча төбәген.
Синең дә бит, укып белем алгач,
Әдип булу иде теләгең.
Җәйге ялда — казах даласында,
Кенәрдә я Казан каласында
Очрашабыз дигән вакытта —
Бәреп керде илгә фашист явы!..
Киттек без дә яуга... окопка.

Үлемен үз оясында тапты
Җиргә афәт алып килгән яу!..

Европаны арчып гыйфритләрдән,
Ут эченнән чыктык исән-сау.

Кул кысыштык Бөек Җиңүдән соң
Казанда, чал Идел буенда...
Яшь пионер чаклар учак якты
Без ветеран солдат уенда.

Алга басты Кенәр урманнары,
Җил искәндәй булды даладан...
Алып кайтты хәтер аргамагы
Балачакка безне яңадан.

## Карлыгач

Килеп аудым диңгез итәгенә,
Тау юлларын урап арыгач.
Ярда жырлый кемдер казахчалап...
Ул син булып чыктың, Карлыгач.

Һәр сүзеңне тыңлыйм онытылып,
Дала моңнарына тарыгач.
Туган ягым баса күз алдыма
Синең жырың аша, Карлыгач.

Заңгар тасы бүлттарга,
Айбат берген Алатау.
Өр түлгасы жастарга
Кайрат берген Алатау[1].

Дала ерак,
Кара диңгез янда:
Тирәсе тау аның, яры таш.
Чыгырыннан чыккан дулкыннар да
Син жырлауга, тына, Карлыгач.

Тау белән тау гына очрашмый тик,
Без табыштык, без бит — бавырдаш.
Рәхмәт, туган!
Синең моңнарыңнан
Җанлана таш хәтта, Карлыгач!

## Теләк

Туган ягым — гомер таңым,
Үс,
матурлан,
чынык тагын!
Онытмагыз бабагызның
Туган ягын, оныкларым!

*1985—1987.*

*Казахстан—Казан.*

[1] *«Зәңгәр ташы болытларга ямь биргән Алатау, ирләре яшьләргә гайрәт биргән Алатау» дигән мәгънәдә. Ред.*

9*



*Шагыйрь, 1979 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы Нәҗип Гәрәй улы Мадьяров 1928 елның 3 мартында Татарстан АССРның Арча районы Кызыл Утар авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлауга, аның хезмәт юлы башлана: ул гади колхозчы, хисапчы, бухгалтер булып эшли. 1950—1953 елларда Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткач, урта мәктәпне, аннары В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый, укытучы булып, аннан озак еллар буе Арча һәм Балтач район газеталары редакциясендә бүлек мөдире, редактор урынбасары булып эшли. 1980 елдан — Чаллы шәһәрендә яши. 1955 елдан бирле КПСС члены. Нәҗип Мадьяровның беренче китабы — «Чык бөртекләре» 1960 елда басылып чыга. Хәзер ул — дистәдән артык шигырь җыентыгы авторы. Арада «Рәшәле офыкларым» исемле күләмле китабы (1979) бар. Шагыйрь, нигездә, сугыштан соңгы һәм бүгенге авыл кешесенең уй-фикерләрен, замандашларының хисләрен җырлый, ул балалар поэзиясендә дә нәтиҗәле эшләп килә.*

*Без бу санда укучыларыбызга шагыйрьнең төрле елларда язылган бер бәйләм шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

# Нәҗип Мадьяров

# ЕЛЛАР УЯТКАН УЙЛАР

## Табылмаган, димәк

Чын ихластан, каләмемне манып
Көнелдәге шигъри ялкынга,
Күп яздым мин туган җир турында,
Күп җырладым аның хакында.

Илһам белән сугарылган йөрәк
Тынычлана алмый алай да.
Туган җирне бәһаләрлек сүзләр
Табылмаган, димәк, һаман да.

*1987.*

## Бозлар акканда

Инеш буе халык белән тулы,
Ташкын суга күзләр текәлгән.
Яз тудырган шаулы тамашаны
Көткән идек инде күптәннән...

...Каерылып купты әнә анда
Бәкеле боз — күпер алдында.
Бу яклардан китәр минутлары
Килеп җитте менә аның да.

Кузгалды ул инде соңгы юлга,
Һөҗүменә язның түзмәде;
Карап калдык аннан
Яшь киленнәр
Су китереп йөргән эзләрне.

Карап калдык...
Күздән югалды ул
Борылмалар аша узды да.
Салкын гына озатып булмый икән
Туган җирнең салкын бозын да.

*1958.*

## Чишмә булсаң иде

Жырлап аккан чишмә
Авыр көрсенә күк:
— Инеш булсаң иде!
Суларыңны зур-зур елгаларга
Илтеп куйсаң иде!

Ярсып ага инеш,
Сөйли гүя ул да:
— Елга булсаң иде!
Суларыңны шаулы диңгезләргә
Илтеп койсаң иде!

Җәелеп ага елга,
Үз язмышын тиргәп:
— Диңгез булсаң иде!
Иксез-чиксез, данлы океанга
Кушылып торсаң иде!

Шаулый диңгез, йөгерек
Дулкыннары шыңшый:
— Чишмә булсаң иде!
Дөнья буйлап, матурлыкны күзләп,
Агып узсаң иде!

*1966*

## Куркак солдат турында баллада

«Ил язмышы хәл ителгән чакта,
Мин бит сугыш кырын ташлап киттем.
Тере калып үлдем, үз-үземне
Куркаклыгым белән корбан иттем.

Туган җиргә, халкым каршысына
Бу йөз белән ничек кайтып керим?
И, зәңгәр күк, болыт итсәнче син?
Танытмыйча дөнья гизәр идем».

Ахры, гаебен аңлаганга күрә,
Күк качкынның сүзен искә алды:
Давыл белән күтәрде дә җирдән,
Мәңгелеккә болыт итте аны...

Тик шомлана халык ирексездән,
Ул килгәндә иген кырларына:
Кешеләргә аннан һаман — хафа,
Коеп үтә бозлы яңгыр гына...

*1968*

## Күпер

Кайгым төяп үттем аннан,
Ничек күтәрде икән?!
Уздым үч, ярсу белән дә...
Дөнья кадәр ярсуларны
Ничек үткәрде икән?!

*1987*

## Тибрәлә кыр

Басу уртасында — җәй уртасы!
Бүген менә мин шул урталыкта...
Башакларның җырын тыңлап киләм,
Кайчагында калам тукталып та.

Чайкалыша алар җайга гына,
Кичке якка көнне авыштырып.
Үстергән җир язгы бодайларны
Көзге арыш белән ярыштырып.

Каерылып-каерылып карыйм
Каерылып уңган шул игенгә.
Канат итеп безнең шатлыкларны,
Тибрәлә кыр бөтен киңлегенә.

*1976.*

## Карап торам таулар итәгенә

Киң болынның кочагында тагын
Чәч чалартты гүзәл тугайлар.
Алардагы яшел үләннәрне,
Яшен түгел, сукты кыраулар.

Исән калган соңгы чәчәкләрне
Салкын җилләр йөри шиңдереп.
Ямен җуйган таулар итәгендә
Көтү йөри җәйне сүндереп.

*1970.*

## Тыныч түгел җаным

Ташлап китте мине кайгылар да,
Шатлыклар да миңа кул селтәде.
Дулкынланмый уй елгасы койган
Көнелем күле. Аның тын өсләре.

Сагындырмый үткән бәхетләр дә,
Сөендерми якты киләчәк тә.
Нигә соң мин, ни өчен соң болай
Башым иеп торам «курәчәк»кә?

Белми хәзер мине дусларым да,
Игътибарсыз хәтта дошманым да.
Ялкынланып, дөрләп элеккечә
Көйрәми эш дәрте һич җанымда...

Яшәп булмый мондый халәт белән,
Әй, вакытлы уйлар, югалыгыз...
Кайгыларым, шатлыкларым, әйдә,
Күңелемә кабат юл ярыгыз!

*1981.*

# ПУБЛИЦИСТИКА

**Флүс Латыйпов**

# ТАТАРСТАН ЧИТЕКЛӘРЕ

## Арча — Париж, Лейпциг, Токио...

Мәсгут Хәкимович алдыма бер бәйләм хат китереп салды:

— Сез боларны белән таныша торыгыз, әле яңарак килгәннәре. Бүлекләрдә дә байтак алар. Хәзер алып керәм...

Директор кабинетында ялгызым гына калып, дисталәгән хатны актарырга керештем. Почта штемпельләренә карап кына да Советлар Союзының тулы географиясен өйрәнергә мөмкин. Нинди кәгазьдә, нинди конвертта булуына карамастан, эчтәлекләре бер — Арча читекләренә соклануларын, аларны кибетләрдән таба алмауларын язалар, үзләренә ярдәм итүне сорыйлар.

«Аһ! Татарстан сынлы сәнгать музеенда нинди нәфис милли читекләр күреп сокландым мин».

Р. Шакирова. Казан.

«Известия» газетасында сезнең бизәкле аяк киемнәрегез турында мәкалә укыгач, хат язмый булдыра алмадым. Үтенеп сорыйм, кыз балалар өчен берәр пар читек җибәрә алмассызмы?»

А. Макарян. Ереван.

«Халык промыселлары музее төзү уе белән йөрибез. Мөмкинлегегезгә карап, кайбер үрнәкләр һәм халык сәнгате промыселының тарихы, күренекле осталарыгыз турында мәгълүматлар җибәрсәгез иде».

Н. Левашова.
Донецк өлкәсенең Торез шәһәре.

«Сезнең матур чәмчәле читекләрегезне «Азат Хатын» журналында күреп, яшем өлкән булуга карамастан, шушы матур, чәмчәле кызыл читекләрегезне кию турында хыялланам».

М. Гәрәева, пенсионерка.
Башкортстан АССРның Мәләвез шәһәре.

Әле өстәлдә яткан хатларны карап чыгарга да өлгермәдем, берләшмә директоры кулына тагын әллә никадәр кәгазь тотып, кояштай балкып килеп керде:

— Аларны берләшмәгә генә түгел, аерым эшчеләребез исеменә дә җибәрәләр.

— Ә ул үтенечләрне үти аласызмы? Теләгән аяк киемнәрен җибәрәсезме соң диюем.

Мәсгут Хәкимович үкенечле рәвештә кулын селтәп куйды һәм авыр сулап, сүзен дәвам иттерде:

— Каян үтәп бетермәк кирәк! Аннан соң безнең андый вәкаләтебез дә юк. Бөтен аяк киеме «Рособувьторг»ның Казандагы базасына җибәрелә. Кая һәм күпме озату аның вазифасында.

Илнең төрле якларыннан гозерләп хат язучыларның халенә керергә

иде бит дигәнне аңлатырга теләп, шул ук сорауны башка сүзләр белән кабатлыйм:

— Ә шулай да... Бик теләгәндә дә җибәреп булмыймы?

Директор миңа сынагандай карап алды һәм бераз тын торгач кына җавап бирде.

— Әгәр аларны үти башласаң, махсус бүлек ачарга кирәк булыр иде. Кызганычка каршы, күпчелек хат авторларына «Казандагы кибетләргә мөрәҗәгать итеп карагыз».— дип җавап язарга мәҗбүрбез. Шулай да... сирәк кенә булса да... кайберләренә ярдәм иткәлибез. Менә мондый хатка ничек битараф каласың ди...

Мәсгут Хәкимович кулындагы конвертларның берсен ачып, калын кәгазьгә вак хәрефләр белән тыгызлап язылган шактый озын хатны күрсәтте:

«Мин үзем рус милләтеннән булсам да, гомерем буе татар халкының гамәли сәнгать әйберләренә гашыйкмын,— дип яза Мәскәүдән Оксана Юрьевна Хан.— Миңа күн әйберләр, сәйлән белән чигелгән калфаклар, ювелир әйберләр ошый. Дөрес, аларны бары тик китаплар буенча гына беләм.

Менә ике ел инде сезнең читекләрне эзләп «Русский сувенир» кибете юлын таптыйм. Әмма әле бүгенге көнгә кадәр тап була алганым юк, чөнки аларны күз ачып йомганчы алып бетерәләр. Күптән түгел читекләр тегүне туктатырга җыенуыгызны ишетеп (дөрестерме-юкмы, анысын белмим), чиксез борчылдым. Гаҗәеп дәрәҗәдә нәфис, затлы һәм чыдам әйберләр бит алар. Әгәр Мәскәүгә алып килсәгез, кулыгызга да тидермәячәкләр. Фольклор стилендә киенергә яратучылар аларны теләсә нинди итальян итекләреннән өстен күрәчәк. Әйберләрегезне шулай ук ярминкәләрдә сатарга һәм хәзер ачылучы кооператив кибетләренә тәкъдим итәргә мөмкин булыр иде.

Берләшмәгез кичергән кыенлыклар турында газетадан укып белдем. Татарстанда бар хатын-кызларның да импорт әйбер кияргә омтылуы табигый хәл. Провинциядә һәркем солиднырак күренергә тырыша. Әмма мода Мәскәүдә башлана. Массовый мода түгел, ә элитар мода, сайланма, затлы мода. Вакыт узу белән һичшиксез ул Казанга да килеп җитәчәк.

Эшегезгә хилафлык китермәгез. Хәзер шартлар үзгәрде. Аяк киемнәрегезне язгы ярминкәгә алып килегез һәм сәүдәнең ничек шома барганын үзегез күрерсез. Ышандырып әйтәм, төсле бизәкләр куелган балалар аяк киеме исә тагын да ныграк ошаячак.

Мин үземә читек алырга теләгәннән генә түгел, ә халык һөнәрчелегенең һәлакәтен чын күңелемнән авыр кичергәнгә күрә уфтанып язам. Тирә-ягыбызга күз салыйк әле: халык сәнгате музейларында күзне иркәләгән нәрсәләрне гадәти тормышта очратабызмы соң?

Туку, чигү, бәйләү кебек һөнәрләр хәзергә яшәп килә. Ә итекчеләр әйтерсең лә, үлеп беткән диярсең. Мәскәү хәтле Мәскәүдә үз рәсемнәрем буенча балаларыма итек тектерергә кеше таба алмадым. Сез әлегә яхшырак шартларда. Итекче осталарыгызны һәм аларның традицияләрен исән көйгә саклагыз. Мәскәүдә Татарстан әйберләрен сату кибете ачарга тырышып карасагыз ничек булыр икән?! Шәхси инициатива күрсәтергә дә вакыттыр.

Тагын шунысы кызыксындыра: әле дә эшләүче ювелирлар Татарстанда бармы? Чулпы, муенса, хәситә, алка кебек бизәнү әйберләрен дә Мәскәүдә яратып алырлар иде. Тик аларны алюминий белән пыяладан түгел, ә көмештән һәм ярымасылташлар куеп ясарга иде. Сәнгать салонында Бурятиядән китерелгән шундый зиннәтләр зур уңыш белән сатыла».

Хатны укып бетерүгә күз карашым Мәсгут Хәкимовичныкы белән очрашты.

— Я, ничек,— диде ул.— Килешәсезме?

— Миңа калса, бу ханым мәсьәләне дөрес куя. Илдә барган яңарыш, үзгәртеп кору сезнең берләшмәне генә читләтеп үтми торгандыр. Бу заказларны үтәүнең нинди дә булса юлларын эзләп карамадыгызмы соң?

— Хикмәт заказда гына түгел. Ул хатларны без, ахыр чиктә, кибетләргә дә җибәрә алабыз. Тагын бер четерекле нәрсә бар.— Аяклары стандарт булмаган кешеләр дә еш мөрәҗәгать итә. Алары инде үзләренә ярашлы әйберне кибеттән ала алмый. Мондыйларга ничек ярдәм итәргә? Күп уйлаштык без... Партия Үзәк Комитетының индивидуаль эшчәнлек турындагы карары күптән борчып, бимазалап килгән әнә шул уйларны куып тараткандай булды.

Мәсгут Хәкимовичның йөзе яктырып китте, ул алдындагы кәгазьләргә күрсәтә-күрсәтә, алардагы саннарны аңлатырга, киләчәктә булачак эшләрне тасвирларга кереште:

— Берләшмә янында аяк киеме тегү кооперативы ачарга булдык. Дөрес, хәзергә зур түгел, нибары өч кешедән. Алар өчен бина таптык, берләшмә күн һәм җиһазлар белән ярдәм итәчәк. Кыскасы, бу проблема озакламый

хәл ителәчәк. Килгән хатларны да кооперативка тапшырып барачакбыз. Ә итекчеләр. үзара килешү буенча, һәркемгә үзе теләгәнчә чүәк, башмак яки читек тегәчәкләр...

— Итекчеләр дигәннән, әнә шул борынгы һөнәрне онытмый саклаган кешеләр бармы? Берләшмәдә чигүдән кала бөтен эшне диярлек хәзер машиналар башкара ич,— дип сүзен бүлдергән идем, директорның йөзе беразга караңгыланып алды.

— Кызганычка каршы, аз шул. Кооперативны өч кенә кешедән ачуның да сере шунда. Ишен-ишкә, төсен-төскә китереп күнне сайлап алу, аны тиешле өлгедә кисү, тегү, калыпка утырту, бизәген зәвыклап чигү кебек бөтен эшләрне дә бердәй осталык белән башкара алырлык осталарыбыз бетеп бара. Шөкер, әлегә андыйлар бар-барын. Әмма алар инде бармак белән генә санарлык. Кооперативка кодалаган осталарыбыз шулардан,— диде ул.— Юкса, борын-борыннан Арча, Дөбъяз яклары үзенең читекчеләре белән дан тоткан. Әмма хезмәтне конвейерга куеп операцияләп бүлү, продукцияне күбрәк һәм арзанрак җитештерергә омтылу ахыр чиктә яшьләр арасыннан бөтен эшне биш бармагы кебек белгән осталар тәрбияләргә комачаулый. Бу өлкәдә дә кооператива өметләнәбез.

— Алайса, мин сезгә бер нәрсә күрсәтим әле...

Кабинетка килеп кергәннән бирле нәрсәдер әйтергә теләп утырган Филсинә Мөбәракшина сүзгә кушыла. Унбиш яшеннән берләшмәдә эшли башлаган ветеранны борчыган нәрсәләр дә байтак икән:

— Менә минем аяктагы чүәкләрне күрәсезме? Тыштан караганда цехларда хәзер тегелә торганнарыннан берни белән дә аерылмый кебек. Шулай бит... Бизәкләре дә шундый, чигелеше дә...

— Әйе...

— Юк шул. Бу — бөтен җире кулдан эшләнгән, олтаны да кулдан тегелгән чүәк. Моннан берничә ел элек алып калган идем, шуннан бирле аягымнан төшерми яратып киям. Тузуны да, искерүне дә белми.

Башта бернәрсә дә аңламаган идем. Сораулы карашымны күреп булса кирәк. Филсинә ханым: «Менә күрегез!» дигәндәй, торып басты һәм уң аягын алга чыгарып куйды, бармакларын, аягын төрле рәвешләргә кертеп хәрәкәтләндерергә кереште. Йомшак күн эчендә аларның ничек бөгелгәненә хәтле сизелеп тора, чүәк, бернинди каршылыксыз, буын хәрәкәтләрен кабатлый иде.

— Хәзер аңладыгызмы инде? Моның табаны да йомшак күннән, өслеге дә... Хәзер андый күннәр дә юньләп килми, тегүебез дә башкача.

— Ничек башкача? Чүәкләр бер төсле ич...

— Олтан хәзер җилемгә утыртыла. Каты табан. Өслеге дә каты. Хатын-кызлар, шуңадырмы, бик яратып алмый аларны. Күренеше элеккечә, ә сыйфаты, йомшаклыгы бетте. Чүәк-чүәк булырга, ягъни йомшак булырга, аягында сизелмәскә дә тиеш.

— Ул гына да түгел, хәзер инде күп кенә әйберләр тегүнең серен онытып барабыз,— дип дәвам итте Филсинә ханым.— Бар иде ул әлгәре саурыйлы читекләр. Үкчәсендә генә яшел бизәк була торган иде. Кәвеш белән кия торган йомшак читек тегәләр иде. Ул бетте. Кәвеш үзе бетте. Башмаклар бетүгә бара. Сәбәбе — йомшак күн килми, катысыннан тегеп булмый. Чигәргә ифрат авыр алар.

Берләшмә директоры каяндыр төрле күн үрнәкләре салынган кечкенә генә әрҗә тартып чыгарды һәм бер сүз дә әйтеп тормастан, арадан берсен — тонык зәңгәр төстәге күн кисәген алды һәм йомарлап өсталгә ташлады. Күн кисәге ничек төшкән булса шул көйгә, йомарланган хәлендә ятып калды. Тагын бер кисәкне, аеруча юка һәм затлы күренгәнен алып, тагын шул ук хәрәкәтләрне кабатлады. Бусы да җыерчыклы көйгә өстәл өстенә килеп төште.

— Ә хәзер карагыз!

Мәсгут Хәкимович икенче бер тартмадан ачык яшькелт төстәге тагын бер күн кисәген алды һәм, ниндидер тылсымлы эш башкаргандай, тантаналы кыяфәт белән аны баягыдан да катырак итеп изәргә, бөтәрләргә кереште. Өстәл өстенә килеп төшкән күн күз алдында языла, турая башлады. Берничә секундтан инде ул баягы, беренчел хәлендә иде. Әйтерсең лә аны измәгәннәр дә, бөтәрләмәгәннәр дә.

— Чын сафьян менә шундый була. Хәзер аларны сагынып сөйләргә генә калды. Ә монысын шул үрнәк өчен генә тотабыз,— дип өстәлдә яткан

шома көн кисәгенә ымлады ул.— Төсенә генә игътибар итегез! Нинди ачык, якты, матур төс!.. Читек тегү өчен кимендә биш, ә чүәк-башмаклар өчен аз дигәндә дә өч төс кирәк. Безгә исә кайчагында ике-өч төс белән чикләнергә туры килә. Бизәген матуррак итим дип, шул чигүчеләр тырыша инде. Чигү җөен салганда үзләренчә килешлерәк, ятышлырак, ачыграк җеп сайлыйлар.

Татарстан читекләренең даны кайчандыр бөтен дөньяга билгеле иде. Күнне сәнгатьчә эшкәртү, сафьян һәм юфть дип аталучы йомшак күннән затлы әйберләр, шул исәптән аяк киемнәре тегү белән әле борынгы бабаларыбыз — Идел буе болгарлары ук танылган булган. Бу турыда археологик казынулар вакытында табылган мәгълүматлар да, рус елъязмаларындагы истәлекләр һәм башка тарихи чыганаклар да ачык сөйли. Хәтта кайбер якларда аеруча яхшы эшкәртелгән күнне әле дә «болгари» дип атыйлар.

Сафьяннан каелган бизәкле читекләр һәм башмаклар үткән гасырда ук Бөтенроссия һәм Европа күргәзмәләрендә төрле дәрәҗәдәге медальләр алган. 1883 нче елда, мәсәлән, татар читекләре Парижда зур алтын медаль, ә 1886 нчы елда бронза медаль белән бүләкләнә. Тагын өч ел үткәннән соң татар осталарының әйберләре Париждагы Бөтендөнья күргәзмәсенә тәкъдим ителә. Бу юлы да халкыбызның гамәли сәнгать әсәрләре күргәзмәдә катнашучыларны әсир итә — алар мактаулы бәягә лаек була һәм көмеш медаль яулап ала. Ул чорлардагы билгесез рәссам-һөнәрчеләрнең дәвамы бүген ничек үстерелә? Бу һөнәргә шулай ук юкка чыгу куркынычы янамыймы? Бу турыдагы шик-шөбһәләремне, уйларымны әйтеп бетерергә дә өлгермәдем, Мәсгут Хәкимович урыныннан күтәрелде.

— Хәзер мин сезне бер кеше белән таныштырыйм әле,— диде ул.— Бөтен нәсел-нәсәбе диярлек — читекчеләр. Әтисе дә гаҗәеп оста кеше булган. Үзе дә малай чагыннан бирле диярлек берләшмәдә. Директор да булып торган, хәзер, пенсиядә булуына карамастан — баш бухгалтер. Берләшмә тарихын, читекчеләр хезмәтен белә дисәң дә белә инде ул. Ә мин... Әле уникс ел гына эшлим...

Абдулла Хәкимович Хисмәтуллин белән шулай таныштык.

— Арча милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе 1972 елда оешты,— дип башлады ул сүзен.— Аңа кадәр берни дә булмаган икән дигән сүз түгел бу. Әлектән дә Арча һәм Дөбъязда милли аяк киемнәре фабрикалары эшләп килә иде. Ә аңа кадәрле төрле исемдәге артельләр бар иде. Борынгы читекчеләр традицияләрен шулар саклап килде. 1936 елга кадәр шушы артельләрдә тегелгән һәр ике пар аяк киеменең берсе чит илгә чыгып бара иде. Ул вакытларда, Торгсин дигән оешма булып, читек-башмакларыбызны шунда җибәрә идек. Ә аннан инде алар алтын бәһасенә Франциягә, Англиягә, Италиягә, Германиягә озатыла, Бельгиягә чыгарыла.

Ул вакытта елына 150 мең пар чамасы читекне чит ил өчен тегә идек. Париж модницалары безнең читекне киеп форсить итмәгән дип кем әйтә ала?..

— Димәк, елына өч йөз мең пар чамасы аяк киеме теккәнсез. Ә хәзер ничегрәк?..

Саннар дөньясына кереп киткәч, Абдулла Хәкимович бернинди кәгазьфәләнгә карап тормастан, электрон-исәпләү машинасы тизлеге белән төрле план, график, аларның үтәлеше кебек саннарны бер-бер артлы тезә башлады. Язып кына өлгер!

— Хәзер без елга бер миллионга якын аяк киеме тегәбез. Берләшмә табигый күннән җиде миллион сумлык продукция бирә. Рентабельлелек турында сөйләп тә торасы юк. Саф табыш — бер миллион сум. Азмы бу, әллә күпме?

Соравына үзе үк җавап та бирә баш бухгалтер:

— Шактый күп бу! Әмма без әнә шул саф табышны тагын да арттыра алыр идек. Ничек итепме? Җавабы бик гади аның — аяк киемнәре тегүне киметеп, ягъни мәсәлән...

— Аңлашылып җитми. Тегүне киметкәч, ничек итеп, табыш артырга мөмкин икән?..

— Әйе, шул! Кызганычка каршы, күпләр әлегә кадәр әнә шулай беркатлырак уйлый. Монда мин безнең берләшмә исеменә туры килми торган аяк киемнәрен күздә тотам. Андыйлары байтак бит аның. Арзанлы, гап-гади чүәкләр, башмаклар... Шуларны бетерергә дә, милли аяк киемнәре, чын

сәнгатьчә читек, чүәк, башмаклар тегүне яхшыртырга кирәк... Хәзер бездә егермедән артык төрдә аяк киеме чыга. Ел саен шуның биштән бер өлеше диярлек яңартыла. Продукциябезнең бары житмеш проценты гына — милли аяк киемнәре. Аны без, акрынлап, һаман киметеп киләбез. Шулай эшләргә мәжбүрбез.

Республика Госпланы безгә елның-елына ничә пар аяк киеме житештерергә икәнлеген дә, аның суммасын да күрсәтеп конкрет бурыч йөкли. Пар санын киметсәң дә, гомуми сумманы киметсәң дә, башыңнан сыйпамыйлар. Шунлыктан үзебезнең ассортименттан читкә китеп булса да, халык әллә ни яратып алмый торган гап-гади чүәкләр, чүпрәк башмаклар тегәргә туры килә. Алар белән хәзер бөтен кибетләр тулды. Хәтта берничә төрле кроссовка тегә башладык. Халык сәнгатенә нигезләнгән һөнәр йорты гапгади аяк киеме фабрикасына әйләнеп бара шикелле. Безнең максат бөтенләй башка иде...

Абдулла Хәкимович берничә кроссовка алып килеп, кулында әйләндерә-әйләндерә күрсәтә башлады.

— Менә карагыз әле, нинди милли аяк киеме булсын ди инде бу. Казандагы «Спартак» берләшмәсе аны рәхәтләнеп елына миллионлаган пар тегә ала.

— Моңа да бизәк төшерәсез икән бит!— дим.

— Аптыраган үрдәк арты белән суга чумган, диме? Аптыраганнан ул. Шул бизәге булмаса, финанс органнары безгә егерме жиде процент налог салачак. Ә болай ул милли аяк киеменнән исәпләнә.

— Димәк, сезнең житмеш процент дигәнегезгә әле шушы кроссовкалар да керә булып чыга?..

Абдулла Хәкимович «Ни хәл итмәк кирәк?» дигәндәй, аптырашлы кыяфәттә иңсәләрен жыерып куйды.

— Өстән төшерелгән саннар безне һаман кысрыклый, зәвыксыз, гади аяк киемнәрен күбрәк чыгарырга этәрә,— дип дәвам итте ул.— Менә карагыз: 1975 елда берләшмә дүрт миллион бер йөз мең сумлык продукция бирде. 1981 елда инде биш миллион чиген узып киттек. Тагын биш елдан, ягъни 1986 елда инде бу сан алты миллион дүрт йөз кырык мең сумга житте.

Бер карасаң, шәп бит, ә?! Предприятие — үсештә. Барысы да ал да гөл кебек. Әмма бу үсеш бөтен Европаны сокландырган, гажәпләндергән, халкыбыз горурлыгы саналган югары сәнгатьле әйберләр тегүне киметү хисабына бара. Кемгә кирәк соң аны киметү? Берәүгә дә кирәкми, нәкъ менә милли аяк киемнәрен сорап бөтен илдән хатлар ява! Татарстан казанышларын, аның халык сәнгатен күрсәтергә кирәк булса, барысы да, йөгереп, безгә килә,— дип сүзен бетерде ул.

Әйе, 1980 елда Лейпцигта үткәрелгән халыкара ярминкәдә Арча читекләренең нинди дан казануы әле барыбызның да хәтерендәдер дип уйлыйм. Алдымда шул дәрәжәле күргәзмә өчен чыгарылган реклама ята. Ялтыравык кәгазьгә төрле төсләр белән басылган ул. «Арча берләшмәсе — дөньяда милли орнаментлы аяк киемнәре чыгаручы бердәнбер предприятие. Алар төсле күнне оригиналь ысул белән кулдан чигеп тоташтыру ярдәмендә эшләнә.

Аяк киемнәре житештерүнең республикада борынгы традицияләре бар. Талантлы осталарның алтын куллары белән эшләнгән, якты бизәкле әйберләр халыкның рухи дөньясы чагылышы да ул. Мондый аяк киемнәре илебездәге барлык милләт кешеләре арасында татар халкының иң яхшы сувенирлары буларак файдаланыла» дигән сүзләрне укыганда горурланмый мөмкин түгел. Лейпцигтагы халыкара ярминкә Дипломы һәм алтын медале белән бүләкләнү бу сүзләрнең тулысынча хаклы һәм дөрес булуын раслый.

Бу урында сәнгать белгече Флүрә Гулованың «Татар милли аяк киемнәре» дигән китабыннан (Казан, 1983) бер өзекне искә төшерү кызыклы булыр: «...татар читекләрен, башмакларын бизәкләү техникасы — төрле төстәге күн бизәкләрне бер үк вакытта тоташтыру һәм чигү — дөнья сәнгате практикасында тиңе булмаган уникаль ысул».— дип яза ул. Дөньядагы башка бик күп халыкларның аяк киеме тегү алымнары, гамәли сәнгате белән яхшы таныш белгечнең бу сүзләре генә дә Арча читекләренә сак карашны, аерым игътибар сорый түгелме соң? Ни өчен соңгы елларда нәк шул игътибар кими бара?

Бу сорауны икенче төрле итеп тә куярга була: халык сәнгате промыселына нәрсә комачаулый? Жавапны эрактан эзлисе юк. Иң беренче чиратта,

әлбәттә, бөтен экономиканы хастага сабыштырган «тулаем күрсәткеч» дигән нәрсә, ягъни вал күрсәткече. Ничек кенә булмасын, бөтен көч-куәт иң элек продукция җитештерүгә сарыф ителә. Ә кулланучыга ул ошармы, аның эстетик зәвыгына җавап бирерме — монысы инде иң ахыргы мәсьәлә. Ә халык сәнгате промыселы исә нәкъ менә шул эстетик зәвык тәрбияләүне, кешеләрдә матурлыкка соклану булдыруны күздә тотарга тиеш тә иде бит. Вал һәм сәнгать — капма-каршы төшенчә. Вал булган җирдә сәнгать, сәнгать булган җирдә вал була алмый.

Берләшмәдә миңа күптән түгел генә булган бер хәлне сөйләделәр.

— Апрель азаклары иде,— дип башлады сүзен Мәсгут Хәкимович.— Арчага Япония белгечләре килде. Кунакларга без, гадәттә, бөтен производство циклын күрсәтәбез. Күнне кисүдән башлап, әзер продукцияне төрүгә кадәр диярлек. Бу юлы да шулай иттек. Төрле төстәге күн кисүне дә, калыплауны да, табан ябыштыруны да карадылар. Үзем алар белән йөрим, үземнең башны бер фикер бораулый: дөнья базарында Американы кысрыклаган японнарны моның белән генә шаккатыра алмассыңдыр шәт? Сүзләре белән шуны әйтмәсәләр дә, һәр хәрәкәтләре шулай уйлаганнарын күрсәтә дә сыман. Йөзләрендә ясалма елмаю, күзләрендә тәкәббер битарафлык чагыла. Бара-бара чигү цехына килеп кердек. Дистәләгән кызның якты, иркен бүлмәдә төрле төстәге күннән күз явын алырдай чәчәкләр-бизәкләр чигеп утыруын күргәч, кунакларыбызны алыштырып куйдылар, диярсең. Күзләрендәге ваемсызлык та, дежур елмаю да бердән юкка чыкты. Бер-берсен бүлдерә-бүлдерә төсләрне ничек сайлау, нинди төстәге күнне нинди җеп белән чигү, күн мозаикасының үзенчәлекләре турында сораша башладылар.

— Аларның һәркайсы үзенчә эшли. Төсләр гаммасын чигүчеләр тудыра,— дигәч, кызларыбызга ихтирамнары тагы да артты бугай әле. Әзер читекләребезне дә сокланып, яратып карадылар.

Бик кызыксынып, «Токиога да җибәреп булмыйммы аларны»,— дип, сорашып киттеләр. Чын матурлык беркемне дә битараф калдырмый, ахрысы,— дип куйды Мәсгут Хәкимович.— Сүз уңаеннан шунысын да өстим инде: күптән түгел СССРның Японияләге илчелеге аша аларга бернича пар читек җибәрелде. Японияга гастрольләргә барачак Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә дә аяк киемнәрен без тегәчәкне әйттек.

Хәер, бу ансамбль өчен генә дә түгел. Илебездәге йөзләрчә сәнгать коллективлары Арча читеген киеп бии.

## Җырлап чигү чигә кызлар...

Кәгазь битенең башына шулай дип язып куйдым куюын. Әмма сүзне икенче бер вакыйгадан, ерактанрак башлыйсы килә.

...Көз көннәре иде. Басулардан инде иген уңышы җыеп алынган. Каралты-кура тирәләрендә дә җәйге мәшәкатьләр ахырына якынлаша. Әмма әле табигать һаман бирешергә теләми. Әлегә сарылык иңмәгән агачлар җәй көннәрендәгечә назлы һәм бер үк вакытта мәгъруր күренәләр. Җәй матурлыгына көзге муллык, бөтенлек, бәрәкәтле туклык өстәлгән чор. Элек нәкъ менә шундый вакытта авыл җирендә туйлар башлана торган булган. Хәзер инде ул гадәтне бозгалап та куйгалыйбыз.

Ни генә булмасын, авыл җирендә туй иң матур күренешләрнең берсе ул. Менә дәртле гармун тавышы яңгырап уза. Бала-чага йөгерешеп урамга чыга; картраклар кайсы тәрәзә аша, кайсы капка төбеннән аллы-гөлле тасмалар белән бизәлгән машиналарны теләкләр тели-тели озатып кала:

— Бәхетле булыгыз! Әти-әниләрегезгә шатлык китерегез, пар күгәрченнәрдәй тату яшәгез.

Машиналар авыл урамын дәртсендереп узалар да, түбәсендә кызыл әләм җилфердәгән авыл Советы бинасы янына килеп туктыйлар.

— Хуш киләсез, кадерле яшьләр! Төкле аягыгыз белән!

Авыл Советы һәм колхоз җитәкчеләренең яшьләрне котларга, ак бәхетләр теләргә килүендә аларның туган якның киләчәге өчен җаннары-тәннәре белән борчылып яшәүчеләр икәнен аңларга була иде. Ләкин бу турыда сүз чыккач, колхоз председателе минем алсу хыялларымны пыран-заран китереп ташлады.

— Авылда туйлар сирәк була хәзер. Шуңа күрә тансыклап килүем,— диде ул.— Авылның киләчәген кем кулына тапшырачакбыз?!

— Сәбәп нәрсәдә соң? Яшьләрегез шактыи күп күренә бит.

— Күренә генә ул. Кызлар бөтенләй юк. Унны бетерәләр дә, шәһәргә китә торалар. Егетләр, ярый анысы. Тракторда, комбайнда, машинада — барысында да алар. Төпкә җигелеп тарталар. Ә кызларга, дөресен әйтсәк, эш юк авылда. Сезонлы эш бар, ә ел әйләнәсендә бөтен барлыгыңны багышларлыгы юк. Ферманы ике сменага күчерү генә дә ярдәм итә алмый. Күпме генә кеше кирәк анда?!

Колхоз җитәкчесе бәхетле парга, аларны чолгап алган егет-кызларга ымлап, тавышын кимәтә төшебрәк дәвам итте:

— Бу кызлар ял көне туйга дип кайткан кызлар. Кайтып-китеп йөриләр үзе. Ә егетләрне кара... Инде утызга җиткәннәре бар, күбесе өйләнмәгән. Күпме түзәр дисең аларны? Яраткан эш, туган як дип тә тормаслар, кул селтәп, шәһәрдәге кызлар ягына каерылырлар...

Бернечә елдан соң бу сүзләрне, көтмәгәндә, милли аяк киемнәре берләшмәсе директоры Мәсгут Хәкимович Хәкимовтан да ишетергә туры килде.

— Милли аяк киеменең мәгънәви төсмерен бик катлаулы хезмәттән саналучы чигү билгели. Һөнәрчедән зәвык та, тырышлык та, осталык та сорый ул. Дөрес, бу эш — Арча, Биектау якларында буыннан-буынга күчә торган шөгыль. Безнең бөтен таянычыбыз өйдә эшли торган чигүчеләр. Берләшмәдә алты йөз чигүче. Шуның иллесе генә цехта утыра. Калганнары — авылларда. Бу эшкә күп балалы аналар, яки авыр хезмәткә ярамаган хатын-кызлар алына. Алар әле җитми, чигүчеләр азлыгы читек тегүне дә тоткарлый.

«Кызларга эш кирәк, чигү участогы ачарга телибез».— дип, бер колхоздан үтенеч ишетелгәч, биш куллап риза булдык. Чимал бирдек, кешеләр җибәреп өйрәттек. Егерме алты кешелек участок эшли башлады. Бер еллап та вакыт узмаган иде әле. Инде эшләр җайга салынды, заданиене арттырып үтибез икән, дип йөргәндә, бер заман план-экономика бүлеге начальнигы килеп кермәсенме.

— Мәсгут Хәкимович, чигү буенча эшләр тагын өзелергә тора бит әле.— ди бу.

— Ни булган? Тагын ни җитми?..

— Ни булган дип, яңа ачылган участокта эшләүчеләрнең алтмыш проценты декрет ялына чыгарга җыена...

Бер карасаң, мәзәк, икенче карасаң, сөенеч диген кебек инде. Баксаң, авылдагы участокта эшләүче кызларыбыз шул арада кияүгә дә чыгып өлгергәннәр икән. Аларның өлешен башка участокларга, башка чигүчеләргә бүлеп бирергә туры килде...

— Ә колхозның үзендә эшләр ничек бара? Алар берәр нәрсә оттымы соң?

— Отмыймы соң?.. Берәм-берәм калага тая башлаган егетләре барысы да авылда төпләнеп калды. Җир җимерттереп эшлиләр. Кызлары исә җырлый-җырлый чигү чигә. Хәзер районда шул колхоздан да алдынгы хуҗалык юк диярлек.

Туган якның бүгенгесен генә түгел, ә киләчәген күздә тотып яшәүче дистәләрчә колхоз председательләре хәзер авылларда аяк киеме берләшмәсенең кечкенә генә булса да участогын ачтырырга тырыша. Бүгенге көндә, мәсәлән, Арча районының Колачы, Урта Аты, Сәрдә, Әтнә, Субаш Аты, Таш Чишмә, Чиконас, Биектау районының Мүлмә, Өнсә, Дөбъяз, Березка, Ямәшүрмә кебек авылларында егермедән артык участок бар.

Күптән түгел генә Арча берләшмәсенең географиясе тагын да киңәйде — Түбән Кама шәһәрендә чигү участогы эшли башлады. Химия промышленностенда эшләп инде пенсиягә чыккан һәм башка хатын-кызлардан җитмешләп кеше татар халкының гамәли сәнгате серләрен үзләштерде. Ә химиклар һаман алга карап яши. Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсе генераль директоры Сәхапов предприятие янында ук милли аяк киемнәре берләшмәсенең филиалын ачу турында планнар кора.

Милли аяк киемнәре берләшмәсендә җәмгысы мең ике йөз илле кеше исәпләнә. Шуларның яртысына якыны — алты йөз кеше чигүчеләр дигән идек. Хәер, аларның күбесенең өйдә эшләүче икәнен дә онытмаган хәлдә үзебезгә бер сорау биреп карыйк: күбрәк түгелме? Чигү шулай күп көч сорыймы?

Биредә иң әлек чигү сүзенең термин буларак дөреслеккә туры килмәгәнлеген әйтергә тиеш булабыз. Тагын сәнгать белгече Флүрә Гулова китабына мөрәҗәгать итик. «Татар җөенең сере» дигән бүлектә ул болай дип яза.

«...Казан аяк киемнәрен бизәкләүгә килгәндә исә, ул гадәти түгел һәм мәгълүматы булмаган кешеләргә бик күптәннән бирле табышмак булып тора ...Күн читекләр, башмакларны бизәкләүдә аппликациягә дә, чигүгә дә охшаш сыйфатлар табарга мөмкин. Ләкин алар арасында шактый зур аерма бар. Әйтик, аппликация ул — бизәкне өстән салу, ягъни бизәүче элемент нигез булып хезмәт итүче материалга куела. Казан аяк киемнәрендә исә төрле төстәге күннән бизәкләп киселгән өлешләр үзара ялгап тоташтырыла, композиция үзе үк нигезне дә тәшкил итә.

Читек тегү техникасын чигү белән тәңгәл кую тагын да киңрәк таралган ялгыш. Бу хата фикер хәтта милли терминологиягә дә үтеп кергән. Мәсәлән, кайберәүләр аны «чиккән читек» дип атыйлар, ягъни аны чигелгән дип күз алдына китерәләр. Ә халык сәнгате һөнәрен белүчеләр «каюлы читек» ди, чөнки гасырлар буена мозаикалы читек тегүчеләр үзләре үк «читек кайыйбыз» дип сөйләп килгәннәр. «Каю» сүзе исә татар телендә, нигездә, әйберне кырые буенча вак бизәкле җөй салуны аңлата».

Миңа калса, бу термин да бөтен үзенчәлекне ачып бетерми. Биредә бәлки борынгы сүзләрне — чәмчә һәм чәмчәләү дигән сүзләрне искә төшерү урынлы булыр.

Инде берничә еллар дәвамында Татарстан Җирле промышленность министрлыгы хезмәткәрләре РСФСР халык сәнгате промыселларын үстерү идарәсенең фәнни-тикшеренү институты юлын таптый. Теләкләре дә изге кебек: алар читек чәмчәләүне механикалаштыру, кул хезмәтен кимету, берләшмәдә эшләүчеләр санын кыскарту, әйберләрне арзангарак җитештерү өчен тырыша. Өстән караганда, заман таләпләренә җавап бирә кебек тоелган шушы шөгыльнең сәнгать промыселына зыянлы булуын, кысыр хәсрәт икәнлеген аңларга иде! Бу мәсьәлә 1985 елның 30 январенда ук хәл ителгән дә кебек. Институт директорының сәнгать-иҗат эшләре буенча урынбасары П. И. Уткин кул куйган хатта Мәскәү белгечләре тулы һәм ачык җавап биргәннәр: «Татар халкының күнне кулдан чигү кебек һөнәрен механикалаштыру максатка ярашсыз һәм зарарлы, халыкның үзенчәлекле гүзәл сәнгатенә үтергеч тәэсир ясаячак дип саныйбыз.

...Арча берләшмәсендә елына 750 мең пар аяк киеме җитештерелә икән, моны җитәрлек дип саныйбыз, милли аяк киемнәре тегүне механикалаштыру исә аның сәнгати эшләнешенә һәлакәтле йогынты ясар иде.

Милли аяк киемнәре җитештерү өчен В. И. Ленин исемендәге Казан күн берләшмәсе җибәрә торган чималга караганда югары сыйфатлырак күн кирәклеген дә искәртәбез».

Барысы да аңлашыла кебек. Әмма республика Госпланында да, Җирле промышленность министрлыгында да һаман сан артыннан, вал артыннан куу дәвам итә, ә милли аяк киемнәренең сәнгать әсәре булуын аңлау, аны саклап калу өчен борчылу, уйлау икенче планда кала килә. Дөрес, сан артыннан куганда да, аны сыйфат турында кайгырту өрфиясенә төреп бирергә мөмкин икән. Республика Госпланының 1986 ел, 16 майда үткәрелгән киңәшмәсе беркетмәсендәге юлларны башкача аңлап булмый: «Милли аяк киемнәренең сыйфатын күтәрү һәм уникаль сәнгать промыселын саклап калу максатларында Татарстан АССР Җирле промышленность министрлыгына аяк киеме җитештерү күләмен уникенче бишьеллыкта елына 900 мең пар итеп билгеләргә».

1987 елның мае... Арчада Җирле промышленность министрлыгы коллегиясенең күчмә утырышы бара. Берләшмәнең киңәшмәләр залы күргәзмәне хәтерләтә. Өстәлләрдә Арча читекчеләре чыгара торган продукция үрнәкләре, киләчәктә тегеләчәк модельләр. Стеналарда төрле күрсәткечләр язылган рәсемнәр, диаграммалар.

Министр Юрий Иванович Демидов аларга күрсәтә-күрсәтә тармак эшчеләренең хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшырту мәсьәләләренә анализ ясый:

— Кызганычка каршы, республикабыздагы тармак предприятиеләрендә әле һаман да кул хезмәте артык күп кулланыла. Хәзерге вакытта ул 49,4 процент тәшкил итә. Бу — Россия Федерациясендә беренче урын дигән сүз. Начар мәгънәсендә...

Министр тагын плакатларга борыла һәм күрсәткеч таягы белән Арча берләшмәсе саннарын эзли.

— Менә карагыз: министрлыкта иң яхшылардан саналган аяк киемнәре

тегү берләшмәсендә 1986 елда ул 38,2 процент булган, ә 1987 елда исә чигенү кузда тотыла — 38,9.

Юрий Иванович бер мәлгә тынып калды һәм сораулы карашын Мәсгут Хәкимовичка төбәде:

— Моны ничек аңлатырсыз?..

Берләшмә директоры төрле дәрәҗәдәге киңәшмәләрдә, җыелышларда йөз тапкыр әйтелгән фикерен йөз дә беренче тапкыр кабатларга мәҗбүр:

— Безнең эш шундый, чәмчәле читекне бары тик кулдан гына бизәп була.

Министрлык күләмендә алганда да, Арчада кул хезмәте файдалану чагыштырмача күп түгел. 49,4 һәм 38,9 процент! Күн чигүчеләрне, рәссам хезмәтенә тиң эш башкаручыларны тармактагы башка предприятие эшчеләре — металл эшкәртүчеләр, мехчылар, агач эшкәртүчеләр, битумчылар, тегүчеләр белән тиңләү әнә шулай урынсыз дәгъвалар тудыра.

...Арчага килгән саен чигүчеләр янына керәм. Зур якты цех җәйге болынны хәтерләтә. Бөтенесе бердәй сары кыекча яулык бәйләгән кызлар көлешә-көлешә күннән чәчәкләр ясыйлар. Алларында аллы-гөлле җепләр, төсле күн кисәкләре. Матурлык, гүзәллек шушында туа. Халкыбызның бай гамәли сәнгате яңара. Шушы матурлыкка соклану, аны үзең тудыру теләге кызларның күбесенә ана сөте белән кергән.

Бу килүемдә тагын бер яңалыкка тап булдым: куңычындагы бизәкләре сәйлән белән чигелгән читекләр (монысы инде чын чигү) тегә башлаганнар. Гаять матур, затлы бу аяк киемнәрен теләсә-кайсы талымчан, көяз кеше дә яратып алачак. Тары бөртеге чаклы гына сәйләннәрне җепкә тезеп чигү — бик катлаулы, нәзберек эш. Әмма кызларның кулына күз иярми, күнегелгән хәрәкәт белән нәни чәчәкләрне бер-бер артлы күнгә төшерәләр.

— Әбием дә чиккән, әнием дә чиккән, мин дә чигәм. Хәзер инде кызым Гөлназ фабрикага килеп йөри, эшкә өйрәнә,— ди Суфия Гыйләҗиева.— Үзем фабрикада 1964 елдан. Әле дә хәтеремдә: Арчадагы башка өйләрдәге шикелле үк, бездә дә чигә белү бик абруйлы санала иде. Җиденче класста укыганда мәктәптә ниндидер ярыш булды. Шунда үзем чиккән күлмәк белән катнашып, беренче урынны алган идем. Менә шул гомерләрдән бирле чигәбез инде...

— Бик вак эш бит, талчыктырмыймы соң? Авыр түгелме?

— Ю-у-ук! Ул бит белгән кешегә җыр җырлаган кебек.— Аннары тагын өстәп куйды:— Арыткан чаклары да буладыр инде. Бер кеше айга 169 пар аяк киеменә өслек чигәргә тиеш бит. Тик... яраткан эшеңдә арсаң да күңелле генә ич.

— Ә хезмәт хакыгыз ничегрәк?— дип сорадым.

— Болай уртача 140—150 сум чыга. Минем үземнең өч йөзгә кадәр куган чаклар бар...

— Читек чигүне машиналарга тапшыру турындагы сүзләр сезгә дә килеп җиткәндер инде? Быел Мәскәүдән галимнәр һәм белгечләр килеп, чәмчәләүне машинага күчереп буламы, юкмы икәнен өйрәнәчәкләр. Кызларыгыз ничегрәк карый?..

Хезмәтеннән гаеп табу кебек ишетелер, кәефе кырылыр, дип уйлап, бераз шикләнеп тә куйган идем, әмма Суфия Фәтхетдиновнаның йөзе аз гына да үзгәрмәде:

— Бик озак уйландык инде без кызлар белән ул турыда... Барып чыкмый ул. Чигү дисәк тә, бу бит чигү түгел. Аның ысулы бөтенләй башка... Андый машина уйлап тапканчы әле...

Бераз уйланып утырды һәм акрын гына тагын сөйли башлады:

— Кайчандыр, фотография чыккач, рәсем сәнгате бетәчәк дип йөргәннәр бит. Әмма алай булмаган. Фото — бер, рәсем — башка. Безнең чәмчәле читекләргә чигүчеләрнең йөрәк җылысы, иҗат осталыгы салына. Сәнгатьчә эш һәрвакыт авыр, тик аны машинага ышанып тапшыру мөмкин түгел.

## Читекләр һәм читенлекләр

Арча милли аяк киемнәре берләшмәсендәге шактый четерекле һәм хәл ителүе һаман сузыла килүче әчпошыргыч мәсьәләләр куера бара. Аларны ничек җиңеп чыгарга? Татарстан читекләренең элеккеге даныи ничек кире кайтарырга? Бу сораулар халык сәнгате промыселы язмышына битараф

ғулмаган йөзләрчә кешеләрне бердәй борчый. Ил күләмендә бара торган үзгәртеп кору, яңарыш Арча берләшмәсенә дә шифалы йогынтысын ясамый калмас, әлбәттә! Һәрхәлдә, хәзер бу турыда ачыктан-ачык сөйләшү, фикер алышу, проблеманы уртага салып киңәш-табыш итү бара.

Ә мин һаман да үз алдыма яңа сораулар куям: әллә халыкта йомшак чүәк, затлы читекләр белән кызыксыну кимегәнме? Аларны алырга теләүчеләр юкмы?

Әмма берләшмә адресына көн саен диярлек илебезнең төрле якларыннан килеп торучы дистәләрчә хатлар моның киресен сөйли түгелме?

Шушы шик-шөбһәләремне Мәсгут Хәкимович белән дә уртаклашкан идем. Аның җавабы исә мин көткәндәгедән күпкә гади булып чыкты.

— Бөтен хикмәт тә менә шунда инде,— дип башлады ул сүзен.— Кайчандыр, кем тарафыннандыр югарыдан төшерелгән бер күрсәтмә әнә шул йөзләрчә кешеләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерергә ирек бирми. Бер яктан, көн саен читек сораган хатлар алып торабыз, икенче яктан аларга шуны җибәрә алмыйбыз...

— Хикмәт дидегез диюен, әмма монда нинди дә булса хикмәт күренми. Аңлашылып җитмәде...

— Үзебез дә бик үк аңлап бетермибез аны. Безнең берләшмә Җирле промышленность министрлыгына буйсына. Ә яшәп килүче кагыйдәләр буенча, андый предприятие продукциясен бары тик үзе урнашкан өлкә яки республикада гына сатарга хаклы. Халык сәнгате промыселының үзенчәлеген искә алмау, әнә шулай итеп, безне һаман чикләп килә. Юкса, сәнгать белән бернинди уртаклыгы булмаган, өйдә сөйри торган гап-гади башмаклар, яисә кроссовкалар чыгарып ятар идекмени? Берләшмә ел саен ике йөз меңнән алып ярты миллион сумга кадәр үсеш биреп килә. Елына сигез йөз-тугыз йөз мең пар аяк киеме җитештерәбез. Республикабызда халык саны өч миллион ярым, диярлек була. Без бит, әле нигездә, хатын-кызлар өчен генә тегәбез... Һәр хатын-кыз ел саен бер пар читек яисә чүәк ала, дип әйтеп булмый ич. Шулай итеп, безнең затлы мал республика кибетләрендә хәрәкәтсез ята. Берләшмә исә теләсә кайсы фабрика чыгара ала торган әйберләр тегүгә күчә бара.

— Башка өлкәләргә дә җибәрү мәсьәләсе шулай ук хәл ителерлек түгелмени?— Баядан бирле тел очымда әйләнгән сорауны бирдем. Берләшмә директоры авыр сулап куйды һәм, чарасызлыгын белдерергә теләгәндәй, кулын селтәде.

— 1986 елда РСФСР Сәүдә министрлыгының күн аяк киемнәре бүлеге начальнигы Александр Иванович Горылов янында гына да дүрт тапкыр булдык. Үзем генә түгел. Баш бухгалтерны, план-экономика бүлеге башлыгын да алып барган идек. Керәбез, хәлне аңлатабыз, саннар белән анализлап күрсәтәбез... Җаваплары бер: «Карарбыз, уйлашырбыз, әлегә бу төр продукциягә ихтыяҗ өйрәнелмәгән», имеш. Мәсьәлә бер генә адымга да урыныннан кузгалмый.

— Хәзер дә шул ук хәлме?

— Ниһаять, боз кузгалды, дип әйтергә була. 1987 елдан продукциябезне азлап булса да Иваново, Ярославль, Тамбов, Ростов шәһәрләренә җибәрә башладык. Соң булса да уң булсын!.. Хәзер башка якларга озату мәсьәләсе дә хәл ителер дигән өмет уянды.

Әйе, монысы күңелдә шатлык һәм арчалылар өчен сөенү хисе уята торган яңалык. Димәк, Татарстан читекләренең даны бөтен илгә таралачак, халкыбызның борынгы сәнгатенең абруе яңадан күтәреләчәк. Арчада чәмчәле читек тегү яңарыш алачак.

Берләшмә бу яңарышка әзерме соң? Әйдәгез, бераз гына фараз итеп карыйк. Илнең төрле өлкәләреннән, республикаларыннан заказлар ява, ди. Һәммәсе дә зәвык белән эшләнгән, йомшак, затлы нәфис читекләр, халык җырларында җырланган бизәкле башмаклар сорый, ди. 1972 нче елда төзелгән һәм елына нибары өч йөз мең пар аяк киеме җитештерүгә исәпләнгән бинадагы берләшмә ул заказларны үти алырмы? Инде хәзер үк биредә чиктән тыш кысанлык сизелә: предприятие өчләтә нагрузка белән эшли. Шуның өстенә, затлы әйберне шундый ук затлы итеп төрергә дә кирәк. Ә хәзергә Арча чүәкләре һәм читекләре ямьсез, төссез, йомшак катыргы тартмаларга салына. Әгәр алар рәссам кулы белән бизәлсә, яхшы сыйфатлы тартмаларда озатылса, тышлыгына «Татарстан читекләре» дип язылса, Париж һәм Лейпцигларда алтын медаль алган читекләрнең төсле сурәте дә торса — начар бу-

лыр идемени?! Егерме-утыз тиенлек исле сабыннар да алтын бизәкле кәгазьгә төреләә бит. Чын сәнгать әсәре булган аяк киемен сәнгатьчә итеп күрсәтә белү тиеш!

Хәл итәсе мәсьәләләрнең иң мөһиме — чимал. В. И. Ленин исемендәге Казан күн берләшмәсе җибәрә торган чималның кимчелекләре турында алдарак сүз булган иде инде: күн катыланды, буявы тонык, төсләр гаммасы җитәрлек түгел.

Бу турыдагы әңгәмәбез күн берләшмәсенең партия оешмасы секретаре Петр Станиславович Бурдиков бүлмәсендә башланды. Аңа Арча берләшмәсенең илебездә уникаль продукция чыгаручы предприятие икәнен дә, милли аяк киемнәренең республика горурлыгы саналуын да, аларның гади чүәк яки читек кенә түгел, ә чын сәнгать әсәре — халык сәнгате казанышы булуын да, моның өчен бары тик яхшы сыйфатлы күн кирәклеген дә аңлатырга тырыштым. Ашыгыч эшләре күп булуга карамастан, ул сүзләремне бүлдермичә, игътибар белән тыңлады һәм шулай ук җентекләп, бөртекләп аңлата башлады:

— Беләбез... Болар барысы да диярлек мәгълүм нәрсә. Без болай да инде Арчага күннең иң яхшысын җибәрергә тырышабыз. Әмма хәзер берләшмәнең үзенең кыенлыклары шактый.— Петр Станиславович бармакларын бөгә-бөгә санарга кереште.— Аларның объектив һәм субъектив сәбәпләре дә бар. Элегрәк без, мәсәлән, тирене чит илләрдән кайтара идек. Яхшылап эшкәртелгән, ярымфабрикат хәленә китерелгән чимал. Буяулар да шулай ук чит илнеке иде. Чит ил чималына бәйле булу тармакның үсешен тоткарлап килде. Ә хәзер, партия бу практиканы тамырдан үзгәртә башлагач, җиңел промышленность кичерә торган чатаклыклар шәрәләнеп калды һәм бөтен нечкәлекләре белән күз алдына килеп басты. Химия индустриясе җитәрлек күләмдә һәм ачык төстәге буяуларны биреп җиткерә алмый. Алар тонык. Төсләр гаммасы сакланмый. Ит комбинатларыннан, аеруча Казаннан начар сыйфатлы, чистартылмаган тире килә. Тырышканда эшли алырлар иде. Әнә Мари АССРдан килгән чималның сыйфатына тел-теш тидерерлек түгел. Яхшылап юылган, чистартылган, әйбәтләп төрелгән.

Һәм безгә бәйле булмаган тагын бер сәбәп — хуҗалыклардан калын тире килә. Аны ничек кенә эшкәртсәң дә, йомшак күн ясап булмый.

...Бу турыда инде Арчада чагында ук ишеткән идем.

— Колхозлар һәм совхозлар хәзер сыерларны ит комбинатына дүртәр йөз килограммга җиткереп тапшыра. Ни өчен шулай эшләнгәнен аңлыйсыз булыр,— дип сөйләгән иде Мәсгут Хәкимович.— Халыкка ит күп кирәк. Әмма таяк ике башлы булып чыкты. Эре, симез малның тиресе калыная, аннан яхшы күн алам димә...

Сыйфатны яхшыртуга бер дә өмет юк микәнни соң? Шуны сизгәндәй, Петр Станиславович тагын дәвам итте.

— 1988 елның январеннан берләшмәдә дәүләт кабул итүе кертелә. Шуңа әзерлек бара. Һәрхәлдә, начар сыйфатлы күн чыгармаска тырышабыз.

Арчага җибәрелә торган продукцияне берләшмәнең «Кызыл күнче» заводы җитештерә. Күннең ничек эшләнүен, аның нечкәлекләрен үз күзләрем белән күрәсем килде. Шунда юл тоттым. Баш инженер Аслан Магомедович Тлюстангелов журналист килгәнлеген белгәч, артык шатлану билгеләре күрсәтмәсә дә, производство белән үзе таныштырырга булды. Хәер, аны аңлау кыен түгел. Шул көнне генә «Социалистик Татарстан» газетасында (21 май, 1987 ел) күн берләшмәсе һәм, аерым алганда, «Кызыл күнче» заводы турында шактый күләмле тәнкыйть мәкаләсе басылып чыккан иде.

— Иске, карт эшчеләр китә, яшьләр килми. Килсә дә, бездәге шартларны күргәч, кул селтәп китеп бара,— дип башлады сүзен Аслан Магомедович акланырга теләгәндәй.— Җиһазлар бик иске. Хезмәт шартлары ташка үлчим: эссе, юеш. Начар тире килә. Аңардан яхшы күн эшләп буламыни?!

Һәм ул әзер күн өемнәре янына килеп, аларны берәм-берәм яктыга тотып күрсәтә башлады. Кайберләрендә берәр тиен акча зурлыгындагы тишекләр тезелеп киткән. Малларга пулеметтан атканнар, диярсең.

— Менә күрдегезме,— диде Аслан Магомедович,— болары кигәвен тешләгән эзләр.

Күнне өстәлгә салып, сыйпап карый башлагач, башка җитешсезлекләр дә аерым-ачык булып күзгә ташланды.

— Болары көтүче чыбыркысы эзе,— дип дәвам итте ул күннең буеннан

буена сузылган батынкылыкка күрсәтеп.— Монда чуан шикелле нәрсә булганга охшый. Берсен дә беренче сортлы күн дип әйтеп булмый.

Әнә шулай, үзенә-үзе җавап бирә-бирә сөйли ул. Тире чималын эшкәртүнең шушындый нечкәлекләре булыр дип, башыма да китермәгән идем. Хәер, дөньяда бер генә нәрсә дә эзсез калмый дигән тәгъбирне беләм. Әмма кайдадыр болында, эссе көндә көтүченең сыерга чыбыркы белән сугуының яман эзен күн заводында күрермен дип уйламый идем.

Сүз Арча берләшмәсенә күчте.

— Без, нигездә «Спартак» берләшмәсенә йөз тотып эшлибез. Хәзерге вакытта күннең унбер төстәгесен чыгарабыз. Аяк киеме тегү өчен тулысынча җитәрлек,— диде Аслан Магомедович.— Арчалыларга килгәндә, аларның безгә дәгъва белдергәне юк...

1986 елда милли аяк киемнәре берләшмәсеннән җиде мең квадрат дециметр күнгә рекламация килүе турында гына нишләптер искә алмады баш инженер. Инде унбер төс дигәнгә килсәк, тонык буяулы һәм, башлыча, караңгы төсләрдәге ул күннәрнең чәмчәле читекнең төп асыл сыйфатын бозуга илтүен искәрмичә булмый.

Кайчандыр ил күләмендәге социалистик ярышта алдынгы урыннарны яулап килгән Казан күн берләшмәсе авыр көннәр кичерә. Планнар үтәлми, сыйфат начар. Арчалыларның гына түгел, спартаклыларның да күнчеләргә дәгъва белдерүе, һичшиксез, урынлы.

Бу өзеклектән чыгу юлы кайда?

Иң беренче чиратта, әлбәттә, предприятиене техник камилләштерүдә, җитештерүчән яңа җиһазлар куюда, ит комбинатларына таләпчәнлекне арттыруда.

— Горбунов исемендәге Казан авиация берләшмәсе күнне вакуумда киптерә торган җайланма ясый. Ульяновск заводларының берсендә буяу машиналары әзерләнә. Без хәзергә кадәр кулдан буйыйбыз,— дип сөйләгән иде берләшмәнең баш инженеры Лидия Куроедова.— Рязаньда хром заводы төзелә, Минскида һәм Украинада да шундый предприятиеләр сафка бастыру күздә тотыла. Безнең предприятиегә дә реконструкция җиле кагылыр дип көтәбез. Һәрхәлдә шуның беренче чаткылары бар инде.

Халкыбыз горурлыгы — милли аяк киемнәренең элеккеге данын кире кайтару әнә шулай бик күп нәрсәләргә бәйле. Һәркем үз урынында тапшырылган эшне җиренә җиткереп башкарса, үзен көнлекче дип түгел, ә производствоның хуҗасы итеп хис итсә генә яңарышка ирешә алачакбыз. Монысы — бәхәссез.

**P. S.** Язманы әнә шундый өметләр, киләчәктә Арча берләшмәсенең яңарышка юл алуына ышаныч белән тәмамлаган идем. Узган ел азагында предприятиенең РСФСР Җирле промышленность министрлыгының халык сәнгате промыселлары идарәсенә буйсындырылуы да (элек ул киң куллану товарлары идарәсенә карый иде) моңа нигез биргән иде кебек. Ләкин, кем әйтмешли, әкият кенә тиз сөйләнә, ә вакыйгалар бик акрын үсә, һәм кайчагында, бөтенләй көтмәгән юнәлеш ала.

Журналның бу саны басылып яткан көннәрдә Арчадан борчулы хәбәр килде: РСФСР Госпланы 1988 елга берләшмәгә бер миллион йөз сиксән мең пар аяк киеме җитештерү заданиесе җиткергән. Арчалылар берни белән нигезләнмәгән, түшәмнән алып бирелгән саннар алдында калдылар. Шуның өстенә продукцияне чит өлкәләргә һәм республикаларга чыгару бөтенләй туктатыла. Узган ел кузгала башлаган боз яңадан үз урынына утыра. Болар барысы да коллективта борчулы, җитди сөйләшүгә сәбәп була һәм хезмәт коллективы советы карары белән Мәскәүгә яңа делегация юл ала. Россия Федерациясе Министрлар Советында озак сөйләшүләр, аңлатулар, киеренке әңгәмәләрдән соң, ниһаять, планны 980 мең парга «төшерергә» ризалашалар. Озак та үтми, берләшмәне чын халык сәнгате әйберләре җитештерүче үрнәк предприятие итүгә җан атып, тырышып йөргән директор Мәсгут Хәкимовны райком аппаратына алып куялар. Яңа директор Илдус Гайнетдинов та иске проблемалар алдында кала. Күн берләшмәсеннән начар чимал килә, кайчандыр халкыбыз данын еракларга тараткан чәмчәле читекләр тегү кими, кибетләрдә һәм базаларда затсыз башмаклар өеме арта бара. Ә Арчага илебезнең төрле почмакларыннан югары зәвыклы, нәфис һәм сәнгать үрнәге булган читекләр сорап хатлар килү дәвам итә...

## Хөсәен Вәлиәхмәтов

# АЛТЫН УТРАУ БИЗГӘГЕ

Яз көннәре иде. Зеленодольск районы эчке эшләр бүлегенә уртача буйлы, кырык яшьләр чамасындагы ир кеше килеп керде. Ишек янында туктальп тормастан, туп-туры дежурлар утырган тәрәзә янына килде, башын иеп пыяла уентыгына сузылды.

— Тикшерүче Хикмәтов үзендәме?— дип эндәште ул беләгенә кызыл тасма бәйләгән капитанга.

— Үзендә... Ни йомыш иде?

— Сез монда яңа кеше, ахрысы. Башкалар мине яхшы белә. Юлаев мин,— диде ул тирә-ягына карангалап.— Эш бар иде, начальник, керт әле.

Дежурный аңа кызыксынып карап алды һәм, берни аңламаганын белгерткәндәй җилкәсен җыерып куйгач, сөйләшү җайланмасы аша кертергә рөхсәт сорады.

...Тикшерүче Хикмәтовның көр тавышы ишек аркылы ук ишетелеп тора. Кем беләндер телефоннан сөйләшә, ахрысы. Юлаев тавыш тынганны бераз көтеп торды да калын кара тырнагы белән генә йозак тимеренә чиртеп алды һәм ишекне ачып, башын тыкты:

— Рөхсәтме, гражданин начальник?

— Ә-ә, иске таныш,— дип, язган җиреннән башын күтәрде Мансур.— Син һаман кешечә сөйләшергә өйрәнеп җитә алмыйсың, ә...

— Гафу ит, шеф, кәҗүнни йортта алты еллап лаеш шулпасы чөмергәч, тел каткан шул.

— Я, сөйләп җибәр, нинди җилләр ташлады бу тарафларга? Әллә балык шулпасына чакыра килдеңме?

— Күрәм, сезгә барысы да билгеле, начальник. Кыек-мыек сөйләп тормыйм. Дөресен генә әйткәндә, бер-ике тапкыр энекәш белән «Каргалы култыгы»на чыккан идем...

— Бер-ике генә микән? Рөхсәт язуың да бардыр инде, ә?!— Юлаевның салпы ягына салам кыстыргандай итеп сорап куйды тикшерүче.

— Рөхсәт белән, билгеле, начальник...

— Бөтен сулыкларда балык тоту тыелган чордамы? Күрсәтә аласыңмы, кайда ул лицензияң?

— Бар, дип, инспектор телдән рөхсәт иткән иде.

— Кем ул? Исемен, фамилиясен белмисең инде. Шулай бит? Я онытканеыңдыр...

— Белмим, күрсәм — таныйм үзен... Начальник, мин сезгә үз аягым белән килдем лабаса.

— Артыңа су кергәч кенә килергә иткәнсең шул, барыбер эләктерәчәкләрен белеп килгәнсең.

Бу сүзләрдән соң Юлаевның яңагы сулкылдап куйды. Маңгаена бөртек-бөртек тир бәреп чыкты. «Капчыклары тишелде микәнни тегеләрнең? Кайсы капты икән?..» Кисәк кенә килеп төшкән шундый уйлардан тыны кысылды. Шулай да үзен бик тиз кулга алып, аңгәмәне элекке җиңелчә юлга борырга булды.

— Юк ла, начальник, ике тапкыр чыктым — икесендә дә эләктем. Гаебемне таныйм. Шуңа сезгә үзем килдем дә...

— Килмәсәгез, барып алган булыр идек. Я, ярый, монысын истә тотарбыз, тик бер шарт белән. Балык тотарга кем рөхсәт иткәнен һәм моның өчен күпме ришвәт биргәнегезне әйтсәгез...

— Нинди ришвәт, ди инде ул,— дип кабынып китте Юлаев.— Тотканыбыз уртак булыр, дидем. Шул гына.

Тикшерүче аның белән ризалашкандай башын кагып, тагын сорап куйды:

— Кемгә әйттегез инде шулай дип?

— Исеме — Юра бугай. Казаннан булырга тиеш. Фамилиясен белмим. Юлаевның мондый сорау алуларда беренче генә утыруы түгел. Бүген дә

разведкага килгәне сизелеп тора. Хәзергә шушы кадәресе дә җитеп торыр, дип уйлады Хикмәтов. Башкалары ничек сайрар. Алар белән дә сөйләшәсе бар.

— Хәзергә кайтып тор. Мәзәкә авылыннан беркая да чыгып китмәскә! Кирәк булгач чакырырбыз.

Браконьерларның башбаштаклыгы турында эчке эшләр бүлегендә беләләр иде инде. Бигрәк тә балыклар уылдык чәчә торган чорда Кызылъяр, Кырындык, Мәзәкә авылларында, Васильево һәм Зеленодольскида яшәүчеләр, яшеренеп, Иделгә, Зөягә чыгалар. Тын култыкларда, әрәмәле яр буйларында, ерак утрауларда ятьмә, челтәрле ау, сөзгечләр белән кыйммәтле балыкны күпләп тоталар. Хәтта беркайда эшләмичә, балык сатып көн күрүчеләр дә бар. Алары да мәгълүм. Андыйлар көнен дә, төнен дә йокламый. Владимир Юлаев та шундыйларның берсе булса кирәк.

Хикмәтов аның милиция бүлегенә үзе килүе турында кичекмәстән район прокурорына хәбәр итте. Прокурор исә үз чиратында Казан белән дә элемтәгә керде.

— Безнең өчен яңалык түгел бу,— диделәр телефоннан.— Иделдә хәтта җинаятьчел бригадалар йөрүе билгеле. Ләкин эле бүгенгә кадәр кулга төшереп булмый. Иң гаҗәбе — балыкчылык инспекторларының ваемсызлыгы, җинаятькә юл куюы. Ничек дисез әле исемнәрен? Картрагы Юра, яшьрәге — Валера, димәк. Ярый, тикшерербез.

Шулай итеп, тотылмас браконьерларга каршы ике яктан челтәрле ау салына башлады.

* * *

Иртәнге киңәшмә тәмамлангач, Флүр Баһаветдиновны республика прокуроры урынбасары үзенә чакырып кертте. Тикшерү бүлеге начальнигы Фәрит Хәбибуллин да анда иде.

— Балык тотарга яратасыңмы, Флүр?— дип сорап куйды урынбасар, серле генә елмаеп.

Баһаветдинов әле яшь тикшерүчеләрдән булса да, инде берничә шактый чуалчык җинаятьне ачып, үзен хезмәттәшләре арасында танытып өлгергән иде. Кешеләрнең дә кем икәнен аңлый. Прокуратурада озак еллар эшләгән урынбасарның характерына да төшенә башлаган иде инде. Сүзне читләтеп кенә, көлемсерәп кенә башлый икән, көт тә тор, җайлап кына бирәр четерекле эш тоттырып чыгарачак.

— Балык чирттерү — җинаятьләр теркәлгән томнарны актарып утыру түгел инде,— дип, тыйнак кына җавап кайтарды Флүр.— Саф һавада йөреп кайтсаң, ярар иде. Балыгы эләкмәсен дә ди.

— Монда зур балыклар эләгергә тора әле,— дип сүзгә кушылды тикшерү бүлеге начальнигы.

— Кармакны белеп салсаң, ярыйсы гына эләгергә тиеш. Инде берничә хәбәр бар.— Урынбасар өстәлдә яткан кәгазь битләренә ымлап күрсәтте.— Синең кармагың шәплегенә ышанабыз.

Автобустан төшкәндә көн инде кичкә авышып килә иде. Шулай булуга карамастан, тикшерү эшен башларга кирәк.

Прокуратурага милиция бүлегеннән Хикмәтов та чакырылган. Ул Флүрне ни-нәрсә мәгълүм булуы белән таныштырды.

— Ә Юлаев дигәне үзе килдеме милициягә?— диде Флүр, сорау алуны башларга ниятләп.

— Башка чарасы калмагач, нишләсен...

— Ничек алай?

— Әшнәләре кулга алынды аның. Ушанов һәм Крысиннар белән бергәләп Алтын утрауга йөргәннәр.

— Кызык,— диде Флүр.— Ни өчен «Алтын»?

— Кыйммәтле ятмалар юк-югын,— диде Хикмәтов, көлемсерәп.— Ләкин исеме җисеменә туры килерлек. Ярларына алтынсыман ком түшәлгән, үзе ямь-яшел әрәмәлекләр белән капланган. Лаеш турындарак ул. Көймә белән чыксаң, рәхәтләнеп ял итәрлек. Әмма Крысин, Юлаев кебекләргә матурлык ни дә, яшеллек ни. Балык күп үрчи анда. Чөгә белән корбан тарта комсызларны.

— Менә ничек икән,— диде Флүр.— Юлаев кайчанрак килде соң, нәрсәләр сөйләде тагын?

— Кичә килеп керде. Ләкин бик тиз генә чишелә торган түгел ул. Утырды шунда баш әйләндереп. Теләсәгез, менә биографиясе белән танышa аласыз.— Флүр каршына язулар төпләмәсе китереп куйды ул.— Соңгы ун ел эчендә генә дә өч тапкыр хөкем ителде. Гомумән, җиңел кәсеп эзләп йөри торган кеше.

— Болай булгач, сорау алуны да үзеннән башлыйк инде,— диде Флүр, тикшерү кәгазьләренә тиз-тиз генә күз салгалап.— Кертегез монда.

* * *

Эшкә республика прокуратурасы тотынуын абайлап алган Юлаев башкачарак сайрый башлады. Иртәме-соңмы, барыбер казып чыгарырлар, бөтенесен дә беләчәкләр, дип уйлады ахрысы. Флүр дә Юлаевның тактикасын беренче сүзләрдән үк аңлап алды һәм ашыктырмыйча, бирелеп тыңларга кереште.

— ...Башта Иделгә июль-август айларында Крысин һәм Ушанов белән чыккаладык,— дип сөйләп китте Юлаев.— Көннәрдән бер көнне инспектор, фамилиясе Рогов бугай, килеп тотты. Казанныкы ул. Тоткан бөтен балыгыбызны алды да, беркетмә белән яный башлады. Шуннан Крысин читкәрәк китеп, моның белән нидер гәпләште. Беркетмә язылмый калды. Тәҗрибәле картлач ул безнең. Икенче көнне инспектор тагын килде, балыклырак култыкка керергә кушты. Ухага дип, дүрт чүгәне дә алып китте...

— Балыкны нәрсә белән тоттыгыз?

— Башта үзебез яраклаштырган кечкенә ятьмәләр белән инде...

— Ә соңыннан...— дип сүзне үзе теләгән юнәлешкә борды Флүр. Юлаев бераз тын торды һәм, читкә карап, кул селтәп алгач, беткән баш беткән инде дигәндәй, түкми-чәчми белгәннәрен сөйли башлады.

— Крысинның өенә кергән идем бервакыт. Дүрт зур ятьмә эленеп тора. «Рогов китерде,— ди,— дүртебезгә дә булыр. 60 шар сум акча җыеп бирергә кирәк»,— ди. Дүртенчебез — минем энекәш Миша була инде. Без акчаларны җыеп тапшырдык та, көн саен балыкка йөри башладык. Рөхсәт бар дип уйладык инде. Ятьмәләр яхшы, балык шәп эләгә. Көн аралаш җитмеш-сиксән килограмм ала идек.

— Шул кадәр балыкны кая куеп бетерә идегез соң?

— Танышлар аркылы да, яр буенда үзебез дә саткаладык. Бер сум 50 тиеннән, бер сум 70 тиеннән дә җибәрә идек.

— Инспектор белән исәп-хисапны ничек ясый идегез?

— Атна саен ике йөзәр сум биреп бардык.

— Барлыгы ничә тапкыр бирдегез?

— Алты тапкыр бугай, хәтерем ялгышмаса...

— Акчаны кайда һәм кем тапшыра иде?

— Я мин илтә идем, я Крысин... Зөя причалына алып барып тапшыра идек.

— Рогов үзе генә була идеме?

— Юк. Яшьрәк кенә бер иптәше белән килә иде. Фамилиясе Тихонов иде, бугай. Анысы күбрәк читтән карап тора. Катнашы юк кебек кыланырга тырыша иде.

— Шуның өстенә балык та ала идәләрме?

— Ничек кенә але?! Безнең тирәдән әйләнеп узмый калмыйлар. Тоткан саен илле-алтмыш килограмм балык — аларныкы.

«Балык башыннан бозыла, дип юкка әйтмиләр икән,— дип уйлап куйды Флүр.— Алты атнадан санаганда гына да, ике йөзәр сумнан мең дә ике йөз тәңкә җыела. Тагын күпме балык!..»

— Ярар,— диде Флүр,— хакыйкатьне ачарга булышуыгыз, һичшиксез, искә алыныр. Ләкин браконьерлыгыгыз өчен барыбер җавап бирергә туры килер.

* * *

Бу эш белән шактый утырырга туры килде Флүргә. Кем әйтмешли, нәкъ балык каптыру кебек булды ул. Калкавычны сынап та, юри дә селкетеп карадылар, тикшерүне ялган юлдан җибәрү өчен ниләр генә эшләнмәде. Ләкин ничек кенә булмасын, хәлләр көннән-көн ачыклана барды.

Крысинның яшерен бригадасы чүгә һәм корбан балыгы тотудан гына

да дәүләткә биш мең сумлап зыян китергән. Әмма «бригадир» гаебен тулысынча диярлек кире кага. «Балыкка 1—2 тапкыр гына чыктык,— дүрт ятьмәнең барысын да куймадык», янәсе. Балык та алтмыш-җитмеш килограмм түгел, ә егермешәр чамасы гына эләккән. Ришвәтне дә бер генә тапкыр биргәннәр имеш. Тихонов турында исә ул, берни дә белмим, дип бара.

Ләкин башкалар дөреслекне сөйләп биргән иде инде. Ушановның күрсәтмәләре Юлаевныкы белән туры килә. Ул да гаебен таныды. Михаил Юлаевка да дөресен сөйләп бирүдән башка чара калмады. Аларны судка кадәр иректә калдырырга да мөмкин, дип уйлады Флүр. Ә Крысин, Рогов, Тихоновларны кулдан ычкындырырга ярамый.

Крысин, кулга алынган хәлдә дә, тикшерүгә комачаулык итәргә маташып карады. Ул ирекка бер язу кисәге биреп чыгарган: Михаил Юлаев белән Ушановка күрсәтмәләр җибәргән. Ике йөз сум акчаны бер генә тапкыр бирдек, анысын да Рогов дәүләт автомашинасын ремонтлау өчен сорады, ә балыктан берниндi дә керем алмады, дип әйтергә кушкан.

— Соңга калдың шул, гражданин,— дип куйды Флүр, бу хәбәрне ишеткәч. Чөнки әлеге егетләрнең күрсәтмәләре беркетмәгә бәйнә-бәйнә язылган иде инде.

Хәер, машинасын тикшереп карау зыян итмәс. Инспекция машинасын шофер Нефедов чыннан да Ульяновскига ремонтка илткән икән ул вакытта. Рогов та, Тихонов та аңа берниндi акча бирмәгәннәр. Җинаятьчеләрнең һаман җаваплылыктан тайпылырга маташуларын гына күрсәтә иде бу. Ушанов, Юлаев белән йөзгә-йөз очраштырып сорау алгач, Крысин уйдырмалар белән мавыгуның мәгънәсезлегенә тәмам ышанды. Тикшерүчедә бөтен дәлилләр дә бар иде.

Тихонов исә тагын да кызыклырак кәмитләр оештырды. Ул башта Зеленодольскидагы изоляторда иде. Беренче тапкыр сорау алганда үз гаебен таныды. Рогов белән бергә браконьерлардан балык һәм акчалата ришвәт алуын әйтеп язды. Ләкин тора-бара, ашыгыбрак ташладым, дип уйлаган булса кирәк. Икенче тапкыр сорау алырга чакыргач, ул кай арададыр, игътибарсызлыктан файдаланып, үзенең өстәлдә яткан күрсәтмәсен ерткалап, авызына кабып чәйни башлады. Аннан тикшерү һәм эчке эшләр хезмәткәрләренә каршы чынлап торып һөҗүмгә күчте: «Мин гаепсез, мине кыйнап яздырдылар»,— дип кычкырырга керешге.

— Андый дәгъвагыз булгач, сезне врачларга күрсәтеп карарбыз,— диде Флүр.

Әмма врачлар берниндi дә кыйнау, җәрәхәт эзе булмавын билгеләделәр.

— Мондый кәмитләрегез сезгә берниндi җиңеллек тә китермәячәк бит,— диде Флүр.— Киресенчә, башта гаебегезне танып, дөрес эшләгән идегез. Болайга киткәч, телисезме, барлык кылган җинаятьләрегезне сөйләп бирәм?!

— Тырышып кара, гражданин тикшерүче,— диде Тихонов зәһәр генә көлемсерәп.

— Әйдә алайса, 1979 елдан башлыйк. Апрель ахырында Алтын утрауда Чувашиядән килгән кешеләргә йөз егерме килограмм корбан балыгы сатып җибәрәсез. Кем аша саттырганыгызны әйтергәме? Рәхим итегез: Лаеш балык заводындагы Пахомов аша. Пахомов китергән 240 сум акча сезнең кесәгә кереп утыра.

Инде май аена күчик, Гаврилково авылы янында сез шул ук Пахомовка беркетмә тутырасыз. Ләкин ул сезгә йөз сум ришвәт бирә. Ә бу беркетмәне таныйсызмы?

— Таныйм,— диярга мәҗбүр булды Тихонов. Чөнки тикшерүче сөйләгәннәр барысы да шаһитлар күрсәтмәсе белән расланган иде.

— Я, тагын дәвам итәргәме?— дип сорады Флүр.— Сезнең эш урыныннан явыз ният белән файдалану гына түгел, әле властьны арттырып җибәрү очраклары да булган.

— Монысы ялган!— дип кычкырып җибәрде Тихонов.

— Мәсәлән, 25 апрельдә сез Гаврилов һәм бертуган Вавиловларны тоткансыз, көймә моторын салдырырга кушкансыз. Валерий Вавилов моторга кагылмауны сорый. Ә сез аның башына пистолет белән сугып, салкын суга төртеп төшергәнсез. Браконьермы-түгелме икәнен ачыкламас борын, шундый ук ысул белән Бусоровка да җәрәхәтләр ясыйсыз.

— Шунсыз җиңеп булмый аларны,— диде Тихонов.— Әле дөмектерерлек итеп сугасы калган.

— Әйе, катырагын да суккансың син, Тихонов. 1982 елның маенда браконьер Ерошин белән Чекушинны тоттыгызмы?

— Хәтерләмим...

— Шаһитларның күрсәтмәләре менә монда,— диде Флүр өстәлдәге папкага кулын куеп.— Ул чагында да диңгез пираты кебек һөҗүм итәсез, пистолет белән икесенең дә башларына сугасыз, Ерошинның яңак сөяген ике җирдән сындырасыз. Ул больницада ятарга мәҗбүр булган. Мондый алымнарны кулланырга ярамаганын яхшы беләсез бит.

— Әгәр мин аларны аткан булсам?..

— Корал сезгә соңгы чиктә саклану өчен бирелә. Сугу өчен дә, куркыту өчен дә түгел.

— Әйе, браконьерларга каршы аяусыз булдым. Бөтен Иделне, Зәяне ятьмәләр, сөзгечләр белән тутырдылар бит кабахәтләр.

— Кызганычка каршы, браконьерларның азынуына сез дә гаепле. Алар белән тиешенчә көрәшәсе урынга, бөтен сулыкларны шәхси биләмәгә, браконьерларны батракларыгызга әйләндергәнсез. Халык байлыгын, дәүләт байлыгын бергәләп талагансыз. Сез тараткан комсызлык бизгәге бу.

Тикшерученең басынкы һәм йөрәккә төшәрлек итеп әйткән сүзләреннән соң Тихоновның башы түбән иелде, яңаклары тимгел-тимгел булып кызарып чыкты. Ул бер сүз дә дәшмәде. Беравык шулай утыргач, теш арасыннан гына зәһәр сүзләрен ысылдады:

— Тиш-ш-шек капчыклар, кабахәтләр!

* * *

Республика прокуроры урынбасары бүлмәсендә шаярып кына башланган сөйләшү әнә шундый тирәнлекләргә алып төште. Флүр кабул итеп алганнан соң, тикшерү эшләре дүрт ай барды. Шул дүрт ай эчендә дүрт ел буена эшләнгән җинаятьләр тулысынча фаш ителде. Нәтиҗәдә җиде кешенең гаепле булуы беленде.

Тикшерү барышындагы тентү вакытында Тихоновның өеннән җиде саклык кенәгәсе табылды, аның 7477 сум акчасы һәм 12195 сумлык мөлкәте сак астына алынды. Җинаятьчел группа членнары Рогов һәм Крысиннарның хәрәм юл белән табылган меңнәрчә сумлык мөлкәтенә дә сак мөһере суктылар.

...Тугыз томлык эшне читкә куеп, Флүр гаепләү сүзен язып бетерде. Аннан төрле белешмәләрне, гаепләнүчеләр, шаһитлар исемлеген күтәреп, прокурор бүлмәсенә юнәлде: эшне раслатып, судка җибәрергә кирәк иде.

Прокурор да, аның урынбасары да, тикшерү бүлеге начальнигы да Флүрнең эшне үз вакытында һәм белеп башкаруыннан канәгать иделәр.

Татарстан Верховный Суды халык байлыгына кул сузучылар белән тиешле исәп-хисапны ясады, җинаятьчеләрне озак вакытка ирекләреннән мәхрүм итү турында карар чыгарды.

* * *

Бу язманы әзерләгәндә миңа күл һәм елга балык хуҗалыгы фәнни-тикшеренү дәүләт институтының Татарстан бүлегендә, балык запасын арттыру һәм саклау инспекциясендә булырга туры килде. Шактый гыйбрәтле саннар ишеттем. Соңгы биш елда республикабызда сулыкларга төрле агулы химик матдәләр түгәргә сәләтле предприятиеләр саны 856 дан 1010 га җиткән.

Агропромышленность оешмалары китергән зыян аеруча зур. 1986 елда, мәсәлән, Тукай районының Сосновый Бор дуңгызчылык комплексы Минзәлә елгасына пычрак калдыкларны түгеп балык запасына 147 мең 480 сумлык зыян китерә. Казан чистарту корылмаларының 1982 елда Иделне пычратуыннан килгән зарар 320 мең сум тәшкил итә. «Казан» кошчылык фабрикасының Зөя елгасына коңы тизәге агызып, сулыкларга ун меңнәрчә сумлык зыян китерүе турында да күпләр ишеткәндер.

Республикабыз сулыклары алты районга бүленгән. Аларны тикшерү 48 инспекторга йөкләнгән. Ә балыкчылары күпме соң? Балыкчылар җәмгыятендә член булып торучылары гына да биш меңнән артып китә. Браконьерларга килгәндә исә, аларны исәпләп бетерү мөмкин дә түгелдер. Хәер,

кайбер саннар мәгълүм: 1986 елның беренче яртысында балык тоту кагыйдәләрен бозучылар саны 2025 булса, 1987 елның шул ук чорында 2236 га җиткән. Аларга салынган штрафлар суммасы гына да 51 мең 520 сум тәшкил итә.

Әйе, тотылганына тиешле җәза бирелә анысы. Ләкин үтерелгән балыкны яңадан терелтеп булмый. Корбан балыгына, мәсәлән, нәсел калдырыр дәрәҗәгә җиткәнче 6—9 ел чамасы вакыт кирәк. Бу чорда ул нибары 600 грамм авырлыкта була. Чөгә 3—7 елдан, сыла 4—7 елдан гына уылдык чәчәр дәрәҗәгә үсеп җитә. Җитлеккән сыла бер ярым килограмм тартса, чөгә өчен бу авырлыкны җыярга 10 еллап вакыт кирәк. Менә шуның өчен дә аны тоту бөтенләй тыелган. Ятьмәгә очраклы эләккәндә дә балыкчылар аны кире җибәрергә тиеш. Теләсә нинди зурлыктагы чөгәнең бәясен 20 сумга күтәрү дә юкка түгел. Фән бу төр балыкларның динозаврлар заманданы булуын исбат итте. Борынгы бабаларыбыз да аларны чамалап кына, кирәк кадәресен генә тоткан, димәк. Без дә аның киләчәк буыннарга барып җитүе турында кайгыртырга тиешбез.

Шуның өстенә, чөгә теләсә кайда үрчи дә алмый. Ул Алтын утрау кебек чиста комлы, агымсу урыннарны ярата. «Ә андый урыннар Зөя һәм Мишәнең Иделгә кушылган урыннарында гына калды»,— ди балыкчылык инспекциясенең баш ихтиологы Валерий Неизвестный, әчке бер уфтану белән.

Ләкин браконьер «киләчәк буын, халык байлыгы, сакчыллык» дигән төшенчәләрне башына да китерми. Әле күптән түгел генә инспекторлар Казан мәктәпләренең берсендә производствога өйрәтү мастеры булып эшләүче М. Гыйматдиновны «эләктерделәр». Ул ятьмә белән 81 чөгә балыгы тоткан. Республика клиник больницасы инженеры В. Евдокимовның да нәфесен тыярга туры килде. Шәхси машинасына утырып Мишә буена йөрергә яраткан бу кеше ятьмә һәм ау белән бер чыгуда гына 285 данә корбан, 12 сыла, 2 чуртан, 7 сазан балыгының башына җиткән. Инспекторлар күрсәткән исемлектә Чаллы, Түбән Кама һәм Алабуга шәһәрләреннән А. Ламко, Г. Васильев, Н. Кузнецов, Ю. Пьянков кебек браконьерларның да фамилияләре теркәлгән иде. Алар барысы да шартлы рәвештә икешәр елга хөкем ителгән. Исемлек шулар белән тәгәлләнсә бер хәл иде. Ләкин җәен дә, кышын да су буеннан кайтып кермәүче меңнәрчә Крысиннар, Юлаевлар бар, аларның кара эшләрен хуплап торган Тихоновлар юк түгел. Һәркем тарафыннан изге, кагылгысыз саналырга тиешле табигать йөзенә пычрак түгүдән тартынмаган җитәкчеләр дә очрый.

Элегрәк Иделдә мәрсин, кырпы кебек эре балыклар да бар иде. Моннан берничә ел элек Кама Тамагында ике йөз килограммнан артык авырлыктагы кырпы балыгы тоттылар. Галимнәр аның көтелмәгән «визиты»на таң калды. Чөнки ул безнең якларда күптән беткән санала иде. Кырпы үзенең табигате буенча төче сулы елгадан тозлы диңгезгә чыгып, ерак араларны урап йөри торган балык. Ләкин хәзер андый мөмкинлекләр юк. Иделдә күпме плотина, шлюз төзелде. Шулай итеп кырпы бездән мәңгегә китте дияргә мөмкин. Татарстан Дәүләт музеенда гына аның шытырдап кипкән һәм ялтырап торган олы карачкысы сакланып калды. Комсызлык бизгәген вакытында дәваламасак, киләчәктә чөгә белән сыланы да музейларда гына очратуыбыз мөмкин.

Ә тотылган кырпы балыгына килгәндә, ул мөгаен, куркыныч шлюзлар аша үтеп, тәмле сулы туган Иделенә кайткан булгандыр. Кошлар да бит туган-үскән якларын сагынып, меңнәрчә чакрымнардан очып кайта.

Урманнан рөхсәтсез киселгән бер төп агач, браконьер яки төрле химия ташландыклары һәлак иткән һәрбер балык, һәр кош-корт, җанвар өчен төн йокыларын югалтып, янып-көеп йөрүче әчкерсез җаннар кирәк безгә. Мөмкин кадәр күбрәк кирәк.



**Г. Х. Хафизов,**

КПССның Яңа Чишмә райкомы
беренче секретаре

# ЯҢАРЫШ АДЫМНАРЫ

Бүгенге көннәребезгә хас булган үзгәртеп корулар безнең Яңа Чишмә районы өчен аеруча зарур иде. Чөнки заманында безнең район, «эрелəтү шаукымы»на эләгеп, «кыскартылган» иде һәм әле 1983 елда гына, Чистай районыннан аерылып чыгып, мөстәкыйль рәвештә яши башлады.

Яңа Чишмә — аграр район. Хезмәт ияләребез төп игътибарны Азык-төлек программасын тормышка ашыруга, авыл хуҗалыгы продуктларын күпләп җитештерүгә юнәлтә. Бу — безнең борынгы ата-бабалардан калган шөгыль. Шул хезмәт халыкны бергә туплаган.

Районның борынгы тарихы Болгар дәүләте чорларына барып тоташа. XVII гасыр башында исә бу якларга руслар килеп урнаша башлый. Бу төбәктә үзенең ныклы таянычын булдыру өчен Рус хөкүмәте Чишмә елгасының уң ягындагы тау башына кальга салдыра. Хәрби поселениеләр, яңа бистәләр барлыкка килә. Бу төбәккә күпләп-күпләп хәрби әсирләр, карт гвардиячеләр китереп урнаштырыла. Тора-бара биредә хәрби көч тотуның әһәмияте калмый, хәрбиләргә үз көннәрен үзләренчә күрергә тәкъдим итәләр. Биредә яшәп калучылар Екатерина II (1762—1796) хакимлек иткән елларда дәүләт крестьяннары разрядына күчерелә. Ләкин моның белән халык килешми, чөнки алар хөкүмәтнең моңарчы күрсәтеп килгән ярдәменнән мәхрүм ителәләр. Халык урман кисеп, агач төпләп чәчүлек җир әзерләргә мәҗбүр була, игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә башлый. Төбәктәге Кичү һәм Чишмә елгалары буенда су тегермәннәре салына.

Революциягә кадәр бу төбәктә яшәгән крестьяннарның күбесендә ниблары бер ат була. Әмма яхшы җирләрне, терлек-туарны, эш коралларын үз кулларына төшереп алган байлар, сәүдәгәрләр, поплар (Яңа Чишмәнең үзендә генә дә ике чиркәү булган) комсызлыклары, кансызлыклары белән ярлы крестьяннарның үзәгенә үтә. Шуңа да халык Бөек Октябрь социалистик революциясен бик шатланып каршы ала.

Совет властен урнаштыруда актив көрәшче коммунист Степан Прокофьевич Буреевны билгеләп үтәсе килә, ул 1918 елда беренче авыл Советы председателе итеп сайлана. Аның янәшәсендә фикердәшләре коммунистлар: М. Лихачев, М. Швеев, П. Рузанов һ. б. атлый. Алар аерым хуҗалыкларны күмәкләштерүгә хәзерлиләр. Район үзәгендәге беренче «Трудовик» колхозы 30 крестьян хуҗалыгын берләштерә. Тиздән колхоз зурая һәм Блюхер исемен йөртә башлый. Аны егерме биш менче Тихонов җитәкли.

Утызынчы еллар башында Яңа Чишмә, Зирекле, Ямаш волостьлары берләшеп, Яңа Чишмә районы төзелә. ВКП(б) райкомының беренче секретаре итеп Ванифатьев сайлана.

1930 елда районда биш колхоз оешкан була инде. 1933 елда МТС оеша, колхозларга «Фордзон» тракторлары кайта. 1934 елда МТСта тәгәрмәчле 24 трактор, 36 «Коммунар» комбайны һәм йөк машиналары туплана.

Бу чорда район үзәгендә зур төзелеш башлана: ике катлы культура йорты, китапхана, райком, райисполком биналары, мәктәп салына. 1933 елда төзелгән электр станциясе яңа төзелешне һәм берничә урамдагы йортларны яктылык белән тәэмин итеп тора. 1935 елда инде бөтен Яңа Чишмә радио челтәре белән урала. 1937 елда районга СССР Верховный Советының беренче чакырылыш депутаты, төньяк котыпны тикшерүче атаклы галим О. Ю. Шмидт килә. Матур кояшлы көндә Яңа Чишмә районының бөтен халкы район үзәгенә җыела, алар Отто Юльевичның чыгышын дулкынланып тыңлыйлар. Аның хөрмәтенә клубта концерт куела.

1941—1945 елларда районның кулына корал алырдай һәр кешесе Совет властен якларга, илне немец фашистлары тырнагыннан коткарырга күтәрелә. Яңа Чишмә авылының

үзеннән генә дә сугышка 560 кеше китеп, шуларның 286 сы батырларча һәлак була, 400 ләбе орден, медальләр белән бүләкләнә. Районыбызда ике Советлар Союзы Герое бар: Федор Петрович Савельев һәм Чекин Борис Сергеевич.

Сугыш үзенең канлы эзләрен тормышның һәр тармагында калдыра: район хуҗалыгын яңабаштан торгызырга кирәк була. Игенчелектә, терлекчелектә техника белән идарә итүчеләр өчен махсус курслар оештырыла. Электр акренләп колхозчы йортларыннан игенчелек, терлекчелек тармакларына да, ремонт мастерскойларына да хезмәт итә, көнкүреш нокталарына да керә башлый. Моның өчен Яңа Чишмәдә әллә ни зур булмаган бер подстанция төзелә. Яңа Чишмәне тулысынча электрлаштыру производство һәм көнкүреш культурасын күтәрергә, авылларның социаль йөзен үзгәртергә мөмкинлек бирә.

1963 елдан 1983 елгача, Чистай районына кушылу нәтиҗәсендә, безнең төбәк авылларына тиешле игътибар җитми. Хәзер безгә җиң сызганып эшләргә кирәк.

Районыбыз мәйданы — 1320 кв. км, халкы — 14200 кеше, 9 колхозы, 8 совхозы һәм 13 авыл Советы бар, руслар, татарлар, чувашлар яши.

Районның яңадан төзелгән беренче көннәре бик авыр булды. Кая барып төртелсәң дә кадрлар җитми. Оешмаларны урнаштырырга биналар юк. Кечкенә генә өйләрдә ике-өч оешма эшләгән вакытлар бар иде. Кайберәүләр вагоннарда яшәде. Яңгырлар явып үтсә, район үзәге урамнарыннан үзар чама калмый иде. Романтика эзләп килгән яшьләр, авырлыкларга түзә алмыйча, китеп тә баргаладылар. Игенчелектә дә, терлекчелектә дә күңелне сөендерерлек хәл юк. Һәр тарафта хуҗасызлык, игътибар җитмәү сизелә иде.

Иң әүвәл төзелешкә тотындык. 9 төзү базасы булдырылды. Торак йортлар, сәүдә, төрле оешма объектлары сала башладык. Аларны табигый газ, җылылык һәм су белән тәэмин иттек.

Районда табигый газдан файдалану арта бара. Шахмай, Чаллы Башы авылларында һәм район үзәгендә аны киң куллана башладылар. «Татнефть» берләшмәсе ярдәмендә юлларга асфальт җәелә, хәзерге көндә районыбыздагы юлларның йөзләп километрына асфальт җәелгән. Җиде күпер салынды. Район үзәген һәм авылларны төзекләндерүгә зур игътибар бирелә.

Күп авылларда профилакторийлар ачылды, культура йортлары, балалар бакчалары, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү пунктлары эшли башлады, медицина, культура, сәүдә юлга салынды. Безнең районда хуҗалык үзәгеннән читтә урнашкан кечкенә авыллар да байтак. Аларның таралуына юл куймаска тырышабыз. КПССның район комитеты, район Советы башкарма комитеты вәкилләре, район активы, хуҗалык җитәкчеләре белән берлектә, кечкенә авылларда яшәүче халык белән очрашып тора, урыннарда халыкны борчыган сорауларны өйрәнә, аларны хәл итү юлларын билгели.

Районның яңадан терәкләнеп китүен, тормышның яхшыра баруын күреп, районга кире кайтучылар да, килеп урнашучылар да күренә башлады. Хуҗалык җитәкчеләре авылларда үз хезмәтчәннәре өчен йортлар салуга, өйләргә газ, су кертүгә зур игътибар бирәләр. Зур авыл мәктәпләрендә өч класска тугыз бала укып йөргән вакытлар артта кала бара. Хәзер районыбыз мәктәпләрендә ике меңнән артык бала белем ала. Район төзелгәннән алып туучылар саны да мең ярымга якынлаша! Димәк, районның киләчәге бар дигән сүз.

Моннан дүрт ел элек район больницасында биш кенә врач эшләсә, хәзер алар дистәдән артып китте. Укытучыларыбыз да ишәя. Без яхшы аңлыйбыз: район язмышы — яшь белгечләр кулында. Нигездә колхоз, совхозларны, оешмаларны, берләшмәләрне яшь белгечләр җитәкли. Уртача 35 яшьтәге җитәкчеләр иң авыр, катлаулы участокларда эш алып баралар. Алар арасында «Татарстан» колхозы председателе Рәшит Габдуллаҗанович Лотфуллин, XX партсъезд исемендәге колхоз председателе Анатолий Михайлович Холин, «Советская Татария» газетасы исемендәге колхоз председателе Дилшат Кәшфиевич Әшрәпов, М. Горький исемендәге колхоз председателе Евгений Александрович Белоглазов, «Алга» колхозы председателе Рифкат Назыймович Садретдинов җитәкләгән хуҗалыкларда эшләр уңайга бара.

Проблемалар күп, бигрәк тә эшче куллар җитешмәү һәр нәрсәдә үзен сиздерә. Бу мәсьәләне чишү юлларын үзебезчә хәл итәбез. Беренче чиратта, хуҗалыклар мәктәпләр белән элемтәгә керде, игътибарны хезмәт тәрбиясенә юнәлттеләр, әле яңа гына ачылган 118 нче СПТУ яшь механизаторлар хәзерли.

Соңгы ике елда гына да районны социаль үзгәртеп кору буенча зур эш үткәрелде, шушы чор эчендә 27 миллион сумнан артык капитал салу үзләштерелде. 28 мең квадрат метр торак йорт файдалануга тапшырылды, 230 урынлы ике балалар бакчасы, 300 урынлы мәктәп, ике культура йорты салынды, хуҗалыкларның үзәк усадьбаларына автобуслар йөри башлады. Хәзер район үзәгендә больница комплексы, аптека, балалар комбинаты, культура йорты, телефон станциясе, административ биналар, торак йортлар төзелә. Санап китсәң, эшләнгәне байтак. Әмма алда әле күп эшләр көтә. Боларның барысын да без яхшы

беләбез һәм аларны хәл итүдә төпле чаралар күрәбез.

Безнең төп бурыч — авыл хуҗалыгы тулай продукциясен уртача еллык җитештерүне 14—16 процентка арттыру. Игенчеләрнең фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә бу тармакта инде хәзер үк алга китешләр бар. Районыбыз тигез җирдә урнашкан. Җирләребез кара туфраклы. Әмма әче туфрак өстенлек алып тора. Бәхеткә, җиребез известь ятмаларына да бай икән, моны әлегә кадәр куллнучы гына булмаган. Район яңадан оешкач, республика агропромы ярдәмендә известь карьеры төзелеп, әйбәт кенә эшли башлады. 1987 елда 70 мең тонна известь әзерләнде, 9 мең гектар җиребез известьләнде.

Район яңадан оешкан 1983 елны 87,3 мең тонна ашлык җыеп алсак, 1986 елда ул 104,63 мең тоннага җитте. Белгәнебезчә, җирләрнең уңдырышын күтәрүдә интенсивлаштыру зур роль уйный. Без менә шуңа йөз тотабыз да инде. Хезмәтне оештыруда прогрессив алымнардан файдаланырга тырышабыз. Бригада подряды, гаилә подряды белән эшләү үзен аклый. Суган, бәрәңге, чөгендер үстерүдә без шул ысулларга таянабыз. Яңа алымнарның үз кыенлыклары бар. Бригада подряды тәртибенә күчүдә дә тайпылышлар булгалый. Менә шунда инде игенченең ышанычлы кими башлый. Без моңа юл куймаска тиешбез.

Районыбызда хезмәт сөючән халык яши. Алар арасында Октябрь Революциясе ордены кавалеры «Кичү» колхозы механизаторы Минзакир Сибгатуллин, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалерлары Калинин исемендәге колхоз тракторчысы Габдрахман Гыймадиев, «Маяк» колхозы механизаторы Вагыйз Сәлахов, Халыклар дуслыгы ордены кавалеры «Закамский» совхозы механизаторы Константин Лапшин кебек дисталаган фидакарьләр бар.

Алтын куллы игенчеләребез белән бергә уңган терлекчеләребез дә районның мактанычы булып тора. Менә алар: Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры коммунист Надежда Иголкина, дүртменле чикне узып китүче савымчы Клавдия Малышева, аның янәшәсендә — Александра Логинова, терлек симертүдә В. Сыров, Л. Ведякин, М. Малакаева, Е. Разживина, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры С. Банцеров иптәшләр күпләргә үрнәк хезмәт күрсәтә. «Алга», М. Горький исемендәге, XX партсъезд исемендәге, «Татарстан» колхозлары, «Иванаевский» совхозы терлекчеләре аеруча тырышып эшлиләр. Алар Бөек Октябрьнең 70 еллыгына терлекчелек продукцияләрен җитештерү буенча икееллык планнарын үтәделәр.

Әлбәттә, бу нәтиҗәләр безне тулысынча канәгатьләндерми әле. Эшлисе эшләр күп: кадрларның осталыгын арттыру, коллектив, гаилә подрядларын күбрәк куллану, аренда подрядын, эштә ике смена кертү, хуҗалык исәбе һәм хезмәткә тулай керемнән чыгып түләүгә күчеп бетү. Игенчелектә интенсив технологияне үзләштерү, органик һәм минераль ашламаларны тиешенчә куллану, урып-җыю вакытында нигезләнмәгән югалтуларга юл куймау, техник әзерлек һәм башкалар, һәм башкалар.

Район кешеләре арасында халыкка аң-белем бирү, аның культурасын үстерү юлында зур фидакарьлек күрсәтүчеләр дә күп. Арадан мәгариф өлкәсендә илле еллап хезмәт иткән Ленин орденлы укытучы Камил Рәхмәтуллинны (Шахмай авылы) аерып искә алырга мөмкин. Хәзер Мәскәүдә яшәүче юридик фәннәр докторы, профессор, детектив әсәрләре белән популярлык казанган Зөфәр Фәтхетдинов та — безнең Чаллы Башы авылыныкы.

Уңган кешеләребез ничек ял итә соң? Бу өлкәдә без әлегә бераз аксыйбыз. Районның озак еллар мөстәкыйльлеген югалтып, игътибардан читтә кала килүе үзен бу тармакта аеруча нык сиздерә. Район культура бүлегенә дә, спорт комитетына да, ДОСААФка да бу юнәлештә нык тырышасы бар. Куанычыбыз шул: район халкының матур гадәтләре күп. Культура эшлеклеләренә, нигездә, шул байлыктан файдаланырга, халыктагы күркәм йолаларны тагын да баетырга, заман рухы белән тулыландырырга туры килә. Көнкүрешебездә киң урын ала баручы йолалардан кышны озату, кышкы сабантуй, никах һәм туган көн бәйрәмнәрен тантаналы үткәрүләрне санарга мөмкин. Егетләрне Совет Армиясе сафларына озату, «Өч буын вәкилләренең очрашуы»н оештыру, үзара ярышучы хуҗалыкларның иҗат отчетлары, халык һөнәре конкурслары, хезмәт алдынгыларына багышланган кичәләр уздыру гадәткә кереп бара.

Күргәнегезчә, без әле күбесен яңадан башлап кына килəбез. Шуңлыктан, яңалыкка, үзгәртеп коруларга, тизләнешкә өметләребез аеруча зур.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Газинур Моратов

# АТОМКАЛА ЭСКИЗЛАРЫ

Татарстан атом электр станциясен төзү идарәсенең партия оешмасы секретаре Рифкать Кәтиевның кәефе күтәренке иде. Җитәкче кешенең кәефле чагына туры килү, кем әйтмешли, үзе ярты бәхет инде ул.

Сынаганым бар: эшләре көйле барган җитәкчеләр, гадәттә, аз сүзле булалар, башкарылган эшләре турында артык җәелеп сөйләргә яратмыйлар. Рифкать Кәшифович та сүзгә шактый саран кеше булып чыкты. Ул миннән төзелеш турында конкрет сораулар көтә, ә мин сүзне нидән башларга белми торам. Ңишләмәк кирәк. АЭС күргән малайлармыни без!

Рифкать Кәшифович минем бу халәтемне аңлады булса кирәк, сәгатенә күз төшереп алды һәм үзе үк «ярдәм кулы» сузды. «Әйдәгез, киңәшмәгә чаклы, реакторны күреп кайтыйк,— диде ул урыныннан кубып.— Безнең иң гаярь егетләр бүген шунда эшли...»

Атом станциясе Кама Аланыннан җиде-сигез чакрым читтәрәк төзелә. Төзелеш дүрт йөз гектар чамасы мәйданны били. Беренче карашка, аның иге-чиге юктыр кебек тоела. Сәер хәл: АЭСка якынайган саен күңелне тынгысызлык били бара. Әйтерсең, янәшәдә генә бар куәтенә реактор эшләп утыра. Ни бу? Чернобыль авариясеннән соң ел ярым вакыт эчендә барлыкка килгән шартлы рефлекс галәмәтеме әллә? Мөгаен, шулайдыр, кеше җаны беркайчан да хәвефкә күнегә алмый... Бәйдән ычкынган атом һәр очракта да һәлакәткә әверелә...

— Беренче энергоблок 1990 елда ток бирә башларга тиеш, дип куйды Рифкать Кәшифович уйларымны сизгәндәй.— Күрәсез, вакыт ашыктыра. Ә безгә, киресенчә, кабаланырга ярамый.

Партия оешмасы секретаре хаклы: төзелеш оешмаларында ныклап формалашкан бик күп стереотиплар АЭС өчен бөтенләй яраксыз, хәтта куркыныч. Мисалга план үтәлешен генә алыйк. «Фәлән объект вакытыннан алда файдалануга тапшырылды» кебек рапортларга без күнеккән идек инде. Ул тапшырылган объектларның соңыннан озак-озак вакытка ремонтка тукталуы да сер түгел иде. Сүз дә юк, дәүләт планнарының үз вакытында үтәлүе зарур. План үтәмәгән өчен бер җирдә дә баштан сыйпамыйлар. Димәк, АЭСта да һичнинди ташлама була алмый. Ләкин урынлы сорау туа: әгәр дә материаллар белән тәэмин итүдә өзеклекләргә юл куелса, төзүчеләр нишләргә тиеш? Кызганычка каршы, беренче энергоблокны корганда мондый хәлләрдә дә еш калырга туры килгән. Бетон булмау сәбәпле, кайвакыт көннәр, атналар буе эшсез утырганнар. Утырмаслар иде, үзләрендә бетон заводы юк. Аны машинага төяп Яр Чаллы каласыннан ташыганнар. Өстәвенә, бетон үтә дә нәзберек нәрсә. Ике сәгать ачык һавада торганнан соң, аның байтак үзлекләре югала. Дөрес, КамАЗдан Кама Аланына кадәр килер өчен бер сәгатьләп кенә вакыт кирәк. Әйтүләренә караганда, ул арада гына бетонның сыйфатына бернинди дә зыян килми икән.

Әмма атом реакторы өчен фәкать «мичтән төшкән», иң югары сыйфатлы бетон гына таләп ителә! Димәк, заводны АЭСның үзендә төзергә кирәк. Һәм шулай эшлиләр дә. Реактор белән янәшәдә генә бетон заводы үсеп чыга. Ниһаять, бетон кытлыгына да чик куела. Реактор төзүчеләрнең дә эшләре көйләнә. Ике ай эчендә (29 апрель — 29 июнь) алар энергоблок нигезенә 13 мең кубометр бетон кудыралар. Июнь аенда гына да 410 мең сумлык эш башкарыла. Бер эшченең хезмәт җитештерүчәнлеге айга 2750 сумга җитә. Ярты елга исәпләнгән эш төп-төгәл ике айда тәмамлана...

Димәк, төзүчеләр ашыкканнар, кабаланганнар, сыйфатка зыян килмәдеме икән дип шөбһәләнеп куйган идем. Ярты еллык эшне ике айда тәмамлау өчен, кем әйтмешли, шабашниклар җәһәтлеге кирәк ич.

Лəкин юкка хафаланганмын. Рифкать Кәшифовичның: «Безгә кабаланырга ярамый».— дигән сүзләре чыннан да хак булган икән. «Госатомнадзор» аларның хезмәтен югары бәяләгән. Төзүчеләр ирешкән уңышның сере шунда: алар заманча фикер йөртергә һәм эшләргә өйрәнгәннәр...

* * *

Атом реакторының кыл уртасында басып торам. Тагын берничә елдан шушы урында атом казаны кайнап утырыр. Ә хәзергә барысы да гадәти кебек. Һәркем үз эше белән мәшгуль. Әле анда, әле монда очкыннар чәчрәтеп электр дугалары кабынып ала.

...«Аппаратстрой» участогы начальнигы Сергей Александрович Сидоровны без монда туры китерә алмадык. КОСка китте, төзүчеләрнең күбесе хәзер шунда эшли, диделәр. КОС дигәннәре, безнеңчә әйтсәк, сууткәргеч-чистарту корылмасы була икән. КОС реактордан әллә ни ерак түгел. Участокның өлкән мастеры Илгиз Мусин белән без җәяүләп кенә Кама елгасы тарафына юл тоттык. Илгизнең йөзе нигәдер борчулы иде.

— Атна ахырына кадәр күрше совхозга дүрт тонна яфрак-азык әзерләп тапшырырга кирәк,— диде ул авыр сулап.— Хәзер генә дүрт егетебез балта тотып Кама тугайларына төшеп китте. Участокта да кылны кырыкка ярырдай вакыт, югыйсә.

Юк, өлкән мастер совхозга терлек азыгы әзерләп тапшыруга каршы түгел. Авыл хезмәтчәннәренә көчтән килгәнчә булышырга кирәк, билгеле. Лəкин нигә моның өчен ял көннәрен файдаланмаска әле? Нигә бишенче разрядлы төзүчене тора салып эшеннән аерырга?

Дөрес, беренче карашка, болар вак-төяк булып та күренергә мөмкин. Әмма Илгиз алай уйламый. Коллектив подряды ысулы белән эшләүгә күчкән участокта һәр төзүченең нинди кыйммәткә ия булуын бик яхшы аңлый ул.

Өлкән мастер белән килешмичә булмый. Саннар-фактлар аның файдасына сөйлиләр. Шулай булмыйни. Берничә ел элек кенә Н. Злобинның үзе белән сөйләшергә, зирәк киңәшләрен тыңларга туры килгән аңа. Һәр эшне исәпләп, нигезләп башкару гадәте дә аннан күчкән.

Илгиз Мусин атом электр станциясе төзелешендә 1984 елдан бирле эшли. Өч еллап Көнбатыш Себер киңлекләрен иңләгәннән соң кайта ул бирегә.

Көннәрнең берендә аны идарәгә чакырып алалар.

— Биштәреңне бүген үк төйнәп куй,— диләр аңа.— Без сине Мәскәүгә укырга җибәрергә булдык. Злобин мәктәбенә...

Шулай итеп, Илгиз Мусин ике ай буе Мәскәү каласында хуҗалык исәбенә күчү серләрен өйрәнә. Бригада подряды ысулы белән эшләүгә күчүнең никадәр әһәмиятле, зарур икәнлегенә төшенә. Алар янына Злобин үзе дә еш килеп йөри. Бер килүендә ул Илгизгә хәтта автографлы китап та бүләк итә. Китапның исеме «Злобинча эшләргә» дип атала...

— Без бүген нәкъ шулай эшләргә тырышабыз да,— диде әңгәмәдәшем тыйнак кына елмаеп.— Сидоровтай егетләр барында тау күчерү дә берни тормый безгә. Төзелештә андыйлар күбрәк булсын иде...

Илгиз участок начальнигының исемен юкка гына искә алмады булса кирәк. Моның берәр сере бардыр, ахрысы. Кайсы гына төзүчедән сорасаң да, бер үк җавапны ишетеп гаҗәпкә каласың.

— Ә, Сидоровны әйтәсезме?..— диләр алар уенын-чынын бергә кушып.— Безнең Злобин ич ул. Сергей Александрович безне яңача эшләргә өйрәтте...

Мин килеп кергәндә, участок начальнигы прораб бүлмәсендә нидер язып, исәпләп утыра иде. Көл савытында яртылаш тартылган тәмәке пыскып ята. Сергей төс-кыяфәткә яшь күренсә дә, чәчләренә чал кунарга өлгергән инде.

...«Аппаратстрой» участогы коллектив подряды ысулы белән 1987 елның апрелендә эшли башлый. Лəкин аңарчы Сергей Сидоровка үзенең хаклыгын исбатлау өчен күпме көч түгәргә, күпме чәч агартырга туры килде. «Сидоров эксперименты»ның (шулай әйтүчеләр дә табыла) уңышлы чыгасына икеләнеп караучылар шактый була ул вакытта. Атом реакторы тәҗрибәләр ясап шаярганны яратмый, янәсе. Искечә эшләргә күнеккән кайбер җитәкчеләр һәм эшчеләр әнә шулайрак фикер йөртә. Коллектив подрядына күчеп эшли башлагач, бериш төзүчеләр участокны ташлап ук китәләр. Кемнәр китә? Эшендә эленке-салынкы йөреп тә, мул акча алырга гадәтләнгән ялкаулар китә, билгеле. Әйе, күмәк җаваплылык ысулы белән эшләр өчен инициативалы, тырыш, тәвәккәл кешеләр кирәк. Шөкер, коллективта андыйлар күбрәк булып чыга. Василий Аксаков, Илгиз Мусин, Владимир Маленький, Вазыйх Минһаҗев, Альберт Вәлиев, Владимир Стецко, Ренат Идрисов, Фоат Габбасов, Александр Федоров... Бу егетләр — коллективның тәрәге, С. Сидоровның фикердәшләре. Ул һәрвакыт аларга таяна.

Монтажчы Василий Аксаковны гына алыйк. Күперең торган бөдрә чәчле бу егеткә хезмәттәшләре ихтирам белән Вася абый дип эндәшәләр. Василий АЭСка килгәнче дә бик күп мөһим төзелешләрдә эшләгән: Ставрополь өлкәсендәге Невинномысск һәм Яңа Чебоксар ГЭСларын төзүдә, Мәскәү олимпиадасының матбугат үзәген торгызуда катнашкан.

Менә алтынчы ел инде Василий АЭС төзелешендә. Атомкала нигезенә тәүге таш салучыларның да берсе ул. Аның белән төзелешкә килгән байтак кешеләр өч-дүрт ай эшләгәч, тормыш-көнкүреш шартларына риза булмыйча, кире кайтып китәләр. Ә Василийның башлаган эшен ташлый торган гадәте юк. Озакламый аны бригадир итеп сайлап куялар. Бригада социалистик ярышта һәрчак алдынгылар сафында бара, берничә мәртәбә Татарстан атом станциясен төзү идарәсенең күчмә вымпелы белән бүләкләнә.

Быелның апрель ахырында Аксаков бригадасы «Аппаратстрой» участогына берләшеп, коллектив подряды ысулы белән эшли башлый.

— Коллектив подрядына күчкәч, минем эш бермә-бер җиңеләйде,— ди Сергей Александрович елмаеп.— Коллективтагы һәрбер мәсьәләне участок советы хәл итә хәзер.

Участок начальнигы шаярта гына, билгеле. Яңача эшләүгә күчкәч, аның коллектив алдында шәхси җаваплылыгы, киресенчә, арта гына төшкән.

— Без Сидоровны сабыр, итагатьле, туры сүзле булганы өчен яратабыз,— диде эретеп ябыштыручы В. Минһаҗев.— Беркайчан да тавышын күтәрмәс, тузынмас, кырын сүз әйтмәс... Җитәкчең әйбәт булса, эш тә көйле бара.

Ә «Аппаратстрой» участогында эшләр чыннан да көйле бара. Күрсәткечләр шул хакта сөйли. Мәсәлән, июнь аенда план 241 процентка үтәлгән, бер эшченең хезмәт җитештерүчәнлеге 2750 сумга җиткән, хезмәт хакы бер ярым тапкыр арткан. Бүгенге көндә төзүчеләр уртача 350—400 сум алып эшлиләр (ел ахырында түләнә торган өстәмә акчадан тыш). Эш хакы төзүченең разрядына һәм хезмәткә катнашу дәрәҗәсенә карап түләнә. Тәртип бозган, прогул ясаган, сыйфатка зыян китергәннәр белән исә сүз кыска — барлык бу «гөнаһ»ларың үз кесәңә китереп сугачак. Һәм шактый сизелерлек сугачак. Шуңа күрә участокта хезмәт дисциплинасын бозу, эшкә соңга калу, яисә иртәрәк китү кебек нәрсәләрне инде күптәннән онытканнар.

— Ә иң мөһиме — эшчеләрнең хезмәткә карашы үзгәрде. Бу үзгәрешнең асылы материаль стимулның мораль стимулга әверелә баруыннан гыйбарәт,— ди С. Сидоров.

* * *

Кама аръягында — КамАЗ һәм Түбән Кама нефтехимия гигантлары янында — тагын бер баһадир күтәрелеп килә. Хезмәт эстафетасы, дәверләр эстафетасы дәвам итә.

Моннан сигез гасырлар элгәре нәкъ шушы төбәкләрдә борынгы болгар бабаларыбыз Европада беренче булып чуен койганнар. Ә бүген Чулман аръягы кабат Яңарыш кичерә! Борынгы Шайтан, Ибраһим калалары янында Тыныч Атом каласы үсә.

Дөресен әйтергә кирәк, Чернобыль фаҗигасеннән соң, АЭС дигән аббревиатура күңелләрдә төрле каршылыклы тойгылар уятты... Хәлбуки, кайчандыр ерак бабаларыбызга кыргый атны кулга ияләштерү дә җиңел булмагандыр. Һәм шул игелекле җан иясе ничә мең еллар буе адәм баласына тугры хезмәт итеп килә. АТ һәм АТом... Кызык, бу сүзләр бер үк тамырдан ясалганга охшый... «Атом» сүзен беренче мәртәбә борынгы грек философы Демокрит кулланган, диләр. Ул чакта да ат кешенең иң якын ярдәмчесе булып саналган. Дәүләтләрнең көч-куәте атлар саны белән дә исәпләнгән. Ат белән җир сөргәннәр, йөк ташыганнар, сәяхәт иткәннәр. Энергия чыганаклары һаман кими барган бүгенге заманда атом да кешенең беренче ярдәмчесенә, көч чыганагына әйләнә бара сыман. Ләкин шул кадәресен дә онытмыйк: кешелек дөньясы атомны кулга ияләштерә башлады гына әле. XX гасырны еш кына атом гасыры диләр.

Килер бер көн: атом кешенең иң тугры, иң көндәм ярдәмчесенә әверелер. Кешелек атомны мәңгелек яшәеш арбасына җигәр дә ерак йолдызларга сәфәр чыгар... Татарстан атом электр станциясе — шул арбаның бүгенге бер моделе булып тоела миңа.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

Тәлгат Галиуллин

# АЧЫШЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

Татар поэзиясенең бүгенге торышы, илдәге абруе җәмгатьчелекне канәгатьләндерми. Бер-берсенең үкчәсенә басып килгән «афәтләр»— юкатта яңачалык җитешмәү, фикерләүдәге торгынлык, дөньяны һәм кеше рухын сурәтләүдә кыюсызлык, әнисенең итәгенә ябышкан бала шикелле, традиция колы булу (рифмасыз, ирекле шигырь дә шуңа керә) һәм шуның табигый нәтиҗәсе — укучыны югалту — беркемгә дә сер түгел. Бу — аксиома. Әлеге чирләрдән арыну өчен теориядә түгел, ә гамәлдә нәрсә эшләргә дә, шигъриятне бу авыр хәленнән ничек чыгарырга? Алтмышынчы еллар башында әдәбиятның алгы сызыгында торып, бәхәсләр уянуга сәбәпче булган, сәхнәләр тоткан шигырь ни өчен соң әле бүген әйдәп баручы көчен югалтты? Баксаң, түгәрәк туп шикелле гапгади сораулар икән: ни өчен? Ни сәбәпле? Әзер җавапларга караганда сораулар күбрәк...

Бер нәрсә ачык: укучының билгеле бер жанрга, тематик борылышка мөнәсәбәте, теге яки бу күренешне кабул итмәве күп очракта аклана. Ә вакыты белән без — әдәбият үсеше өчен җаваплы кешеләр — сәрхүшләнеп, хыялыбызны чынга, тормышка ашкан хакыйкатькә санап, үзебезне алдау, күз буяу юлына басабыз.

Шигырьгә апатия кире кайтарып булмаслык югалтуларга алып килергә мөмкин. Кешедә өмет сүнә, ышаныч кими бара, укуга ихтыяҗ югала...

Бөтен идеологияне яңарту, ачыклык, кыюлык, демократия чорында әдәбиятка таләпләрнең арта баруы табигый. «Казан утлары» битләрендә башланып киткән поэзия турында сөйләшү дә шул олы процессның бер күрсәткече. Революцион борылыш чорларында поэзиянең алга чыгуы, башка жанрлар үсешенә тон бирүе турында да онытырга ярамый. Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиевләрне күтәргән Беренче рус революциясе дәверен, 1917 елдан соңгы талантларга гаять мул әдәби ситуацияләрне искә төшерик. Нинди бай ул чорлар поэзиясе! Кырыс реалистик стиль янәшәсендә күп тармаклы романтизм гөрләп үсә, формализм баш күтәрә, натурализм җирдән шуышып бара... Илленче еллар әдәби эстафетаны алтмышынчы унъеллыкка тапшырган чорда, халык башына шәхес культы алып килгән фаҗигаләрдән котыла бару процессы йогынтысында, татар поэзиясендә яңа, М. Кәрим сүзләре белән әйткәндә, 20 нче елларга тиңләгәндә, тоныграк, әмма шактый үтемле «шартлау» барлыкка килде. Тормышны яңача күрү, гаҗәеп ачык образлылык, көтелмәгән борылышлар, күчешләр, детальләр, әлегә чаклы халык күңеле, халык теле тирәнлекләрендә яткан чагыштыру-метафоралар, рифмалар, шул ук вакытта халык җырларына эчке якынлык, чакма таш уты кебек, чәчрәп чыккан сатира дисеңме... Үз чорында без бу ачышларны бәяләп тә, фәнни аңлатып та бетермәдек шикелле. Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Р. Гатауллиннар поэзиясен күбрәк форма яңачалыгы, тиз сүнә торган вакытлы ялтырап алу дип аңлатулар матбугат битләрендә тулып ятты. Ничек кенә булмасын, аларның фәлсәфи фикерне калкытып куйган, иркен форманы алга сөргән поэзиясе күпмедер күләмдә укучының сусавын басты, күңеленә хуш килде. Менә бүген шундый бер буын поэзиягә килсен иде әле! Үткәнне иҗатка кире кайтарып та, кабатлап та булмый шул. Сагынып кына була...

1987 елны «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Сез кабызган утлар» поэмасында (7 сан) И. Юзеев элек ирешелгән үрләрне искә төшерү, яңарту юнәлешендә бер тәҗрибә ясап карады.

Туган йортының көчүе турында хәбәр алган шагыйрь, хисләренә ияреп, үткәнгә юл ала, немец гармунында татар, рус көйләрен уйнаган, белорус, чех өйләрендә җылылык тапкан әтисенең самими образын тудыра. Тукай, Җәлил, Есениннарны искә төшерү гомуми фонны киңәйтә, изге төшенчәләр турында уйланулар юлына алып чыга: без кемнәр соң, «Әткәйләрнең нигезендә туган хыялны һәм моңны сүндерсәк?», «Туган йортым — татар шигыре» кебек юллар да күңелгә сарылып кала. Кыскасы, поэма оста кул белән язылган, рифмалары үз урынында, җепләре төйнәлгән... Әмма И. Юзеевның соңгы елларда иҗат ителгән масштаблы фикерле, әхлакый эчтәлекле, галәмнең фаҗига белән тулы проблемаларын эченә алган поэма-драмаларыннан соң, бу әсәрне шигъри үсештә яңа бер адым дип кабул итүе кыен. Мондый сентименталь, күбрәк гаилә сферасына, аталар һәм балалар мөнәсәбәтен ачуга багышланган «бер кыллы» әсәрләрне И. Юзеев яшьлегендә күп иҗат итте, шулар белән поэзиягә керде. Тормыш, яшәү мәгънәсе, табигать яме, мәңгелек моң турында уйлану үзе дә яңалык түгел аның өчен. Замана башка — җыр башка шул. Рифмасыз кыска шигырьләр бәйләме белән Р. Фәйзуллин да хәзерге укучыны, алтмышынчы еллар башындагы шикелле үк, сискәндерә алыр идеме икән? Кистереп уңай җавап бирүе кыен бу сорауга.

Иҗтимагый һәм экономик тормыш мәсьәләләрен, тарихи үткәнне күтәрү, олы язмышлы кешеләр, тирән һәм дәртле хисләр белән эш итү юлындагы чикләнмәгән мөмкинлекләре бүгенге поэманы еш кына бөтен поэзиянең алгы сызыгына алып чыга. Соңгы ике унъеллыкта бу жанр шактый җитди һәм үтемле казанышларга иреште. Яңачалык рухы иң әүвәл С. Хәким белән И. Юзеев поэмаларында югары шигъри аккорд алды. Беренчесенең лиро-эпик әсәрләре үзенә бер сыйфат үлчәме, поэма үсешенең чагыштыру-бәяләү бизмәне була килде. Шул фонда Роберт Әхмәтҗанов, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалим, Зөлфәт, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, З. Мансуров һ. б. шагыйрьләр олы жанрда кыю эзләнүләр юлына чыктылар, татар поэзиясенең традицияләрен баетып җибәргән җилле-җилле әсәрләрен язып чыктылар. Иң уңышлылары белән хәзер дә сокланмый мөмкин түгел.

Ә инде соңгы ике ел аралыгында матбугатта чыккан күләмле әсәрләр белән танышкач, оптимистик рух сүрелә, күңелгә шомлы уйлар үрли. Дөрес, 1986—1987 елларда укучыга ирешкән поэмалар тематик иңнәре, композицион үзенчәлекләре, сурәтле фикерләү чаралары буенча төрле-төрле.

Р. Харисның «Борылышта», Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ», Р. Зәйдуллинның «Күпер» поэмаларында чынбарлык тарихи материал фонында ачыла. Ә. Рәшитов «Автопортретка штрихлар» әсәрендә үзәккә шәхси биографиясен алса, «Ачыктан-ачык» поэмасында М. Шабаевны чорыбызның яңару, рухи сәламәтләнү, яшәрү проблемалары борчый, уйландыра. Һәммәсе авторларның уй-хисләрен шигъри юлларга сеңдереп, изге ният белән язылган әсәрләр. Һәркайсының үзенә күрә ачышы, идея-эстетик офыгы бар. Әмма аталган поэмаларның менә шунысы-шунысы әдәбият тарихына кереп калыр дип раславы кыен. Безнеңчә, шагыйрьләрнең изге ниятләре ахыргача «сүтелмичә», потенция хәлендә калган.

Нечкә хисле, халык җырларына якын композицияле лирик шигырьләр авторы Рәшит Әхмәтҗановның поэма жанрына мөрәҗәгать итүе («Казан утлары» 1987 ел, 4 сан) хуплауга лаеклы күренеш. «Бер елмайдым, биш моңайдым. Сизмәдем дә, таңнар атты»,— кебек шәхси интонация, кояшлы образлар белән башланып киткән әсәр акрынлап реаль җирлеккә — Әлмәт шәһәрен кору вакыйгаларына алып чыга. Төрле бәяләмәдәге ташларны шагыйрь «күңел корабына», аңына, җанына алып керә, «бишташның» һәркайсы үзенә бер мәгънә сирпи башлый.

Поэма халыкның олы тарихын иңләргә омтылыш ясый (кеше таштан савыт, балта ясый, бер-берсенең муенына да урап ташлый). Әмма кеше рухындагы акыллы, гуманистик нигез җиңә килә. «Башка бәргән Ташлардан да кеше юл сала», чөнки аның характерында, дөньяга мөнәсәбәтендә эшләүгә, коруга, торгызуга омтылыш көчлерәк. Туфанга ияреп, шагыйрь «Талантлы син, кеше туганым!» — дип замандашының әхлакый һәм физик көче алдында баш ия. Шәхес безнең киеренке чорда үзен-үзе яклый белергә дә тиеш (әгәр тисәләр, «аш белән бәр» дигән сүзгә ышанмыйча, «таш белән бәр» дигән киңәш тә яңгыраш ала поэмада).

Р. Әхмәтҗанов бер үк вакытта афористик төгәллеккә һәм күп мәгънәлелеккә омтыла: «Җан — азатлык таҗы», «Туган җир — ташлар бакчасы» һ. б. Әмма урыны белән гомумиләштерүләре ясалма килеп чыга, артык акыллы, философ булып күренергә тырышу үзен сиздерә: «Мөмкин түгел, безне һәм кояшны өйрәтергә ничек яшәргә». Драматик күпертүе ышандырмый башлый: «Җир өстендә күпме агач үссә — Барысына да кеше астылар!»

Поэма ачык һәм төгәл сюжетка корылмаган. Бүлекчәләрне шагыйрь шәхесе һәм шактый кызыклы ачылган Туфан образы бәйли. Жанр таләбе ноктасыннан килгәндә, «Бишташ» поэмадан бигрәк, үзенчәлекле шигъри бәйләмгә тартылып тора. «Бишташ» атамасының символик мәгънәсе дә ахыргача ачылып-актарылып китмәгән.

Р. Зәйдуллин поэмасының («Казан утлары», 1986 ел, 5 сан) исеме, киресенчә, реаль һәм күчерелмә төсмерләргә бай. Күпер, бер яктан, татар һәм чуваш авыллары арасында яткан елганы тоташтырган, ике як бергәләп торгызган, язгы ташу вакытларында зур мәшәкатьләр тудырган реаль күпер булса, икенчедән, ул халыклар арасындагы дуслык, аңлашу һәм бәйрәм символы: «Таш күпердә — бәйрәм!». Поэма исеменең әле өченче семантик мәгънәсе дә бар. Ул — үткән белән бүгенгене бәйләүче хәтер, ата-бабалар калдырган рухи мирас белән ике арада яткан таяныч: «Туктый калсаң — күперең булсын икән Гасырларны тоташтырырлык».

Ләкин менә шул уңышлы табылган нигез әлеге поэмада конкрет сюжет, эчтәлекле образлар җирлегендә үстерелми. Ике халык якынлыгы, әйтик, С. Хәким әсәрләрендә татар белән мари арасындагы мөнәсәбәт шикелле күңелгә сарылып калырдай образлар, детальләр аша ачылмый. Үткәнне сурәтләгәндә әле азмы-күпме этнографик күзәтүләр, чагыштырулар ясалса (дөрес, анда да бөек мәгърифәтче Ульянов образы әдәби реминисценция кебек кенә кабул ителә), безнең көннәргә килгәндә исә, автор гомуми ялтыравык җөмләләр, газета битләреннән күчкән штамплар стихиясен җиңеп чыга алмый: «Халыкларның бүген бердәм булып Дуслык җырын җырлар сәгате» кебек җөмләләрне безнең поэзия 30 нчы еллардан башлап шактый тәкрарлады инде. Мондый риторик сүзләр күп кабатланды, әмма аңа карап, Р. Фәйзуллин әйтмешли, бәхет артмады.

Поэма — ифрат мәкерле жанр. Ул, Р. Зәйдуллин кебек яшьләрне генә түгел, үз эчке үзенчәлекләре белән санашмаган тәҗрибәлерәк шагыйрьләрне «төп башына» утыртырга да күп сорамый. Шул яссылыктан караганда, Ә. Рәшитовның «Казан утлары»нда (1986 ел, 3 сан) басылган «Автопортретка штрихлар» язмасын төгәлләнгән, анык композициясе булган поэма рәтендә карау җитди булмас иде. Ул — төрле кисәкләрдән тегелгән төсле юрганны хәтерләтә. Шагыйрь иң әүвәл сыкрау, моң белән авыр яшьлеген искә ала (бездә бу нәрсә «бисмилла» урынына әйтелә торган гомуми урын булып китте):

*Ә ул көнне Идел моңсу иде,*
*Ике күзем тоташ дымсу иде,*
*Утлар йота-йота акчам юкка,*
*Утырдым да ап-ак пароходка,*
*Бәхет эзләп чыктым Ерак юлга...*

Күз яшьләрен «еллар сөртә», герой университетка керә, тормыш мәктәпләрен үтә һәм туган ягына әйләнеп кайта... Бераздан ул инде күңеле белән «Татар хәятеннән аерылмыйча мунча кебек эссе Сингапурда» йөри һәм көтмәгәндә үзен 50—60 елларда актив иҗади тормыш белән яшәгән, сугышны үз җилкәләрендә алып чыккан Ш. Мөдәррис, Ә. Давыдов, З. Мансур, Г. Хуҗиларга каршы китереп куя:

*Рәнҗемәсен рухы Мөдәрриснең,*
*Әнвәр, Зыя, Гали абыйларның:*
*Олы җаннары өчен мин аларга*
*Гашыйк идем...*
*Ләкин табынмадым.*
*Ут уйната иде әле алар,*
*Ә мин артык горур идем, шуңа*
*Шигыремә толкач кирәкте дә,*
*Тотынмадым алар чабуына.*

Әйтер сүзең, үтемле фикерең булмаса, үткәннәргә, үлгәннәргә бәйлән, диләр. Биредә дә нәкъ шулай килеп чыккан. Бәхәсне шагыйрь чит илдә йөргәндә башлап җибәрә һәм олы, мөхтәрәм шагыйрь Шәрәф Мөдәррискә карата фамильярлык «үрнәге» күрсәтеп ташлый. Иң мөһиме: ә ни өчен ул кемнеңдер чабуына ябышырга тиеш? Ифрат сәер логика. Фронтовик шагыйрьләр аның өчен «толкач» булырга тиеш? Ифрат сәер логика. Биредә әдәби буыннар арасындагы иҗади мөнәсәбәт ялгыш ноктадан килеп бәяләнә. Синең горурлыгың декларациңдә, манифестыңда түгел, ә шигыреңдә күренсен дигән бер тәнкыйтьче.

«Штрихлар» күтәренке пафос, югары «штиль» белән тәмамлана: «Алга әйди шигырь байрак булып — Миллион кояш яна йөрәгемдә». Әмма мондый шартлы күтәренкелек

галәм иңләү инде ышандырмый, өлкәннәргә һич кирәкмәгәндә кизәнүдән туган авыр хисне җиңеләйтә алмый.

Мәгълүм булганча, һәр җитлеккән шагыйрьнең тормыш тәҗрибәсе, чынбарлыкны күрү, аңлау һәм сурәтләү үзенчәлеге тудырган билгеле бер эстетик дәрәҗәсе бар. Әйтик, Р. Фәйзуллин белән Ш. Галиев, Р. Харис белән И. Юзеев поэзияне бәяләүдә, бәхәсне башлап җибәргән Р. Мостафин белән В. Нуруллин бизмәненә салып үлчәгәндә, «бер тиенгә тормаслык» шигырь яза алмыйлар. Бик теләсәләр дә. Шул яссылыктан килеп карaганда, Р. Харисның «Борылышта» поэмасы («Социалистик Татарстан», 1987 ел, 5 сентябрь) бүгенге татар поэзиясенең йөзенә кызыллык китермәслек әсәр.

Аның буенча шагыйрьнең уйлану рәвешен, хәтер ярдәмендә үткән белән бүгенгене бәйли алу сәләтен, тормышны сурәтле күзаллау алымнарын, кыскасы, шигъри индивидуальлеген таныш була. Ил узган авыр һәм катлаулы юлны ул эре штрихлар белән иңли. Безгә таныш алсу буяуларны, мажор интонацияләрне реалистик кырыслык алыштыра: «...нык үскән социализмның торгынлыкта баһын кашуын... күрдек» ди ул. Әмма төп юл дөрес иде:

*адашмадык!*
*Без тайпылдык кына,*
*югалтмыйча Ленин маягын!*

Шулай да олы теманы ачу ягыннан караганда да, сурәтле фикерләү яңачалыгы ноктасыннан килеп бәяләгәндә дә «Борылышта» поэмасы шагыйрьнең бу жанрда һәм тарихи темада элегрәк иҗат ителгән әсәрләреннән кайтышрак.

Һәр художникның тарихи күренешләрне хыялы белән баетырга, тулыландырырга хакы барлыгын таныган хәлдә дә, үзәк вакыйганың бирелеше бәхәс уятырга мөмкин. Җил дулаган, йолдызлар сирпелгән Кокушкино юлында, әтисе белән абыйсының үлеме, кыяматне тудырган җинаятьне бетерү хасияте турында фикер алышкач, Володя Ульянов шундый карарга килә:

*фәкать Саша салган эздән,*
*ләкин*
*аның кебек түгел!..*
*Башкача!*

Ленинның патша самодержавиесенә каршы көрәшенең яңа, марксистик чорын билгеләгән бу фикере һәркемгә мәгълүм. Тик алдынгы тәгълиматның революцион хәрәкәт белән кушылуы нәтиҗәсендә ясалган әлеге ачышка Ленин шул чорда ук килә алдымы икән? Шулай булган очракта да, аның дөньяга карашындагы борылыш Кокушкино дәверенә туры киләме? Бу олы фикер бер фактка таянып кына дәлилләнә аламы? Тарихи деталь генә поэма жанры өчен кирәкле конфликтны күтәрә аламы?

Р. Харисның олы язмышлы шәхесләр, аларның тормыш юлларына игътибарлы булуы, шул эзләнүләрендә мәгълүм казанышларга ирешүе турында матбугатта фикер әйтелә килә. Тарихи шәхесне сурәткә алып керү бер хәл. Ә инде аның рухи дөньясын ачу, укучыга таныш информация рамкаларын киңәйтеп җибәрү бөтенләй башка нәрсә. Р. Харис «Борылышта» поэмасында исемнәрне күп атый, әмма вакыты белән, тирәнгә үтмичә, таныш төшенчәләр һәм мәгълүматлар белән чикләнә. Володя Ульяновның әнисе Кокушкино юлында менә шул гомуми әйберләрне «кабатларга» мәҗбүр була:

*Атаңның бар иде чуваш дусы —*
*бик мөхтәрәм Иван Яковлев.*
*Атаң аңа чуваш мәктәпләре*
*ачарга да байтак булышты.*

Р. Харис яшьлегендә шигъри әсәрләренең үзәгенә катлаулырак образларны алырга ярата иде.

Кызганычка каршы, диикме, ул соңрак бу юлыннан читенде. Хәтта Дәрдмәндкә багышланган шигъри көлтәсен дә, авылдан килгән туганыннан оялган шәһәр егете шикелле, җыентыкларына читенсенеп һәм сирәк кертә башлады. Идеологиядә, иҗатта барган яңа атмосфера, ачыклык рухы Р. Харисны да «ачып җибәрер» һәм ул каршылыклы, үзләренчә намуслы, туып-үстергән халыкларына бирелгән авыр язмышлы шәхесләргә карата да игътибарлырак һәм миһербанлырак булыр дип ышанасы килә.

Хәзерге поэма халык намусы, аның матурлыкны һәм дөреслекне аңлау юлында

ярдәмчесе булырга тели икән, ул чынбарлыкка бер йөз белән генә карый алмый. Шуңа күрә публицистика һәм вакытлы матбугат үрнәгендә, поэзия үсеш кыенлыкларын, тормыш низагларын, авыр язмышларны да читләтеп үтә алмый. А. Твардовский әсәрләрендәге шикелле, җитди поэзиядә дә тәнкыйть пафосы булырга тиеш. Туфан шигырьләрендә шәхес культын фаш итү ни чаклы тирән һәм образлы ачыла!

«Казан утлары» журналында үткән ел М. Шабаевның «Ачыктан-ачык» исемле публицистик әсәре дә басылды (9 сан). Соңгы вакытта әдәби бәйгедә сирәгрәк катнаша башлаган шагыйрь илне борчыган проблемалар уртасына килеп чыга. Әсәр тизләнеш, үзгәртеп кору, яңача мөнәсәбәтләрне гамәлгә ашыру өчен көрәш рухы белән сугарылган. Автор «зур масштаблы зур эпик бер әсәр» язарга нияте барлыгы турында хәбәр итә дә, партия корган олы планнарны тормышка ашыруга аяк чалып килүче тискәре күренешләргә, күләгәле якларга каршы күтәрелә. Шигъри юлларга кискен, ачык интонация, соңгы еллар публицистикасына хас усал тәнкыйди рух йөгерә. Аны иң борчыганы — начар сыйфат, тышкы муллык эченә яшеренгән ваемсызлык, мәгънәсезлек, җавапсызлык: «Аяк киеме — киштә сыгыла... Костюм, чалбарлар — дивизиялек». «Карачкылар да баш тарта торган», әмма бирkасына «сыйфат билгесе» сугылган кием тегүчеләрне фаш итүваграк проблемаларны да тартып чыгара («төймә-каптырма дефицит заман!») Юлдагы хәрәкәт алдында калыккан авырлыкларның иң кыены: «Чөнки болар бит — нәкъ үзебез! Үзеңне үзең бетереп кара...» Яхшы шигырь иҗат итүне дә шул проблемаларга тиңли, алар белән янәшә куя автор (чын «шигырь» җаныңны сыгып язганда гына» туа ала). Дөреслек сулышын, хакыйкатьне эзләүне шагыйрь поэманың барометры итеп алган.

М. Шабаевның кыю адымын, темпераментын, шигырь белән публицистика арасындагы якынлыкны эзләү юлындагы тәҗрибәсен хуплау белән бергә, «Ачыктан-ачык»ның поэзиядә «яңарыш чоры»н башлап җибәрүгә дәгъва итә алырлык әсәр дәрәҗәсенә күтәрелеп җитә алмавын искәртәсе килә. Коры публицистика тормыш драматизмын да, шигърилекне дә алыштыра алмый. Маяковский белән Такташ «Яхшы», «Киләчәккә хатлар» кебек әсәрләрендә публицистик хөкемне ачык сюжетка һәм образлы фикерләүгә буйсындыралар. Публицистик гомумиләштерү алар өчен мөһим, әмма ярдәмче бер чара. Бу момент М. Шабаев поэмасында исәпкә алынмаган. Икенчедән, поэзия игътибарын тискәре моментларга юнәлтү белән генә чикләнә алмый, ул укучы каршысына үзенең уңай, позитив программасын да калкытып куя белергә тиеш. Поэмада бу нәрсә юк.

Ниһаять, Барнаулдагы малаена мебель эзләү низагларын, аны төяү, озату «кыйссасын» тәфсилле сөйләп бирү әсәрнең диапазонын тарайта, ышандыру көчен, җитдилеген киметә һәм сүзне олыдан кубып башлаган иҗатчының үз шәхесен дә ваклый. «Бытка» кереп батып, җегәрен бушка әрәм-шәрәм итмичә, вакытын поэма өстендә эшләүгә бирсә, М. Шабаев ифрат тәэсирле һәм заманча әсәр иҗат иткән булыр иде дип тә уйлап куясың. Тулаем алганда, бу башлангыч тормыш катлаулыкларына тирәнрәк үтеп кереп, кеше хисләренә, әхлакый проблемаларга игътибарлырак булып, киләчәктә поэзия үсешенә яңачарак юнәлеш бирер дип ышанасы килә. Юкса, соңгы ике ел аралыгында поэма жанры биләгән үрләреннән чигенеп, элгәрләренә бурычка кереп бара икән. Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, С. Хәкимнәргә әҗәткә кереп бара икән...

Ә поэмага ихтыяҗ кимеми. Бөтен илне биләгән рухи яңарыш, «кеше формуласын» эзләү чорында күбрәк идеянең хисси, тойгылы ягын, анда да бер мизгелен генә үзәккә алган лирик шигырь кичереш киңлекләрен иңләүгә, җан һәм зиһен эшчәнлеген бөтен муллыгында сурәтләүгә дәгъва итә алмый. «Олы сүзне» поэма алырга тиеш.

Теләсә кайсы чор поэзиясенең йөзен көчле табигый талантка ия, иҗтимагый темпераментлы шагыйрь иҗаты билгели. Шуңа күрә без Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан, С. Хәким чорлары дибез... Олы шәхес иҗатында гомуми әдәби атмосфера, поэзиянең үсеш юнәлеше, мәйданы тәгаен төсмерләнә. Чөнки шигъри пегасны йөгәнләү сәләтенә ия шагыйрь поэзиясендә тормышта, һавада, йөрәктә яшәгән, әле генә туа килгән фикер һәм хисләр төгәл, үтемле һәм сәнгатьчә камил чагылышын таба. Аның концепциясе белән килешмәскә, бәхәсләшергә, башкачарак юнәлешне расларга да мөмкин. Ахыр чиктә, менә шул нәрсә поэзиядә иҗат атмосферасы тудыра, аңа эзләнү рухы бөрки, тынгысызлык утын элдерә.

Чордашлары иҗатына поэзия лидеры шифалы яңгыр булып та, киресенчә халдә торган өермә, туфан кебек тә тәэсир итә. А. Блок куен дәфтәренә шундый сүзләрне язып куя: «Даһиның арада яшәве үзе үк замандашларына һәр даим яктылык нуры сирпеп тора. Бу яктылык якыннан гына яхшы күрүчеләрне бик күп балаказалардан саклап калды».

Талант иясе «коеп куйган» шагыйрь булып, гомерен чәчәкләр һәм күбәләкләр, йолдызлар һәм гашыйклар арасында гына уздыра алмаган кебек, мәрмәр мактау пьедесталында гына да басып кала алмый. Поэзиянең алгы сафында атлаучы шагыйрь иҗтимагый-әдәби тормышның уртасында кайный, үз чорының алдынгы идеаллары белән янып-көеп яши, яшь алмашның иҗади үсешенә савыктыргыч йогынты ясый, хатлары, чыгышлары белән укучыда зәвык тәрбияләүгә өлеш кертә. Аның теге яки бу чорда яшәве үк гомуми әдәби атмосферага уңай тәэсир итә. Андый шәхеснең юклыгы поэзия үсешендә үзен нык сиздерә.

Илленче еллар башы татар поэзиясен искә төшерик. Игътибарга һәм хөрмәткә лаеклы мөхтәрәм исемнәр аз түгел. Алар халык күргән авырлыкларны, совет кешесенең каһарманлыгын әдәбиятта калдыру юнәлешендә зур эш башкаралар. Поэзиянең төп көчләре эпик поэмалар, шигъри повестьлар белән мәшгуль. Сөйләп бирерлек вакыйгасы, ихтимагый конфликты, характерлар бәрелеше үзәктә ятмаган әсәр «җитди»¸ бәягә лаеклы түгел. С. Хәким, С. Баттал, Ш. Маннур, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗи һ. б. иҗатында күләмле поэма — баш дирижер. Шәхеснең тирән кичерешләрендә «казынган» лирика өчен (шул чорда көчле шигъри әсәрләрен биргән Ә. Фәйзи формализмда һәм артык тар, субъектив хисләрне идеаллаштыруда гаепләнә) шигъри мәҗлес түрендә урын юк. Ул — пропискасыз гына яши.

Менә шундый бер чорда әдәби процессны яңартып, шагыйрьләрне сискәндереп, уйландырып җибәргән ике олы вакыйга була. Нахакка гаепләнеп, озак еллар буена туып-үскән җиреннән читтә яшәргә мәҗбүр булган Туфан Казанга кайтып төшә, Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» дөнья күрә. Туфанның элеккеге иҗаты белән берләттән, сөргендә язган тирән эчтәлекле, тормышчан кичерешкә бай, олы гражданлык хисе белән сугарылган шигырьләре гаҗәеп бер ачыш буларак кабул ителә. Шигырьгә битараф, аны элек кабул итми, аңламый торган кешеләр дә Туфанны ябырылып укыйлар. Җәлилнең батырлык һәм матурлык поэзиясе белән сокланалар. Шигырь ятлау, сәхнәдән сөйләү, үзара укышу йоласы яңара.

Йөрәктән чыккан сүзгә, табигый моңга, самими, кешелекле мөнәсәбәткә сусаган укучы әле генә модада йөргән озын-озак поэмалардан шатлана-шатлана баш тарта. Табигый рәвештә поэзиянең лидеры буларак танылган Туфан иҗаты әле генә әдәбият бусагасын атлаган Г. Афзал, Ш. Галиев, И. Юзеев, С. Сөләйманова һ. б. өчен якты маяк, таяныч һәм юлдаш буларак күтәрелә. Бу олы рух алар артыннан килгән яңа буын шагыйрьләр иҗатына да шифалы тәэсир ясый. Кеше кичерешләре белән тышкы дөнья арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, әхлак, этика мәсьәләләрен ачыктан-ачык сурәтләгән, югары шигъри камиллеккә омтылган әсәрләр күбәя.

Җитмешенче-сиксәненче еллар татар поэзиясенең идея-эстетик һәм әхлакый көче, үсеш юнәлеше, эчтәлеге Х. Туфан белән С. Хәким иҗатларында ачык чагылышын тапты. Ул гына да түгел. Аларның әдәби процесста катнашуы, яңа әсәргә, яшь көчләр иҗатына битараф карамаулары, ел йомгакларында, идарә утырышларында булулары гына да җыелышларга җитдилек, саллылык рухы бөрки. Поэзиянең аксакаллары залда утырганда дәгъвачыл, мөнәсәбәтләрне югары дулкыннарда ачыкларга яраткан дуамал, буталчык кешеләрне дә сәхнәгә күтәрелүдән оялта, чыгышлары турында уйланыбрак килергә мәҗбүр итә. Вак-төяк ыгы-зыгылар ничектер арткы рәткә күчеп, сүз күбрәк әдәбиятның сыйфат үсеше, жанрлар байлыгы, телнең нәфислеге, әдәби алмаш әзерләү кебек мәсьәләләр тирәсендә бара. Аларның җитди, уйчан йөзләре, синнән әдәбият үсеше турында яңа сүз, җитдилек, эзләнү рухы көткән күзләре, әйтерсең лә, фикер алышуга юнәлеш биреп тора. Кыскасы, мәдәният мәнфәгатьләреннән башка нәрсә турында сөйләү оят һәм түбәнлек тоела. Чыгыш ясамасалар да, фикер юнәлешләрен сиземләве кыен түгел: талантка — яшел юл, халтураны — чүплеккә!

Х. Туфан белән С. Хәким арабыздан киткәч, без ничектер ятимсенеп калдык, фланглар да, тыл да ачылып калды. Аларның кирәклеген аңлау, чын мәгънәсендә бәяләү физик югалтудан соң туган юксыну хисе белән бергә генә килде дисәк тә, ялгыш булмастыр.

Сәләтле, танылган каләм ияләренә, мөхтәрәм исемнәргә бай хәзерге татар поэзиясендә берәүнең дә лидерлык «тасмасын» киясе, авыр иҗтимагый йөкне җилкәсенә салып, поэзия үсеше өчен җаваплылыкны өстенә аласы килми. С. Хәким калдырган вакантлы урын буш. Бер шагыйрь иҗат диапазонының киңлеге, төрле жанрларда актив һәм продуктив эшләве, һәр әсәрендә яңача фикерләүгә омтылышы, әдәби алмашка игътибарлы булуы белән шигъри процессның алгы сафында атласа да, аңа каләмдәшләренә карата таләпчәнлек, сорылыкны актив кире кагу, иҗтимагый темперамент җитенкерәми. Ул үзенең романтик рухлы чыгышларында барлык шагыйрьләр белән дә яхшы, тигез мөнәсәбәт сакларга, берәүне дә рәнҗетмәскә

тырыша... Икенчесе исә иҗтимагый эшкә ныклап кереп китүдән үзен тыеп кила, характерына хас потенциаль мөмкинлекне тулысынча файдаланмый. Вакыты-вакыты ул алдан уйланылган чыгышлары белән үзе турында искә төшерә дә, янәдән башлыгы белән үз проблемаларына кереп югала... Өченчесенең җегәрен рәсми эшләр ала... Дүртенчесе үзен мондый олы эшләрдә катнашу өчен яшьрәк саный...

Поэзиянең алгы сафында атлаучы менә бу шагыйрьләрнең мәдәниятка, әдәбият тарихына кагылышлы мәсьәләләрне сирәк күтәрүе, борчусыз, ниндидер ваемсыз тормыш белән, искечә яшәргә омтылулары шактый гаҗәпләндерә. «Огонек» журналында Е. Евтушенко алып барган шигъри рубриканы искә төшерик. Шагыйрь кыска гына вакыт эчендә укучыны XX йөз башында иҗат иткән бик күп катлаулы, каршылыклы шәхесләр иҗаты белән таныштырырга өлгерде.

Яшь шагыйрьнең тәүге җыентыгына тотылган тиеннәрне санап утыруга караганда, милли интеллектның көчен, үткән һәм бүгенгесен халыкка тулырак ирештерү юнәлешендә кыюрак эшләсәк, заман рухына якынрак килер идек. Әйе, архивларда казынып утыру, революциягә чаклы, 1917 елдан соң төрле-төрле шәһәрләрдә вакытлы матбугат битләрендә, бик аз тиражлы җыентыкларда басылган әйберләрне табып, җиз иләк аша үткәреп, янәдән халыкка ирештерүе җиңел эш түгел. Берничә ел эчендә өч алфавит алыштыруны да искә алсак. Ә чынлыкта, без үзебезнең нинди шигъри байлыкка ия булуыбызны да тәгаен белеп бетермибез.

Бу юнәлештә Р. Фәйзуллин, Р. Мингалим, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Гатауллин, Зөлфәт кебек урта буын шагыйрьләр зур эш башкара алырлар иде. Аларга үз иҗат рамкаларында гына бикләнеп калмыйча, дәүләт кешеләре буларак иҗтимагый эшләргә кыюрак алынырга бик тә вакыт.

Башка жанрларда ничектер, әмма поэзиянең алгы сафында бер урын буш. Такташ үлгәч, Ә. Фәйзи бер шигырен «Безнең шеренгада бер урын буш» дип атаган иде... Бу «урын» түләүле түгел, аңа җиңел машина да беркетелми, секретарь да бирелми, җитәкчеләрне сайлаган шикелле, гомуми тавыш бирү алымы да батмый бирәдә. Лидерлык абруе, табигый рәвештә, үзеннән-үзе килергә тиеш.

Проза турында барган дискуссиядә чыгыш ясаучыларның күпчелеге ни өчен бездә Ю. Бондарев, Ч. Айтматов, В. Астафьев, В. Распутин, В. Беловлар юк дип лаф ордылар, уфтандылар. Ачык ишекне көч белән алудан ни файда! Юк әйбер күп кабатлаудан гына, күктән җиргә төшеп, җисемләшә алмый. Сүз булган кадрларны идея-эстетик яктан үстерү, казанышларын күрсәтә белү, җылы сүзгә генә түгел, тәнкыйтькә дә колак салырга өйрәтү, язучылар оешмасында да, матбугат һәм нәшрият эшчәнлегендә дә иҗади атмосфера тудыру хакында барырга тиештер.

Шигырь тәнкыйте дә поэзия каршында бурычлы. Аңа үпкә белдерүләрне нигезсез дип булмый. Чынлыкта «шигырь тәнкыйте» дигән нәрсә үзе үк шартлы төшенчәгә әйләнеп бара. Тәнкыйтьчеләрнең иң актив дигәннәре башка жанрларга яисә теорияне, әдәбият тарихын өйрәнүгә күчеп бетте дияргә була. Бу өлкә прозаикны шагыйрьдән аермаган битараф, аз мәгълүматлы кешеләр кулына калып бара. Яшьләрдән тәнкыйтькә килүчеләр аз, аларны үстерүгә тиешле игътибар бирелми. Рецензияләрдә шагыйрьнең индивидуальлеген ачу мактауга кайтып кала, җитешсезлекләр йомгак алдыннан әйтелә торган җөмләдә туплана. Әдәбиятның мәгънәви ягы, эчтәлеге, идея яңгырашы турында язгалыйбыз, ә инде осталык, техника мәсьәләләре көн тәртибеннән бөтенләй алынды дияргә дә була.

Яшь тәнкыйтьчеләр арасында русча каләм тибрәтүчеләр бөтенләй диярлек юк. Заманында республикада тәрҗемәчеләр әзерләүгә зур игътибар бирелде. Бу юл үзен әллә ни акламады, аларны Мәскәүдән эзләү файдалырак булып чыкты. Ә тәнкыйтьче үзебезнең арада яшәргә, әдәби процесста кайнарга тиеш. Шуннан башка аның эшчәнлегеннән файда булмаячак.

Поэзия турында сөйләшү барышында урта кул әсәрләрнең күп басылуы, фикерләүдәге сорылык, шаблонлык турында әйтелде инде. Поэзия тормыштан артта кала дигән бәя дә дөреслектән артык ерак түгел. Битарафлыкка, салкынлыкка, ваемсызлыкка каршы поэзиядә тиешле көрәш алып барылмый.

Җәмгыять каршындагы җаваплылык белән шәхси азатлык, кеше белән җәмгыять, кеше белән тирәлек арасындагы яңача борылыш ала барган мәсьәләләр дә шигъри музаларны битараф калдырмаска тиеш.

Күп милләтле совет поэзиясенең аерылгысыз өлеше булган татар шигърияте кеше рухы матурлыкларын тулырак ачу юнәлешендә үсүен дәвам итәр дип ышанасы килә.

# БУАЛАР ЕРЫЛГАН ВАКЫТ

Сөйләшүне башлап җибәргәндә прозаик Вакыйф Нуруллин да, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин да сүзне күбрәк китап кибете тирәсендә куерттылар. Китап сатуны оештыру мәсьәләләре ачыкланды. Кыскасы, алар: «Ни сәбәпле киштәләрдә өем-өем шигъри макулатура ята?» — дигән сорауга җавап эзләделәр. Бик урынлы сорау, тик нәтиҗә генә бераз сәеррәк булды бугай. Чөнки шигъри сүзнең кадере кимүдә яшь авторларның өлеше зур дип билгеләнде. Шуңа күрә, яшьләр иҗатына үтә таләпчән булырга, кирәк икән — аларның кулына ташка басылган китап урынына кулъязма тоттырудан да тартынмаска кирәк дип расланды. Хәтта яшь әдипнең беренче китабы дәүләт өчен ничә сумга, ничә тиенгә төшүен дә онытмадылар...

Мондый вакчыллык бәлки кирәктер, бәхәсләшмим. Әмма шигърият үзенең позицияләрен соңгы вакытта бераз югалткан икән, кибет киштәсенә генә күз салып сөйләшү аз. Чөнки әдәбиятның иң сугышчан жанры поэзиянең аксавы безне уйланырга, бик нык уйланырга мәҗбүр итәргә тиеш. Бүген — шигърият, иртәгә — проза, драматургия, аннан соң — гомум татар әдәбияты аяныч хәлдә калмасмы? Әдәбиятыбызның шаулап чәчәк атуына тулы гарантия бармы?

Бактың исә, бүгенге поэзия язмышы турында сөйләшү — әдәбиятыбыз хакында да икән.

Һәр әдәбиятның киләчәге — яшьләр. Шуңа сүзне мин дә яшь авторларга булган мөнәсәбәттән башлыйм.

Әдәбиятка яшьләрнең һәркайсы үзенчә килә. Спортчылар теле белән әйтсәк, старт — я уңышлы, я уңышсыз. Әмма эш стартта гына түгел бит әле, финишта... Әдәбиятка чәчрәп килеп кереп тә, ярты юлда сулышы кысылып, хәле беткән шагыйрьләрне беләбез. Киресенчә, беренче иҗат ялкынында өтелеп һәм янып та соңыннан гаҗәеп ачылган талантлар да бар лабаса.

Узган гасырның утызынчы еллар башында рус әдәбиятында яңа бер йолдыз кабына. Ул Николай Васильевич Гоголь була. Менә бу язучының әдәбиятка аяк басуы бик кызыклы һәм гыйбрәтле.

Н. Гоголь 1829 елны Петербургка күчеп килә, шул ук елда беренче әсәре «Ганц Кюхелгартен» исемле поэмасы дөнья күрә. Яшь автор әдәбият сөючеләрне таң калдырмакчы була. Ләкин поэма үз укучысын тапмый, автор барлык экземплярларны сатып ала да яндыра.

Бу чор рус әдәбияты тарихында ташкынлы чак була. Табигый таланты булган Н. Гоголь шул ташкынга кушылып китә һәм елдан-ел аның әдәби сәләте ачыла бара. Күп тә үтми, ул рус реалистик әдәбиятына нигез салучыларның берсе булып өлгерә. Моның белән нәрсә әйтмәкчемен: әдәбиятка көчле яшьләр килсен, талантлар ачылмый калмасын өчен гайрәтле һәм кайнап-ташып торган әдәби мохит булу шарт.

Безнең бүгенге поэзиядә шундый ташкын бармы? Әдәбиятыбызга көчле дулкын куптаручы давыл җитми түгелме? Тукай кыюлыгы, Такташ дуамаллыгы, Муса батырлыгы кирәк безгә! Һәм шул сыйфатларны яшьләребезгә мирас итеп калдырасы иде, аларның иҗатына карата тагын да игътибарлы булсакчы. Югса, илебез тарихында авыр, бик авыр көннәр булды. Шундый чакларда да яшьләргә, аларның беренче китабына игътибар кимемәде. Киресенчә, партиябез яшь авторларның китабын вакытында һәм сыйфатлы итеп бастыру җәһәтеннән даими эш алып барды. Егерменче еллар башында булсынмы, Бөек Ватан сугышы чорындамы — шагыйрьләребезнең беренче китаплары каты тышлык белән һәм заманына күрә матур гына бизәлеп чыгарылды.

Бүген элеккеге гыйбадәтханә гөмбәзләрен алтынга манарлык хәлебез бар икән, ник әле яшь авторның кулына югары зәвык белән эшләнгән тәүге китабын тоттырмаска? Хәтта классикларның томнарыннан да матуррак итеп бастырыйк ул беренче җыентыкны. Моның өчен, билгеле, яшь авторның әсәрләрен нәзек иләктән үткәрү зарури.

Язучылар союзы каршында иң принципиаль әдипләрдән торган махсус комиссия төзик, аның беренче китапка булган фатихасын алыйк.

Күз алдына китерик: укучылар дәфтәре калынлыгы һәм төссез генә бизәлгән йөз-йөз ун шигырь тупланган җыентык өстәлебездә ята ди. Янәшәдә иң оста рәссамнар бизәгән һәм илле-алтмыш әсәрдән (чын мәгънәсендә шигъри җимешләрдән) торган китап. Сүз дә юк, укучы соңгысын сайлар, бу — бер. Икенчедән, авторга без нинди олы куаныч китерербез? Аның үз-үзенә ышануын арттырырбыз? Ә ышаныч, мәгълүм ки, көч-кодрәт бирә. Бу безнең өчен мөһим, бик мөһим нәрсә.

Поэзиянең җанлануы турыдан-туры гомум әдәби хәрәкәткә бәйле. Ә әдәбият язмышы — үз чиратында халкыбыз язмышы ул.

Бүген балалар бакчасына йөрүче сабыйлар теленә игътибар итик тә, әдәбиятның иртәгесен күзаллыйк. Хәтта кайбер мәктәпләрдә дә ана телен өйрәнүгә игътибар итмиләр. Янәсе, татарча укыган балалар надан кала, кешеләр арасына чыга алмый. Бу фикерне укытучылар авызыннан ишетү икеләтә авыр. «Татарча сөйләшеп, коммунизм төзеп булмый»,— дип кем әйтә? Кеше нинди генә дәрәҗәләргә ирешмәсен — ана телен белми икән, аны югары культуралы дип һич тә әйтеп булмый. Чөнки үз халкының тарихын, телен, әдәбиятын һәм сәнгатен аңламый торып, эчке гармониягә ирешү мөмкин түгел. Ә бу гармония фәкать кече яшьтән, бишектән тәрбияләнә. Шуңа күрә дә республикабыз радиосы һәм телевидениесе, опера һәм балет, драма театрларына балалар өчен ана телендә җитди тапшырулар, спектакльләр әзерләргә вакыттыр. Әйтик, мультипликация фильмнарын татар халык әкиятләре сюжетларына нигезләп һәм ана телендә яңгыратырга мөмкин бит. Ә опера һәм балет театрында татарча язылган җитди әсәрне сәхнәләштерергә нәрсә комачаулый? Милли кадрлар булмавымы? Аларны кем тәрбияләр?

Бу мәсьәләләрне хәл итүгә җәмәгатьчелек җиң сызганып тотынмаса, алләниләр эшләп булмас.

Кемдер: «Балалар русча да аңлый, нигә акча әрәм итәргә?»— дип сорар. Моңа бер генә җавап: «Халык рухын акчага сатып алу мөмкин түгел. Бер генә юл — аны күз карасы кебек сакларга!»

Шулай ук, иҗади багланышлар әдәбиятны җанландыра, язучыларның активлыгын үстерә. Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Муса Җәлилләр чорына гына күз салыйк. Татар, башкорт, казах, үзбәк һәм башка республика әдипләре бер-берсе белән якыннан танышып, аралашып яшиләр. Әсәрләренә рецензияләр языла, хатюлламалар аша киңәшләр һәм тәкъдимнәр җиткерелә. Мисал дисезме? Үсеп килүче яшь башкорт прозасына утызынчы еллар уртасында талантлы әдибә Һадия Дәүләтшина килә. Аның беренче хикәяләр җыентыгы Уфада дөнья күрә. Ә Казанда Муса Җәлил шул китапка карата булган тәэсирләрен язып чыга. Мондый мисалларны татар — казах, татар — үзбәк, татар — рус әдәбиятлары нигезендә күпләп очратырга мөмкин. Ә соңгы егерме ел эчендә бу эш сүрелде. Нибары дүрт-биш елга бер мәртәбә тансык кунак рәвешендә әдәбият бәйрәмнәренә баруга кайтып калды. Көндәлек аралашу, җан дус һәм киңәшче булулар югалды. Без үз кабыгыбыздан чыга алмыйбыз. Гомер-гомергә интернациональ рухлы булган татар әдәбиятын бу хәл бизәми. Әйдәгез, каләмдәшләр, капкаларны иңенә ачып, кунаклар каршылыйк, юл таягына таянып, сәфәр чыгыйк. Илләр күрик, үзебезне дә күрсәтик. Моның әдәбиятыбызга шифасы тими калмас.

Уйлап карасак, бүгенге көнгә кадәр СССРда яшәүче төрки телле халыклар әдәбияты үрнәкләрен тәрҗемәдә укыйбыз. Ни өчен әле казах, үзбәк, каракалпак, кыргыз, башкорт, кумык, балкар һәм башка карындаш халык әдипләренең әсәрләре кибетләребездә сатылмый? Безгә беренче чиратта төрле халыклар телендә чыккан әдәби-политик журналларны һәм китапларны алу мөмкинлеге тудырган «Дуслык» кибете бик кирәк. Интернациональ дуслыкның чын, нык күперен салырга вакыт җитте. Ул күпердән башлап язучылар утырган кәрваннар да чыгарга тиеш дип уйлыйм.

Билгеле, югарыда әйтелгәннәр шигъриятькә бик көчле тәэсир итсә дә, төп факторлар түгел әле. Пегасның канатлары хәлсезләнә икән, моның төп сәбәпләрен шигъриятнең үз асылыннан эзләргә кирәктер. Бүгенге татар поэзиясенә нәрсә җитми? Беренче нәүбәттә — көрәш ялкыны.

Кол Гали «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында шәхеснең рухи азатлыгын, Тукай милләтебезнең телен, мәдәниятен якладылар. Такташ поэзиясе яңа тормыш өчен барган көрәш ялкынын дөрләтеп җибәрде. Зәңгәр төсләргә бай, романтик сулышлы әсәрләре замандашларын яңадан-яңа батырлыкларга әйдәде.

Илебезгә фашист яулары ташланды, озакка сузылган тиңдәшсез давыл-гарасат купты. Татар шагыйрьләре кулларына корал тотып һәм каләм тотып афәт ялкынына ташланды. Ирләребез сыгылсалар да, сынмадылар. Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алишларның поэтик аһәңе илләрне һәм кыйтгаларны тетрәндерде, үлемнең үзен үтерде. Ир арысланнарыбыз яу кырында ятып калсалар да, җырлары әйләнеп кайтты, күңелләребезне һәм уйларыбызны биләде.

Менә шушы киң колачлы һәм нык бәдәнле татар поэзиясе илленче еллардан бирле көрәш рухын сүрелдерә төште. Аның урынын калын-калын «мәхәббәт китап»-
лары яулады. Сүз дә юк, шигърият мәхәббәт сүзеннән башка яши дә алмый. Бары
тик, шагыйрь әйтмешли: «Ул да — урыны белән, аз-аз гына» кирәктер. шат
Бүгенге татар поэзиясенә кешеләрнең рухи сафлыгы өчен көрәшү җитми. Әйтер

идем, мөгез чыгарулары да булган ялкынлы сүз юк. Ник Владимир Высоцкий, Булат Окуджава һәм башкалар халык арасында популяр? Чөнки алар торгынлык чорында акны — ак, караны — кара дип әйтергә курыкмадылар. Шуның аркасында аларны поэзия аренасына чыгармый да тоттылар. Җырны читлеккә бикләп, тау чишмәсен томалап буламыни? Кульязмалары кулдан-кулга күчеп йөрде, җырлары йөрәкләрне иулады.

Я, әйтегез, кыю сүзле татар барды (үз җырларын үзе башкаручы шагыйрь) кем? Кызганычка каршы, җәмәгатьчелек фикерен ярып салган үткен, хәтта әче телле шагыйрь табылмады.

Бүгенге негатив күренешләрне фаш итәсе урынга, безнең шагыйрьләр гомерләрен мәхәббәт бакчасында, я тузан баскан чал тарихханәләрдә үткәрделәр. Һич югында кабер ташындагы язмаларга, казык башындагы чүлмәкләргә, иске тегермәннәргә карап үткәннәрне сагындылар, күз яшьләрен түктеләр. Шулай итеп өч дистә ел үтеп тә киткән, ә офыкта шигъриятебезнең Таң батыры һаман күренми. Йөрәкле шагыйрьләребез Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмовларыбыз бар барын. Тик аларга Юрий Кузнецов, Леонид Мартынов, Олжас Сөләймановлар үренә күтәрелергә әллә мәйдан, әллә сүз иреге җитмәдеме? Әгәр шулай икән, моның өчен фәкать алар көрәшергә тиешләр иде. Белүебезчә, Сергей Есенин, Һади Такташлар халыкның аңын уятырлык, сискәндерерлек, хәтта кемнәрнеңдер дәрәҗәсенә сугарлык шигъри сүзләре өчен ачыктан-ачык та, астыртын рәвештә дә эзәрлекләнделәр. Алар, шул эзәрлекләүләргә дә карамыйча, поэтик хакыйкатька тугры булып калдылар.

Мин аталып үткән шагыйрьләребез күтәргән олы фикерләрне инкарь итәргә җыенмыйм. Һәм бу эш мөмкин дә түгел. Кыю гына әйтелгән шигъри үрнәкләр дә юк түгел. Мисал өчен Равил Фәйзуллинның «Космополит түгел» исемле шигырен алыйк. Моннан унсигез ел элек язылган әсәрендә шагыйрь милли чикләнгәнлек, шовинистик рухка каршы чыккан иде.

*«Минеке» дип булмим кукне, айны,*
*мөһер сукмыйм ел фасылына.*
*Милләт исемен такмыйм урман-суга,*
*агач-ташның асылына.*

Күренеп тора, кыю фикер. Бигрәк тә бездә милли мәсьәләләр тулысынча хәл ителде дип, күкрәк каккан бер мәлдә әйтелүе олы батырлык таләп итә иде.

Кызганычка каршы, бу шигырь башка телләргә тәрҗемә ителмәде булса кирәк. Әллә тәрҗемә кылынып та, Р. Фәйзуллинның китапларына керми калдымы? Һәрхәлдә, адресатына шагыйрь фикере барып ирешмәде шикелле.

Әле берничә ел элек кенә «авырткан» мәсьәләләргә кагылган, «тыелган» проблемаларны күтәргән әсәрләр басылмый иде. Хәзер илебездә сафландыргыч демократия җилләре исә. Җәмгыятебезнең иң четерекле якларын да ачып салган әсәрләргә юл ачык. Ә татар әдипләренең «андый» әсәрләре юк. Бу хәл безне сагаймырга тиеш. Бүгенге көннең шаулы мизгелләрен дә чагылдыра алмый калмасак иде. Бигрәк тә шагыйрьләребез кыю, фикерле әсәрләрен яза алса иде. Буалар ерылган вакыт.

**Радик НУРЕТДИНОВ.**

# ТАРИХ — ИЗГЕ

(ИЛТАНИ ИЛЯЛОВАНЫҢ «ТЕАТР ИМЕНИ КАМАЛА» ДИГӘН КИТАБЫ ТУРЫНДА)

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры турында язылган бу тарихи очерклар, һичшиксез, зур игътибарга лаек. Бигрәк тә аның рус телендә язылып, киң катлам укучыларга юнәлтелгән булуы авторга, шулай ук китапны чыгарышуда ярдәмләшкән редакторга, рецензентларга зур җаваплылык йөкли.

Озын иҗат юлы үткән Татар дәүләт академия театры, аны тудыручы артистлар, режиссерлар, драматурглар һәм әледән-әле өстәлеп торган яшь яңа көчләр, аеруча соңгы төркем — щепкинчылар килгәч, театрның яңа баскычка күтәрелүе илебездәге алдынгы театрлар сафына басуы турында китапта яхшы ук тулы һәм дөрес әйтелгән.

Театрыбыз һәм аның бүгенге спектакльләре турында алдынгы рус театрлары фонында карап, әдәби яктан оста итеп язу шулай ук бик әһәмиятле.

Театрның туу тарихында төп рольне уйнаган шәхесләр И. Кудашев-Ашказарский, Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская һәм беренче драматурглар Г. Камал, К. Тинчурин дип күрсәтү дә дөрес дип саныйм.

Театрның үсешендә зур роль уйнаган драматурглар Г. Камал, К. Тинчурин, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, М. Фәйзи, Ф. Бурнаш, Хәй Вахит дип күрсәтү һәм соңгы елларда Т. Миңнуллин ролен күренеклерәк итеп язуны да дөрес дип уйлыйм.

Соңгы 20 ел эчендә театр үсешенә аның баш режиссеры «СССР халык артисты Марсель Сәлимҗанов күрсәткән иҗатка басым ясап әйтү дә, минемчә, бик урынлы. Аеруча аның режиссерлык хезмәте, әсәрләрне сәхнәләштерүдә керткән яңалыклары, пьесада сурәтләнгән образларның рухи халәтләрен ачуга бәйләнгән моментларны тулы һәм дөрес итеп ача белүе турында язылган юллар китапны яхшы ук күтәрәләр.

Кыска гына булса да Ш. Сарымсаков, Г. Исмәгыйлов, Г. Юсупов, Х. Уразиков кебек режиссерлар хезмәтенә җылы һәм дөрес бәһа биреп узу да бик яхшы.

Кыскасы, Камал театрының соңгы 25—30 ел эчендәге иҗат эшләренә, аның үсешенә нигездә дөрес бәя бирелә дип әйтергә мөмкин.

Әмма бу зур һәм җаваплы хезмәт белән (ул 328 бит күләмендә) яхшылап тынышкач бик күңелсез һәм канәгатьләнмәү тәэсире кала. Чөнки тарихи очеркларның авторы Г. Камал театры 80 еллык тарихының беренче 35 елын белми, яки белгән кадәресенең дә кайбер фактларын бозып күрсәтә.

Совет дәүләте төзелгәч татар театры сәхнәсенә профессионал яктан өлгергән артистлар, режиссерлар кадры әзерләү өчен 1922—23 елда Казанда татар дәүләт театр техникумы ачылу зур бер тарихи хәл булды һәм ул менә инде 60 ел буе Г. Камал театры өчен дә, шулай ук башка театрлар өчен дә артистлар һәм режиссерлар әзерләп килә. Әмма ни өчендер бу бик әһәмиятле фактны автор тарихтан төшереп калдыра диярлек. Диярлек кенә диганем шуннан — чөнки 137 биттә, 1930 нчы елгы артист кадрларның кабул килүләре турында язылган буталчык җөмләләрдә мондый сүзләр бар: «кайберәүләр техникум тәмамлагач килеп кушылды, алар — Рәшидә Җиһаншина, Галимә Ибраһимова, Габдулла Сәгыйтов, Нәҗиб Гайнуллин, Бакер Юсупов, Газиз Зыятдинов, Мәҗит Илдар, Ибраһим Гафуров, Уральский II, ә башкалары Фуат Халитов, Гөлсем Камская, Фатыйма Камалова, Мингали Надрюков башка театрлардан». Тарихны болай язу чеп-чи наданлык. Ниндидер бер билгесез техникум телгә алына. Әгәр ул театр техникумы булса, анда, техникумда укучылар арасында бөтенләй булмаган Илдар Мәҗит, Уральский II кебек артистлар кабул килеп кергән?

Ә хакыйкать, тарихи дөреслек, театр техникумын беренче биш-алты ел эчендәге (1926—1932) чыгарылышларда тәмамлап Г. Камал театрының иҗат үсешендә зур роль уйнаган артист, артисткалар, режиссерлар кайда? Алар — Х. Сәлимҗанов, Г. Нигъма-

туллина, Г. Кайбицкая, Г. Булатова, Х. Кәтиев, К. Бариев, Р. Ишморатов, З. Закиров, К. Тумашева, М. Чанышева, Ф. Саллави. (1926—27 чыгарылыш) Г. Исмәгыйлов, Г. Таһиров, Г. Ибраһимовалар әз генә соңрак. Шулай ук А. Юсупов, М. Миндубаева, Ф. Халитов, В. Минкина, Н. Гайнуллин, С. Өметбаев h. б. h. б.

Г. Камал театры белән беррәттән театр училищесы да үсә, яңара барды бит. Анда укыту өчен профессионал яктан нык үскән, театр сәнгатен бөтен тирәнлеге белән аңлаган яңа тип укытучы кадрлар килде. Нигә ул турыда да тулы итеп язмаска иде?

И. Илялова егерменче елларда Г. Камал театры спектакльләре бары тик натуралистик, ягъни нәкъ тормыштагыча булырга тиеш дигән принциптан чыгып сәхнәләштереләләр иде, ди һәм болай яза: «Хәтта Кәрим Тинчуринның үткен сатира стилендә язылган «Американ» пьесасы да 1924 нче елны тормыш-көнкүреш комедиясе (ягъни бытовая комедия) итеп сәхнәләштерелде».

Ә дөресе шул: ул елларда күп кенә режиссер һәм артистлар спектакльләрне барлык детальләре белән тормышка мөмкин кадәр якынрак итеп сәхнәләштерергә тырышалар иде. К. Тинчурин да күп кенә спектакльләрне шулай тормышчанрак итеп сәхнәләштерергә тырышты. Ләкин барлык очракта да диярлек тормыш дөреслегенең күп детальләренә кадәр дөрес чагылдырырга омтылган Тинчуринны театрның шартлы сәнгать икәнен яхшы аңлаган Тинчурин, тормыш дөреслегеннән бигрәк сәхнә дөреслеген алга сөргән, сәхнәнең күтәренке рухын, гүзәллеген яхшы сизгән художник Тинчурин җиңә килде. Ә инде «Американ» спектакленә килгәндә бу аеруча шулай булды. Юк! Ул, автор язганча, бытовая комедия булып түгел, әсәрнең үзендә язылганча, кискен сатира булып яңгырады. Режиссер буларак та, автор буларак та нәкъ шулай яңгыратырга тырышты К. Тинчурин!

Бу юлларны мин ишеткән, спектакльне күргән кеше булып кына түгел, ә спектакльдә катнашкан, студент ролен башкарган артистларның берсе буларак та язам. Ә инде Салих Сәйдәш музыка язган «Студентлар җыры», театр техникумы укучылары башкаруында җырланган дәртле җыр бөтен залны яңгыратып тора иде.

Гомумән, К. Тинчурин драматургиясен, режиссерлык хезмәтләрен, шулай ук артистлык иҗатын натурализм юлы белән тудырылган иҗат дип кенә аңлату зур хата. Ул сәхнәнең шартлы сәнгать икәнен яхшы аңлый торган реалист художник иде.

Ә инде «Кандыр буе», «Алар өчәү иде» әсәрләре белән ул үзен чын мәгънәсендә социалистик реализм юлына баскан художник итеп танытты. Гомумән Г. Камал театрын яктырткан бу тарихи очеркларда, аеруча китапның беренче яртысында, фактларны белмичә язылган хаталар һәм белә торып та аңлы рәвештә сызып ташланган хәлләр, иҗат «җимешләре» әз түгел. Мин аларның кайберләрен генә телгә алып китәм. 65 нче бит. 1923—1933 еллар эчендә театрның баш режиссер вазифасын Кәрим Тинчурин, Гомәр Дәвишев, Зәйни Солтанов, Риза Ишморат, Касыйм Шамилләр алып барды, диелә. Касыйм Шамилнең беркайчан да баш режиссер булганы булмады. 101 нче биттә «Кандыр буе» әсәре турында яхшы ук тулы һәм дөрес фикер әйтелә. Ләкин рольләрне башкаручыларны санаганда күп кенә артистларның уйнавын дөрес күрсәтү белән бергә Уральский I дә телгә алына. Дөрес түгел. Бу спектакльдә Уральский I уйнамады. Ә спектакльдә Балан Сафа образын гаҗәеп бер осталык, үзенчәлек белән иҗат иткән Гата Уральский II телгә дә алынмаган. Бу бик тыйнак һәм тырыш артист үз иҗатында, аеруча шушы образы белән күренекле эз калдырды. Андый бәхет артист иҗатында сирәк була. Ә менә шул сирәк очракта килгән иҗат уңышын да аңардан тартып алып, икенче артист исеменә язу — бу инде театр белгеченең зур хатасы.

...Мин Ленинградка Югары сәнгать курсларына җибәрелеп өч ел укыганның соңында партия өлкә комитеты тарафыннан чакырып кайтарылдым һәм Камал театрының баш режиссеры итеп билгеләндем. Ә китап авторы 1930—1940 еллар эчендә минем театрда җаваплы эш алып баруыма күз йома. Мәсәлән, мин режиссер буларак В. Киршонның «Искиткеч эретмә» комедиясен сәхнәләштерәм. Аның яхшы әсәр булуы һәм тамашачыларның спектакльне яратып кабул итүләре турында 100—101 нче битләрдә сүз бара, мактап языла. Әмма зур көч куеп, яхшы спектакль барлыкка китергән төп иҗатчы режиссер Р. Ишморатов исеме төшереп калдырыла. Шулай ук минем иҗатым булган «Икмәк» спектакле дә икенче режиссерлар эше итеп калдырыла.

Автор 1934 нче елны режиссер буларак минем тарафтан сәхнәләштерелгән К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» драмасын бөтенләй театр тарихыннан ук төшереп калдыра. Ә бит бу спектакль Кәрим Тинчуринның үзе тарафыннан 1934—35 ел сезонында куелган иң яхшы спектакль дип бәяләнгән иде. Матбугат битләрендә күп кенә язылган бу фактны театр тарихын язучы Иляалованың белмәве бик гаҗәп. Белә торып та төшереп калдырган булса, тагын да гаҗәбрәк.

Театрда борынгы темаларга куелган спектакльләрнең уңышлы баруы турында язгач (146 бит), автор бүгенге темаларга күчеп болай ди:

«Современная же тема в предвоенные годы была представлена в основном целой серией (!) интригующих «шпионских» пьес о «врагах народа» — «Давлет Бадриев» Г. Иделле, «Родина» Р. Ишмурата, «Испытание» С. Баттала.» Игътибар итегез: 1936—

1938 еллар Германия фашизмының котырынып сугышка әзерләнгән чоры. Коммунист автор һәм режиссер буларак та, театрыбызның художество эшләре җитәкчесе буларак та мин дә «Сынау» пьесасының авторы Салих Баттал да, «Ватан» пьесасын сәхнәләштерүче бөтен көчен совет дәүләтенең иминлеге өчен көрәшкә юнәлткән режиссер Сарымсаков та Ватан алдында торган изге бурычларыбызны яхшы аңлый идек.

И. Илялова шпионнар турында пьеса язгансыз, сәхнәгә куйгансыз дип безне мыскыл итә. Ә сугыш башланган беренче көннәрдә үк безнең арабызга кереп сырышкан дошманнар, шпионнарның Татар дәүләт академия театрыннан 2—3 квартал гына ераклыкта (Гоголь урамы) урнашкан хәрби складта кызылармеецлар өчен әзерләнгән кием-салымны ут төртеп яндырулары, коточкыч бер һәлакәт булды. Бер Гоголь урамында гына оештырдымы шпион-диверсантлар мондый дәһшәтле фаҗигане? Юк, түгел! Бер Казанда гынамы? Юк!

Г. Камал театрында мин эшләгән чордагы уңышлар турында Татарстан китап нәшрияты 1975 елны бастырып чыгарган «Татар Совет театры» китабында мондый юллар бар: «Татар дәүләт академия театры идеялелек һәм художество осталыгы өчен көрәш билгесе астында үсә, үз заманының мөһим проблемаларын күтәрә. Шуңа күрә 30 нчы еллар татар театрында социалистик реализмның ныгып урнашуы өчен хәлиткеч этап була» (161 бит).

**Риза ИШМОРАТ.**

* * *

Зур һәм бай иҗат хәзинәсе туплаган Татар дәүләт академия театры турында, аның оешу һәм яшәү тарихы хакында җитди хезмәт язу күптән өлгергән мәсьәлә иде инде. Бу эшкә тәҗрибәле һәм абруйлы театр белгече алыну тарих хезмәтенең уңышлы булуына, театрыбыз тарихына лаеклы чыгачагына ышаныч кузгатты. Чөнки Илтани Илялова менә инде ничәмә дистә еллар татар театр тәнкыйте өлкәсендә җиң сызганып эшләп килә. Яңа спектакльләр турында аның мәкалә һәм рецензияләре, Татарстан культура министрлыгының яңа спектакльләр һәм концерт программалары кабул итү комиссиясендәге төпле чыгышлары аны республикадагы театр тәнкыйтенең төп көчләреннән берсе итеп таныттылар. Без аның белән бергә берничә мәкалә яздык. Татар артистларының уен сәнгате турындагы китабын һәм башка хезмәтләрен дә исәпкә алганда, Академия театрына багышланган китапның да уңышлы булачагына ышаныч тууга гаҗәпләнмәскә мөмкин.

Сөенеп каршыладык: китап чыкты. Ләкин бу сөенечне вакыт-вакыт гаҗәпләнү катыш көенеч болыты каплады. Минем үзем өчен китапның редколлегиясе составында фамилиямне күрү шаккату булып әверелде, чөнки бу турыда беркем, беркайда минем белән алдан сөйләшмәде, ризалыгымны сорамады, кульъязма белән танышырга тәкъдим ясамады. Гаҗәпләнергә генә кала!..

И. Илялова китабында театрыбызның 80 еллык бай тормыш һәм иҗат юлы күпмедер күләмдә тулы булып күз алдына баса. Әйбәт һәм оригиналь бүлекләрдән берсе итеп мин соңгы бүлекне санар идем. Монда автор материалны яхшы белә, театраль процесс — аның күз алдында барганга күрә — китап авторы тарафыннан тирән кичерелгән һәм төшенелгән. И. Илялова актерлык сәнгатен өйрәнүдә көчле, аның тәнкыйтьче куәте һәм мөмкинлекләре спектакльләрнең уйналу дәрәҗәсен, артистларның башкару осталыгын тикшергәндә чагыла һәм ачыла. Монда аерым табышлар аз түгел, бигрәк тә соңгы спектакльләргә анализ-бәяләр тулы һәм ышандыра.

И. Илялованың йомшак ягы исә — драматургик мирасны белмәү. Китап белән танышкач, автор кайбер әсәрләрне укымагандыр, кеше сөйләве буенча, рецензияләрдән һәм моңарчы язылган хезмәтләрдән чыгып кына фикер йөртәдер дигән шик туа. Мәсәлән, «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе дин әһелләрен фаш итә торган әсәр дип тәкъдим ителә (14 бит), хәлбуки, пьеса үзәгендә сәүдәгәр образы тора. «Казан сөлгесе» комедиясендә «тарихи үткән гади, гадәти кешеләр— крестьяннар дөньясы аша күрсәтелгән» (48 бит), дип әйтеп буламы? Һ. Такташ әсәренең ни өчен «Җир уллары трагедиясе» дип аталуын инде расладык, автор аны һаман да искечә «Җир уллары» дип кенә ала (50 бит). К. Тинчуринның «Ил» мелодрамасында сыйнфый көрәш күрсәтелми (145 бит), дип аның эчтәлеген яхшы белгәндә язып булмый. Т. Гыйззәтнең ике әсәре бер булып киткән («Мактаулы заман яки Таймасовлар», 150 бит). Н. Исәнбәтнең «Мәрьям»е сугыш турында язылган беренче әсәр түгел (159 бит), аңарчы Т. Гыйззәт, Ф. Кәрим, М. Әмир һ. б. пьесалары языла. «Миңлекамал» драмасында үзәк героиня өчен «бернинди шәхси тормыш яшәми» дип язу да бәхәсле (177 бит) һ. б.

Теоретик гомумиләштерүләр ясаганда да китап авторы кайбер үкенечле төгәлсезлекләр җибәргән. Мәсәлән, «Автордан» дигән бүлекчәдә үк аның «егерменче еллар — яшь татар сәхнәсенең реалистик үсеш юлында формалашуы өчен кискен көрәш чоры» дип билгеләве гаҗәпләнү тудыра (3 бит). Без татар театры Бөек Октябрьгә кадәрге чорда

ук реализм юлында формалашты һәм уңышларга ирешә дип беләбез. Ә 20 һәм 30 елларда инде театрда асылда социалистик реализм формалаша. «Социалистик реализм» димәктән, аның төп сыйфатларын И. Илялова чикләп тәкъдим итә, «чынбарлыкны дөрес итеп, аны революцион үсештә сурәтләү» дигәндә, аңар хас тагын бер төп сыйфатны — тарихи конкретлыкта алып сурәтләүне — «онытып» калдыра (83 бит).

Китапта драматург һәм режиссер Риза Ишморат иҗаты атлап үтелгән. Ә бит «таптап үтсәң үт, атлап үтмә», дигәннәр. Р. Ишморатның Татар дәүләт академия театрында баш режиссер (ул вакыттагыча әйтсәк, художество җитәкчесе) булган дистәгә якын ел, аның 20 еллар ахырыннан башланган драматургиясе — бу авторның әсәрләре бигрәк тә 50 елларда репертуарда актив булалар — һич тә мондый мөнәсәбәткә лаек түгел. ТДАТ ның 50 еллар тарихында гомумән уңайны күрү юк. Бу елларда «Зифа», «Шайтан таягы» кебек, М. Җәлил турындагы спектакльләр туды. Аларга игътибарсызлык үсеш процессының нинди каршылыклар эчендә баруын күрергә дә комачаулый. Китап авторы театр тарихын барлаучы һәм өйрәнүчеләргә карата да илтифатсызлык күрсәтә. СССРның халык артисты Х. Әбҗәлилов турында, мәсәлән, иң тулы итеп, беренче буларак сәнгать фәннәре кандидаты Х. Кумысников язды. Татар театрында романтизм проблемасын башлап сәнгать фәннәре кандидаты Ф. Кадыйрова күтәрде. Бөек Октябрьгә кадәрге театрны, шул исәптән «Сәйяр» труппасы эшчәнлеген дә, галимнәр Баян Гыйззәт, Хәсән Гобәйдуллин, бигрәк тә һәнүз Мәхмүтов нык өйрәнделәр. Боларга мөрәҗәгать итү (ссылка бирү) юк, хәлбуки китапта аларның фикерләре шактый ук мул очрый. Үземнең табышлар һәм фикерләр дә китапка И. Илялованыкы булып кереп киткән (мәсәлән, Ф. Бурнаш партиялелек турында, К. Тинчуринның театр эшчеләренең I конференциясендәге доклады, андагы үзәк фикерләр, аларның теоретик нигезләре һ. б.). Мондый ачышлар артык зур да түгелдер, ләкин аларга дистәләрчә ел «казыну», чыганакларны табу һәм җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә киләсең, аларның театр тарихын тулы күзаллатуда рольләре зур, һәм аларның ансат кына кемнекедер булып китүе, әлбәттә, күңелне рәнҗетә. Компелятивлык — популяр һәм дәреслек характерындагы хезмәтләргә хас булса һәм гафу ителсә дә, фәннилеккә дәгъва кылган хезмәт өчен ул гафу ителми,— плагиат була. Мондый фактлар, кызганычка каршы, И. Илялова китабында аз түгел.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: олы һәм дәрәҗәле театрыбыз турында, аның катлаулы иҗат тарихын өйрәнеп язган бу китапны шул юлда беренче һәм башлангыч адым дип карап, андагы кимчелекләрне бетерергә һәм кабатламаска тырышып, объектив һәм тагын да тирәнрәк тарих язарга кирәк.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН.**

* * *

Бөтен бер театр коллективының тарихын язу үтә җаваплы һәм күп көч куюны сорый торган эш. Әгәр коллективның Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры кебек 80 еллык иҗат гомере, буыннан-буынга тапшырылып килгән данлы традицияләре булса, бигрәк тә. Мондый хезмәттә коллективның үсеш этапларын, тенденцияләрен, юнәлешен билгеләргә, казанышлар белән бергә вакытлы уңышсызлыкларны да күздән кичерергә, һәр чорның репертуарына, актерлык, режиссура, сценография сәнгатенә анализ ясарга кирәк. Алай гына да түгел, биредә гомерләрен шушы сәнгатьне үстерүгә багышлаган йөзләрчә кешеләрнең эшләре бәяләнә, аларның милли театр тарихындагы урыннары билгеләнә. Ә китап, рус телендә чыгып, бөтенсоюз укучысына тәкъдим ителсә, бу җаваплылык тагын да арта. Чөнки татар театры белән якыннан таныш булмаганнар аннан чыгып сәхнә сәнгате турында гына түгел, гомумән халкыбызның бөтен мәдәни байлыгы турында да фикер йөртә.

И. Илялованың «Театр имени Камала» дип исемләнгән китабы алда билгеләнгән таләпләргә бары тик өлешчә генә җавап бирә ала. Авторның төп игътибары моңа кадәр татар һәм рус телләрендә чыккан һәм киң катлау укучыларына яхшы таныш материалны билгеле бер эзлеклелеккә салуга юнәлтелгән. Бу җәһәттән бары тик хезмәтнең 1960—1980 нче елларга багышланган кисәге генә аерылып тора. Бүлеккә И. Илялова үзе катнашкан иҗат процессы, үзе караган спектакльләр, таныш артистлар, режиссерлар турында сүз алып бара. Кызыклы күзәтүләр, җанлы детальләр өстәлгәнгә күрә китапның бу өлеше кызыксыныбрак укыла.

Мондый зур күләмле хезмәтне язарга утырганчы автор иң элек шушы өлкәгә караган бөтен чор газета-журнал мәкаләләрен, архив, музей материалларын өйрәнү, әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашып сөйләшү кебек гадәттә берничә елга сузыла торган «кара» эшне башкарырга тиеш. И. Илялова, кызганычка каршы, әнә шул хезмәттән баш тарткан һәм китабын кемдер тапкан һәм инде каядыр кулланган икенчел материалга нигезләгән. Бу нәрсә китапның кыйммәтен бик күпкә кимetә. Кул астында җитәрлек фактик материалның булмавы, авторга дөрес методика кулланырга, ягъни милли театр

сәнгатен үсеш-үзгәреш диалектикасында ачарга ирек бирми. Хезмәттә И. Илялова нинди дә булса бер чорны ала да аның турында тулы килеш, гомуми планда фикер йөртә башлый. Гәрчә, кагыйдә буларак, һәр театр сезоны, үсешнең һәр баскычы аерым-аерым каралып, нәтиҗәләр иң соңыннан, бүлек ахырында бирелергә тиеш булса да, материал азлыгы шулай ук аерым фактларның гомумиләштерү дәрәҗәсенә күтәрелүенә, ялгыш нәтиҗәләр ясауга китерә. Мисал өчен китапның иң беренче бүлегенә күз салыйк.

Мәскәүдә «Наука» нәшриятында Сәнгать тарихы институты чыгарган күптомлы «Совет драма театры тарихы» дигән капиталь хезмәттә татарлар турында Октябрьгә кадәр үк өлгереп җиткән театрны белгән халыкларның берсе буларак сөйләнә (I т., 61 б.). И. Илялова үзенең китабында бу фикерне тулысынча диярлек кире кага. Ул язганча, «Говорить о полнокровных ансамблевых спектаклях в дореволюционном татарском театре не приходится» (25 б.), «Оформление спектаклей было довольно убогим... Драмы Г. Камала, Островского, комедии Мольера и переводные мелодрамы шли в одних и тех же павильонах, при ровном, бледном освещении». «Что касается костюмов, то общественного театрального гардероба труппы не имели» (27 б.). Бу сүзләрдән соң халыкның өлгергән театры булуы турында уйларга мөмкинме? Юк, әлбәттә. Чынында, татар театрының актерлык, сценография сәнгате, шулай ук яктырту, музыка, костюм кебек сурәтләү чаралары аерым үсеш, формалашу процессы узалар. Автор тарафыннан алар турында әйтелгән фикерләр татар сәхнә сәнгате үсешенең 1911 нче елга кадәрге тәүге этабына карый. «Сәйяр» труппасы Шәрык клубы штатына алынгач, яки соңрак Г. Кариев антрепризасына күчкәч, алар дөреслеккә туры килми. Димәк, ул фикерләрне берничек тә татар театрының Октябрьгә кадәрге бөтен үсеш чорына күчереп карарга ярамый.

Китапның 20 нче елларга багышланган бүлеге дә канәгатьсезлек хисе калдыра. Театр тарихында иң катлаулы, шул ук вакытта иң кызыклы исәпләнгән бу чорда Кызыл Октябрь исемендәге дәүләт театры бинасында 1926 нчы елга кадәр сезон саен диярлек яңа коллектив җыела, баш һәм чираттагы режиссерлар гына түгел, хәтта директорлар, администраторлар да алышынып тора. Чынында мөстәкыйль театр саналырлык еллык труппалар башында торган М. Мутин, К. Тинчурин, Ш. Шамильский, соңрак Г. Девишев, З. Солтанов кебек режиссерлар совет җирлегендә милли театр төзүне һәркайсы үзенчә аңлый, күз алдына китерә, шул өлкәдә үз программасын тәкъдим итә. Табигый, аларның практик эшләре дә бер-берсеннән күпкә аерыла. Мондый шартларда бөтен унъеллык турында берьюлы фикер йөртү түгел, бәлки һәр театр сезонына аерым анализ таләп ителә. Материалга ныклап кермәгәнгә, кызганычка каршы, И. Илялова андый анализны башкара алмый.

Хезмәттә сугыштан соңгы унъеллык турында да шактый ашыгып, күбрәк конфликтсызлык теориясенә бәйле рәвештә генә диярлек язылган. Хәлбуки, Г. Камал исемендәге театр тарихында (сүз уңаеннан, 1939 нчы елда ТДАТка Г. Камал исеме бирелә. Ә «Камал исемендәге театр» дип аталган китапта бу исемнең коллективка кайчан һәм нинди уңай белән бирелүе турында бер сүз дә юк) гаять авыр бу еллар җитди игътибарга лаек. Театрда чорның тискәре тенденцияләре белән кискен көрәш бара һәм авторга периодны әнә шул көрәш күзлегеннән чыгып яктыртырга кирәк иде. Унъеллык бит бөтенләй өметсез түгел. Н. Погодинның «Мылтыклы кеше», Б. Лавреневның «Диңгездәгеләр өчен», М. Кәримнең «Ялгыз каен», дүртәрбишәр елга сузылган тормыш нәтиҗәсе буларак Н. Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов», «Зифа» кебек әсәрләр сәхнәгә куела. Шулай булгач, ТДАТ тарихының бу чорын күбрәк кара төсләр кулланып тасвирлау үсеш-көрәш процессын гадиләштерү түгелме?

Китапның моңа кадәрге күп кимчелекләрен материал азлыгы, дөрес методика кулланмау белән бәйләп булса, йомгаклау өлешендәге яңарыш процессының ТДАТта ун елга соңарып башлануы, 60 нче еллар урталарына күчүе турындагы фикерне берни белән дә аңлатып булмый. Бу театр коллективына ташланган бик зур гаеп. Димәк, ул ун ел дәвамында үсештән туктаган, ил күләмендә барган үзгәрешләр процессыннан, халык язмышыннан, заман проблемаларыннан читтә торган, тормыштан артта калган дигән сүз. ТДАТ практикасына күз салу белән бу фикернең ялгыш икәнлеге күренә. Сәнгатебезгә К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов кебек драматургларның иҗат мирасы кайту, беренче карлыгач «Зәңгәр шәл»нең зур уңыш белән сәхнәләребездә уйналуы, Мәскәү декадасында күрсәтелүе, «Җилкәнсезләр»нең иң беренчеләрдән булып Г. Тукай исемендәге республика дәүләт премиясен алуы, театрга Ш. Хөсәенов, Хәй Вахит, А. Гыйләҗев кебек драматурглар килү, яшь режиссер Р. Бикчәнтаевнең «Беренче мәхәббәт», «Җиргә тапшырылган серләр», «Рәхим итегез» кебек спектакльләре, 1961 нче елда щепкинчыларның кайтуы — болар яңарыш процессының башлануы түгелмени?

Гадәттә зур күләмле хезмәтләрнең кереш һәм йомгаклау сүзләре аеруча игътибар белән языла. Биредә әйтелгән һәр уй, һәр җөмлә төпле, тирәннән уйланылган булырга тиеш. «Камал исемендәге театр» китабының әлеге бүлекләрен укыгач, кызганычка каршы, андый фикерне әйтеп булмый. Кереш бүлегендә автор ТДАТның эшчәнлеген периодларга бүлә һәм аларга кыскача гына характеристика биреп китә. Мисал өчен шул

характеристикаларның берсенә игътибар итик. «В сороковые-пятидесятые годы коллектив стремится создавать художественно целостные спектакли, с единым режиссерским замыслом». Бу юлларны уку белән күңелдә: «Ә нигә кырыгынчы-илленче елларда гына?»— дигән сорау туа. Чынлап та, нигә? Татар театрында режиссура сәнгате беренче труппа дөньяга килү белән үк формалаша башлый һәм аның алдына куелган иң тәүге бурыч — режиссер фикере белән берләштерелгән идея эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан бербөтен спектакль тудыру. Бу бурыч театр үсешенең барлык этапларында да режиссерлар алдында тора һәм, табигый, алар аны үтәргә омтылалар. Шулай булгач, ул ни өчен бары кырыгынчы-илленче елларны гына характерларга тиеш? Бердәй уңыш белән аны ТДАТ эшчәнлегенең бөтен этапларына карата да язып була. Яки китапның йомгаклау өлешеннән икенче бер мисал. Ул 60 нчы елларга карый. «Театр, традиционно славящийся замечательными актерами-мастерами сцены, обогащается талантливой режиссерской мыслью». Татар театрының тәүге елларыннан ук сәләтле артистлары белән танылуы һәркемгә мәгълүм. Ләкин талантлы режиссура белән дә ул бары алтмышынчы еллар урталарында, ягъни М. Сәлимҗанов килгәч кенә баемый. Г. Кариев, К. Тинчурин, Г. Дәвишев, С. Вәлиев-Сульва, Г. Исмәгыйлов, Ш. Сарымсаков кебек режиссерларны кем талантсыз дип әйтә ала? Тарихны язганда нинди дер бер шәхесне күтәрү икенчесен төшерү исәбенә булырга тиеш түгел.

Әлбәттә, китап уяткан уй-хисләрне, икеләнү-борчылуларны тулысынча әйтеп бетереп булмады. Күренгәнчә, аларның тискәресе өстенлек ала. Шулай ук бирелә зуррак, принципиальрак мәсьәләләргә күбрәк тукталу максатыннан чыгып факт хаталарына, төгәлсезлекләргә бөтенләй диярлек тукталынмады.

**Гали АРСЛАНОВ.**

* * *

Мин исә бу китапта очраган җитешсезлекләрне конкрет күрсәтеп барырга уйлыйм.

7 биттә мондый юллар бир: «Некий Х. Ахтямов вспоминает о том, что 27 января 1901 г. в медресе «Усмания» был поставлен спектакль из жизни шакирдов». Бирелә билгесез бер кеше кебек әйтеп үтелгән Хәбибулла Әхтәмов ул — атаклы юрист, 1906 елның 21 апрелендә Уфада куелган татарча спектакльне оештыручы. 1923 елда Уфадагы «Яңа юл» журналының 2—3 саннарында аның «Бездә беренче театр» исемле истәлеге басылып чыга. Бу кешенең эшчәнлеге бик билгеле. Шуңа күрә китапта аңа карата кулланылган «нинди дер» дигән кыерсыткыч сүз бер дә туры килми.

15 биттә «Наряду с Г. Камалом, М. Файзи, С. Рамеевым, Ш. Камалом был еще целый ряд драматургов — И. Казаков, Ф. Туйкин, Я. Валеев, М. Нариманов, пьесы которых шли до революции. Но в силу невысокого художественного уровня они не оставили заметного следа в истории театра» дип яза автор. Бу уңайдан шуны әйтеп үтәргә кирәк: И. Казаковның «Казанга сәяхәт» исемле комедиясе озак еллар буена «Сәйяр» труппасы тарафыннан уйналып килә. Ә Г. Кариев бу әсәрдәге Гата бай образын менә дигән итеп башкара. Шунлыктан әлеге әсәрнең татар театры тарихындагы ролен алай түбәнәйтергә ярамый.

17 биттә автор «артист Ә. Кулалаев үзенең язмышын бөтенләйгә театр белән бәйләде» дигән фикер әйтә. Бу алай түгел. Әхмәт Кулалаев «Сәйяр»дән 1913 елда китә һәм Саратов өлкәсендәге туган авылына кайтып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр укытучылык итә.

18 биттә И. Илялова болай ди: «Тягостные испытания-преследования реакционеров всех мастей, запрещение спектаклей, полуголодное, безнадежное существование подорвали веру организатора первой труппы Кудашева-Ашказарского в перспективность дела, и он отходит он него». Мондый фикердә шулай ук төгәлсезлек бар, чөнки И. Кудашев-Ашказарский бу труппадан киткәннән соң башка труппалар да оештыра.' Октябрь революциясеннән соң да ул Оренбург һәм Казан шәһәрләре театр тормышында актив катнашып йөри. Беренче татар профессиональ труппасының 20 еллык юбилее уңаеннан аңа Хезмәт герое дигән мактаулы исем бирелә.

Татар артистларының беренче буыны күп санлы түгел иде. Шуңа күрә без аларның иҗатына аерата игътибарлы булырга тиеш. Ә бу китапта исә талантлы актриса Фәхрия Кудашева-Арская кебекләрнең иҗаты да телгә алынмыйча үтә. Димәк, театр тарихыбызның кызыклы гына битләре яктыртылмый калган, дигән сүз.

20 биттә автор: «Репертуар всех трупп, в том числе и «Нур»а был идентичен. Они все с небольшой разницей, повторяли афишу «Сайар»а» дип яза. Ләкин ул елларда чыккан вакытлы матбугатны укыган кеше моның алай түгелен белә. «Сәйяр» белән «Нур» репертуары арасында аерма шактый, чөнки «Нур» труппасы күпкә кечкенәрәк тә.

25 биттә, Аитовның истәлекләренә таянып, автор ул чорда актерларның бик ярлы булуын яза. Әмма бу сүз труппаның башлангыч чоры өчен генә дөрес. Г. Кәрамнең «Йолдыз» газетасында 1916 елның 4 мартында басылган мәкаләсеннән дә күренгәнчә, «Ре-

визор»ны куюы гына да труппага 1100 сум кирәм бирә. Шулай ук труппа акчасына бөек шагыйрь Г. Тукай каберенә чардуган куелганы да мәгълүм. М. Рахманкуловага уку өчен дә акча табалар труппа артистлары. Ә 1916 елны Кариев яхшы пьесаларга конкурс игълан иткәч, аның бүләкләре түбәндәгечә билгеләнә: I бүләк — 1000 сум, II бүләк — 500 сум, III бүләк — 100 сум («Кояш», 1916 ел, 6 июнь саны). Февраль революциясеннән соң «Ирек йорты» салу өчен дә «Сәйяр» 1000 сум акча бүлеп бирә. Тагын 10.000 сум вәгъдә дә итә. Сәхнәдә «Таһир-Зөһрә» трагедиясен куйган вакытта үзенең зур составы белән рус балеты һәм тынлы оркестр да чакырыла, махсус костюмнар тегелә, сәхнә бизәлә. Боларның барысы өчен дә күп чыгым тотыла. Димәк, труппаның хәле начар булмый.

54 биттә С. Айдаров белән Р. Кушловскаяның театрга егерменче еллар башында килүе әйтелә. Бу да дөрес түгел. С. Айдаров труппада 1915 елдан ук уйный. Ул хакта 1975 елда чыккан «Татар совет театры» китабында ук әйтелә.

Китапның 148 битендә автор, «Тукай» спектаклен дөрес кенә яктырткannан соң, җитди генә хата да җибәрә. Ул «беренче мәртәбә татар сәхнәсенә тарихи шәхесләр чыгарылды»,— ди. Ә бит алай түгел.—«Тукай»ны куйганчы ук «Казан өчен көрәш» спектакле уйнала, аның төп герое Мулланур Вахитов була («Кызыл Татарстан», 1927 ел, 13 февраль саны). Шулай ук «Степан Разин», «Иван Грозныйның үлеме», «Туктамыш хан» да куела. Бу хакта ул чор газеталарында хәбәрләр басылган.

Йомгак ясап әйткәндә, И. Иляловаңың бу хезмәтендә байтак кына хаталар җибәрелгән. Автор документаль чыганакларны аз файдалана. Бу очракта мин шул чорның көндәлек матбугатын һәм архив документларын күздә тотам. Әлеге чор хакында язган күренекле театр тәнкыйтьчеләре Самат Шәрәфетдинов (Уфа), Кәбир Бәкер (Оренбург), Заһид Нуркин һәм Г. Кәрам (Казан) мәкаләләре дә файдаланылмый диярлек.

Театр үсеше өчен шактый күп көч куйган драматург һәм режиссер Риза Ишморатның эшчәнлеген аз телгә алып үтү дә аңлашылмый. Артистлар Габдулла һәм Габдрахман Камаловлар да искә алынмый. Гозаир Хаҗибеков һәм Мортазин-Иманский кебек эшлеклеләр дә онытылган... Шулай ук белешмә библиографик материалның да бик ук җирен җиткереп эшләнмәвен әйтергә кирәк.

Аннан соң китап авторы театрның соңгы егерме елдагы эшчәнлеген генә мактарга теләле төсле. Нәтиҗәдә төп пропорция бозыла, тарихның революциягә кадәрге чорына җитәрлек игътибар бирелми, Гражданнар сугышы чоры турында бик аз әйтелә. Театрның егерменче-утызынчы еллардагы эшчәнлеге дә өстән-өстән генә яктыртыла.

Кыскасы, Татар дәүләт академия театрының тарихын фәнни яктырту әле көн тәртибендә торып кала.

**Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН.**

* * *

Миңа калса, безнең барыбызның да теләге китапны яхшырак, театрыбыз тарихын дөресрәк итеп күрәсе килүгә кайтып кала. Күп вакыт, күп көч таләп итә торган мондый зур хезмәттә кимчелекләр аз булса, барыбызга да күңелле генә булыр иде. Ләкин эш катлаулана төшә. Татар театры тарихы белән таныш булмаган кешегә беренче карашка китап әйбәт тәэсир калдырырга мөмкин. Ә чынында алай ук түгел. Хезмәтнең иң йомшак ягы — тарихилык принцибы сакланмауда. Бу беренче чыганаклар белән җитәрлек эш итмәүдән килә. Ә беренче чыганакларны табу, аларның эченә үзең керү өчен күп еллар, күп эзләнүләр кирәк. Автор тегеннән-моннан алып өстән-өстән генә фикер йөртә һәм шуның аркасында эзлекле бер тарихи, иҗади процесс күз алдына басмый.


Китап «Театр имени Камала» дип исемләнгән. Ләкин 30 нчы елларга кадәр диярлек без монда Камал театрын ныклап күрмибез. Тарихта без Камал театрының башын «Сәйяр» труппасына бәйләп карыйбыз, монда исә Камал театрының Октябрьгә кадәрге чоры кайсы труппага караганлыгын аңлавы кыен. Автор нигездә «Нур» труппасы материалларыннан чыгып Октябрьгә кадәрге бөтен татар театрына диярлек бәя бирә, хаталана, театр сәнгатебезне түбән төшерә, фактларны, шәхесләрне, елларны, вакыйгаларны бутый. Гражданнар сугышы чоры, 20 нче еллар белән дә шундый ук хәл. Казанда эшләгән төп татар театрыбызның 1917 елдан соң нинди үзгәрешләр кичерүе, өешу-үзгәрү процессы да ачыкланмаган. Гомумән, китапта иң йомшак эшләнгәне — Октябрьгә кадәрге чор, Гражданнар сугышы чоры һәм 20 нче еллар. Алдагы бүлекләрдә материал бераз байый, театр бер эзгә салына барса да, әлеге шул милли драматургияне ныклап белмәү нәтиҗәсендә байтак төгәлсезлекләр, урынсыз бәяләр, аерым чорлардагы табышларны күреп җиткермәүләр, бераүләрне күтәреп, икенчеләрне читтә калдырулар күзгә ташлана.

Китапта бигрәк тә хәзерге татар театр тәнкыйтьчеләрен читләтеп үтү, кирәксәкирәкмәсә дә, башка халык вәкилләре язмаларына таяну бар.

Мондый хезмәтнең ашыгыч рәвештә, күп җитешсезлекләр белән һәм рус телендә дөньяга чыгуы авторны да, татар театрын да кыен хәлдә калдырды.

**Һәнүз МӘХМҮТОВ.**

## Уфада культурабыз истәлекләре



**Уфада С. Рәмиев яшәгән йорт**

Новомостовая урамы, 18 йорт

*А. Тимергалина рәсеме*

# СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ УФАДА

Агыйделнең текә ярындагы биек тау өстендә, зифа каеннар күләгәсендә ак мәрмәр таш. Шома ташка уелган лаләләр янында — тере алсу чәчәкләр. Мәрмәрне чокып, тигез, матур хәрефләр белән шигырь язылган:

*Булмас артык, олуг бер эш*
*Илгә хезмәт итүдән;*
*Илгә хезмәт хөрмәтеннән*
*Үскән җирдән китүдән.*

Шагыйрь Сәгыйть Рәмиев.

Матбугат һәм әдәбият мәйданына 1906 елда Казанда шушы сүзләре белән чыккан иде ул. Россиядә уйнаган җил-давылларда татар халкының «таң вакытын» җырлап, шаулап күтәрелде. Шушы уй-теләкләр белән киткән иде туган-үскән җирләреннән — Көньяк Урал, Агыйдел һәм Җаек-Иләк буйларыннан.

Агыйдел ярына ул кабат 1914 елның язында аяк баса: Әстерханнан күчеп килеп, Уфада урнаша.

Уфада С. Рәмиев земствоның нәшрият эшләренә җитәкчелек итә, русчадан тәрҗемә итеп татарча «Уфаның авыл көнкүреше журналы»н чыгара. М. Гафури, Г. Ибраһимов һ. б. әдипләр белән тыгыз аралашып, әдәбият-культура хәрәкәтендә якыннан катнаша, кичәләрдә шигырьләрен сөйли, мәкаләләр яза. С. Рәмиев һәм М. Гафури квартиралары кара-каршы гына булып, бу ике гаилә, тәрәзә ачып кына сөйләшеп, «бары бергә, югы уртак» дигән нигездә яшиләр.

С. Рәмиев театр һәм музыка сәнгатен үстерү турында зур кайгыртучанлык бе-
ләк сугарылган мәкаләләрендә С. Габәши, Ш. Бабич һ. б. яшь талантларның уңышла-
рына сөенеп, хәер-фатихасын, киңәшләрен бирә. «Галия» мәдрәсәсендә һ. б. урыннарда
оештырылган кичәләрдә катнашып, шигырьләрен сөйли. Яшьләр куйган спектакльләр-
гә катнаша. Мәсәлән, 1916 елның гыйнварендә Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» драмасы
сәхнәгә куела. «Уенга Сәгыйть Рәмиев иштиракъ итәчәктер», дип яза «Тормыш» газе-
тасы.

Уфада С. Рәмиевнең поэтик иҗат эше дә яңа активлаша. Империалистик сугыш
тудырган катлаулы шартларда аның Н. А. Некрасов, Щепкина-Куперник, большевик
шагыйрь Д. Бедныйдан алып язылган «Аналар», «Күлмәк җыры», «Сука белән Пуш-
ка» кебек әсәрләре сугышка, ерткычлык һәм җимерү көчләренә нәфрәт, иҗади тыныч
хезмәт кешеләренә кайнар мәхәббәт белән сугарылган. Уфада 1915 һәм 1918 елларда
шагыйрьнең ике җыентыгы дөнья күрә.

Әмма аны властьлар тарафыннан эзәрлекләү Уфада тагын да куркынычрак төс
ала...

Социалистик революцияне С. Рәмиев дәртләнеп каршы ала. 1919—1922 елларда
Магнитка, Верхнеуральск, Чиләбе шәһәрләрендә партия-совет органнарында эшли,
большевиклар партиясенә керә (моны КПССның Чиләбе өлкә комитеты партия архи-
выннан яңарак алынган документлар да раслый).

1922 елда шагыйрь яңа Уфага кайтып, Җир эшләре халык комиссариатының
нәшрият бүлегенә җитәкчелек итә. Көннән-көн көчәя барган үпкә авыруына карамас-
тан, иҗат эшен активлаштырырга омтыла. «Башкортстан» газетасында басылган «Су-
зем һәм үзем» шигырендә: «Тутыкмый ул сүз кылычым кынысында»,— дип белде-
рә.— Р. Джованьолиның «Спартак» романын, «Интернационал»ны тәрҗемә итә. Баш-
кортстанның Гыйльми мәркәзе эшләрендә, башкорт теленең әлифба-орфографиясен
төзүдә катнаша.

Челтәрләп бизәлгән матур агач йорт. Шагыйрь соңгы елларын шунда яшәгән.
Соңгы юлына шуннан киткән. 1926 елның 17 марты... Телеграф, «Правда» һәм «Из-
вестия», татар, башкорт, әзербайҗан, казах, кыргыз, үзбәк һ. б. телләрдәге газеталар
бөтен илгә кайгылы хәбәр сала.

Уфа урамнары меңнәрчә халык җыелган 21 мартны хәтерли. Тын гына агылган
музыка. Байраклар иелгән. Агыйделнең текә ярындагы биек тау күкрәгендә яңа яра...
Бу урынга кулларына чәчәкләр тотып, кешеләр килә. Кызлары: Молдавиядән —
Фирдәвес, Мәскәүдән — Флера кайта. Тик Уфада туган, үзеннән соң исән калган
берданбер улы Рәми генә килә алмый: ул 1943 елның гыйнварында Сталинград фронтында
батырларча һәлак булды.

Уфа җәмәгатьчелеге шагыйрь истәлеген кадерләп саклый. 1980 елның 25 апреле-
дә ул яшәгән биналарның берсенә (Октябрь революциясе урамындагы 29 нчы йорт)
мемориаль такта куелды.

Шагыйрьнең баш очында үскән зифа ак каеннар, тау астында — көньяклардан,
әдипнең туган җирләреннән агып килгән Агыйдел. Агыйдел өстенә җәелгән алсу
таң шәүләсе гүяки аның якты романтик идеалларының аклыгы, сафлыгы, бөекләр
күңелендә яшәве турында сөйлиләр.

*Ш. Садретдинов тексты.*

Сибгат Хәким

# РЕДАКЦИЯГӘ ХАТЛАРДАН

Бу санда укучыларыбызны без Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким әдәби мирасының яңа бер тармагы — аның журнал редколлегиясе әгъзасы буларак, күп еллар дәвамында актив эшчәнлегенең бер өлеше — 1975—1983 еллар эчендә редакциягә, поэзия бүлегенә язган хатлары белән таныштырабыз.

* * *

«Иртәгә»...

Рөстәм Мингалимовның яңа поэмасы.

Бүгенге заман ритмын тапкан, тоткан, шуны шигъри гомумиләштерүләрдә оста биргән поэма. Болай караганда, сюжеты да юк кебек, проблема, объект та юк шикелле, ә поэма бар, заман бар, уйланулар бар. Бүгенге заман шагыйренең кичереш, уйланулары. Әйбәт әсәрне анализлау кыен, анализлыйсы урында яңадан укып чыгасы килә. Бөтен хикмәт шушындый юллардадыр:

Бүген алган тизлек бүген ярый,
Яңа тизлек кирәк иртәгә.
Гел үзгәреп очкан дөнья белән
Әй китәргә ерак! Китәргә!
Бүләгем бар ерак ул көннәргә,
Илтә барам Тукай якларын,
Бәрхет түшле яшел тауларымның
Язмышлары бездә чакларын.

Киләчәккә омтылган ритмикасы беләнме, Такташның «Киләчәккә хатлар»ын да искә төшереп куя — омтылышы, оптимистик рухы, сөрелеше, шагыйрьнең үзенең ашкынуы белән... Иҗат — сәер нәрсә, кайвакыт шулай оста тотылган интонация бөтенесен хәл итә дә куя. Яраттым мин бу поэманы. Аерым юлларын, строфаларын моңа хәтле үзем әйтә алмавыма үкендем. Р. Мингалимовның моңа чаклы язган поэмаларын да беләм. Бусы — яңа баскыч, эзләнә торган шагыйрь Рөстәм Мингалимов. Мин бу әсәреннән соң аннан күпне көтәм.

22/X — 75.

* * *

«Исәннәр моңы»![1]

Тигез, дөрес, ләкин Ватан сугышы турында зуррак нәрсә көткән идем. Күп язылган, күңел яңарак, кабатланмаган нәрсә өмет итә бит. Билгеле, басарга ярый, журналда да, китапта да чыгар...

30 елдан соң Ватан сугышы темасын яңачарак күрәсе килә, 30 ел узды бит! Тормыш бу темага бүгенге югарылыктан карарга куша. 28/VII — 76.

[1] Рәш. Әхмәтҗанов поэмасы.

* * *

Сәҗидә Сөләймәнованың бу ике шигырен алда каралганнар янына куш. Болары ачык. Алдагылары тонык иде, артык нечкәртеп җибәргән шигырьләр. Белланы да уздырган.

* * *

Салисә Гәрәева шигырьләрен сайлап алдым (өйгә җибәргән, «Казан утлары»на), хезмәт темасына шушындый шигырьләр кирәк. Уралның зурлыгын, хезмәтнең матурлыгын укучы тоярлык шигырьләр. Журналга җыебрак бирик әле. Читтә, аерылып яши. Булышасы иде аңа.

1976.

* * *

«Иблис».

Нәҗар Нәҗминең яңа поэмасы.

Нәҗар Нәҗми бу поэма өстендә озак эшләде. Сюжетын моннан берничә ел элек Уфада бер очрашканда сөйләгән иде. Мине сюжеты, идеясе ул чакта ук кызыксындырды. Үз җире, үз иле, үз йорт-нигезеннән аерылганнарның язмышы. Тарихи тема. Тукайның «Китмибез»е һаман яңгырый, хәтта безнең заман белән тоташып яңгырый. «Китмибез»дән соң Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» романы — шул темага язылган әсәр. Баграт Шинкубаның 1976 елда «Дружба народов»та басылып чыккан әсәре дә күчеп китеп фаҗигале язмышка очраган убых халкы турында. Зур социаль тема. Нәҗар Нәҗми дә бу темага очраклы алынмаган. Сюжетлы әсәр, вакыйгага, конкрет образларга корылган фәлсәфи әсәр. Әхмәт язмышы — туган туфрагы, халкыннан, туган теленнән аерылганнарның котылгысыз язмышы. Илеңнән читтә бер генә язмыш көтә — фаҗига... Бу — Нәҗар темасы. Туган тел турындагы шигырьләр авторының «Иблис»кә тотынуы бик табигый, Нәҗар стихиясе. Шуның өстенә шагыйрь поэманың вакыйгасы барган җирләрдә булган, тоеп яза. Шуның өстенә Шәехзадә «Иблис»енең[1] Нәҗарга күченүе дә бик табигый. Традиция яңара, икенче формада. Поэманы зур кызыксыну белән укыдым. Соңгы вакытта поэмалар бөтенләй азайды. Бу яктан да шактый өйрәнерлек әсәр. Оста язылган, тирән, киң пландагы әсәр.

25/X — 1976.

---

[1] Ш. Бабичның «Газазил» әсәре күздә тотыла.

* * *

«Илләр күргәч».

Рәдифнең[1] яңа шигырьләре.

Шагыйрь зуррак дөньяга чыкса, шигырьгә барыбер яңа хис килеп керә, тематик яңалыктан тыш яңа фикер, яңа деталь... Шагыйрьгә зур дөнья кирәк, өзлексез, туктаусыз, төрле халәттә, шатлык, фаҗига, каршылык көрәше һ. б. Париж шигырьләрендә шул публицистик колач, ритмик иркенлек, хисләрнең тыгызлыгы. «Казан утлары»нда Кара диңгез буе шигырьләре генә түгел, Париж шигырьләре дә басылсын әле.

16/III — 77.

---

[1] Рәдиф Гатауллин.

* * *

Мөдәррис Әгъләмовның журнал өчен әзерләнгән яңа шигырьләр циклын укыдым. Бүгенге поэзия — миңа таныш нәрсә, көндәлек. Китап булып чыкканнары да, журналда басылып барганнары да һәм кулъязма хәлендәгеләре дә көндәлек таныш. Тәҗрибәм җитәрлек, көндәлекләрдән тупланган тәҗрибә. Шигырьнең төрлесен күрдем, төрле дәрәҗәдәгесен. Профессиональлыкка ирешкәннәрнең җайга салынган шома, тигез, бер буразнадан бер адым да читкә чыкмый аккан шигырьләрен дә күп укыдым. Карт, гомер иткән, язасын язып бетергән шагыйрьләр өчен мондый профессиональлыкны мин гафу итәм. Әмма талантлы яшь шагыйрь профессиональлыкка күнекса, ул хәтәр. Димәк, ул шигырь техникасына төшенгән, серенә ирешкән, күптәнге темасына гадәт буенча тасбих

төймәсен тарткан кебек тезеп кенә бара. Күпләр хәзер шулай. Мөдәррис Әгъләмов күнегелгән юлдан бармый. Гражданлык — төп юлы. Профессиональлыгы гражданлыгында. 1976 елда Зөлфәт шигырьләр циклын укып бер рухи канәгатьләнү хисе кичергән идем, быел, 1977 елда Мөдәррис шигырьләре Зөлфәткә җавап шикелле яңгырады. Шагыйрьдән мин шушындый борчулы, тынгысыз, раслый, бәхәсләшә торган, хис, фикер, публицистик яну бергә кушылган шигырьләрне көтәм. «Лит. газета»да барган поэзиягә ни җитми дигән мәкаләләрнең сорауларына менә шушындый шигырьләр җитми дип җавап бирер идем. Мөдәррискә үзе кебек тәрҗемәче җитми, менә нинди шигырьләр белән чыгарга кирәк зур мәйданга. «Казан утлары»на да шушындый шигырьләр җитми.

27/IX — 77.

• • •

«Яшә, илем», «Дөнья яшьләренә», «Янудан», «Аның күз яше», «Көзге төндә», «Күгәрченнәр», «Күзләренә карап», «Исән калды», «Беренче кар», «Бичара Маэмай», «Ят була», «Яңа көй»[1].

Ачыла бара картлач. Ярый шушындый шагыйрьләр бар әле. Поэзия ничек булырга тиеш дигән сорауга Мөдәррис белән икесе җавап бирергә уйлаганнар, фәкать шулай. Кушылам.

27/XII — 78

---

[1] Нури Арсланов шигырьләре.

• • •

Бар да Равилчә[1], уй күп, сагыш күп, моң күп, поэзия!

17/IV — 79.

---

[1] Равил Фәйзуллин.

• • •

Рәдиф![1]

Англия шигырьләренә мин синең урында булсам, яңадан бер әйләнеп кайтыр идем. Нәрсәдер, әле ачылып бетмәгәнсең, дөресрәге, эченә кереп җитмәгәнсең. Бу теманы бу килеш бастырсаң әрәм итәрсең шикелле. «Парижда татар шагыйрьләре» көчлерәк иде, гражданлык бәреп тора иде, хисләр дә күп иде, шигырьләр дә тигез аккан иде. Англиягә ел саен барылмый, тагын бер уйла әле... Калганнарын журналга бир, чыга торсыннар... Англия шигырьләре басылырга ярамый дигән сүзем түгел. Синең мөмкинлек читтә калган кебек, яртысы! Ашыкма! Ашыгып алдырып булмый, өлгерсен бераз. Маяковскийның Америка шигырьләренә күз сал, Константин Симоновның «Друзья и враги» циклын кабат укып чык. Симонов тапкан ачкычны. Самед Вургунны да оста файдаланган, Баку нефте дә бик урынлы. Зур дөнья, катлаулы дөнья. Өченче сугышка әзерләнә дөнья. Синең шигырьләр — гөнаһсыз сабыйлар күк. Ашыкма, әрәм итмә, уйла әле.

29/XI — 79.

---

[1] Рәдиф Гатауллин.

• • •

Әхсән Баяновның яңа ел алды шигырьләре турында.

Әхсән ташыган, мәхәббәт, яшьлек, сагыш, теләр-хисләр ташыган. Күптән болай ташыганы юк иде. Көтеп йөри идем, озакка китте дип. Күптән тоташ бер шундый цикл укыганым юк иде. Күңел булды, ярым-йорты түгел, тоташ, тулы, ахырынача. Шагыйрьнең шулай ачылуын яратам, әйтеп бетергәнен яратам. Менә сиңа прозаик! Мин шагыйрьләрдә аз ялгыштым. Тагын бүтән яклары белән сөендерер әле поэзия. Талантлар яшәсен!

25/XII — 79.

* * *

«Гасыр фаҗигасе».

Илдар Юзеевның яңа әсәре.

Тукай турында драма, музыкаль әсәр. Шигырь белән язылган. И. Юзеевның Тукай турында мондый күләмле драматик әсәре юк иде әле. Ләкин мин көттем, бу егет барыбер бер алыныр әле дип көтеп йөрдем. Нигә дисәң, И. Юзеевның шагыйрьлек рухын яхшы беләм мин. Тукайны да беләм. И. Юзеевта Тукайлык бар. Табигатендә, рухында. Поэмалар, драматик поэмалар, җырлар авторы. Бу рух Тукай белән кайчан да булса бер кушылырга тиеш иде. Менә ул хәзер кушылган, Тукай туган, халык эченнән аның «Туган теле» булып, мәңгелек җыр булып, улы, шагыйре булып туган. Халык эченнән... Әсәр шулай башлана, татар халкы тудыра, тарих тудыра. Әсәр башыннан ахырынача Тукай халык белән бергә итеп күрсәтелә. Шул Тукай яшәгән заманның бөтен катлаулары, бөтен каршылыклары... Тукайның өмете «Уралчылар» белән, бу да әйбәт табылган! Тукай фаҗигасе — гасыр, халык фаҗигасе. Менә шушылай зур планда бара драма. Сәнгать әсәре, плакат түгел, шигъри, музыкаль әсәр. Кайчан да булса сәхнәгә менәчәк, я опера, я балет, яки башка бер формада барыбер бер сәхнә күрәчәк әсәр язылган. Музыканы үзе сорап тора. Хәзер эш композиторда! Ышанам, туар.

14/I — 81.

* * *

«Яшьлек мәйданы».

Флера Гыйззәтуллинаның мин белгән зур әсәре, поэмасы. Ватан сугышы еллары истәлеге. Яшьлек. Дүрт яшь кыз язмышы. Чыннан да, Флераның мин мондый әсәрен беренче тапкыр укыйм. Ни өчен ошады? Кыскалыгы, тыгызлыгы белән. Образлар шигъри, хисләр шигъри. Ялыктырмый, теле әйбәт. Авторның шулай үз-үзенә зур таләбе ошады миңа. Нык утырганы сизелеп тора. Авторга бер киңәшем бар. Исемен «Дүрт кыз» дип куяр идем. «Яшьлек мәйданы» бик абстракт, бик гомуми. Әсәр бик конкрет — дүрт кыз турында.

8 сентябрь, 1982.

* * *

Шигырьләрне һәм поэманы укыдым. Нурия Измайловадан соң үземнең дә шундый шигырьләр язасым килде. Чын талант. Халыкчан, гади, табигый, хисле, фикерле. Искиткеч җиңел иреш кебек. Сүнмәсен генә!

Әхсән Баян — усал шагыйрь, талантлы. Прозаик буларак та, шагыйрь буларак та үзенчә, усал. Үз юлы, үз карашы.

Гәрәйдән [1] күбрәк көткән идем.

Рашат [2] поэмасына «мин» җитми.

19/IX — 83.

[1] Гәрәй Рәхим

[2] Рашат Низамиев

* * *

Өч шагыйрь: Гамил Афзал, Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов... Иң җыйнагы, аз сүзле, образлысы — Рәшит Әхмәтҗанов. Шигырьләренең кадерен белеп яза. Профессионал таләп сизелә. Үзегез теләгәнен сайлап алыгыз дип тутырмаган. Өлгерү галәмәте. Шамил дә саран. Гамил бу юлы күп сүзле. Яхшысын да, уртачасын да бергә өя. Үземчә сайлап карадым. Матур әйберләр бар.

26/XI — 83.

# ШӘМ СУАР

Идел-Кама болгарларының өченче зур үзәк шәһәрләренең берсе Суар исемен йөрткән. Урта гасырларда шөһрәт тоткан, күп җирләрдә исеме соклану белән кабатлана торган кечле, хәтта шәһре Болгарның үзе белән үк бил алышып, ярышып яшәгән бу шәһәрнең кайда урнашуы тарихи әдәбиятта озак еллар буе бәхәсле мәсьәлә булып исәпләнде һәм аның эзләре югалган дип уйланды.

Суарның төгәл урынын беренче тапкыр күренекле галимебез Ш. Мәрҗани «Мөстафадел әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» дип аталган китабында күрсәтә. Китап гарәп телендә язылганга күрә, Ш. Мәрҗанинең бу фикере киң фәнни әйләнешкә керә алмаган. Шәһре Болгардан ерак булмаган Суар каласының урынын, халык риваятьләренә таянып, 1893 елда тарихчы Г. Әхмәров тапкан. Бу шәһәрнең хәрабәләре Татарстанның хәзерге Куйбышев районы, Кузнечиха авылы янында 30 нчы елларда тирә-юньдәге авыллардан күчеп утырган татарлардан оешкан Татарский городок дип аталган авыл урынында (җирле халык аны Шәмсуар дип атый) һәм аннан көньяк юнәлештәге Утка суының сул ярында урнашкан. Икенче төрле аны Шәм Суар дип тә атыйлар. Һ. В. Иосыпов Шәмсур атамасының мәгънәсен матурлыгы кояшка тиң, кояш кебек нурлар чәчеп тора торган шәһәр дип аңлата.

Бу шәһәр турында мәгълүматлар урта гасыр чыганакларында шактый күп сакланып калган. Алар X—XIV йөзләргә карыйлар. X йөздә әл-Бәлхи түбәндәгеләрне яза: «...бу шәһәрдән (Болгардан — Ф. Г.) ерак та түгел икенче бер — Суар шәһәре урнашкан. Анда да җамигъ мәчет бар. Мөселман хатибы миңа шуны әйтте. Ике шәһәренең дә халкы 10 меңгә җитә. Йортлары агачтан салынган һәм аларда кышын торалар; җәен кешеләр киез тирмәләргә күчәләр». «Хөдүд-әл-галәм» исемле чыганакта: «Суар — Болгар янындагы шәһәр; андагы халыкның дине дә болгарларныкы кебек үк». XI йөздә яшәгән атаклы галим М. Кашгариның «Төрки телләр сүзлеге»нә һәм сүзлеккә кушымта итеп бирелгән картага да Суар шәһәре кертелгән, ләкин, кызганычка каршы, ул ялгыш Каспий диңгезе буенда, Идел суының уң ягында күрсәтелгән. Үзе Суарда булмаганга күрә, М. Кашгари бу каланы Саксин шәһәре белән бутаган. Суар турындагы соңгы мәгълүматлар XIV йөзгә карыйлар. Аны «Иөрәкләр ләззәте» дигән язмасында Хәмдулла һәм моннан тыш, «...бу өлкәдә (Болгар дәүләтендә — Ф. Г.) өч зур шәһәр: Болгар, Сивар, Асбал (Эсбел) бар»,— дип, Фәрхәг язып калдыра.

Бу шәһәрнең исеме татар халкының дастан һәм риваятьләрендә дә тиешле урынны алган. Шунысы игътибарга лаек — ул Болгар белән янәшә кулланыла.

Изге шәһәр Болгарны,<br>
Астаналы Суварны,<br>
Капкасы биек Казанны...

Суар сүзе XIII—XIV йөз болгар чоры кабер ташларында кеше исеме буларак та чагылыш тапкан. Кан-кардәшләребез булган Дунай болгарларының бер кнэзе Суар исемен йөрткән.

Суар шәһәренең югары үрләп үскән чорлары монгол яулап алуларына кадәрге вакытларга мөнәсәбәтле итеп карала. 1236 елдан соң да ул яшәвен дәвам итә, ләкин элекке данын һәм экономик әһәмиятен югалта. Суарда галимнәр, фикер ияләре, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, йорт салу осталары, игенчеләр һәм башка һөнәр ияләре эш белән мәшгуль булып яшәгәннәр. Бу шәһәрнең борынгыдан ук яшәеш алуын һәм үзәк урыннарның берсендә торуын күрсәтә торган әһәмиятле факт — нумизматика мәгълүматлары. Суар шәһәрендә акча 931 елда Насыйр ибне Әхмәт тарафыннан сугылган. Шулай ук Суарда 948—952 елларда Талип ибне Әхмәт исеменнән чыгарылган акчалар билгеле. Мөэмин хан акчалары 976 елда Суарда да, Болгарда да сугылган. Шунысы әһәмиятле, 976 елдан 980 елларга кадәр Мөэмин хан (Ибне Хәсән)

заманында акчалар Болгарда гына сугыла. Димәк, X йөзнең ахырында Суар, үзәк шәһәрләрнең берсе булуга карамастан, инде мөстәкыйльлеген югалта бара һәм Болгар дәүләтенең башка үзәкләрендә әле бу чорда акча сугу күзәтелми (бу ике шәһәр арасында барган көрәш шуның белән аңлатыла да). Әлеге акчаларның таралыш ареалы бик киң. Тверь, Псков, Рязань өлкәләрендә һәм хәтта Скандинавия илләренең берсе Даниядә болгар шәһәре Суарда сугылган акчалар табылган. Менә нинди ерак илләр белән дә тыгыз мөнәсәбәтләрдә яшәгән бабаларыбыз!

Суар шәһәренең чагыштырмача мөстәкыйль яшәгәнлеге Ибне-Фазлан хезмәтендә күрсәтелә. Җәй көннәрендә киез йортларга күчеп торырга яраткан болгар патшасы Алмыш, Ибне Фазлан килгән елны да халкы белән җәйләүгә чыкканда, суарларны үзе белән чакыра.

Болгар шәһәрләренең башкаларындагы кебек үк, Суарда да алдынгы фикерле кешеләр, галимнәр булган. Мәсәлән, XII йөзнең беренче яртысында яшәгән галим Сөләйман бине Дауд Суарда туган. Аның «Зәһрәтер рийаз» әсәре күп урыннарда: Идел-Каспий буйларында, Анатолиядә, Һиратта, Бохарада, Урта Азиядә һәм башка урыннарда билгеле булган. Идел буенда, ягъни авторның туган һәм иҗат иткән җирендә, аны аерата хөрмәт иткәннәр. Суар шәһәрендә Болгар каласындагы кебек үк җамигъ мәчетләр каршында мәдрәсәләр дә булган. Ибне Рөстә болгарларның хәтта авыл җирләрендә дә башлангыч мәктәпләре булуы хакында яза. Ул Болгарның зур күпчелеге ислам дине тотуына, авылларда башында имамнар һәм мөәзиннәр торган мәчет һәм мәктәпләр булуына игътибар иткән. Болгар, Биләрдәге кебек үк Суарда да китап культурасы үскән.

Суарда йортлар төрле-төрле булган. Алар нык, таза һәм матур итеп эшләнгән. Суар үзәгендә кирпечтән салынган бай сарай калдыклары табыла. Аның тирә-юне кирпеч койма белән әйләндереп алынган була. Бу бина үзәк җылыту системасы белән җылытылган. Төтенлеге идән астына челтәр формасында урнаштырылган. Сүүткәргеч торбалар аша су килгән. Бу сарай X—XI йөзләрдә төзелгән, монголлар һөҗүме нәтиҗәсендә җимерелгән, соңрак яңадан торгызылган һәм XIV йөз азагында ул шәһәр белән бергә яшәүдән туктаган. Суарда агачтан бурап бик матур итеп эшләнгән йортлар да булган. Болгарларның йортлары агачтан салынуларына урта гасыр сәяхәтчеләре дә игътибар иткән. XIII йөз авторы Якут болай дип яза: «Болгарлар йортларын бары агачтан салалар, бер бүрәнәне икенчесе өстенә куялар һәм аларны нык агач кадаклар белән ныгыталар». Агач йортлар белән янәшәдә балчыктан салынганнары да булган.

Суарда тимерче учаклары эзе, тимер шлак, тимерче кораллары, сөяк, агач эшкәртә торган осталарның, чүлмәкчеләрнең һәм башка һөнәрчеләрнең кораллары һәм ярымфабрикатлары сакланып калган. Урта гасырларда Суар җирле һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак танылган.

Суар халкы, нигездә, иген иккән. Шәһәр урынында ашлык саклый торган 90 чокыр, тегермән ташлары табыла. Гарәп галиме Ибне Рөстә: «Болгарлар — игенчелек белән шөгыльләнүче халык: бодай, арпа, тары һәм башка шундый һәртөрле ашлык үстерәләр»,— дип яза.

Борынгы болгарларның Шәмсуар шәһәре тирәсендә соңрак барлыкка килгән авылларга рәсми рәвештә Суар атамасы кушылмаган. Әмма элекке Болгар җирләре булган Татарстан районнарында суар сүзе рәсми кулланылышта да йөри. Казан арты һәм Тау ягы районнарында суар сүзенә мөнәсәбәтле авыллар һәм елгалар бер тирәгә укмашып утырганнар. Элек бу сүз белән Иксуар, Кылсуар, Янсуар, Нырсуар дигән авыллар булган. Иксуар белән Кылсуар исемнәре тарихи документларда гына сакланып калган. Авыллар үзләре беткән. Мишәнең сул кушылдыгы Нырсы суы да элекке чыганакларда Нырсуар дип йөртелә. Составларында суар сүзе булган географик атамалар элекке Болгар иленең политик, экономик йогынтысында булган чиктәш өлкәләр һәм кайчандыр борынгы болгарлар үзләре яшәгән урыннарда очрыйлар: Мокша елгасы бассейнында, Әзербайҗан, Осетия, Кабарда-Балкар республикасында һ. б.

Бабаларыбыз төзегән Шәм Суар каласы үзе җир белән тигезләнсә дә, аның исеме, чал тарих истәлеге булып, халкыбыз күңелендә, йөрәгендә саклана.

**Фирдәүс ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

библиография

# МӘХӘББӘТ ЯКТЫСЫ

Шагыйрә Фирая Зыятдинова — әдәбиятка бүген генә килгән каләм иясе түгел. Аның лирик җылылык, романтик рух, гражданлык пафосы белән сугарылган шигырьләре алтмышынчы еллар урталарыннан ук газета-журналларда әледән-әле күренеп тора. «Беренче карлыгачлар», «Кызлар моңы» исемле җыентыкларда, «Идел» альманахында басылып килә.

Һәм менә 1986 елда Фирая Зыятдинованың Татарстан китап нәшриятында «Матур буласым килә» исемле мөстәкыйль җыентыгы да басылып чыкты.

Китапның «Кызлар сагышы» исемле шигырь белән ачылып китүе бер дә гаҗәп түгел. Яшьлек, мәхәббәт — Фирая Зыятдинова иҗатында мөһим урынны алып торган тема. Беренче карашка, мәхәббәт турында әйтеләсе сүзләр әйтелгән, фикерләр белдерелеп, яңалары калмагандыр шикелле. Ләкин шуны да онытмаска кирәк: таңны — нурдан, гөлне чәчкәдән башка күз алдына китереп булмаган кебек, яшьлекне дә мәхәббәттән башка күз алдына китереп булмый. Кеше күңеленә аклык, сафлык, пакьлек бөркүче, аны батырлыкка, матурлыкка, зурлыкка, бәхеткә әйдәүче, илаһи, изге тойгы тудыручы һәм тиңе булмаган кодрәт бирүче мәхәббәт турында гомер-гомергә язып килгәннәр, хәзер дә язалар, киләчәктә дә язачаклар. Эш тагын шунда — теманың яңача гәүдәләнешендә, поэтик алымнарның шуңа нисбәтән яңа һәм бай булуында, лирик «мин»нең характер дәрәҗәсенә җиткереп ачылуында. Икеләнмичә әйтергә кирәк, Фирая Зыятдинова мәхәббәтне үз шигърияте͏ндә моңа кадәр әйтелгән фикерләрне кабатламыйча җырлый, үзенчә яңгырата, үзенчә яшәтә. Ул мәхәббәткә кыз белән егет, ир белән хатын арасындагы хис итеп кенә түгел, ә бәлки аларның бер-берсенә гомерлеккә биргән тугрылыклы анты, бер-берсен бәхетле итү өчен көрәше итеп карый. Аны иҗтимагый күренешләргә бәйләп сурәтләргә һәм шул җирлектә бүгенге совет хатын-кызының үзенчәлекле образын тудырырга омтыла.

*Ай кызыдай ачык йөзле,*
*Матур буласым килә.*
*Җил-давылга бирешмәслек*
*Батыр буласым килә.*

*Җилдән дә җитез буласым,*
*Уңган буласым килә.*
*Дуслар сөенерлек матур*
*Тормыш корасым килә.*

*Син миңа шундый булырга*
*Булышырсыңмы, иркәм?*
*Син миңа шундый тормышны*
*Корышырсыңмы, иркәм?*

*(«Ай кызыдай ачык йөзле...»)*

Шагыйрәнең мәхәббәт лирикасы әнә шулай кайнар хисләр, җылы моңнар, якты омтылышлар белән мөлдерәмә. Әгәр дә ул:

*Алларыма кыя булып бастың,*
*Дулкын булып шунда мин кактым;*
*Дулкын төсле чәлпәрәмә килдем,—*
*Мин барыбер сине яраттым.*
*Серләр тулы кара урман булдың,*
*Кердем дә мин шунда адаштым.*
*Син серлерәк була барган саен,*
*Мин ныграк сине яраттым.*

— дип, үзенең буе җитмәстәй егеткә омтылган икән, без аңа дуамал, җилбәзәк кыз итеп карамыйбыз, ә бәлки яратуына телəктәшлек кенә белдерәбез. Ул мәхәббәтнең олылыгына да, ихласлылыгына да чын күңелдән ышанабыз. Чөнки «Бәхеттән җиденче күккә менгән», «Мин сине шундый сагындым. Сизәсең микән шуны? Ак бураннар урап алса, Табарсың микән юлны?» дип шикләнгән, «Син дә шулай сагына калсаң, Карама җилләренә,— Җыр булып килеп керерсең Наз тулы йөрәгемә» дип канатланган, «Шулай язган: елый-көлә, Гомерләр кичерербез... Һәрчак кояш булалмасак, сез инде кичерегез» дип тыйнак кына үтенгән, сөя һәм сөелә белгән йөрәк авазы булып яңгырый һәм табигый булып ишетелә бу сүзләр.

Мондый ялкынлы лирик шигырьләр исемлегенә «Син әле сизмисеңдер», «Бер

әйтүең җитә», «Су сибәм гөлләремә», «Аңладың микән?», «Бер син генә», «Мәңгелек язымдыр син», «Тик онытма...», «Кара әле тутырып күзләремә» әсәрләрен кертергә була.

Шагыйрәнең туган як, туган туфрак, туган йорт һәм бураннар эстафетасы, ата-бабалар әманәтенә тугрылык, ил иминлеге, халык, җир язмышы турындагы шигырьләре дә үзләренең самимилеге, ихластан язылулары белән аерылып торалар.

Сер түгел: бездә (бигрәк тә яшь шагыйрьләр арасында) туган як, туган ил турында язылган күп кенә шигырьләр лирик геройның туган авылына ерактан сагынып кайтуы, шунда бер каенны, я яңа төзелгән бер йортны күреп фәлсәфә сатуы кебек штампка әйләнгән әчтәлеккә корылалар. Билгеле, мондый шигырьләр ышандырмый, алар үзеңне мәҗбүр итеп кенә укылалар. Фираяның шигырьләре исә кайнар хисле, якты моңлы. Ул беркайчан да ялган хис, төче тойгылар белән мавыкмый, ә реаль кичерешләргә нигезләнә. Чөнки ул аларны үзенең йөрәге аша үткәреп, шәхси тәҗрибәсе, шәхси язмышы, үз буынының шәхси биографиясеннән чыгып бәян итә, укучысы белән үзе һәм үз буыны исеменнән, ягъни халык исеменнән сөйләшә.

*Хәтер калган, хатирәләр калган,*
*Тол-ятимнәр калган дөнья тулып.*
*Без калганбыз мәнә егылмыйча,*
*Шул афәткә утлы шелтә булып.*

*(«Мин туганмын сугыш беткән елны...»)*

*Күңел ярсый язгы ташкын кебек,—*
*Сагынуларга түзеп буламы?!*
*Язлар белән бергә тагын сиңа*
*Кайттым әле, авылым урамы.*

*(«Авылым урамы»)*

«Матур буласым килә» китабының күңелне куандырган яклары белән бергә әле анда җанны көендергән урыннар да бар. Мәсәлән, давыл образы шигырьдән шигырьгә күчеп, төссезләнеп, үз егәрен югалтып бетергән. Менә аңа кайбер мисаллар: «Кирәк чакта давыл-туфан булып Ябырылдык дошман өсләренә...» (11 бит), «Канатларым иң-иң көчле Давылларга чыдарлык...» (30 бит), «Давылларда шашынасың Коточкыч бер ярсу белән...» (32 бит), «Күңелемдә купкан буран, Җил-давыллар тынар иде...» (44 бит), «Давыллап кердең күңелгә, Давыллап китмәссең, дим...» (51 бит), «Ә дөньяга, Якты җиргә Ябырылып давыл килгәндә...» (54 бит), «Җил-давыллар килгәндә дә, Күтәрмен үлгәндә дә...» (56 бит).

Үз-үзеңне кабатлау — куркыныч чир. Ул торгынлыкка, бер урында таптануга, схематизмга, штампка алып килә. Моны Фирая Зыятдинова искә алыр дип ышанасы килә.

Шигърият күгендә югарыга очу насыйп булсын шагыйрәгә.

**Әнһәр ГАБИДИ,**
Сарман районы.

# СҮЗ ТЫЛСЫМЫ

## АЙРАТ АРСЛАНОВКА 60 ЯШЬ

Безнең әдәбият-сәнгать дөньябызда хәйран үзенчәлекле шәхесләр бар. Нәфис сүз осталарыннан Айрат Арсланов та нәкъ әнә шундый артист. Аның үзен күрмичә үк, радиодан чыгыш ясаган чагында да танышсың, беркем белән саташтырмыйсың. Монда хикмәт аның тавыш тембрында гына да түгел — әсәрне яратып, рухланып, канатланып-очынып укуында.

Кайсы гына төбәктә шигырь укымады икән инде Айрат: Себер дә бар аның маршрутларында, Урта Азия республикалары да, төньяк та бар, Кавказ арты да, Ленинград та бар анда, Владивосток та...

Хәер, гастрольгә йөрүләре бер бүген башланган хәл түгел икән. Студент чагында ук, моннан кырык ел элек, илнең төрле шәһәрләрендә иптәшләре белән бергә спектакльләр куеп йөри ул. Ә артистлык һөнәрен театр училищесында 1945—1949 елларда үзләштерә. Мәскәүнең ГИТИСын исә шактый вакыт эшләгәннән соң, 1967 елда тәмамлый. Эш дигәннән, училищеда укыганда ук радиода диктор була, аннары академия театрында эшли; мәшһүр актерлар белән аралаша, аларның фидакарь хезмәте үрнәгендә тәрбияләнә. Ә 1965 елдан алып ул инде Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә — эстрада артисты.

Нинди генә аудитория алдында чыгыш ясарга туры килми Айратка: авылларның ягылмаган клубларындагы суык диварларны сәхнә осталыгы, күңел җылысы белән эретә; шәһәрләрнең мәһабәт культура сарайларында да гөрли аның тавышы; хәтта әле Мәскәүдәге Үзәк концерт залында да, шулай ук Колонналы залда да чыгышлар ясый... Кая гына барса да, сүз остасы татар поэзиясенең моңын-аһәңен еракларга тарата.

Репертуары да гаҗәеп бай аның: Кол Галидән алып бүген яңа канат җилпи башлаган Нияз Акмаловкача дистәләгән шагыйрь һәм әдип иҗаты. Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан, Ә. Фәйзи, С. Хәким әсәрләренә атап төзелгән махсус программалар. Ул үзебезнең әдәбият белән генә дә чикләнми, күп милләтле совет поэзиясенә дә колачын җәя: ничәмә-ничә халык вәкиленең шигырен яттан укый. Моңа нинди көч кирәк тә, күпме вакыт кирәк! Бөек Пушкин белән Маяковский әсәрләрен эстрададан торып сәгатьләр буе сөйләр өчен ни рәвешле әзерләнергә туры килүен күз алдына китерүе дә кыен.

Айрат Арсланов бөтен Россия күләмендә барган нәфис сүз осталарының конкурсларында бәйге тоткан кеше: ике мәртәбә (1957 һәм 1974 елларда) лауреат титулын, ә В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә үткәрелгән конкурста дипломант исемен яулап ала. «Күңелем Ленин белән сөйләшә» һәм «Туган ягым Татарстан» дигән әдәби концерт программалары өчен ул 1969 елны Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек табыла. Янә ике елдан (1971) Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Үз кабыгына бикләнеп яшәгән әдәбиятчы яки сәнгать әһеле бервакытта да артык зур уңышка ирешә алмый торгандыр. Ник дигәндә, ул үзенең иҗатыннан тулысынча канәгать була, үз-үзенә мөкиббән китүдән уза алмый. Моның шулай икәнен Айрат Арсланов яхшы белә. Һәм ул үзе яулап алган үрләргә соклану белән мавыкмыйча, бүтән халыкларның культурасы белән даими кызыксына, аерым шәхесләрнең үз иҗатларында зур казанышка ни рәвешле ирешүен махсус өйрәнә. Анда да әле фәкать эстрада белән генә чикләнми, драма артистларының иҗаты белән дә кызыксына, кемнең ничек уйнаганы хакында уйлана, гыйбрәт ала.

Ә аның үткәннәрне искә алып сөйләвеннән шунысы аңлашыла: Айратны малай чагыннан ук мәшһүр композиторыбыз Салих ага Сәйдәшев үз күргән, якын иткән. Радиога килеп йөри торган яшь егетне көнгә, әйтик, дүрт-биш мәртәбә күрсә дә, һич иренмичә:

— Нихәл, Айрат?! Ни эшләр бетереп йөрисең?— диебрәк, хәл-әхвәлен белешә торган, киләчәгенә зур өметләр баглаган.

Салих ага үзенең 50 еллыгына багышланган тантана кичәсендә концертны алып бару вазифасын әле сәхнәдә юньләп сыналмаган яшь-яшь егеткә ышанып тапшыра. Мөгаен, Айратның беренче тапкыр зур иҗади дулкынлану кичерүе, чирканчык алуы да нәкъ әнә шунда, 1950 елны булгандыр. Һәрхәлдә, кичәдән соң Салих аганың үз янына дәшеп алып:

— Рәхмәт, энем, концертны матур алып бардың!— дип, кулын кысуын Айрат әле бүген дә исендә тота.

Сөекле композиторыбызның әлеге сүзләре сәхнәгә яңа гына аяк баскан егеткә фатиха булып яңгырый, эшендә зур җаваплылык таләп итә.

Хыялсыз кешене канатсыз кошка тиңлиләр. Ә безнең Айрат олы хыяллар белән яши. Ул татар культурасының, шул исәптән эстраданың киләчәген кайгырта, сәнгатьнең милли тармагына игътибар җитеп бетмәвенә ихлас көенә, борчыла:

— Консерваторияле шәһәр инде, югыйсә, ә милли концертларны еш кына бернинди әзерлексез музыкантлар башкара... Халыкта сакланган моңны алар тирәнтен кичереп азапланмыйлар, җиңел кулдан гына, ансат кына башкарып чыгалар. Бу исә примитивлыкка китерә...

Ә инде үзе эшләгән эстрада сәнгатен сүз остасы һичкайчан тыныч кына телгә алмый, бу тема аны һәрвакыт борчый, дулкынландыра. Чынлап та, борчылырга урын бар. Бүгенге көндә сәнгатькә җиңел караш хөкем сөрми микән? Театр училищесында укучылар алдында олы таләпләр куя беләбез микән? Эстрадага нык әзерлекле яшьләр килә башлар микән?..

Уйлап баксаң, эстрада артистының хәле чынлап та җиңел түгел анысы. Ник дигәндә, драма театрында кеше үзен коллективта дип тоя, үзенә тапшырылган рольне партнерлар ярдәмендә ерып чыга. Ә менә сәхнәгә шигырь сөйләргә чыгып баскан кеше, теләсә-теләмәсә дә, бер ялгызы торып кала. Монда син шигырьне яттан сөйләргә өйрәнеп кенә котыла алмаячаксың.

Шуңа күрә ялгыз башы бәйге тотар өчен, Арсланов үзе көн-төн әзерләнә. Бер-ике шигырь укырга кирәк булганда авторның барлык шигырьләре белән таныша, прозадан бер өзек уку өчен — әдипнең язу алымнарын, стилен, бөтен иҗатын өйрәнеп чыга... Әле бит тагын язучыны трибун дәрәҗәсенә күтәргән дәвер бар, заман бар! Шуларның барчасына игътибар итеп җиткермәгән тәкдирдә синең Фатих Әмирханың — Әмирхан Еникигә, Тукаең Туфанга әйләнеп китүе бик тә ихтимал... Тагын сәхнәгә килеп чыгу бар бит әле! Драма актеры кием белән, грим белән үк сихерләсә, моның битендә грим да юк, өстендә дә гап-гади бүгенге кием. Менә сихерләп кара инде син тамашачыны! Ышандырып кара син бөтен залны! Коры текстны өйрәнеп кенә, атналар-айлар буена шуны уйланып йөрми генә һич ышандыра алмыйсың син аны. Икенче төрле итеп әйткәндә, үзең янмый-дөрләми торып, бүтәннәрнең күңеленә һич тә үтеп керә алмыйсың. Ә бит сихерләргә кирәк, күңелләрне тетрәндерергә кирәк...

Безнең республикада нәфис сүз осталарының бармак белән санарлык кына булуы әнә шул объектив шартлардан гына, бу хезмәтнең энә белән җир казу шикелле читенлегеннән генә киләме, әллә инде яшь буын эстрада артистларын тәрбияләү эшенә берәр кеше аяк чаламы? Юк ла! Аяк чалучы юк! Ләкин әлеге эшкә игътибар юнәлдерүче дә юк! Әнә шуның нәтиҗәсендә бернинди үсеш тә, алга китеш тә, хәтта әле омтылыш та юк! Әле дә ярый, театр училищебыз бар — анда педагоглар сәхнәдә уйнарга, саф ана телендә матур итеп сөйләргә өйрәтәләр.

Ләкин бит группада укып, коллектив белән бергә-бергә сәхнәдә спектакль куярга өйрәнгән яшүсмер, үгетләүләргә бирешеп, эстрадага килеп чыга икән, ул бит котылгысыз рәвештә аяныч хәлдә кала. Әдәбиятыбыз шундый да бай инде югыйсә, ә яңа кеше... аптырашка төшә. Чөнки эстрада артистының эш стиле дә, репертуар сайлау сере дә аңа таныш түгел. Чөнки әлеге хезмәткә махсус өйрәтү зарур. Миңа калса, гомерен шуңа багышлаган һәм зур уңыш казанган эстрада артистыбыз Айрат Арсланов театр училищесында укучылар арасыннан укымышлырак һәм өметлерәкләрен сайлап алып, шуларга махсус дәресләр биреп, сүз жанрына олуг мәхәббәт тәрбияли алыр иде. Еллар буе әнә шул рәвешле эшләү нәтиҗәсендә үзенә лаек булырдай алмаш хәзерләү бәхетенә ирешер иде.

Бүгенге көндә РСФСРның халык артисты Айрат Арсланов моның шулай икәнлеген үзе дә аңлый.


— Шәкертләр кирәк! Эшлисе килә! Табылыр бит андыйлар?!— ди ул.


**Кыям МИҢЛЕБАЕВ.**

## Кем елый соң?..

Фасил Әхмәтов музыкасы
Фәнис Яруллин сүзләре

РОМАНС






Тукта, тукта, кем елый соң,
Тетрәндереп күңелне?—
Әтисез, иписез үскән
Балачагым түгелме?

Тукта, тукта, кем елый соң
Бәгырьне кисеп-кисеп?—
Рәнҗетелгән яшьлегемме
Тора һаман да үксеп?

Тукта, тукта, кем елый соң,
Ишетәм нинди өннәр?—
Җирне тырнап елый мәллә
Заяга үткән көннәр?

Хәтер диген учагымның
Җил актара көлләрен:
Көл астыннан калкып чыга
Күзе яшьле көннәрем...

## ДӘРЕСЛЕКЛӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

11 февральдә Татарстан Язучылар союзында балалар әдәбияты һәм тәнкыйть секцияләренең берләштерелгән утырышы узды. Ул рус һәм катнаш мәктәпләр өчен чыгарылган татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре турында сөйләшүгә багышланды. Сүз, нигездә, мәктәпләрдә татар телен укытуның торышы, дәреслекләрнең сыйфаты, дәреслекләр төзүдә язучыларның катнашуы турында барды. Утырышта Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, әдипләр Ә. Еники, Ш. Галиев, Л. Ихсанова, Г. Зәйнашева, М. Мәһдиев, галимнәр Ф. Хатипов, Б. Мифтахов һ. б. чыгыш ясады. Сөйләшүдә шулай ук дәреслек авторлары, галимнәр, ТАССР Мәгариф министрлыгы хезмәткәрләре, Казандагы татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнашты.

## ӘДӘБИЯТЫБЫЗ БӘЙРӘМНӘРЕ

Соңгы айлар әдипләребезнең юбилейларына бай булды. Узган елның 23, 25 декабрендә Казанның Актерлар йортында танылган прозаиклар Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм Мәхмүт Хәсәновның тууларына 60 ел тулу уңаеннан иҗат кичәләре, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Горький урамындагы бинасында, 23 январьда — РСФСРның М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты язучы Аяз Гыйләҗевнең 60 еллыгына, 10 февральдә — Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты шагыйрь Фәнис Яруллинның 50 еллыгына багышланган юбилей кичәләре булып узды. Алар чын мәгънәсендә әдәбиятыбыз бәйрәмнәре булды, әдәбият сөючеләр күңелендә матур истәлекләр, якты тойгылар уятты.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

30 январьда Татарстан Язучылар союзының Чаллы бүлегендә 1987 нче әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш узды. К. Сибгатуллин (поэзия), Н. Алешков (рус язучылары иҗаты), Равил Вәлиев (проза) докладларыннан соң бүлекнең җаваплы секретаре Г. Кашапов, язучылар Н. Лаисов, Е. Кувайцев, Р. Сәлимҗанов, Ф. Дунай һ. б. катнашында кызыклы һәм файдалы фикер алышу булды.

Чаллы, Түбән Кама, Алабуга төбәгендә яшәүче иҗат көчләренең бер еллык эшчәнлегенә йомгак ясаган һәм принципиаль бәя биргән бу җыелышта Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Г. Рәхим, «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары С. Маннапов катнашты һәм чыгыш ясадылар.

## ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ЯҢА КЛУБ

Чаллы язучылар оешмасында Г. Тукай исемендәге яңа клуб ачылды. Клубның мөдире итеп җәмәгатьчелек тәртибендә шагыйрь Хәниф Хөснуллин билгеләнде. Биредә татар һәм рус телләрендә әдәби кичәләр, очрашулар уздырыла. Күптән түгел, шәһәрнең әдәбият сөючеләре татар шагыйре Н. Мадьяров, рус шагыйрьләре Н. Беляев, Н. Алешков һәм башкорт шагыйре Р. Сафин белән очраштылар.

## ЯКТАШЛАР ЯНЫНДА

2 январьда Чүпрәледә яңа культура йорты ачылу уңаеннан сәнгать бәйрәме булып узды. Анда Чүпрәле районында туып үскән, хәзер инде иҗатлары белән халыкта танылган шагыйрь Зәки Нури, РСФСРның халык артистлары Ринат Таҗетдинов, Венера Шәрипова, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рафаэль Ильясов һ. б. катнашты.

КПСС райкомының беренче секретаре С. Р. Төхбәтуллин район халкы исеменнән кунакларга рәхмәт белдерде, иҗатларында яңа уңышлар теләде.

## «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ»НЕҢ ЯҢА КИЧӘСЕ

30 январьда Татарстан Язучылар союзымузыкаль берләшмәсе Түбән Кама шәһәренең Техника йортында Роберт Миңнуллин иҗатына багышланган кичә үткәрде. Шагыйрь көндез шәһәр балалары һәм татар теле укытучылары белән, кичен шигърият сөючеләр белән очрашты. Ул үзенең шигырьләрен укыды, «Яшь ленинчы» газетасы турында сөйләде, тамашачыларның сорауларына җавап бирде. Кичәдә Түбән Ка-

ма һәм Чаллы үзешчәннәре башкаруында шагыйрь сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм илле яше тулу уңаеннан язучы Фәнис Яруллин, СССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 8 февраль Указы нигезендә, Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

Совет музыкасы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 60 яше тулу уңаеннан Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры баш дирижеры Фуат Шакирович Мансуров, Татарстан АССР Верховный Советы Президумының 1988 ел, 29 январь Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор Ренат Әхмәтович Еникеевка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 25 ноябрь Указы белән, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы доценты, язучы Зәет Мәҗитовка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 11 декабрь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең бер төркем артистларына, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 27 ноябрь Указы нигезендә мактаулы исемнәр бирелде. «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем:

бию группасы репетиторы Гатиятуллин Мансур Әхмәтовичка, симфоник оркестр солисты Гыйльфанов Альберт Гыйлемхановичка, музыкаль-әдәби лекторий солисты-вокалисты Нурмөхәммәтов Зиннур Закировичка.

«Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем:

җыр һәм бию ансамбле балет артисты Вәлиева Дамира Мәгъсумовнага,

җыр һәм бию ансамбле балет артисты — Фәйзуллин Фердинанд Хәнифулловичка,

җыр һәм бию ансамбле хоры артисты Әмирҗанов Гарифҗан Гафуровичка,

эстрада бүлеге артисты Вәлитов Иосыф Мордухаевичка,

җыр һәм бию ансамбле хоры артисты Шамукова Людмила Васильевнага,

сөйләм жанры артисты Зәйтүнә Әсәдулловна Яруллинага бирелде.

Хезмәт иялэренә коммунистик тәрбия бирүдәге хезмәтләре өчен телевидение һәм радиотапшырулар буенча Татарстан АССР Дәүләт комитетының Татарстан радиосы әдәби-драматик тапшырулар редакторы Рөстәм Фәйзуллинга, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 23 ноябрь Указы нигезендә, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

# КИТАП КАБЫ

Ука белән чигү татар хатын-кызлары арасында борынгыдан ук киң таралган һәм ул зәркән сәнгате белән аерылгысыз бәйләнгән. Элек заманнарда укачылар саф алтын, көмеш җепләр белән, яисә аларның икесен катнаштырып чигә торган булганнар. XIX гасырда чиста көмеш, алтын суына манылган көмеш һәм бакыр җепләр дә кулланыла башлый. Металл кыл җитен яки ефәк җепкә урап, бары алтын гына күренерлек итеп, тыгыз эрләнгән. Алтын чигешле әйберләр төрле бизәкләр, шигъри афоризмнар төшерелгән келәм, асылма, япмалар формасында ясалган. Аларның безгә килеп җиткәннәреннән кыйммәтле киемсалым: яулык, калфак, кәләпүш, такыя, туфлиләр, шулай ук көнкүреш әйберләре: букча-сумкалар, чәй, мөһер, акча савытлары, тәмәке янчыгы, җеп-инә келәмчекләрен әйтергә мөмкин.

Татар чигешләрендә кыйммәтле металл җепләр әйбернең өслеген тулаем каплап, аны гадәти алтын тукымага — парчага әйләндерми. Аларда композицияләрнең үз хосусияте бар, бизәкнең эчтәлеге, характеры үзәктә тора. Татар алтын чигешләрендә күп очракта алар шигъри образларга, фольклор хиссиятенә тартым һәм «букет», «гөл» композицияләре, шәҗәрәләр, асылкош, гөлбакча образларында чагылыш таба. Укачылар җан өргән архитектура корылмалары, алтын-көмеш атлар, агачлар әкияти көчкә ия сыман. Тутыкмас металл җепләрдән чигелгән бу дөнья — халыкның табигатькә, дөньяга карашын, фикер йөртү рәвешен тасвирлый, тормыш һәм хезмәт сөючәнлеге турында сөйли.

Татарстан берләштерелгән дәүләт музеенда саклангaн, ак җитен тукымага алтын-көмеш бизәкләр төшереп башкарылган китап кабы әнә шул бай мирас үрнәкләренең берсе. Конвертсыман итеп тегелгән капның бер ягында, капкачка охшашлы өчпочмаклы «теле» бар. Аның ярдәмендә конверт ансат ачыла. Китап кереп урнашкач, ул урталай бөгелә, ябыла һәм зиннәтле китап тышы барлыкка килә.

Каптагы бизәкләр дә үзенчәлекле. Кабатланып килгән композицияләрнең һәр өлешендә кош гәүдәсенә охшаган сурәт игътибарны җәлеп итә. Ул үз тирәсендә түгәрәк гөлләрне-чәчәкләрне, йолдызсыман балкышларны бербөтен стихиягә берләштерә. Гүяки канатларын җәйгән тылсымлы кош томшыгында яшәү һәм тереклек чыганагы чәчәк аткан гөл ботагын алып килә...

Катлаулы сюжетның икенче өлеше тагын да кызыклырак. Анда эченә ниндидер сыекча салынган икешәр нәфис алтын комган-кувшин, ә астарак алтын ләгән сурәтләнгән. Кувшиннарның төбе йөрәксыман бизәккә әверелгән. Аларның асларыннан үрелмәле яфраклар үсеп чыга. Кувшинның борыннарына, тоткаларына бизәкле сабаклар уралган. Монда бизәк, кауырый каләм, каллиграфия үрнәгенә охшаган урамалар һәм, ниһаять, шигъри юллар китерелгән.

Ул юлларның мәгънәсе әсәрнең шигъри концепциясеннән, бизәкле пространствоның рухыннан һәм җисемнең тормыштагы вазифасыннан аерылгысыз. Димәк, сүз юыну әсбаплары турында түгел, ә бәлки китап хикмәтен татып, алтын җепләр тудырган сәнгать гүзәллегеннән азыкланып, рухи чистарыну, сафлану турында бара. Нәтиҗәдә гадәти чигү мотивларына янә бер милли үзенчәлек өстәлә. Китап кабы XIX гасыр татар культурасының аерылгысыз бер кисәге булып күз алдына килеп баса.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.*

Тышлыкның дүртенче битендә: В. И. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсе.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)